ӘДӘБИЯТ

8

«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ

ӘДӘБИЯТ 8

И Идел-йорт, Идел-йорт,
Идел эче имин йорт...
Ашлык белән тулган йорт...
Котлы булсын туган йорт!

«Идегәй» дастаныннан

А. Г. Әхмәдуллин, Ф. Ә. Ганиева

ӘДӘБИЯТ

Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 8 нче сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән

Дүртенче басма

КАЗАН
«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ
2006

УДК 373.167.1:821.512.145*08
ББК 83.3(2Рос=Тат) я721
Ә87

Дәреслекнең *Ф. Кәрими, М. Фәйзи, Ш. Камал, Һ. Такташ, М. Җәлил, Т. Миңнуллин* бүлекләрен — **А. Г. Әхмәдуллин;**
Дастан, Г. Бәширов, Н. Фәттах, А. Гыйләҗев, С. Сөләйманова, М. Юныс бүлекләрен **Ф. Ә. Ганиева** язды.

Фәнни редакторы
Татарстан Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы
А. Г. Әхмәдуллин

Охраняется Законом РФ «Об авторском праве и смежных правах». Воспроизведение всей книги или ее части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

Әхмәдуллин А. Г.

Ә87 Әдәбият : Татар урта гомуми белем бирү мәкт. 8 нче с-фы өчен дәреслек-хрестоматия/А. Г. Әхмәдуллин, Ф. Ә. Ганиева; А. Г. Әхмәдуллин ред.— Дүртенче басма.— Казан : Мәгариф, 2006.— 335 б.: рәс. б-н.
ISBN 5-7761-1575-2

ISBN 5-7761-1575-2

© «Мәгариф» нәшрияты, 2001, үзгәрешләр белән
© Бизәү. «Мәгариф» нәшрияты, 2006

Әдәбият турында сөйләгәндә, без аның янәшәсенә тормыш-чынбарлык, сәнгать, иҗат төшенчәләрен дә куябыз. Аларны үзара чагыштырабыз, бәйләнешләрен эзлибез һәм һәркайсының үз урынын билгелибез. Узган сыйныфларда әдәбият белән бик якыннан бәйле халык авыз иҗатына игътибар итеп бардык. Әдәбият халык иҗатыннан үсеп чыга, аннан образлар, өлгеләр, сурәтләү чараларын күчереп ала дидек, күп төрле мисаллар, уртак яклар күрдек.



Хәзер дә без сүзне халык авыз иҗатының гаять үзенчәлекле бер тереннән — дастаннардан башлап китәрбез. **Дастан** — матур яңгырашлы, аһәңле, затлы сүз. Ул — данлау, кемнәрнеңдер исемен, ниндидер вакыйгаларны, язмышларны еракларга яңгырату, киләчәк буыннар хәтеренә, халык күңеленә язып кую, тарихта калу дигән сүз.

Дастан халык иҗатының башка жанрлары арасында аерым урын алып тора. Аңа әкият һәм риваятьләрдәге маҗаралылык, сихри тылсым, бәет һәм җырлардагы шигъри бизәкләр, мәкаль һәм әйтемнәрдәге хикмәтле фикерләр хас. Шулай да дастанга гына хас булган яклар аеруча әһәмиятле, әсәрнең кыйммәтен, яңгырашын шул сыйфатлар билгели. Аларның беренчесе — вакыйгаларның реаль, тарихи җирлеккә нигезләнгән булуы. Вакыйгалар барган урыннар география картасына билгеләп куярлык дәрәҗәдә төгәл-дөрес билгеләнә, вакыт та конкрет бер тарихи чорга тәңгәл килә. Икенчедән, әсәрдә халыкның иң матур сыйфатларын, хыялларын гәүдәләндергән герой тасвирлана. Тарихи дастаннарда

ул — реаль тарихи шәхес. Өченчедән, дастаннар иң гүзәл әдәби әсәр дәрәҗәсендә бизәкле тел белән иҗат ителгәннәр. Сәнгатьчә эшләнеше: вакыйгаларны дулкын-дулкын итеп тасвирлау, геройлар сөйләменә зур урын биреп, әһәмиятле якларга кайта-кайта тукталу, энҗе ташлардай ялтырап торган чагыштыру, кабатлаулар — болар барысы да дастанны халык иҗаты белән әдәбиятны тоташтырган салават күпере биеклегенә күтәрә. Дастаннарны теләсә кем ятлый һәм сөйли дә алмаган. Аны иҗат иткән һәм башкарган кеше, һичшиксез, сандугач телле шагыйрь, искиткеч хәтерле һәм фикерле кеше булган.

Татар халкының ерак тарихын чагылдырган, әдәбиятыбызның горурлыгы булган әсәр белән танышыйк. Аның үзен дә ашыкмыйча, кайта-кайта укырга, мәгънәсенә генә түгел, көенә-моңына да төшенергә кирәк.

ИДЕГӘЙ

Туктамыш хан белән Аксак Тимер низагы һәм Котлыкыя би белән углы Идегәйнең үлемгә хөкем ителгәне

Борын үткән заманда
Болгар белән Сарайда,
Җаек белән Иделдә,
Алтын Урда, Ак Урда —
Данлы кыпчак җирендә,
Татардан туган Нугай илендә
Туктамыш дигән хан булды;
Ил булганга — ил булды,
Яу булганга — яу булды.
Биләгәне кол булды,
Әйдәгәне мал булды.
Сарай дигән каласы,
Сиксән кучә[1] арасы,
Сары мәрмәр Алтын Таш
Сигез йортка дан булды,
Аларда дан булмады.
Суна[2] тибеп каз алган
Кара лачын Төкле Аяк —

---

[1] *Кучә* — урам.
[2] *Суна* — кыр үрдәге.

Ау лачыны бар иде,
Тугыз йортка дан булды.
Азамат ир Туктамыш —
Акбүз аты астында,
Лачын ияр кашында,
Чирүле күлдә кош чөеп,
Дәүран[1] сөргән хан булды.
Ул дәрья да бу дәрья,
Ул дәрьядан Сыр-Дәрья,
Сыр-Дәрьядан — Сәмәрканд;
Сәмәркандта утырган
Әмир Бырлас Шаһ Тимер
Туктамышка хат бирде.
Ул хатында бу диде:
«Җаектан ашу Ак Түбә[2],
Иделдән ашу Күк Түбә,
Күк Түбәдә ак сарай;
Анда утырган Туктамыш,
Ул Туктамыш син булсаң,
Курымны[3] эчкән син булсаң,
Сине баккан[4] мин булсам,
Тугрына[5] кунган Төкле Аяк
Тугыз йортка дан булса,
Аны миңа тапшыргыл».
Туктамыштай олы хан,
Укыган соң бу хатны,
Уңына торып бер бакты,
Сулына торып бер бакты,
Эченә суык боз төште —
Туң тимердәй күк булды,
Эченә кызу ут төште —
Сум[6] тимердәй кызарды.
Кызарган соң ут булды,
Аннан да үтеп ак булды.
Азамат ир Туктамыш

---

[1] *Дәүран* — гомер, вакыт.

[2] *Ак Түбә, Күк Түбә* — Алтын Урда заманында Идел белән Сыр-дәрья арасындагы җирләр.

[3] *Кур* — кымыз.

[4] *Баккан* — тәрбияләгән.

[5] *Тугыр* — ирдә ау кошы кундыру урыны.

[6] *Сум* — саф.

Анда җавап хат бирде,
Ул хатында бу диде:

«Ул дәрья да бу дәрья,
Ул дәрьядан Сыр-Дәрья,
Сыр-Дәрьядан — Сәмәрканд;
Сәмәркандта утырган
Аягы чонтык[1] Шаһ Тимер
Әмир Бырлас син булсаң;
Аргы атасы[2] — Чыңгыз хан,
Бирге атасы[3] — Туйгуҗа,
Аннан туган Туктамыш,
Ул Туктамыш мин булсам;
Күк Түбәдә ак сарай,
Анда утырган хан булсам,
Ил булганга — ил булсам,
Яу булганга — яу булсам,
Кара лачын Төкле Аяк
Сиңа булмас, Шаһ Тимер!
Аннан кала Бүз тойгын[4] —
Ул да булмас, Шаһ Тимер!
И Шаһ Тимер, Шаһ Тимер,
Тешең җитсә, таш кимер!
Сигез йортка сыймадың,
Тугыз йортны куймадың,
Сычкан типкән бидаяк[5]
Сиңа булсын, Шаһ Тимер!»

Хат бөтелде[6], сүз бетте,
Ай бетте дә көн бетте;
Ел артыннан яз килде,
Чирүле күлгә кош килде,
Күгәл[7] белән каз килде.
Оя баскан Төкле Аяк —
Ул да бала чыгарды.

---

[1] *Чонтык* — бер аягы кыска, аксак.
[2] *Аргы атасы* — бабасы.
[3] *Бирге атасы* — үз атасы.
[4] *Бүз тойгын* — ак карчыга.
[5] *Бидаяк* — карчыга.
[6] *Бөтелде* — язылды.
[7] *Күгәл* — кыр үрдәге.

Кош чөюгә мәл[1] килде.
Ау кошларын караган
Котлыкыя би иде.
Азамат ир Туктамыш
Аны үзенә чакыртты.

(Туктамыш хан Котлыкыя бигә Төкле Аяк чыгарган ике лачынны алып килергә куша. Аларны очыртып карый, ләкин кошлар очмыйлар. Туктамыш хан Котлыкыяны хыянәттә гаепли: ау лачынының балаларын Шаһ Тимергә җибәреп, миңа карчыга балаларын алып килгәнсең, Шаһ Тимергә сатылгансың, ди. Котлыкыя аңа бик кыю җавап бирә, Туктамыш ханны ил белән идарә итә белмәүдә гаепли.)

— Били белсәң, ханиям,
Икселмәс[2] дәүләт бу иде.
Алтын Урда, Ак Урда
Алтмыш йортка юл иде,
Индегенең[3] көнендә
Кәрван, дөя килалмый,
Дәрвазаңнан[4] иңалмый,
Дәрвазаңнан иңгәндә,
Сиңа бүлеп биралмый.
Синнән дәүләт тайганы
Шул түгелме, ханиям?
Янә торып, янә әйтсәм,
Идел сырты Сары тау
Илем кунган йорт иде,
Илем йортта куймадың,
Иделне ике кичердең,
Анда да аны куймадың,
Кырлы курай шур[5] татыр
Кола чүлгә китердең,
Комкәнт дигән каламны
Комга түгеп бетердең!

Азамат ир Туктамыш
Ике биен чакырды:
Чакмагыш би, Дөрмән би

---

[1] *Мәл* — вакыт.
[2] *Икселмәс* — кимемәс.
[3] *Индеге* — хәзерге.
[4] *Дәрваза* — шәһәр капкасы.
[5] *Шур* — тозлы җир, су.

Анда килеп баш орды.
Туктамыш хан анда әйтте:
— Әй Дөрмән би, Дөрмән би,
Айбалтаңны тот,— диде.—
Айпычагың так,— диде.—
Котлыкыя ялган бине
Муйнын ора чап! — диде.—
Пәридән алган хатыны,
Бишектә ятыр баласы;
Аны да ташлап калдырган
Пәридән булган анасы —
Ул баланы тап! — диде.—
Бишеген ора чап! — диде.
Шунда торган Җантимер —
Киң кунычлы Җантимер —
Алты угыллы ир иде;
Атагы — өлкән аталык,
Йортта өлкән пир[1] иде;
Туктамышның кашында
Киңәше киң, килбәтле,
Сүзе үткен би иде;
Котлыкыя би белән,
Кан тамызып ак сөткә,
Ант эчешкән ир иде.
Торып килеп Җантимер,
Хан алдында йөгенде[2]:
— Әй ханиям, ханиям!
Җир китәр дә, ни калыр?
Җиреннән тайган ил калыр.
Ил китәр дә, ни калыр?
Ил киткәндә, йорт калыр,
Йорт китәр дә, сөт калыр;
Ак күкрәктән сөт имгән
Сүзе татлы тел калыр.
Тел китәр дә, ни калыр?
Язганнан язган хат калыр.
Баш китәр дә, ни калыр?
Буында типкән кан калыр.
Буыннан буын чабылса,

[1] *Пир* — изге кеше.
[2] *Йөгенде* — тезләнде.

Ул чагында ни калыр?
Йорт урынында яу калыр.
Яу чапканда ни калыр?
Ялгыз башы каңгырап,
Куйдай булып маңгырап,
Чүл-далада тинтерәп,
Дуадактай[1] хан калыр.
Аталыгым хакына
Хаталыгын кич[2],—диде.—
Аталыгым хакына
Хаталыгын кичмәсәң,
Бишектә яткан баласы —
Кашык канын кич,—диде.—
Буында типкән кан калсын,
Баладан кулың тарт[3],—диде.—
Каныннан аның кайт! — диде.
Җантимер би әйткәндә,
Туктамыштай олы хан
Аның телен алмады,
Сүзенә колак салмады.
Ачуы аннан каты иде,
Кичүе аннан кайт[4] иде.
Котлыкайны тоттырды,
Кулына кыл-җеп тактырды.
Чапкылыкка мендереп,
Чүң[5] бүкәнгә чүктереп,
Айбалталы Дөрмән бидән
Анда башын чаптырды.
Җантимердәй атага
Хан колагын салмады.
Хан колагын салмаса,
Ул да карап калмады.
Ни кыласын аңлады,
Өенә карый юл алды.
Җантимернең алты угыл,
Алтынчы угыл — Кобогыл.
Алып килеп ул аны,

---

[1] *Дуадак* — ялгыз, нәселсез.
[2] *Кич* — кичер, гафу ит.
[3] *Тарт* — кире ал.
[4] *Кайт* — кайтыш, ким.
[5] *Чүң* — зур.

Котлыкыя өенә,
Салып куеп бишеккә,
Котлыкыя баласын
Киң кунычлы Җантимер,
Кунычына яшереп,
Үз өенә китерде.

Ул баланы Җантимер,
Итегемнән алдым, дип,
Итегемнән алганда,
Илсез-көнсез калдың, дип,
Атын куйды Идегәй.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Шәһәр исемнәренә һәм башка географик атамаларга игътибар итегез. Аларның кайсылары сезгә таныш, бүген дә сакланып калган, кайсылары тарихи исемнәр?
2. Туктамыш хан белән Аксак Тимернең кемнәр булуын, кайларда яшәвен билгеләгез. Вакыйга кайчан бара дип уйлыйсыз?
3. Туктамыш белән Аксак Тимер һәм Туктамыш белән Котлыкыя арасында низаг тудырган сәбәп нәрсә? Бу — җитди сәбәпме? Тирәндәрәк яткан башка сәбәпне күрдегезме?
4. Җантимернең нәрсә эшләгәнен аңладыгызмы, сезнеңчә, ул дөрес эшләдеме? Нәрсә хакына үз баласын куркыныч астына куйды?
5. Аңлашылмаган сүзләрне ачыклап бетерегез, бүлекне тагын бер кат игътибар белән укып чыгыгыз. Геройларның сөйләменнән чыгып, алар турында нинди фикер әйтә аласыз?

Идегәйнең Кобогыл исемендә үсеп, Туктамыш хан сараенда түрә булганы

Җантимернең алты угыл,
Алтынчы угыл — Кобогыл,
Кобогыл дип беленеп,
Үсә куйды Идегәй.
Бер яшендә бер икән,
Баскан җире шил[1] икән.
Ике яшьтә ил булды,
Әйткән сүзе им булды.

---

[1] *Шил* — чокыр, иңкү җир.

Өч яшендә аталык
Остаздан китап башлатты.
Дүрт яшендә дан булды,
Фирасәте[1] фаш булды;
Биш яшенә килгәндә,
Җантимернең биш угыл —
Бишенә дә баш булды.
Алтысында ат менде,
Җидесендә, җай[2] тартып,
Җиде тотам ук атты.
Сигез-тугыз булганда,
Сигез тукмак сындырып,
Туң тимергә кул орды.
Унга җитте — ул булды,
Ул ни дисә, шул булды;
Чүлгә чыгып басканда,
Чүл ярылып юл булды,
Тауга чыгып басканда,
Тау сыгылып уй булды.
Унберендә бер булды,
Уйпыксыз чичән[3] ул булды;
Уникегә җиткәндә,
Алпамыштай ир булды.

«Ир булган соң җир булыйм,
Инсәм җиргә тисен, дип,
Ил игелегем күрсен, дип,
Асыраган чал бабам —
Ул игелегем күрсен»,—дип,
Тауда ятты, тай бакты,
Кырда ятты, куй бакты,
Елкы бакты , кол булды,
Өстендә ямар тун булды;
Башы белән баш булды,
Атагы[4] белән дан булды,
Түрәсе[5] белән фаш булды,
Ятимнәргә яр булды.

---

[1] *Фирасәт* — зиһенлелек, сизгерлек.
[2] *Җай* — җәя.
[3] *Уйпыксыз чичән* — тел остасы.
[4] *Атак, ат* — исем.
[5] *Түрәсе* — хөкем, гаделлек.

Идегәй андый ир булды:
Аты юкка — ат булды,
Чүлләгәнгә[1] — су булды,
Адашканга — юл булды;
Ялгызга — ясак[2] ,
Җәяүгә — таяк ул булды.
Ундүртенә килгәндә,
Ундүрт дауны бетереп,
Түрәсен биргән ул булды.
Унбишенә килгәндә,
Туксан башлы Урданың
Туксан углы бер булып,
Айдалага[3] килгәндә,
Алар белән ант тотты.
«Көрәшеп барың мин ексам,
Мин барыңа баш,— диде.—
Көрәшеп берең мине екса,
Улыгыз миңа баш»,— диде.
Кушагын алып ту[4] итеп,
Анда мәйдан күтәрде.
Туксан башлы Урданың
Туксан углы җыелып,
Идегәй белән көрәш тотканда,
Екса ега белмәде,
Чалса чала белмәде —
Барын екты Идегәй;
Еккан береннән тун алып,
Айдалага өйдерде.
Өеп салып Идегәй,
Өстенә менеп тайчанды.
— Туктамыш хан тәхетенә
Мин мендем! — дип яр[5] салды.
Аннан әйтте Идегәй:
— Анау килгән ак атлы —
Ул Туктамыш хан булса,
Алдында баш имәгез,

---

[1] *Чүлләгәнгә* — сусаганга.
[2] *Ясак* — монда: ярдәм, таяныч, корал.
[3] *Айдала* — ачык, такыр дала.
[4] *Ту* — байрак.
[5] *Яр* — аваз, хәбәр.

Үзе сәлам бирмәсә,
Башлап сәлам бирмәгез...
Туктамыштай олы хан
Анда торып моны әйтте:
— Туксан бала айдалада,
Туксаны булып бүз[1] бала,
Бүз балалык итә белмәдең —
Башлап сәлам бирмәдең.
Ханыгыз булган минме өлкән,
Әллә юкса сезме өлкән?!

Анда әйтте Идегәй:
— Башта булсаң син өлкән,
Аякта[2] чыгар без өлкән.
Әйтеп бирсәм ник өлкән —
Туксан башлы Урданың
Янымда туксан баласы,
Шушы туксан баланың
Яшен санап салсам мин,
Анда чыгар без өлкән...
Айбалталы Дөрмән би,
Дөрмән улы Урман би —
Туксан бала эчендә
Каракчылык кылган би:
Балалар менгән таяк ат —
Аны урлап тотылды...
Өч урлады — котылды,
Дүртенчедә тотылды.

(Идегәй Урман бинең башын чабарга дип хөкем чыгара. Моны ишетеп, Туктамыш хан Идегәйне чакырып ала.)

Туктамыштай олы хан
Идегәйне алдырды:
— Әй Кобогыл, Кобогыл,
Яхшы атаның баласы —
Җантимернең утлы идең;
Елкы бактың, куй бактың,
Айдалага ут яктың:
Айбалталы Дөрмән би,

---

[1] *Бүз* — асыл, затлы.
[2] *Аякта* — азакта, соңында.

Дөрмән углы Урман би,
Аның башын ник чаптың?
Анда әйтте Идегәй:
— Иleңдә йөргән каракчы
Өч ат урлап котылса,
Дүртенчедә тотылса,
Синең түрәң[1] буенча
Дүртенчедә чабылса,
Дөрмән улы Урман би —
Ул да шулай тотылды,
Синең хөкемең буенча
Ул да шулай чабылды,
Аның аргысын мин белмәм...

Кобогылга аны әйтте:
— Әй Кобогыл, Кобогыл,
Сараемда кал,—диде.—
Өстеңдәге иске тун —
Ул туныңны сал,— диде...
Анда әйтте Идегәй:
— Атың булса, багамын,
Утың булса, ягамын,
Мин яхшыга яхшымын,
Мин яманга яманмын,
Кул биргәннең колымын —
Хезмәтеңдә каламын.

Торып килеп Идегәй,
Хан ни бирсә, аны алды:
Ал кара[2] кеш тун[3] икән —
Кияренә аны алды;
Тимгел чуар ат икән —
Менәренә аны алды;
Күн давылбаз[4] бар икән —
Төяренә аны алды;
Асыл шонкар кош икән —
Чөяренә аны алды;

---

[1] *Түрә* — хөкем, закон.

[2] *Ал кара* — чем-кара.

[3] *Кеш тун* — кыйммәтле, затлы мех бирә торган җәнлек тиресеннән тегелгән тун.

[4] *Давылбаз* — күннән ясалган барабан.

Бер бите айдай балкыган,
Бер бите көндәй салкыган,
Болгардаен болкыган,
Җофардаен[1] аңкыган
Айтулы атлы ару кыз икән —
Туеннан туен кылдырып,
Сөяренә аны алды.
Кырымнан кыен дау килсә,
Дауны кырды Идегәй;
Кырымнан калын яу килсә,
Яуны кырды Идегәй.

Туктамыштай олы хан
Идегәйнең көнендә
Яу белән даудан котылды.
Сарай дигән калада
Дүрт дәрваза бар икән:
Икәве бикле булганда,
Икәвен ачык куйдырды,
Береннән килгән кәрваны
Береннән чыгып бетә алмый.
Боҗрасы бөтен алкадай
Боралып килгән мал булды.
Туктамыштай олы хан,
Идегәйдәй ирнең көнендә
Ил казнасы бай булды,
Билгәне кол булды,
Әйдәгәне мал булды;
Җәеп салсаң көмешен —
Җәйрәп яткан күл булды;
Өеп салсаң алтынын —
Әлдермештәй тау булды.
Ашаган казы ял булды,
Эчкәне сары бал булды.
Әмма Идегәй үзе кем? —
Анысын белмәс хан булды.

(Туктамыш ханның хатыны Йәникә игезәк кызлар таба. Бу шатлыктан хан утыз көн уен, кырык көн туен үткәрә. Нәкъ шул вакытта Идегәй белән Айтулының да уллары туа. Идегәй улына Норадын дип исем куя, бәби туен да бик зурлап

[1] *Җофар* — хуш исле.

үткәрә. Йәникәнең моңа бик ачуы килә, һәм ул Туктамышны, чичән-җырчыларны чакыртып, Кобогылның кем икәнен сорарга кирәк дип котырта. Туктамыш хан кол булган Кобогылның үзен хан белән тиң итеп, хәтта аннан да өстенрәк итеп тотуын күреп, моның серен беләсе килә. Тугыз күрәзәче-җырчы һәм хикмәтчене чакырып сорыйлар, берсе дә Кобогылның кем икәнен әйтә алмый. Иң ахырда йөз туксан биш яшьлек Субра картны алып киләләр.)

Күп батырны мин күрдем,
Күп батырны мин белдем,
Яшем йөз туксанга килгәндә,
Чыкмаган җан йөргәндә,
Миннән дәүран[1] үткәндә,
Сезгә дәүран җиткәндә,
Утыз тешем беткәндә,
Шунча ирләр күргәндә,
Утыз ханның гомерен үткәндә,
Кобогылдай ирне мин
Бер күрмәгән картыңмын!
Кашларына карасам,
Каләмнән пәйда булгандай;
Күзләренә карасам,
Күгеннән пәйда булгандай;
Каршыннан торып карасам,
Каһәрдән пәйда булгандай;
Буйларына карасам,
Нурдан пәйда булгандай!
Инде мин кеше танымам,
Әгәр кеше танысам,
Котлыкыя би улы
Идегәй ул — Кобогыл!

(Субра карт Идегәйнең, Ак Урданы алып, Туктамышны тәхеттән куачагын да әйтә. Бу хәбәрне ишеткәч, Идегәйгә агулы бал биреп, аны үтермәкче булалар. Дуслары ярдәмендә Идегәй хан сараеннан качып китә; туган җирен ташлап, Аксак Тимер янына юнәлә.)

Сораулар һәм биремнәр.

1. Идегәйнең бала чагы һәм «ай үсәсен көн үскән» алпамыштай ир булуы нинди алымнар белән тасвирланган? Сүзләрнең сайланышына игътибар итегез.

[1] *Дәүран* — гомер, вакыт.

2. Идегәйнең ир-егет булуы нинди сыйфатлар белән аңлатылган? Аның туксан угылга баш булуы гаделме? Идегәйнең акылы, тапкырлыгы кайсы очракларда аңа ярдәм итә?
3. Ни өчен ул Туктамыш ханга хезмәт итәргә була һәм нинди дәрәҗәгә ирешә? Аның алтын-көмешләренең күплеге бары тик байлык билгесе генәме әллә башка мәгънәләргә дә ияме?
4. Туктамыш ханның Идегәйгә мөнәсәбәте ни өчен үзгәрә, аңа кем сәбәпче була? Көнчелек, мәкер, хыянәт кебек куркыныч сыйфатларның кешеләр һәм халыклар язмышында нинди роль уйнаганлыгына бу дастанда һәм башка әсәрләрдә игътибар итеп барыгыз.
5. Субра карт образы сездә нинди тәэсир калдырды? Ул реаль образмы?

(Ак Урдадан качып киткәннән соң, Кара Тиен Алып белән сугышып, Идегәй Аксак Тимернең кызы Акбеләкне коткара, аны, Сәмәркандка илтеп, әтисенә тапшыра һәм, би дәрәҗәсен алып, шунда яши башлый.
Бу хәлләрдән соң Туктамыш хан Идегәйнең улы Норадынны да мәсхәрәләп, Ак Урдадан куып җибәрә. Норадын, озын юллар үтеп, Идегәй янына Сәмәркандка килеп җитә.)

Азамат ир Идегәй
Хәл сорашып белгәндә,
Норадынның ат-тунын,
Бар шайманын[1] күргәндә,
Туктамышның нияте
Ни булганын аңлады.
Норадынга өй бирде,
Үз кулыннан сый бирде.
Менәренә ат бирде,
Уеннан уен калдырып,
Норадынга ял бирде.
Айлар-көннәр үткәчтен,
Норадынны чакыртып:
— Газизем, сөйлә,— дигәндә,
Ир Норадын аны әйтте:
— Ат сөренми җир танымас,
Ир сөренми ил танымас,
Иделдәй илем барында
Шаһ Тимер иле тартмыйдыр,
Һич күңелемә ятмыйдыр,
Таңы таң булып атмыйдыр,
Суы су булып акмыйдыр.

[1] *Шайман* — 1) корал, җиһаз; 2) ат сбруе.

Анда әйтте Идегәй:
— Әй Норадын, Норадын,
Нидер синең морадың?
— Әйтсәм әйтим морадым:
Ат та туйган җиренә,
Ир дә туган җиренә;
Кендек каным тамган җир —
Көмеш сулы Идел булганда,
Сине дә куган Туктамыш,
Мине дә куган Туктамыш;
Бабамның башын чаптырган
Әзәлдән яу Туктамыш;
Туктамышта кигем[1] бар,
Кик алганда кинә[2] юк,
Үч алганда үпкә юк;
И газизем, и атам,
Каерылып атны тартаек,
Ана Иделгә кайтаек,
Идел багында ятаек.
Ул Туктамыш хан икән,
Ук-садак[3] билдә булганда,
Угыбызны анда атаек,
Ата-ата ятаек!

Анда әйтте Идегәй:
— Әй Норадын, Норадын,
Сагынсам да илемне,
Санласам да санымны,
Туктамыштай бер ханны
Хан итеп белгән ул илгә
Янә бер кире кайтмыймын.
Илемә ул хан булганда,
Ил күңелемне тартмыйдыр,
Суы су булып акмыйдыр.

Анда әйтте Норадын:
— Әй газизем, әй атам,
Сарай белән Болгарның,

---

[1] *Кик* — үч, үпкә.
[2] *Кинә* — гаеп.
[3] *Садак* — ук савыты.

Иделдәге иленнең
Халкы ханнан өркә инде,
Татар белән нугаең
Ханга каршы купты инде,
Идегәй безгә кайтсын дип,
Башыбызда торсын дип,
Сөт белән юган кылычын
Кан белән янә юсын дип,
Болгариның Бодай би
Артымнан куа җитеп әйтте инде.
Әй газизем, әй атам,
Каерылып атны тартаек,
Идел чыгып ятаек!
Ук-садак билдә булганда,
Ил-халык бергә булганда,
Угыбызны анда атаек,
Ата-ата ятаек!

Анда әйтте Идегәй:
— Газизем, асыл икәнсең,
Рас сөйләрсең, морза улым.
Сарай белән Болгарның,
Чулман белән Нократның
Халкы ханнан өреккәндә,
Өркеп мине көткәндә,
Без дә анда булаек;
Ил сүзен тоткан — ир булыр,
Ил сүзен кабул кылаек!

(Идегәй азатлыкка омтылган халкына ярдәмгә ашыкканда, Шаһ Тимер дә Актүбәне басып алу уе белән гаскәрен җыя, сансыз чиру, кара яу булып, Идел-йортка юнәлә.)

Җаектан ары Актүбә,
Актүбәгә менгәндә,
Идел-йортны күргәндә,
Туфрагын үбеп ярсулап,
Идегәй аны тулгады[1]:
— И Идел-йорт, Идел-йорт,
Идел эче имин йорт,
Атам кияү булган йорт —

---

[1] *Тулгау* — көйләп, такмаклап әйтү.

Иелеп тәзем кылган[1] йорт;
Анам килен булган йорт —
Иелеп сәлам әйткән йорт;
Кендегемне кискән йорт,
Керем-коңым юган йорт,
Бия сауган сөтле йорт,
Кымыз эчкән котлы йорт;
Идел — Җаек арасы
Елкы белән тулган йорт,
Казан — Болгар арасы
Кала белән тулган йорт;
Ашлы белән Ибраһим
Ашлык белән тулган йорт,
Ата-бабам тоткан йорт,
Котлы булсын туган йорт!
Айдан якты нәрсә юк,
Кара болыт басмаса,
Адәм гарибә шул булыр —
Кайтып илен тапмаса!
Мин барамын, барамын,
Үз илемне аламын;
Яфракларың саргаеп,
Күк тугаең каралып,
Хан Туктамыш кулында
Син ни булдың, туган йорт?
Синдәй илдән аерылган
Мин ни булдым, туган йорт?

(Туктамыш хан төш күрә, төш юраучы аның җиңеләчәген, кулыннан дәүләт китәчәген әйтә. Идегәй үзенең якыннары белән, Шаһ Тимердән аерылып, Туктамышка каршы кузгалган халкына барып кушыла. Аксак Тимер Туктамыш хан белән сугыша һәм җиңелә. Шуннан соң Туктамыш гаскәре белән Идегәй орыша. Чолганышта калган Туктамыш сараеннан качып китә. Аксак Тимер Сарай, Болгар шәһәрләрен, Ак Урданы җимерә. Туктамышны куа барган Идегәй җимерелгән ил-йортын күреп хәйран кала, Аксак Тимерне үз иленә кире җибәреп, шәһәрләр салырга тотына.)

Яр салдырды калага,
Яр салдырды далага.
Туктамышның сансыз кол,
Барын-югын җыйдырды,

---

[1] *Тәзем кылу* — олылау.

Җыеп азат кылдырды.
Угылларны сатуга
Бер чигара кылдырды[1].
Кисмә-кисмә сары алтын
Кисеп улҗа[2] кылдырды.
Идел-йортны җыйдырып,
Өлкән бер туй кылдырды.
Агаларны алдырып,
Киңәшсез үскән бу йортны
Киңәшле йорт кылдырды,
Каланы кайта торгызды,
Илне илгә тутырды,
Уртасына ару урда кундырды.

(Идегәй һәм аның улы Норадын башыннан бик күп хәлләр кичә, алар күп сугышларда катнашалар, мәкер-хыянәт белән аларның араларын да бозалар. Шулай да Идегәйнең батырлыгын дошманнары да танырга мәҗбүр була, дастан Идегәйнең үлемен тасвирлап тәмамланса да, халык канын койган хан игелекле була алмаячагын ул әйтеп үлә.)

Кадыйрбирде яшь солтан,
Гайрәте килеп, анда әйтте:
— Идегәй андый ир икән,
Идел-йортта бер икән,
Ирекле кеше ул булып,
Илне тоткан ир икән;
Идегәй илдә бер икән,
Ир сыртланы ир икән;
Бүре булып бараем,
Бурбаеннан[3] алаем!
Җавап бирде Идегәй:
— Кабагыннан кар явып,
Керпегенә боз туңып,
Эзләп килгән Кадыйр белән
Ярышырга көчем бар.
Аны да бел, Кадыйрау,
Арыслан хәлдән тайса да,
Бер сарыклык көче бар!..

---

[1] *Чигара кылу* — чик кую.
[2] *Улҗа* — сугышта кулга төшкән мал, трофей.
[3] *Бурбай* — тез асты.

Анда әйтте Идегәй:
— Үлем белән куркытмаң,
Курка торган уем юк!
Үлем туры килә икән,
Котыла торган буем юк.
Илем өчен илсенеп,
Җирем өчен җирсенеп,
Халыгым өчен яхшы уем.
Күкрәк тулып җилсенеп,
Көрәшкәнне халыгым
Аңладымы — белалмам!
Аңламаса халыгым
Аңламастан үлалмам!
Барсын бердәй аралап,
Аттан атын яралап,
Анда батыр Идегәй
Унике ирне үтерде.
Кан ярасы ачылып,
Идегәй хәле беткәндә,
Барын морза бер җитеп,
Идегәйне бер чапты.
Башы тәннән аерылып,
Тәгәри биреп аны әйтте:
— Барын[1], сиңа ни кылдым?
Берең ике булмасын![2]
Йортың-караң калмасын!
Ханнан ханны мин ектым,
Хан булып син дә калмассың!
Сөт урынына кан койдың,
Канымны түгеп ни кылдың?
Идегәй башы аны әйтеп,
Көнгә табан әйләнде,
Әйләнгәндә янә әйтте:
— Алдагы көн агырга[3]
Без барабыз, ул килмәс!..

Сораулар һәм биремнәр.

1. Вакыйгаларны эзлекле итеп сөйләп чыгыгыз. Норадын туган ил, туган җир турында нинди сүзләр белән сөйли?

---

[1] *Барын* — кеше исеме, тарихта мәгълүм нәселдән.
[2] *Берең ике булмау* — нәсел үрчүдән туктау.
[3] *Агыр* — хөрмәт.

2. Ни өчен Идегәй Иделгә, Болгарга кире кайтырга була? Аны кемнәр чакыра?
3. Идегәй Идел-йортка мөрәҗәгать иткәндә нинди хисләр кичерә? «Йорт» сүзенә нинди мәгънәләр салынган? Бу өзекне ятлагыз.
4. Бүлектә очраган атамалар сезгә танышмы? Вакыйгалар нинди мәйданда, кайсы урыннарда бара? Ул вакыйгаларда кемнәр, нинди максат белән катнашалар?
5. Әсәрдә нинди тылсымлы хәлләр, экияттәгечә сурәтләнгән вакыйгалар очраттыгыз?
6. Идегәй Идел-йорт белән ничек идарә итә? Шул чордагы вакыйгалар, гореф-гадәтләр белән бүгенге көн арасында бәйләнеш, охшашлык, уртаклыклар бармы? Шул турыда сөйләгез.

Гасырлар авазын саклаган әсәр

Иң башта «Идегәй» дастанының тарихи җирлеген күз алдына китерик. XIV гасырның икенче яртысында Көнбатыш һәм Көнчыгыш Европаны тетрәткән унар, йөзәр елларга сузылган, дәүләтләрнең үзәкләшү-берләшү яки, киресенчә, үз дәүләтләрен төзү, азатлыкка чыгу өчен көрәшләре бара. Югарыдан торып карасак, вулкан кебек кайнап торган гаять киң мәйданны, хакимлек өчен барган тартышларны, азатлык-хөрлек, ирек өчен көрәшкән каһарманнарны күрер идек. Европа һәм Азиянең үзәгенә урнашкан Алтын Урда дәүләте әле үзенең көч-куәте, байлыгы, җирләрнең иксез-чиксез булуы белән дан тоткан чор була. Алтын Урда дәүләте белән Чыңгыз ханның уллары һәм оныклары идарә итә. Бу чорда Идел тамагыннан алып төньякка таба күп санлы шәһәрләр төзелә. Иң танылганнары — бөтен дөньяга мәшһүр Сарай һәм болгар кенәзлекләренең башкаласы Болгар шәһәрләре турында тарихи истәлекләрдә күп сөйләнә. Иксез-чиксез җир-сулар, киң далалар аерым феодалларга бүлеп бирелгән була, һәм алар белән идарә итү торган саен кыенлаша бара. Эре феодаллар үз кулларына көч туплыйлар, гаскәр җыялар һәм, үз дәүләтләрен төзү өчен, әледән-әле баш күтәрәләр. Үзәк дәүләт белән бәйсезлеккә омтылган өлкәләр арасындагы озак елларга сузылган тартыш Алтын Урданың таркалуы белән тәмамлана.

«Идегәй» дастаны — менә шундый гаять катлаулы, каршылыклы вакыйгалар, зур шәхесләр белән тулы чорга халыкның мөнәсәбәтен белдерү максаты белән иҗат ителгән, тарихтан

алынырга тиешле гыйбрәтле сабаклар турындагы әсәр. Дастанны җентекләп өйрәнгәннән соң, бездә нинди тәэсирләр һәм фикерләр калды соң?

Әйтерсең тарихның үзе белән очраштык — искиткеч үзенчәлекле, безгә моңа кадәр таныш булмаган, хыялларны уятып җибәрә торган сөйләм теле. Могҗиза бит: шәһәрләр җир белән тигезләнгән, дәүләтләр юкка чыккан, ә сүз сакланып калган. Хәтер һәм хисләр кайнарлыгын саклап калырга сәләтле бердәнбер чара — ул тел, дип юкка гына әйтмибез икән!

Бик җитди уйландыра торган, бүгенге көн өчен дә бик актуаль булган мәсьәлә — дәүләтләр ничек, нинди шартларда төзелә, яши һәм нинди сәбәпләр аркасында таркала? Бу табигый процессмы, аерым шәхесләрнең теләгенә, ихтыярына бәйлеме? Тарих белән нинди көчләр идарә итә? Бу сорауларга җавапны тарих фәннәре эзли, барлык чорларның акыл ияләре уйлана. Әдәбият, халык иҗаты әсәрләре исә, тарих, халык, тормыш дигән мәңгелек төшенчәләрне җанландырып, вакыйгаларны тарихта, чынлыкта булганча гына түгел, башкачарак — үз хыялына туры китереп, үзгәртеп сурәтли. Әдәби әсәрдә булса да, үз хыялын тормышка ашырып куя.

Дастанда без игътибар итәргә тиешле тагын бер як — герой, шәхес мәсьәләсе. Үзе белән идарә иткән ханнарга, хакимнәргә мөнәсәбәтен халык үз иҗатында гел чагылдырып торган: кайсындыр яклаган, кайсындыр күңеле, рухы белән кабул итмәгән, андыйларга каршы үз геройларын куйган. Ягъни хикмәт кемнең хан, патша, әмир булуында түгел, ә аның нинди сыйфатларга ия булуында дигән нәтиҗә ясап була.

«Идегәй» дастаны нәрсә турында дигән сорауга җавап бирә башласак, вакыйгаларның реаль, тарихи икәнлегенә басым ясап, Алтын Урда дәүләтенең таркалуы турында дип атап әйтергә мөмкин. Менә шушы хәл нинди сәбәпләр аркасында килеп чыга? Туктамыш белән Аксак Тимер дәрәҗә, беренчелек өчен ярышалар: тугыз илгә даны таралган лачынга бары мин генә ия булырга тиеш дип саныйлар. Юктан башланган ызгыш ни белән бетәчәк, халык өчен нинди бәягә төшәчәк — бу аларны кызыксындырмый. Халкының мәнфәгатен кайгырта, уйлый белмәгән хан акыллы хан түгел дигән нәтиҗә соралып тора. Өстәвенә Туктамыш, үзенең шикләнүләренә генә нигезләнеп, Котлыкыяның нәселен юк итәргә, бишектәге баласын да чабарга боера. Кансыз, мәрхәмәтсез хан бер кешегә генә түгел, киләчәк буыннарга да зыян сала. Бу турыда Җантимер тарих-

ларга язып куярлык акыллы сүз әйтә. Хәтта үз баласын корбан итеп булса да, данлы бер нәселне саклап кала.

Идегәй, әлбәттә, халык герое итеп тасвирлана. Ул әкияттәгечә акыллы, көчле, булдыклы ир булып үсә. Бу урыннарда дастанчының хыял-өмете иң югары ноктасына җитә. Идегәй Туктамыш сараенда зур дәрәҗәгә, байлыкка ирешә. Әмма дөньяда көнчелек, мәкер, хыянәт бар. Явыз көчләр дигәндә кешеләр, язмышлар юлында торган шундый сыйфатларны күздә тотабыз. Шул сыйфатлар колына әйләнгән кешеләр үзләре дә явызлык чыганагына әйләнәләр. Хан хатыны Йәникә Идегәй язмышында әнә шундый роль үти. Идегәй Туктамышның дошманы Аксак Тимер янына качып китәргә мәҗбүр була. Әсәрдә бик көчле каршылык тудырган урын бу: Идегәй, телиме-теләмиме, иленә һәм халкына да хыянәт итә бит. Улы Норадынның бу турыда әйткән сүзләре зур хакыйкать булып яңгырый. Гомумән, Җантимер, Норадын, Идегәйнең (туган туфрагына баш орып әйткән) сүзләре — һәр очракка, һәркемгә карый торган, бәхәссез дөреслек.

Идегәйнең гел уңай сыйфатлардан гына торган, коеп куйган герой булмавы бик әһәмиятле. Ул әле Туктамыш, әле Аксак Тимер ягына чыга. Горур, үз кадерен белгән кеше буларак, бу хәлгә хурлана да, шул ук вакытта үз гомерен саклап калырга да тиеш бит әле ул. Ул дөрес, акыллы сүзләргә колак сала белә, хаталарын төзәтеп, тәҗрибә һәм көч, акыл җыеп яши. Халкына, иленә зур игелекләр эшли — таркалып барган, җимерелгән илне торгыза, гадел идарә итә. Аның язмышы хыянәтләр, үч алулар белән үрелеп бара: үзара аңлаша алмыйча Норадын һәлак була, бу хәл Идегәйнең дә үлемен тизләтә.

Дастанның ахыры бик хикмәтле. Идегәйнең чабылган башы: «Хан артыннан хан үтереп, сөт урынына кан коеп яшибез икән, алдагы көнебез дә нәкъ шундый булачак»,— дигән сүзләр әйтә. Чынлап та, Идел-йорт үз эчендә татулык, бердәмлек булмаганга күрә таркала. «Идегәй» дастаны бүгенге көндә — дәүләтләр, халыклар, милләтләр язмышы өчен гаять катлаулы, каршылыклы чорда — тарихтан килгән бу акыл-тәҗрибәне бөтен тирәнлеге белән аңлап үзләштерергә чакыру авазы булып яңгырый.

Фатих Кәрими

(1870—1937)

Ике гасыр арасында, ягъни XIX гасыр ахырында һәм XX гасыр башында иҗат иткән күплэгән татар язучылары арасында Фатих Кәрими лаеклы урын тота.

Ул элеккеге Бөгелмә өязенең Миңлебай авылында Гыйльман мулла гаиләсендә дөньяга килә. 11 ел Чистайда мәдрәсәдә, шунда ук ике сыйныфлы рус мәктәбендә укый. Аннары Төркиядә, Истанбул университетында белем ала, берничә тел өйрәнә.

Фатих Кәрими, иленә кайтып, Оренбургтагы үз типографияләрендә әтисе башлаган китап бастырып тарату эшен дәвам иттерә. Соңрак «Вакыт» исемле газетаның баш редакторы булып эшли. Үзе дә әдәби әсәрләр һәм гыйльми хезмәтләр яза, тәрҗемә итә. Укыту һәм тәрбия эшләрен оештыруга җиң сызганып булыша. Оренбургта татар, башкорт, казакъ мәктәпләре өчен мөгаллимнәр хәзерләү курслары ачылгач, анда укыта.

Күрәбез: Фатих Кәриминең бөтен эшчәнлеге һәм тырышлыгы халыкны тәрбияләүгә, аны аң-белемле итүгә юнәлтелгән. Аның әсәрләре дә шул максатны күздә тотып язылган. Әдип «Шәкерт илә студент», «Җиһангир мәхдүмнең мәдрәсәдә укуы», «Мирза кызы Фатыйма» кебек хикәяләре, «Истанбул мәктүпләре» һ. б. хезмәтләре белән кешене белем иясе булырга чакыра, хезмәт сөю һәм намуслылык кына кешене гүзәл итә, бизи дигән идея үткәрә. Җәмгыятьнең алга китүе өчен мәгърифәтле булу кирәк, шундый җәмгыятьтә генә яхшы яшәү өчен мөмкинлекләр туа дигән уй-фикерләрен җанлы образлар ярдәмендә уздыра.

1925 елдан алып Фатих Кәрими Мәскәүдә яши һәм төрле оешмаларда эшли. Мәсәлән, Көнчыгышны өйрәнү институтында төрек теле укыта, Үзәк нәшриятта эшли, хикәяләрен җыйнап бастыра, гомеренең соңгы көннәренә кадәр, журналистлык эшен дәвам итеп, «Эшче» кебек газеталарга язышa.

САЛИХ БАБАЙНЫҢ ӨЙЛӘНҮЕ

(хикәя беркадәр кыскартып алынды)

Мин яшь вакытта, безнең кыяр каравылчысы бер картыбыз бар иде. Бу картны мин бик сөядер идем. Чөнки, төрле-төрле хикәятләр сөйләп, минем күңелемне бик хуш итә торган иде.

Салих атлы бу картның биле бөкрәйгән, сакалы серпәйгән исә дә, үзе, бик сөемле[1] вә бала-чагаларга бик мәрхәмәтле булып, саф табигатьле вә йомшак калепле[2] иде. Картларның барысы да болай булмый бит, бәгъзеләренең табигатьләре бозылыбрак, холыклары тараеп китә вә тиз ачуланучан буладыр. Яшь киленнәрнең күбесе шундаен тар табигатьле вә холыксыз каената, каенаналардан күп әза, җәфа күрәләр.

Алла рәхмәт итсен үзенә, Салих бабай миңа күп хикәятләр сөйли торган иде.

Мәсәлән: аю белән төлкенең дус булып беренче ел шалкан, икенче елда богдай чәчкән хикәятләрен, төлкенең торна белән дус булып ашка чакырышкан хикәятләрен һәм дә бик кызык-кызык пәри вә җен хикәятләрен шулкадәр балландырып, татлыландырып сөйли иде ки, шул хикәятләрен тыңлап, кич белән йокларга яткач, төшемә кереп, саташа торган идем. Аю, бүре, төлке вә кәҗә хикәятләрен, зуррак үсеп мәктәпләргә йөри башлагач, рус мөхәррирләреннән Крылов вә француз мөхәррирләреннән Лафонтен атлы затларның китапларыннан укып ләззәт алсам да, безнең Салих бабай сөйләгән шикелле ләззәтле итеп язылган җен хикәятләренә сирәк туры килдем. Безнең Салих бабай һәр хикәянең башын үзенә махсус аерым сүзләр илә башлаганлыгы шикелле, ахырын да бик килештереп хәтем итә[3] торган иде.

---

[1] *Сөемле* — сөйкемле.

[2] *Калеп* — күңел.

[3] *Хәтем итү* — тәмамлау.

Мәсәлән, ул кыяр каравыллаганда, без, малайлар илә җыелып, аның янына бара торган идек. Күп вакытта ул, без барганда, куышының тышкы ягына бер бүкән өстенә утырып чабата ясый яки юкә каезлый торган буладыр иде. Безне күргәч: «Һай, балакайларым, рәхмәт минем яныма килүегезгә»,— дип сөенә торган иде. Без, аннан-моннан азрак кыяр ашагач, Салих бабайның тирә-янына җыелып, коры туфрак өстенә йөзтүбән сузылып ятадыр идек, терсәгебез илә җиргә, учыбыз илә ияк астыбызга таянып, башларыбызны бабайга таба борып: «Йә, Салих бабай, безгә берәр хикәят сөйләсәнә»,— дип ялварырга башлый идек. Без шулай әйтү белән, Салих бабай, елмаеп көлеп җибәреп: «Һай мутлар, һай наяннар, хикәятләрем бетте бит инде, сезгә барысын да сөйләдем»,— дип әйтә торган иде. Без, аның сүзенә карамыйча, тагын ялварырга башлагач: «Сөйләсәм берне генә сөйлим инде, менә монысы актыгы, моннан соң бер хикәятем дә калмады. Тагын хикәят сөйләргә йөдәтмәссез»,— дип сөйләргә башлыйдыр иде. Һәр мәртәбәсендә шулай әйтсә дә, икенче мәртәбәсендә тагын хикәят таба торган иде.

Салих бабай, азрак төзәтенеп, тамагын кырып: «Бар иде, ди, бер кешенең өч угылы, таз иде, ди, кече угылы» яки: «Бар иде, ди, бер торна, ком ашыйдыр иде дә су эчәдер иде»,— дип, хикәят сөйләргә башлау белән, ике колагыбызны дүрт итеп, гаять дикъкать белән күңел биреп тыңлыйдыр идек.

Әгәр хикәятнең бәгъзе җирләрене аңламаенча калсак, тагын кайтарып: «Салих бабай, шул җире ничек булган әле, шуны икенче кат сөйләсәнә»,— дип риҗа иткәч[1], аслан[2] иренмәенчә бик тәмләп сөйли торган иде.

Салих бабайның хатыны күптән вафат иткән, балаларының бәгъзесе бер тарафка, бәгъзесе икенче тарафка киткән, үзе ялгыз гына калган, карар кешесе дә юк; җәй көннәрендә кыяр, умарта каравылында вакыт кичерә, кыш көннәрендә, бик аз иҗарә (хак, түләү) белән берәрсенең өенә кереп, кыш буенча чабата ясап ризыкланадыр иде.

---

[1] *Риҗа итү* — сорау, үтенү.

[2] *Аслан* — бер дә.

Айлар, еллар үтте, без дә бераз үстек. Кыш көннәре мәктәпкә барадыр идек, җәй көннәре тәгътил[1] вакытында, авылга кайтып, ачык һавада, сахраларда вакыт кичерә торган идек. Бервакыт, тагын бер иптәшем белән кыяр җиребезгә барып, Салих бабайдан хикәят сөйләтмәкче булып ялварсак та сөйләмәде. Бераз кәефсезрәк күренде. Иптәшем: «Салих бабай, ни өчен кайгырасың? Әллә әбине сагынасыңмы?» — дигәч, Салих бабай, күкрәген киереп бер сулыш алып: «Әй балам, сагынырсың да шул, яшь вакытлар инсанның[2] күңеленнән тиз китмәйдер, сезләр әле яшьләр, күп нәрсәдән хәбәрегез юк, дөньяның ачысыны татымагансыздыр, сезнең өчен һәр җирдә уен-көлке генә», — диде. Минем иптәшем:

— Юк, юк, Салих бабай, алай түгел, яшь булсак та, безнең дә башыбызда кайгы-хәсрәтләр бар, дөньяның төчесенә татыганыбыз булмаса да, ачысыны бераз татыйбыз, мәсәлән, мәктәптә имтихан дигән нәрсә бар, шуннан өстенә тоз сипкән торма тәмнәре килә. Гәрчә без моны елында бер-ике мәртәбә татысак та, икенче елга кадәр тамагыбыздан ачысы китми. [...]

Безнең Салих бабай бик тәүфыйклы, истикамәтле[3] бер карт булып, гамәл һәм гыйбадәтенә[4] бер дә кимчелек китерми, хыянәттән бик курка торган бер кеше булса да, безнең өчен ошап бетми торган аз гына бер косуры[5] бар иде. Косуры әйтерлек дәрәҗәдә түгелдер, ләкин безгә азрак уңайсызлыгы тигәнлеге җәһәтле безнең хәтердә калган. Салих бабай борынына вак тәмәке чигә[6] торган иде. Без аның тирәсенә җыелып хикәят тыңларга башлагач, ул шунда сөйләгән арада борынына чигеп ала икән. Без хикәят тыңлауның дәрте илә аңарга игътибар да итә алмаенча калабыз. Арасы аз гына үткәч тә, ни күрәсең, Салих бабай бер башлайдыр төчкермәгә, безләр дә, сикерешеп торып, яныннан качмага башлыйбыз. [...]

---

[1] *Тәгътил* — каникул.
[2] *Инсан* — кеше.
[3] *Истикамәт* — намус.
[4] *Гыйбадәт* — табыну.
[5] *Косур* — кимчелек.
[6] *Чигә* — тарта, сала.

Бервакыт үзеннән шул рәвешчә сорадым:

— Йә, Салих бабай, син үзең яхшы гына бер карт, моның кебек файдасыз бер эшне, яман бер фигыльне кайдан өйрәндең? Ни өчен ташламыйсың?

Биргән җавабы шул булды:

— Әй балам, балам! Фәна (буш) вә яман гадәтләргә өйрәнүдән яшь вакытта бик сакланырга тиеш икән, начарлыгыны белсәң дә, гадәтләнгән нәрсәне ташлавы бик читендер. Мин яшь вакытымда бер хәзрәттә хезмәттә торадыр идем. Аның бер мәхдүме Бохараи шәрифтән[1] укудан кайтты. Бу мәхдүм бик суфый вә тәкъва[2] кеше булса да, әфьюн йоту, тел астына вак салу, борынына тәмәке чигү кебек бәгъзе гадәтләре бар иде.

Башка кешеләрдән яшерсә дә, боларны миннән яшерми торган иде. Үзе берлән икәү генә сахрагафәләнгә чыкканда, миңа да бирә торган булды. Боларны әүвәлән ул биргәндә генә истигъмаль[3] итсәм дә, мәхдүм бер җиргә мөдәррис[4] булып киткәннән соң, үзем эзләп табып, сатып алып истигъмаль итә башладым. Әфьюнга җитәрлек бездә акча да булмады, кайда сатылганын да юньле-башлы өйрәнә алмадым, иң ахырында менә шушы борын тәмәкесенә өйрәнеп калдым. Аллаһы Тәгалә үзе гафу итсен инде.

Иптәшем, Салих бабайның янына гына утырып, имтиханның нә идекене сөйләмәгә башлаган иде, Салих бабай кисәктән генә бер «Һаттечү!» димәсенме, ни чара, бераз читкәрәк китеп тордык. Ул туктагач, тагын янына килдек. [...]

Мин (иптәшемә хитабән[5]):

— Имтихан вә уку мәсьәләләре илә юк җирдә Салих бабайның башыны авырттырмаска кирәк. Менә аннан үзенең яшь вакытларыны, ничек итеп солдатка киткән вә ничек итеп өйләнгәннекләрене сөйләтик.

Иптәшем:

— Бик хуш булыр, йә, Салих бабай, шул яшь вакытта кичергән хәлләреңне безгә сөйләсәнә.

---

[1] *Бохараи шәрифтән* — кадерле (изге) Бохарадан.

[2] *Тәкъва* — дин кушканны гына эшләүче.

[3] *Истигъмаль* — куллану.

[4] *Мөдәррис* — мәдрәсәдә өлкән укытучы.

[5] *Хитабән* — эндәшеп.

Салих бабай борынына бер чигеп алды. «Һаттечү!»не әйткәнче, без читкәрәк китеп тордык. Тагын янына килеп утыргач, йомшак кына тавыш белән шул сурәттә сөйләргә башлады:

— Без яшь вакытта берзаман киттек-киттек, бара торгач, бер авылга барып җиттек. Әстәгъфирулла, ялгыш әйттем, барып җиттек түгел, тик авылга якынлашмага башладык. Мәсҗетнең озын манарасы, чыккан кояшның нуры күңелләргә сафа[1] бирде. Яз вакыты иде. Ялтырап чыккан кояшның нуры, бөтен дөньяны яктыртып, берничә айлардан бирле үлек хәлендә җансыз булып торган табигатькә, ягъни агачларга, суларга, хайваннарга вә инсаннарга яңадан җан бирмәктә исә дә, эсселеге илә рәхәтсез итәрлек дәрәҗәдә түгел иде.

Бара торган юлыбыз бер олуг юл булып, ике тарафка буйдан-буйга каен агачлары утыртылган, уртага калкытып таш түшәгән, өстенә ком сибеп, юлны төзәткәннәр. Ике читтәге каен агачларының уртасында да тар гына юллар бар иде. Әүвәлдән бераз шәбрәк килгәнгә күрә, атларыбыз тирләгән иде. Авылга барып җиткәч тә, атларның сулыш алганыны бик озак көтәргә мохтаҗ булмас өчен, ошбу каеннар арасындагы күләгәлек юлдан атларны үз хәленә куеп, акрын гына киләдер идек. Бик акрын гына искән кыйбла җиле илә агачларның яфраклары җилбер-җилбер итеп кыштырдашып торалар иде. Юлның ике тарафындагы сахралар хәтфә кебек ямь-яшел үләннәр вә төрле-төрле ләтыйф матур чәчәкләр илә өртелмештер. Һәр нәүгы[2] гүзәл вә ләтыйф күбәләкләр илә төрле-төрле чебеннәр вә кортлар, арлы-бирле очышып, сахраның гүзәллегене арттырмакта иделәр.

Бераз ерактан күренгән бер урманның буендагы юлдан атлы бер кешенең чабып барганы мөшаһәдә улынды (күренде). Бераз килгәннән соң, юлымызны аркылы кичеп чыккан вә тизлек илә сузылып ага торган бер елгага җиттек. Елганың өстендә, гаять табигый сурәттә итеп, агачтан күпер салынган. Күпернең ике ягында да елга буенча әрәмәлек бар иде.

---

[1] *Сафа* — рәхәтлек.

[2] *Нәүгы* — төр (сорт).

Ләтыйф вә көмеш кебек саф бер суның янындагы бу яшел әрәмәнең буйлары шулкадәр гүзәл вә шулкадәр шагыйранә иде ки, бу җиргә туктап азрак сәер итмәенчә[1] үтеп китәргә күп кешенең күңеле разый булмас иде. Без бу әрәмәгә килеп җиткәндә, өйлә вакыты булган иде. Шунда туктап тәһарәт алып, җәннәт кебек гүзәл бер җирдә намаз укып, бер истирахәт итсәк[2] ничек булыр икән, дип иптәшемә әйткән идем, минем тәкълифемне[3] бик хуш күреп кабул итте. Без туктап тәһарәт алып бетереп торганда, безгә каршы яктан күпергә берничә арбалы чегәннәр (ченкәнәләр) килеп җиттеләр. Күперне чыккач, әрәмәнең буенарак якынлашып, атларыны туара башладылар. Хәтеремдә бик яхшы калмаган. Ничә арбалы икәнлекләрене белмәймен, шулай булса да бәгъзесенә икешәр ат җигелмеш алты-җиде арбалары бар иде шикелле. Ләкин үзләре бик күп иде. Ничек әйтсәм дә ялган булыр дип куркамын, ир, хатын-кыз вә бала-чага барысы илле-алтмыш кеше булгандыр. Хәтта, арбага сыя алмагач, бәгъзеләре арба артыннан җәяү киләләр иде.

Хәзергә кадәр Салих бабайның хикәятеннән бер дә тат[4] чыкмаган иде, хәтта бераз күңелсезләнеп, тыңларга иренгәнлегебездән, авызларыбыз ачылырга башлаган иде. Ләкин чегән исемен ишеткәч, күңелебез бераз хушланды. Хикәятнең кызык җирләре шуннан соң башланмасмы дия, өметләребез беркадәр артты. Чөнки яшьтән бирле чегән килә дип куркыталар иде. Чегән, күз буып, үзе теләгән нәрсәне алып китә дип алдашалар иде. Зуррак үсеп, укый башлагач, чегәннәр хакында тагын күбрәк нәрсәләр өйрәнгән идек.

[...] Салих бабай тагын шул рәвештә хикәясенә башлады:

— Без намаз укырга башладык, анлар да, шау-шу килеп, каюсы ат туарырга вә каюсы җиргә ут ягып өстенә казан асарак аш пешерергә башладылар. Намаз укып бетергәч, яшел үлән өстенә ятып, бераз ерактан

---

[1] *Сәер итү* — ерактан, бер читтән карап тору.
[2] *Истирахәт итү* — ял итү, рәхәтләнү.
[3] *Тәкълиф* — теләк.
[4] *Тат* — тәм.

чегәннәрнең хәлене сәер итәргә башлаган идек, авылга таба кайтып килә торган ике кыз илә бер угылан күпергә килеп җиттеләр. Кызларның икесе дә буйгасынга җиткән улып, углан унике-унөч яшь тирәләрендә хисап улынмакта иде.

Күпернең бер тарафында безне вә бер тарафында чегәннәрне күргәч, бу ләтыйф юлчылар, тәмам күпернең өстендә туктап, чегәннәрне сәер итмәгә башладылар. Ихтимал ки, без булмасак, болар чегәннәрдән курыккан да булырлар иде. Ләкин без булгач, беркадәр йөрәкләнгәннәр булырга кирәк. Чегәннәр, ут тирәсенә бер җиргә җыелып, бәгъзеләре җырларга вә бәгъзеләре биергә башлады. Кызларның күзләре чегәннәрдә булса да, безнең күзләремез кызларда иде. Нәмәхрәмгә[1] карау дөрес түгел дия игътираз[2] итмәгез, бәлки без алу нияте илә карайбыз, алу нияте илә кызларга карау дөрес дип, муллалар фәтва[3] бирәләр бит. Авыл кызларының киемнәре простой гына булса да, үзләренә бик килешеп тора, табигатьләре уйнак, үзләре хуш, күңелләре күтәренке була. Чөнки үзләреннән югары күп адәм күреп кимсенмәйләр. Уналты, унҗиде яшенә җитеп, җиләк кебек пешкән кызыл яңаклы, саф күзле авыл кызларының ләтафәт вә дилбәрлекне[4] тәгъриф итмәк[5] кемнең кулыннан килер. Бонлар гадәттән мәләктер[6], әфәндем, мәләк! Вәссәлам[7] . [...]

Хикәяткә мондаен кызлар да катышкач, без тагын зиядә (артыграк) дәрт белән тыңламага башладык. Салих бабай диде ки:

— Бу кадәр шагыйранә урында мондаен гүзәл кызлар күргәч, күңелем әллә нишләп китте. Ничек булса да бу кызларның янына барып, азрак сөйләшмәкче булдым.

---

[1] *Нәмәхрәм* — ят кеше (мөселман хатын-кызлары күренмәскә тиешле ир кеше).

[2] *Игътираз* — каршы сөйләү.

[3] *Фәтва* — нинди дә булса бер эшне эшләү дини яктан дөресме икәнен күрсәтеп бирү.

[4] *Дилбәрлек* — гүзәллек һәм сөйдерү сыйфаты.

[5] *Тәгъриф итү* — аңлату.

[6] *Мәләк* — фәрештә.

[7] *Вәссәлам* — бетте, тәмам булды.

Салих бабай шулай сөйләп торганда, минем иптәшем аның сүзен кисеп диде ки:

— Тукта әле, Салих бабай, ул заман синең ничә яшьләрдәге вакытың иде, һәм дә сез кайда барадыр идегез? Шуларны әйтеп китсәң, хикәятнең ләззәте тагын зиядә[1] булыр иде.

Моңа каршы Салих бабайның җавабы бу улды:

— Ул заман минем солдат өчен каралырга тиешле булган вакытым булып, егерме бер яшьләремдә идем. Бу кызларга очраган вакытта, күрше авылдагы бер тутамызга кунакка барадыр идек.

Минем иптәшем:

— Тәмам, хәзер эш бик яхшы аңлашылды, хикәятегезгә дәвам итегез, ягъни күпер өстендәге кызлар илә сөйләшә алдыңмы?

Салих бабай тагын зиядә дәрт илә сүзгә башлап диде ки:

— Егет кеше, дәрт иткән эшне эшләмәенчә, һич куярмы? Яткан җиремнән торып, акрын гына күпергә таба бара башладым, кызлар һәмишә[2] чегәннәрне сәер итеп торалар иде. Тәмам күпер өстенә барып җиткәнчәгә кадәр мине күрмәделәр. Кисәктән күргәч куркып, качып китмәсеннәр дип, күпергә кергәч, аз гына тамак кырдым. Кызлар дәрхаль[3] миңа борылып карадылар да йөзләрене икенче тарафка чөеп өртенмәкче[4] булганнар иде. Ләкин мин:

— Зинһар, миннән кача күрмәгез, мин фәна калепле (начар күңелле) адәм дәгелмен вә сезгә дә бер фәна ният илә кәлмәдем,— дигәч, шырык-шырык көлештеләр, вә ярты качып, ярты күренеп:

— Ярый, бездә нә йомышың бар? — диделәр. Бердәнбергә нә әйтергә дә шашыргач[5], оятлы булып калмас өчен:

— Фәлән адәмнең йорты сезнең авылның каю тарафындарак буладыр? — дия сорадым. Аны тәгъриф итеп җавап бирделәр. Ничек булса да тагын берәр сүз ачар өчен:

---

[7] *Зиядә* — тулы.

[1] *Һәмишә* — һаман.

[2] *Дәрхаль* — шунда ук.

[3] *Өртенү* — йөзенә нәрсә дә булса каплау.

[4] *Шашыргач* — нишләргә белмәгәч.

— Чегәннәрне сәер итеп торасыз икән,— дидем.
— Әйе шул, җиләктән кайтып киләмез,— диделәр.
— Җиләкләр бигрәк гүзәл пешкән икән,— дидем. Шаркылдашып, көлешәрәк:
— Әйе шул, чегәннәрне карап торамыз,— диделәр.
Хатын вә кызлар бик нечкә калепле вә үткен зиһенле буладыр. Анларның бер урта дәрәҗәдәгесе дә җавап турысында үткен зиһенле бер ирне туктата аладыр. Хөласа (кыскасы), ничек булса да аннан-моннан сүзләр ачып көлеп, көлдереп беркадәр сөйләштек. Кызларның һәр икесенең әдәп вә тәрбияләре бик камил иде. Әдәпкә мөхалиф[1] бер сүз сөйләмәдем. Ләкин андаен бер генә сүз качырсам, сөйләшүне ташлап, дәрхаль юлларына китәчәкләрене хәлләреннән катгыян[2] аңладым. Кызлардан бересенең буе-төсе күңелемә бик ошады. Әгәр бездә дә Америка гадәтләре булса, минем илә тәәһһөл итүене (өйләнүне) бу кызга шундук тәкълиф итеп, күпер өстендә туй ясаган булыр идем. Кызлар да миңа илтифат итмәделәр түгел, үземнең әдәпле вә намуслы, ләкин дәртле егет идекемне беркадәр аңлаттым. Үзләренең исемнәрене сорасам да сөйләмәделәр. Аталарының исемнәрене сорагач, тагын көлешебрәк, берсе:
— Минем атам — Сәйфулла, аның атасы — Галиулла,— дисә дә, икенчесе дәрхаль:
— Юк, юк, аңарга ышанма, ул уйнап әйтәдер, минем атам — Алтынбай, аның атасы — Биктимер,— диде. Күрәмсең кызларны, ничек итеп кешене шаярталар. Аңлашылды ки, аталарының исемнәрен дә тугыры сөйләмәделәр. Нә чара! Кем кызлары икәнлекләрене бик беләсем килсә дә, мөмкин булмады. Мин анлар илә сөйләшә торгач, байтак вакыт үтеп киткән булырга кирәк. Минем юлдашым атларны хәзерләп юлга чыгарып куйган, әйдә китәбез дип, миңа да кычкырды. Кем белер, вакыт күп үттеме, юкса юлдашым, минем кызлар илә сөйләшүемне көнчеләп, махсус мине анлардан аермак өчен ашыктымы? Юлдашым чакыргач, китмәенчә ошамады. Кызларга карап: — Сагъ улыңыз, туташлар! — дия китмәгә башлагач, анлар да: — Алла сәламәтлек бирсен,— дип калдылар. Ләкин

---

[1] *Мөхалиф* — ярамаган.
[2] *Катгыян* — анык.

яннарыннан аерылып киткән вакытта, минем күңелем төшкән туташ күз очы илә миңа шулкадәр мәгънәле бер бакты ки, тәэсире халән[1] күңелемнән киткәне юктыр.

Юлдашым илә берлектә арбага утырып киткәч, әйләнеп артыма карасам, кызлар да күпер өстеннән чыгып авылга таба кайтмага башлаганнар. Без киткәч, чегәннәрдәнме курыктылар, юкса калепләребездәге мәхәббәт микънатислары[2] бер-берсене чикмәгәме башладылар, моны бер Алла белер. Авылга җиткәч, кардәшемезнең йортына кереп күрешеп, чәй эчмәгә башладык. Һәрберәсе сөенешеп, куанышып сөйләшәләр иде.

Ләкин минем гәүдәм болар арасында булса да, калебем икенче җирдә улдыгыннан, сүзләрене юньлебашлы аңыша алмаенча, гадәтен төш күргән кебек утырдым. Бөтен зиһенем вә фикерем илә шул кызның кем кызы икәнен ничек итеп вә кайдан өйрәнәем дә тагын бер күреп сөйләшәем дия хыял итмәктә идем. Төн үтте, көн булды. Төн буенча төшемә күпер өсте илә әрәмә буйлары керде. Хөласа[3], шул яшемә җитеп башыма мондаен хәл килгәне юк иде. Гаҗәп шикелле, күңелем әллә нишләп шул кызга бәгланып калды. Әгәр солдатка китү ихтималым булмаса, ничек булса да бу кызны табып, күңелене үземә җәлеп итеп, ата вә анасының рөхсәтләрене алырга тырышкан булыр идем. Дөньядагы һәрнәрсә бер сәбәпкә бәгланмыш кебек күренсә дә, тәкъдир яхут тәсадеф[4] дигән нәрсәнең дә әсәрене[5] инкяр итәргә ярамый икән. Тутабызда кунак булып, ике кич кундык. Сахраларга чыгып йөрдек. Берничә кардәш-кабиләгә зыяфәтләргә[6] бардык. Күпер өстендә сөйләшкән кыз күңелдән китмәсә дә, аны тагын бер күрергә өмитләр азалмага[7] башлаган иде. Бер көн, өйлә намазыннан кайтып аш ашагач, бераз истирахәт итмәк өчен бакчага чыккан идем. Агач астында

---

[1] *Халән* — хәзер дә.
[2] *Микънатис* — магнит.
[3] *Хөласа* — кыскасы.
[4] *Тәкъдир яхут тәсадеф* — язмыш яки туры килү.
[5] *Әсәрене* — йогынтысын.
[6] *Зыяфәтләргә* — кунакка.
[7] *Азалмага* — кими.

күләгәдә утырып торган вакытта, койма аркылы күрше ишегалдыннан сөйләшкән тавышлар ишетелде. Тавышның нечкәлегенә вә татлылыгына караганда, хатын-кызлар тавышы булырга охшайдыр иде. Күңелем хәрәкәткә килде. Ихтыярсыз урынымнан тордым, акрын гына койма янына барып бер ярыктан карадым, әман, Ярабби[1]! Өнемме дияем яки күземә хыялмы күренәдер, күпер өстендә күрешеп, минем илә сөйләшкән кыз ишегалдында киртәгә киезләр элеп йөридер. Йорт эченең аз гына икенче бер җәһәтендә[2] утынлыкта бер ир бала балта илә бернәрсәләр ясап торадыр. Яхшылабрак карасам, бу ир бала әүвәлге көн кызлар илә бергә җиләктән кайткан углан булып, төсенә-кыяфәтенә караганда, кызның кардәше булырга биңзидер (охшыйдыр) иде. Гыйшкының уты күңелемә тоташкан кыз үзебезнең күршедә үк икән. Моны белгәннән соң, әллә ничә төрле хәйләләр корып, кызның берадәрен[3] күрдем вә аның аркылы кызга хәбәр бирдем. Бик күп ялварганнан соң, кич белән ай яктысында койма аркылы кызның үзе белән дә сөйләшмәк нигъмәтенә наил булдым[4]. Кызның да миндә күңеле юк түгел икән. Тутамызда тагын ике-өч кич калып, һәр көн кич белән бу кыз илә койма аркылы сөйләшә торган булдык. Мин үзем бик саф калепле булганым шикелле, аны да шулай таптым. Гәрчә танышуыбыз яңа булса да, бер-беребезгә калепләребезне ачып, серләребезне бәян иттек[5]. Әгәр солдатка китмәсәм, үзене алыр өчен, һәртөрле фидакярлекләрне ихтыяр итәргә[6] хәзер икәнлегемне бәян иткәч:

— Илтифатыңа чиксез рәхмәт, әгәр син солдатка китә калсаң, мин сине көтәргә дә разыймын, тик вәгъдә бир дә сүзеңдә тор,— диде. Кайда ул вәгъдә бирмәгән!

— Ямин[7] итеп вәгъдә бирәмен, әгәр син дә вәгъдә биреп сүзеңдә торсаң, яңадан җан багышлап, мине тергезү дәрәҗәсендә сөендерер идең,— дидем. Ул да

---

[1] *Әман, Ярабби!* — коткар, и Аллам!

[2] *Җәһәтендә* — ягында.

[3] *Берадәрен* — ир туганын (энесен).

[4] *Наил булу* — ирешү.

[5] *Бәян итү* — аңлату, сөйләү.

[6] *Фидакярлек ихтыяр итү* — батырлык эшләү.

[7] *Ямин* — ант.

кабул итте. Мин солдаттан кайтканчага кадәр, башка кешегә бармаска ямин итте. Мин дәхи[1] аннан башканы алмаска сүз бирдем.

Ләкин Ходаның тәкъдире буенча, мин шул сәнә[2] солдатка алындым. Вә хезмәттә өч ел ярым йөреп кайттым. Минем кызга мәхәббәтем һәмишә бик камил булып вәгъдәмдә садыйк[3] исәм дә, кызның бу кадәр вакытлар мине көтеп сүзендә тора алуына өмитем аз иде. Солдаттан өйгә кайтып, ата-ана, кардәш-ыруг илә күрешкәч тә, әүвәлге бер дустымнан тизрәк шул кызны сораштым. Бик күп җирләрдән яучылар килеп, ата-анасы бирергә теләсәләр дә, белмим, нидәндер кыз һичберсенә разый булмады. Бу кадәр каршы торуы хакында төрле-төрле сүзләр дә чыкты диде. Моны ишеткәч, өстемнән бер авыр йөк төшкән кебек булып рәхәтләнеп киттем. Күкрәгемне киереп, киң бер сулу алып, Аллаһы Тәгалә хәзрәтенә тәшәккерләр иттем[4]. Арасы күп тә үтмәде, туебыз булды, кызның ни өчен кияүгә бармаенча торуының сәбәбене һәр кеше аңлады. Халык безне сөйләгән саен, безнең бер-беребезгә мәхәббәтебез артты. Шул кыз илә гаять бәхтияр[5] булып гомер сөрдек. Бөтен гомеребез буенча, бер-беребезгә хәтер калдырышу түгел, каты сүз дә әйтешмәдек. Алла рәхмәт итсен үзенә, менә вафат булган әбиегез шул иде.

Сүз шунда җиткәч, Салих бабай кесәсене кармаламага башлады, якында «Һаттечү!» ишетеләчәген аңлап, бераз читкәрәк киттек. Салих бабай:

— Хикәятем шунда бетте инде, яраттыгызмы? — диде. Иптәшем Салих бабайга:

— Хикәятең ярарлык булды, ләкин шул кыз белән койма аркылы мәхәббәт иткән вакытта ниләр сөйләшкәнегезне азрак бәян иткән булсаң, хикәятең тагын тәмлерәк булыр иде,— дигәч, Салих бабай аңа шул рәвештә җавап бирде:

— Углым, сез әле яшьсегез, яшьләр алдында азрак сакланып сөйләргә тиеш буладыр. Мин тик үз башым-

---

[1] *Дәхи* — тагын бер тапкыр.
[2] *Сәнә* — ел.
[3] *Садыйк* — туры.
[4] *Тәшәккер итү* — яхшылыкка каршы рәхмәт белдерү.
[5] *Бәхтияр* — бәхетле.

нан үткән бер вакыйганы бәян иттем. Әгәр гыйшык хәлләрене бик нечкәләп беләсегез килсә, Жорж Санд илә Эмиль Золя вә Александр Дюмаларның романнарын укыгыз.

Салих бабайның сүзе буенча, бераз зур үскәч, Александр Дюманың вә Эмиль Золяның хикәятләрене укырга башладым. Филхакыйкать[1], Салих бабайның сүзе туры чыкты. Бу француз мөхәррирләренең романнары бик татлы икән. Форсат булганда, бәгъзеләрен үз телебезгә дә тәрҗемә итәргә ниятем юк түгелдер.

Имтиханның нәдән гыйбарәт икәнен белмәгән Салих бабай Александр Дюмалар вә Эмиль Золяларны кайдан белсен дип, игътиразмы итмәкче (бәхәсләшмәкче) буласыз?

Белде исә белер, лима ла язуҗ!.. (Ник мөмкин булмасын!)

1897

Сораулар һәм биремнәр.

1. Хикәядә автор уздырган төп фикерне әйтеп бирегез.
2. Хикәяне төп вакыйга һәм ярдәмче вакыйга-өлешләргә бүлегез. Хикәяләүдә лирик чигенешләр бармы?
3. Салих бабайга характеристика бирегез. Имтиханның ни икәнен белмәгән ялчы картның Жорж Санд, Эмиль Золя кебек язучыларны белүе сезне ышандырамы? Бу деталь сезнең өчен мөһимме?
4. «Дөньядагы һәрнәрсә бер сәбәпкә бәйле кебек күренсә дә, язмыш яки туры килү дигән нәрсәнең дә йогынтысын кире кагарга ярамый икән» дигән җөмләне сез ничек аңладыгыз?
5. Салих бабай төп вакыйганы сөйләүне «Яз вакыты иде» дип башлый. Ә кызлар аңар «җиләктән кайтабыз» шикеллерәк әйтәләр. Кызлар, чыннан да, җиләктән кайтып килсәләр, моның билгеләре булыр идеме? (Әйтик, Салих алар кулында савытлар яки тырыслар күрә һ. б.) Сезнеңчә, автор нигә болай язган?
6. Фатих Кәриминең хикәяләү теле бүгенге язучылар теленнән аерыламы? Сезгә таныш булмаган нинди сүзләр отып калдыгыз?
7. Фатих Кәримине ни өчен мәгърифәтче язучы дип атыйбыз?
8. Мәгърифәтче язучылардан тагын кемнәрне беләсез, аларның нинди әсәрләрен укыганыгыз бар?

---

[1] *Филхакыйкать* — чыннан да.

9. Мәгърифәтчелек әдәбиятына нинди төп сыйфат-билгеләр хас?
10. «Салих бабайның өйләнүе» дигән темага сочинение языгыз.

Күңел матурлыгы

Бу хикәя, барыннан да элек, безнең бабаларыбызның рухи дөньясын, әхлак сыйфатларын ачып бирүе белән, ул вакытларда яшьләр арасындагы мөнәсәбәтләрне, кайбер гореф-гадәтләрне сурәтләве белән әһәмиятле.

Вакыйгалар үзәгендә Салих карт образы тора. Без аны бүгенге, ягъни сүз барган вакыттагы хәлендә хикәяләүче «мин» сөйләве буенча күзаллыйбыз. Сөйләүче,— күрәсең, шәкерт,— аның хакында шактый уңай фикер тудыра. Шул ук вакытта, инде Салих бабай үзе сөйләгән вакыйга буенча, без аның яшь чагындагы холык-фигыле турында да беләбез. Ике чорда да, ягъни яшь егет чагында да, инде олыгайгач та, Салих картның менәзенә (характерына) уртак сыйфатлар хас. Болар — намуслылык, киң күңеллелек һәм мөлаемлык, кешегә хөрмәт белән карау. Әнә ул хәзер дә, инде тормышның ачысын-төчесен татыган өлкән яштәге кеше, малайларга үз тиңе итеп карый, аларны кыяр белән сыйлый, иң мөһиме, балаларның рухын һәм зиһенен баета торган хикәятләр, әкиятләр сөйли. Икенче сүзләр белән әйткәндә, ул аларны тәрбияли. Шуның белән бергә карт тел-теш тидермәслек идеал кеше итеп тә бирелмәгән. Аның тыңлаучыларына ошамый торган бер шөгыле дә бар: ул борынына тәмәке сала («чигә»), нәтиҗәдә, төчкереп-төкереп, аларга шактый ук мәшәкать тудыра. Ахыр чиктә, язучы бабайның бу кимчелеген сурәтләү ярдәмендә дә укучының күңеленә мөһим фикерне сеңдерә: чир китә — гадәт кала; яшьлектә өйрәнгән гадәт, яхшымы ул, начармы, кешене гомере буе озата бара. Шуңа да яшьлегеңдә начар гадәтләргә өйрәнмәскә тырыш!

Матур әдәбият элек-электән кешене тәртипле, яхшы күңелле итеп тәрбияләүне күздә тоткан. «Әдәбият» сүзенең нигезендә дә бит «әдәп» сүзе ята. Әдәбият укучы күңеленә матурлык һәм миһербанлык сеңдерә. XIX йөзнең ахырында, XX йөз башында иҗат иткән татар язучылары әдәбиятның бу сыйфат-хасиятенә гаять зур әһәмият биргәннәр. Төзек холыклы, күркәм гадәтле, аңлы һәм укымышлы кешеләр тәрбияләүне төп максат итеп санаганнар. Шуңа күрә дә әсәрләренең үзәгенә

мәгърифәтле һәм зыялы кеше образларын куеп сурәтләгәннәр. Бу образларны уңай сыйфатлар белән баетканнар. Фатих Кәримидәге Салих бабай да — күп укыган (хәтта ышануы да кыенрак: шәкертләр белмәгән француз язучылары әсәрләрен дә укыган!), асылда, тәртипле, акыллы һәм миһербанлы кеше. Аның очраклы гына танышкан, соңыннан берсенә күңеле төшкән кызларга мөнәсәбәтен генә карагыз. Никадәр сафлык, хөрмәт һәм хатын-кызны изгеләштерү бар аңарда!

Фатих Кәрими, Ризаэддин Фәхреддин, Закир Һади, Фатих Халиди кебек язучылар — мәгърифәткә зур өмет баглаган иҗатчылар, фикер ияләре. Алар мәгърифәт ярдәмендә кешеләрнең холкын төзәтеп була, нәтиҗәдә һәркем бәхетле яши торган җәмгыять төзеп була дип ышанганнар, шул ышанычны әсәрләрендә дә төп фикер итеп үткәрәләр. Шуңа күрә дә аларны **мәгърифәтче язучылар** дип, ә алар тудырган әдәбиятны **мәгърифәтчелек әдәбияты** дип атыйлар.

Мирхәйдәр Фәйзи
(1891—1928)

Татарларда «Галиябану» драмасын, аның авторын белмәгән кеше бик сирәктер. Иске гадәт-йолалар белән бәрелешкә кергән саф мәхәббәт тарихы... Олы мәхәббәтнең фаҗига белән тәмамлануы... Бу хисне зурлауда драма иң күренекле әсәрләрнең берсе дип бәяләнә. Аны язган Мирхәйдәр Фәйзи — үрнәк пьесалар авторы, ягъни классик драматург.

Мирхәйдәр Мостафа улы Фәйзи (Фәйзуллин) 1891 елның 1 ноябрендә Орск шәһәре (Оренбург өлкәсе) янындагы Күкшел авылында туа. Әтисе бу чорда миллионер Хөсәеновлар утарында идарәче (управляющий) булып хезмәт иткән. Бераздан ул, Орск шәһәрендә йорт салып, гаиләсен шунда күчерә.

Мирхәйдәр ике ел Орск мәдрәсәсендә, ә бераздан Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсендә укый. Укуын тәмамларга сәламәтлеге мөмкинлек бирми. Йөрәк авырулы яшүсмер мәдрәсәдән авылга китә, ләкин үзлегеннән укуын дәвам итә, заманы өчен тирән белемле зыялы булып җитлегә.

Мирхәйдәрнең әдәби иҗатка сәләте бик иртә уяна. «Бу кыш мин мөхәррир булырга һәвәсләнә башладым,— дип яза ул көндәлек дәфтәренә 1905 елны.— «Татар туе» исемле бер вакыйгадан алып язган пьесамны җиңгиләргә укып, аларны хәйран да калдырдым. Бәетләр, шигырьләр язуга да бирелеп киттем». Ә бит аңар бу вакытта нибары 14 яшь була. Ә инде 18 яшендә, русчадан файдаланып— «Ике Хәсән» исемле пьеса, 20 яшендә «Бизәнү», «Яшьләр алдатмыйлар» дигән комедияләрен яза. Шул ук елларда бер-бер артлы «Минем шигырьләрем» (1912 ел), «Яшь күңел» (1913) исемле шигырь җыентыкларын бастырып чыгара.

Мирхәйдәр Фәйзи йомшак табигатьле, итагатьле, миһербанлы, романтик рухлы булган, хыялланырга яраткан. Табигатьне, авылны сөйгән, гомере буе авыл кешеләрен хөрмәт иткән. Иң мөһиме, язучы авыл кешеләрен чын мәгънәсендә кешелекле итеп, эшчән, уңган, намуслы, җыр һәм музыкага сәләтле итеп сурәтли. Аның «Галиябану», «Асылъяр», «Ак калфак», «Кызыл йолдыз» кебек иң уңышлы әсәрләрендә крестьян егетләре һәм кызларындагы шул уңай сыйфатлар алга чыгарылып, хәтта беркадәр куертып күрсәтелә. Явызлык, гаделсезлек белән килешә алмаган язучы боларның җир йөзендә әле барлыгын, тормышта еш кына фаҗига тудыруын күргән. Әсәрләре белән ул аларны каһәрли, кире кага, укучыда шул сыйфатларга нәфрәт тәрбияли.

ГАЛИЯБАНУ

(кыскартып алынды)

Драма, дүрт пәрдәдә

ВАКЫЙГАНЫҢ КЕШЕЛӘРЕ:

Бәдри — хәлле генә кеше. 50 дә.
Галимәбану — хатыны. 40 та.
Галиябану — кызлары. Бик матур кыз. 17 дә.
Садретдин — уллары. 8 дә.
Хәлил — яшьләй ата-анасыннан аерылган. Урта хәлле матур егет. 21 дә.
Исмәгыйль — күп җир биләүче бай егет. 25 тә.
Бәдига — яучы булу белән аты чыккан карчык. 65 тә.
Сибгать, Хәмзә — 18—23 ләр арасындагы авыл егетләре.
Старшина.
Кешеләр (ике).

Вакыйга Оренбург ягы авылларының берсендә бара.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Уң якта — бер ишек, түрдә тыкрыкка караган — бер, сул якта бакчага караган ике тәрәзә. Бәдринең ишегалды як өе. Кич.

Пәрдә күтәрелгәндә, урамнан «Галиябану» көенә гармун белән җырлап, сызгырып, куллар чабып үткән тавыш ишетелә.

Галиябану, чигеп яткан эше кулында көенчә, өстәл янында тыңлап утыра.

Жыр:

Бакчада гөлләр ал икән,
Гөлдә былбыл бар икән;
Кашы кара, буе зифа,
Галиябану, сылуым-иркәм,
Кемгә насыйп яр икән?

Тавыш туктый.

Галиябану. Ай, шушы көй, өзә бит минем үзәгемне. Беркөн кайдан, күкрәгемнең кайсы җиреннән алып кына җырладым икән соң мин бу көйне? Инде менә үз исемемне кушып җырлый башладылар. Мин аны үземнең сөйгәнем өчен генә җырлаган идем, ул каршымда булган вакытта гына җырлый алган идем бит... *(Торып.)* Шушы көйне, шундый җырларны никадәр тыңласам да туя алмыйм, бигрәк тә гармунны ул уйнаса. Әтиләрдән курыкмасам, кешедән оялмасам, тәрәзә төбемдә җырлатып төн буе утырыр идем. *(Тәрәзәгә бара башлап.)* Киттеләр бугай. Әти өйдә чакта, күп тормаганнары яхшы. *(Тәрәзәнең пәрдәсен ачып карый.)*

Шунда ук гармун белән җырлап җибәрәләр.

Тәрәзәдән карыйсың,
Карап кемне таныйсың?
Карап күзең талдырганчы,
Галиябану, сылуым-иркәм,
Ник чакырып алмыйсың?
Бөдрә, бөдрә, бөдрәсен,
Бөдрә чәчең көйдерәсең...

Галиябану *(беренче җыр башлангач та капыл чигенеп китеп тыңлап тора да, икенче җыр башлангач)*. Хәерсезләр икән. Тизрәк җибәрергә кирәк. Әти кирәкне бирер... *(Тиз генә барып, лампаны басып күтәрә.)*

Уенчылар җырның яртысында шып туктыйлар.

Киттеләр. Юлыгызга фәрештәләр гөл сипсен! *(Эшен алып утыра.)*

Еракта гына егетләрнең җырлап киткәннәре ишетелә.

Без урамнан үтәрбез,
Җырлый-җырлый сиздереп,
Йокың килсә ятып йокла,
Галиябану, сылуым-иркәм,
Уятырбыз сызгырып...

Шулвакыт Садрый бакча як тәрәзәдән башын тыга.

Садрый. Апа, Фәрханә апа сине монда гына чыксын әле ди, баскычка. *(Китә.)*

Галиябану. Ярый. Җиләккә барырга дидер инде. *(Эшен өстәлдәге кечкенә сандыкның астына куеп чыгып китә.)*

Күп тормый Бәдри керә.

Бәдри *(куанып)*. Карасана, безгә бит, безгә җырлыйлар. Бөтенләй төбәп җырлыйлар. Галиябану сылуым-иркәм, диме, аппагым, диме?.. *(Башын боргалап.)* Ай-яй, усаллар, көй дә чыгарып өлгерделәр.

Бер чиләк су күтәреп, Галимә керә.

Ишеттеңме, хатын?

Галимә. Нәрсәне?

Бәдри. Яңа гына урамнан җырлап үткәннәрен!

Галимә. Ишетмәгән кайда. Шушы безнең тыкрыктан гына үттеләр бит. Яңа көй дигән булалар ич. Әллә безне ачуландырмас өчен юри әйтәләр. *(Суын сәкегә утырта.)*

Бәдри. Яңалыкка яңа инде ул. Кичә Бортас базарында да ишеттем мин аны.

Галимә. Бигрәк безгә төбәп җырлаган кебек инде. Әллә бөтенләй Галиябануга атап чыгарганнар?

Бәдри. Кичә Бортас базарында Камали да әйтә: Бәдри абзый, ди, бу, ди, сезгә, ди, үзегезгә төбәп җырлаган кебек буладыр инде, ди. Төбәп җырласалар да, ярарлык бит, ди. Көлә үзе, бәдбәхет.

Галимә. Халыкка җитә кала инде ул. Шулай ук урам көчекләренә дә сыныкка сылтау табылып кына тора. Җырларын да бит сайлап кына җырлыйлар.

Бәдри. Тимә, хатын, җырлый бирсеннәр. Безгә чыккан көйме, түгелме, йөри бирсеннәр. *(Сәкегә утыра.)*

Галимә. Шулай да инде килешеп бетми. Уңайсыз тоела. Син үзең дә азрак катырак тормыйсың. Синең нindилегеңне белгәнгә, алар ачыктан-ачык җырлый

бирәләр. Азрак катырак була белсәң, алай ук кыйланмаслар иде. *(Мич тирәсендә маташа.)*

Бәдри. Бар, чыгып бәйләнеп кара син! Каш төзәтәм дип, күз чыгарганыңны күрерсең. «Яңа пешкән алма кебек син, Галиябанулар урынына «авызларың алаптай, тешкәйләрең тарактай» дип җырлаганнарын ишетәсең киләмени?.. Әле ничек кенә дип җибәрәләр. Кашың кыйгач, битең кояш, ди бит. *(Куанып көлә.)*

Галимә. Ул кадәресенә шөкер инде шөкерлеккә. Кызыбыз әле дә авылда бер иде. Бу көйләре, бер уйлаганда, нур өстенә нур дигән кебегрәк булды инде. Ходай инде үзе яман ниятләрдән сакласын тагын.

Бәдри. Аргы якның яланы, ди, әче була баланы, ди, ай, кояшым, кыйгач кашым, тилмертмә бу баланы, ди... Ә, хатын, безнең Галиябануның кашы кыйгач ук түгелдер бит?

Галимә. Кыйгач, кап-кара сызылып киткән кыйгач каш.

Бәдри *(куанып куеп)*. Кара син дуңгызларны. Туганнан бирле алдында торган атасы белми, ә алар барын да җентекләп беткәннәр. *(Көлә.)*

Галимә. Күз өстендә каш булып тора инде. Ходай уңайлы урынын насыйп итсен...

Бәдри. Инде егетләр Бәдриеңә бер чакрымнан сәлам бирә башларлар. *(Шәбәеп.)* Шундый бер кыз үстереп биргәч, ни... Ә... ни әйткәндәй, хатын, син абайладыңмы? Мин бу җырлап үткән кешене Исмәгыйль түгел микән диебрәк калдым.

Галимә. Юк ла.

Бәдри. Аны беләсе иде. Яшьләр алар күңелләренең сәламен, шулай читтән әйләндереп китереп, осталык белән генә җиткерә торган.

Галимә. Ай-һай, булмас ла. Ул безнең тирәдә чуалыр микән?

Бәдри. Болай җырлап үтү кадәресенә чуалуныңфәләннең катышы юк та инде аның, шулай да бит, белмәссең, чәчләре чәчкә бәйләнгән булса, Галиябану белән дуслашып йөрүләре дә мөмкин шул.

Галимә. Бик кенә матур эш булыр иде дә бит, белмим шул. Ходай шундый рәхмәтен багышлаган булса, дүрт кул белән бирер идек инде. Үзе черегән бай, үзе яшь...

Бәдри. Аннан да һәйбәт урынны күтәргә дә ярамый. Белмәссең, Галиябануның матурлыгына кызыкса, алам дисә, аның каршы килер кешесе юк. *(Торып, Галимәгәрәк килеп.)* Шунда да, хатын, өметсез шайтан, мин үзем бу турыда күптән уйлап йөрим йөрүен, син караштыргала әле, араларында вәгъдә-мәгъдә барын белеп булмасмы?! Хәзер инде ул җиткән кыз, артык кысып маташырга да ярамый.

Галимә. Галиябану миннән башкага булачак түгел, дип әйтә икән Исмәгыйль дип, беркөн Гайни сөйләп торган булган иде аны. Мин аңа, сөйлисең тагы язмаганны, дидем дә куйдым. Аның сүзләренең уннан берсе генә дә дөрес булмый торган иде. Шуңа күрә ышанырга уйламадым да мин анда.

Бәдри. Шулай булса, Ходайның теләргә курыккан бер теләкне кабул итүе булыр иде кана... Тукта, без, хатын, Садрыйны җибәреп карыйк, шул төркем эчендә Исмәгыйль бармы, юкмы, белеп кайтсын. Әгәр булса, тикмәгә булмас. Ул алай юкка вакланып йөри торган бала түгел.

Галимә. Йөрмәс дип булмый ла ансын. Яшьләр алар ул турыда бары да бер чыбык белән куаланган. Шунда да мин Садрыйны җибәрим әле. *(Чыга башлап.)* Су буена таба төшеп киткәннәр иде шикелле.

Бәдри. Тукта әле син! Исмәгыйль бар микән дип әйтмә тагын. Соңынтын хәйлә белән генә сөйләтербез.

Галимә. Ничек дим соң?

Бәдри. Син болай диген: шул җыенда Ногман абзыең булса, әтием чакырды, дип алып кил, диген! Тиз кайт, диген. Ногман, билгеле, анда юк, ул күптән түгел генә ике кәҗә салып калага китте.

Галимә чыга.

Бәдри. Ходай кушып башланган гына булсачы. Егет менә дигән. Үзе бай, үзе хуҗа. Дөньяны дер селкетеп тора. Шәйхи бай да аннан соң безнең белән сакланыбрак сөйләшер иде. Фатыйхның да авызы томаланыр иде... Исмәгыйльнең теге халык арасына чыккан сүзе рас булса, ул әйткәнен эшләми калмаска тиеш иде. Ай, Галиябану да йоклап тормаган гына булса... Тукта, бер-бер ишарәсен табып булмасмы? *(Як-ягына каранып, сакланып кына өстәл өсләрен актарына. Чиккән кулъяулыгын табып алып, шатланып.)*

Башланган, башланган, Ходайга шөкер, мөгаен, шуңадыр. Яңа гына чигеп беткән. Җебен дә өзмәгән...

Галимә керә.

Бәдри *(тиз генә яулыкны яшерә дә Галимә икәнне белгәч)*. Хатын, хатын, тиз, монда кил әле. *(Галимә килә башлагач.)* Әй, кара, ишегеңне яхшы яптыңмы? *(Галимә ишекне карап килгәч.)* Эш пешә.

Галимә. Ни бар, ә?

Бәдри. Сөенче! Сөенче! Башланган. Менә Исмәгыйльгә бүләккә эшләп куйган.

Галимә *(карап)*. Ах, хәерсез икән, чынмы? Кай җирдән алдың?

Бәдри. Өстәлдә, менә бу сандыкның астында иде. Таслап салып куйган. Шул әнә, мин аны шунда ук уйладым. Өзелеп-өзелеп әйтә бит ул, бер күрергә интизар булам, Галимәбану, ди...

Галимә. Китче инде, мыскыл итеп маташма әле...

Бәдри. Әй, ялгышам гына ла, Галиябану инде, Галимәбану дип аягына таш бәйләп суга салсаң да әйтмәс. Син минем генә назлы бикәм бит. *(Яулыгыннан тартып куя да кычкырып көлә.)*

Галимә. Чү, тилермә. *(Ишекне ымлый.)*

Бәдри, капылт авызын басып, ишекне тыңлап килә.

Галимә. Тизрәк урынына куй инде! Үзе сизмәсен тагы.

Бәдри. Тукта әле. Тагы берәр нәрсә табып булмасмы? *(Яулыкны урынына куя да эзләнә.)*

Галимә *(килеп)*. Ни булса да, менә бу сандыкның эчендә булыр иде дә, бикле икән шул.

Бәдри. Ишекне сакла, ишекне! Галиябану килеп керсә, икебезне дә тотып чикәләр.

Галимә. Нәрсәләрен урынына куй берүк.

Бәдри. Менә, бу ни? Хат бит. *(Ача.)*

Икәве де бик җентекләп карыйлар.

Бәдри *(кычкырып җибәрә)*. Егетләр хаты.

Галимә *(Бәдринең авызына сузылып)*. Акрын дим!

Бәдри *(хатны кесәсенә тыгып, дәррәү ишеккә әйләнеп карый да)*. Мә әле, син маташтыра алмассыңмы?

Галимә. Кит аннан, мин язу танымыйм ич.

Бәдри. Танымыйм дип, моны укымый калырга ярамый инде. Танымасаң да укы! Көндез булса сиңа

әйтеп тә тормас идем. Беләсең бит кич күземнең язу укый алмаганын.

Галимә. Ут янынарак барып карасаң?

Бәдри. Әйтеп торам лабаса сиңа, ут яктысында укый алмыйм дип. Мә, тизрәк кара!

Галимә. Ай Аллам, белмәгәч, ничек итеп укыр ди икән.

Бәдри. Мин өйрәтеп торырмын. Мә, шуннан иң ахыргы сүзен генә кара! Башкасы кирәкми дә.

Галимә *(алып карап)*. Монда бер «әлеп» бар, атасы!

Бәдри. Ә-ә-ә, таяк кебекме? Әнә инде шуның янында бер тырма теше кебеге дә юкмы?

Галимә. Андый юк. Таяктан соң чалгы кебек кәкрәебрәк киткән нәрсә бар.

Бәдри. Анысы ни булды тагы?.. Хуш, тагы, тагы?.. Шул чалгы янында саплы чукмар кебек нәрсә юкмы?

Галимә. Чукмар кебек түгел. Балык аулый торган җәтмә кебегрәк бер нәрсә бар.

Бәдри. Әһә, әһә, инде бер табагач кебеге дә бармы?

Галимә. Бар... *(Куанып китеп.)* Азагында ләм, атасы, ләм!

Бәдри. Ләм? Кармак кебекме?

Галимә. Әйе, әйе, ансын мин үзем дә таныйм.

Бәдри *(бик куанып)*. Исмәгыйль инде, Исмәгыйль. Аллага шөкер, Аллага шөкер!

Галимә. Мә, алган җиреңә куй тизрәк!

Бәдри. Менә син, бөтен эшне пешереп куйган Галиябану... *(Хатны куя.)* И Ходаем, һәр икесенә тигез мәхәббәт бир!

Галимә. Куаныч, шатлык белән гомер итәргә яз.

Бәдри. Күркәм итеп тәмамларга насыйп булсын инде. Әйтәм шул бик тилмереп җырлыйлар иде. «Галиябану, гомерлек яр булсана!» ди бит. Тикмәгә түгел икән ул. Мин аны шунда ук уйладым. Исмәгыйль башкалар катында алагайга йөрмәс дип. *(Куанып көлеп куя.)*

Галимә. Ходай күктән көткәнне җирдән бирде.

Бәдри. Галиябануны әйтәм, җитез соң, вәгъдәгә билге итеп бирергә яулыгын да әзерләп куйган, сиздерми генә.

Галимә. Андыйларны төнлә утырып кына эшлисең инде аны.

Аяк тавышы ишетелә.

Берәү керә, атасы!

Бәдри җәһәт кенә өстәл яныннан китә. Садрый керә.

Садрый. Әти, Ногман абый анда юк. Калага киткән дигән булалар.

Бәдри. Ә, шулай микәнни? Кем әйтте алай дип?

Садрый. Шәми әйтә.

Галимә. Кайсы Шәми?

Садрый. Шәми булгач Шәми инде. Теге... Яр буендагы... Шәмсеттиннәр бар бит.

Бәдри. Вакбасар Ганинең Шәмие була инде. Алар нишләп утыра соң анда?

Садрый. Хәлил абый гармун уйный. Сибгать абый бии. Кызык. Мин әле тизрәк кайт дигәч кенә кайттым.

Бәдри. Тагы нишлиләр?

Садрый. Нишләмиләр дә.

Галимә. Җырлыйлар дамы?

Садрый. Юк, җырламыйлар.

Бәдри. Өч-дүрт кенә кеше ни кызык табып утыралар икән?

Садрый. Анда күп кешеләр. Вәли абый, Төхби, Хәмзә, Йосыфлар да бар.

Галимә. Йә, йә?

Бәдри *(аны тотып туктатып, пошынып)*. Шуннан башкаларын танымадыңмы?

Садрый. Юк.

Бәдри белән Галимә, пошынып, бер-беренә карашалар.

Садрый. Әни, йокым килә.

Галимә. Йокың килсә, апаң урыныңны җәйгәндер. Күргәннәреңне сөйләп бетер, чыгып ятарсың.

Садрый. Бетте инде. *(Чыга башлый.)*

Бәдри. Тукта, тукта әле!.. Ху-уш, Вәли биеп маташкан буламыни?

Садрый. Юк дим ич инде.

Бәдри. Сиңа бер сүз дә әйтмәделәр дәме?

Садрый. Юк, юк, юк!

Галимә. Ногманны кем чакырды дип тә әйтмәгәннәр икән.

Садрый. Исмай әйтә, апаең чакырдымы әллә, ди.

Бәдри *(куанып китеп)*. Исмәгыйльме?

Галимә Бәдригә төртә.

Садрый. Әйе, миңа: «Нихәл, каениш?» — дигән була.

Тегеләр, куанып, бер-берсенә төртешәләр.

Галимә. Кара син хәерсезне.

Бәдри. Син нәрсә диден соң аңа?

Садрый. Сыртыңа ишкән каеш дип йөгереп киттем. Йокым килә инде. *(Чыгып китә.)*

Бәдри. Инде кирәгең дә бетте. *(Кулларын уып, бик куанып.)* Йә, күрдеңме, карчык?

Галимә. И, шулай итеп кыйлануыңны бер яратмыйм. Кырык яшендәге кеше карчык була микән?

Бәдри *(көлеп)*. Йә, хатын, алайса, хатын. Кыз бирергә йөрисең, карчык булмый, әллә кая бара алмассың инде... Менә син, эш пеште бит, ә? Егет тә сөя, кыз да сөя, без ике баштан дүрт куллап риза. Туй итәсе генә калды.

Галимә. Исмәгыйль явызны әйтәм, усаллыгын, Садрыйның безгә кайтып сайрыйсын белеп каениш диюен.

Бәдри *(куанып)*. Әйтмә дә. *(Йөткереп.)* Һем, каениш дип әйтә ди, ә?.. Миңа бабай ди инде ул, сиңа әби ди. *(Куанып көлеп җибәреп.)* Яман түгел бит, хатын, ә? Нибуч, әби булырсың. Туй! Туй!

Галимә. Туй димәктән, быел безнең нибарысы алты гына каз бар. Тагы азрак сатып алырбыз микән соң? Туеңа да, кияү сыйларыңа да булгач.

Бәдри. Алырбыз инде, алырбыз! Иртәгә үк калага китәргә кирәк. Бер солтанатрак чалбар да алып тектерми хәл юк. Ыштаннан гына килешми. Катышкан кешең бай булгач, сиңа да азрак кешечә кыйланмый туры килми.

Галимә. Шунда берочтан гына Садрыйга да камзуллык алырсың. Туйда әллә ни беленмәсә дә, җизнәсен йөрткән чакта күңелсез булыр. Аннан миңа да кодагыйлар алдында кияргә йонмы, сатинмы, бер күлмәк ясамый килешмәс.

Бәдри. Шундый вак-төякне алданрак хәзерләп торырга кирәк, бер егерме-утыз потлап бодай салып, иртәрәк китим... Ә аннары бу мунчасын да тиз генә бетереп алырга кирәк. Иртәгә иртүк, насыйп булса, Габбас картны күреп әйтергә оныттырма әле. Идәнгә үзебездәге такталар да ярар, ләүкәлек, сәкелек яңа такта алырбыз дим.

Галимә. Йә, әйдә, без моннан чыгыйк инде. Галия ятарга көтеп йөридер. [...]

Бу вакыт йомшак кына сызгырган тавыш ишетелә. Картлар бер-берсенә карашалар.

Бәдри. Хатын, берәү сызгыра бит.

Галимә. Мин дә шулай ишеттем.

Икесе де торып, ишеккәрәк авышып, тыңлап торалар. Тагын сызгыру.

Бәдри. Тиз, тиз, хатын! Килде, килде...

Галимә. Исмәгыйль, Исмәгыйль!

Бәдри. Тизрәк Галиябануны җибәр!.. Ят инде диген. Әйдә! Акрын!..

Чыга башлыйлар.

Галимә. И Ходаем, хәерле ит!

Бәдри *(ишектән чыкканда әйләнеп)*. Төкле аягың белән, кияү!

Чыгалар. Күп тормый Галиябану кереп, ишекне элә.

Галиябану. Бөтен авыл йоклап беткән, боларга ни калгандыр төн сакларга. Хәлил килеп сызгырмагае дип куркып беттем. Бердән Фәрханәсе сагыз кебек сыланды. *(Өстәлдән яулыкны алып җебен өзә, очларын төйни-төйни.)* Хәлил тәрәзәгә килми китмәс. Хәер, Исмәгыйль белән сүзгә килгән булсалар кайтып та киткәндер. Ул Исмәгыйль дә бер җан көеге булды миңа. Әтиләргә сүз сала гына күрмәсен инде. Үземне йөдәткәне дә җитәрлек булды. *(Исенә төшереп.)* У, шуның хатын ертып ташлыйм әле. Әтиләр-мазар күрер я. *(Ертып ташлап.)* Хатлары белән, сәламнәре белән, җырлары белән тәмам теңкәмә тиде инде. Үз көемә дип рәхәтләнеп торганда гына, күбесенчә, ул килеп чыга да, чуртан чабакларны качырган кебек, башкаларны читкә кагып, колак итемне кимерергә тотына. Әле бүген дә шуларның артыннан су буена таба төшеп китте. *(Сәкегә урын җәеп маташа.)* Ходай башымны шул кансызга грифтар итмәсен. Унөч яшемнән алып йөрәгемә кереп утырган Хәлилем бар чагында, аның кызыксыз байлыгына бер дә исем китми...

Шул вакытта тагы әче генә сызгыру.

Ай, Хәлилме икән? *(Лампаны сүндерә дә, пәрдәне күтәреп, тәрәзәне ача, тулган ай бүлмәне яктырта. Галиябану тыңлап тора.)*

Тагы сызгыру.

Чыгыйм микән, чыкмыйм микән? *(Башына шәл алып бөркәнә.)* Әниләр дә ятып бетмәгән. *(Ишеккә барып тыңлап килеп.)* Бүген чыкмыйм, булмаса. Әни сизсә, яхшы түгел.

Шулвакыт, матур тавыш белән сузып кына, «Галиябану» көенә жырлаган тавыш ишетелә.

Билемдәге ал билбавым
Тормый кыстырган җирдә;
Үзе чакыра, үзе кача,
Галиябану, сылуым-иркәм,
Чыкмый сызгырган җиргә.

Галиябану *(тәрәзә янына килеп җырлый).*
Йөгереп төштем су буена,
Суда кошлар йөзә дип;
Чыкмыйсың дип үпкәләмә,
Җаныем-бәгърем, сылуым-иркәм,
Куркам кеше сизәр дип. [...]

Хәлил *(тәрәзәгә килә).*
Тәрәзәңне ачып куеп,
Кемгә көлмәк кистең син?
Кара кашым, карлыгачым,
Галиябану, сылуым-иркәм,
Кем бәхетенә үстең син?

Галиябану. Быел, быел дигәнем,
Быелгы ел көйгәнем,
Җаныем-бәгърем, сылуым-иркәм,
Кулларына гармун тоткан
Егет минем сөйгәнем.

Хәлил. Тәрәзә төбем каты бал,
Ашыйсың килсә, ватып ал.
Сөюләрең чыннан булса,
Тәрәзәдән тартып ал.

Галиябану шәле белен капланыбрак кулын бирә. Хәлил бүлмәгә керә. Кулында гармун.

Хәлил *(Галиябануның кулын тоткан көе).*
Читән аша төшкән чакта,
Бүрәнәгә абындым.
Минуты ай, сәгате ел,
Шулкадәрле сагындым.

(Галиябануны сәкегә таба тарта. Үзе утыра. Галиябану утырмый.)

Җанкай, шәлең атсана,
Кил алдыма ятсана.
(Тартып алдына утырта.)
Сөясеңме, сөймисеңме?
Боргаланмый әйтсәнә.

Галиябану. Аягыңдагы итегең
Болгар икән олтаны;
Сине сөйми кемне сөйим,
Син бит егет солтаны.
(Хәлил үбә, Галиябану үпкәли.)

Хәлил. Биек тауга менәмсең,
Болыт килә, күрәмсең;
Үзәкләремне өзәсең,
Елама, Галиям, еламасана,
Бер үпкәннән үлмәссең.

Галиябану *(көлеп җибәрә)*. Алдадым.

Хәлил шатланып китә. Кочаклашып үбешәләр.

Хәлил. Синең тирәдә козгыннар очканы беленмиме?

Галиябану. Ул кадәресен белмим. Су буенда булдыңмы?

Хәлил. Булдым, Исмәгыйль арага керә бит. Мин аның белән чак-чак сүзгә килми йөрим.

Галиябану. Мин мәңге аңа барачак түгелмен. Әтиләр кыстап йөдәтә башласалар, син миңа ярдәм итәрсең бит, Хәлил?

Хәлил. Теләсәң, мин иртәгә үк сиңа яучы җибәрәм.

Галиябану. Яхшылык белән бирмәсәләр, мин ябышып чыгам.

Хәлил *(аякка басып кулын сузып)*. Вәгъдәме?
Җидегән йолдыз бар чагында,
Чулпан йолдыз калкырмы?
Сөйгәне өчен корбан булудан
Яшь егет баш тартырмы?

Галиябану *(кулын биреп)*. Вәгъдә!
Егет әйтә, кыз булсын,
Кызлар әйтә, үз булсын.
Алдым-бирдем шушы булсын,
Вәгъдә өчен сүз булсын.

Хәлил *(Галиябануның кулын кыскан көе)*. Мин иртәгә яучы җибәрәм.

Галиябану. Иртәгә үк җибәр! Иртәгә үк җибәр! Исмәгыйль кысылганчы бер хәл булсын.

Әтәч кычкыра.

Таң әтәче кычкыра,
Аерылуның билгесе.
(Өстәлдән яулыкны алып бирә.)
Бу бүләгем — сине сөеп,
Чын күңелемнән кайнап чыккан
Вәгъдәләрнең билгесе.

Хәлил. Рәхмәт!

Су буенда салкын җил,
Туңам, җанкай, туның бир.
Айлар бата, Чулпан калка,
Чулпан калкып таңны уята,
Китәм, җанкай, кулың бир.

Күрешәләр дә, кочаклашалар да. Хәлил гармунын алып, як-якка карап, сакланып кына чыга.

Хәлил *(кулын сузып)*. Хуш, җаным! Мин тыныч күңел белән китәм!

Галиябану *(күрешеп)*. Юлыңа ак җәймә!

Хәлил гармун уйнап китә. [...]

Пәрдә төшә.

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Бәдринең урам як өе. Сәкедә Галимә каба белән җеп эрләп утыра. Шунда ук, капчыклар тотып, Бәдри керә.

Бәдри. Хатын, менә бу капчыкларны ямыйсы бар икән. Шимбә базарына барганда кирәк булыр. *(Галимәнең алдына китереп ташлый.)*

Галимә. Нигә аны монда ташлыйсың? Бер кулым тигән арада ямармын әле. Чоланга ташлый тор!

Бәдри. Онытма, алайса. *(Алып өйалдына ташлый.)* Син теге көрпәдәге капчыкны да бушатып бирерсең әле... Мине озатканчы, бу эшеңне куеп торсаң да ярар иде.

Галимә. Куеп торсаң дип, минем ни хаҗәтем бар инде. Кирәк-ярагыңны хәзерләп куйдым, капчыкны Гыймади да бушата алыр аны. Галиябануның шәлен тизрәк бәйләтеп алыйм дип маташам. [...]

Бәдри. Ай, хатын, теге яулык нишләгән? Яулык? Очкандыр инде ул күптән.

Галимә. Менә хәзер Галиябану суга китәр, карарбыз.

Бәдри. Инде икеләнеп торасы да юк. Бодайны салып, тизрәк калага китәргә генә. Хәзер базарны арзан диләр диюен. Ясмык күз Хәйрулла өченче көн генә вак бодайны илле тиеннән бирделәр дип торды. Кирәге шундый булгач, алып бармый хәл юк шул... Әле Габбас картны күреп сөйләшеп кайттым, иртәгә килеп ябышмакчы булды. Быелга артыграк чыгым булса да, бай кияүне кара мунчага кертеп булмас бит. *(Куанып көлеп җибәрә.)* Галиябану төс белән дә авылда бер иде, акыл белән дә өстен булып чыкты. Менә дигән егет сайлый белде.

Галимә. Мондыйны инде шәм ягып эзләсәң дә тапмассың. Бай, төскә дә ярыйсы гына, артык бозыклыгы да ишетелми.

Бәдри. Бозыклыгы дип, андый гына гаеп хан кызында да була. «Егет булса — мут булсын, мут булмаса — юк булсын», ди. Кесәң калын булса, йөрәкнең чуарлыгы күренми ул. Алтын күзнең җавын ала диләр бит... Инде, хатын, Галиябану үзенә тиешен үтәде. Без генә йоклап тормыйк... Галиябануны ул үзен алтын-көмешкә чумдырыр. Безгә дә бу турыда... *(Якягына каранып.)* Әйе, үзең беләсең инде... Шулай инде... Әйе, ансын карарбыз әле.

Галимә. Инде Хисамый Әсмасы да акылга килер. Галиябануны көнләп үлеп барадыр иде.

Бәдри. Мин дә шуны әйтәм, Фатыйхларның авызы томаланыр инде дим. *(Эреләнеп кенә бер йөреп килеп, Галимәнең янына гына утыра.)* Хатын, кичә азрак тыңлап торасың калган.

Галимә. Тыңламадым инде. Комачауламыйм дидем. Ир кеше тавышын ишеткәч тә, тиз генә киттем; белдереп куярмын да, китеп калмагае дип курыктым.

Бәдри. Шулай, шулай, бик яхшы иткәнсең. Бу турыда сукыр булып, чукрак булып торырга да ярый. Ярый әле алдан сизенеп калдык. Алданрак хәзерләнеп торырга уңай булды. Бәлки, озакламый яучы да җибәрер. Тукта, мин яулыкны карап керим. *(Чыга.)*

Галимә. Мәһәр котлап ни салырмын икән инде? Ике бөтен тәңкәм бар. Шуңар бер кәшимир яулык

кушып салсам ярар микән? Әллә, ситсы гына булса да, күлмәк кушармын микән? Сатин күлмәк булганда, бик ямьле булыр иде инде булуын, тегене күндереп булмас. Үземә йон күлмәк дигәнгә тиз генә күнде алай да. Күңеле йомшап китте аның да. Бала бит... Ахрысы, кодагыйга бирергә дә бер затлырак нәрсә салмый килешмәс...

Бәдри керә.

Бәдри *(җәһәт керә-керә).* Выжжт җилләр исә тегендә, эрегән! Яулык күптән Исмәгыйльнең кесәсендә ята инде.

Галимә *(куанып).* Бу яшьләрнең усаллыгына да шаккатарсың. Кайдан хәйләләрен табып бетерәләр. Без дә яшь чакта шулай идек микән?

Бәдри. Үткән чакларны искә төшереп, йөрәкне әрнетмә инде, хатын! Ансыз да әле яшьлекне сагынып җибәрдем.

Галимә *(көлеп).* Тилер тагы! Туй дигәч тә дәртләнеп китте.

Бәдри. Вакытында безнең дә кыйланмаган калмады, хатын! Ата-бабадан калган йола булгач инде, яшь чакта шулайрак булганы яхшы. Никадәр сагынсак та, ул бәхет бездән ерак калган...

Галимә *(көлеп).* Читтән генә авыз суын агызып утырырга калдымы?

Бәдри. И чүпрәк баш, син дә мыскыл иткән буласың тагы.

Галимә. Чүпрәк баш булу чүбек баш булудан артык, дип әйткән ди бер хатын иренә.

Бәдри. Кара, кара, нинди җилле кундырды. *(Галимәнең янына килеп утырып, аркасына кулын сала.)*

Галимә *(кыйланып).* Китче, очынма әле, бар инде юлыңа. Сакаллы сабый. *(Бәдринең кулын алып ташлый.)*

Бәдри. Алай итсәң, мин каладан бер яшь хатын алып кайтып та куярмын.

Галимә. Эм-м, ачу китергеч. Син туң күчәнгә кыз бирәм дип торалар иде, ди... Чәй эчеп китәрсең бит? Галиябану самавыр куйгандыр.

Бәдри. Хәзер булса эчәрмен... Мин юкта, хатын, яучы-мазар килсә, мин кайткач җавап бирербез дисәң дә, ризалыгыбызны сиздереп куй!

Галимә *(эшен куеп)*. Кара әле, кем әйткәндәй, үзебезнең ризалыгыбызны Галиябануга да азрак сиздереп куйганда нишләр икән? Аның да алданрак хәзерләнгәне яхшырак булыр иде. Болай ул бездән шүрләп торыр. Аның нәрсәләре бит үзебез кебегрәк кешегә каршы хәзерләнгән. Инде байлар белән аралашасы булгач арттыргаларбыз да.

Бәдри. Кодалар бай булган белән дә бит, безгә шул түшәгебезгә карабрак аяк сузмый булмас, хатын. Галиябануны ул үзе дә киендерер. Безгә бигрәк үзебезне кайгыртырга кирәк. Азрак юнәткәләрбез дә, ярар.

Галимә. Алай дип инде, атасы, бердәнбер кызың шундый бай йортка төшәргә торганда, аяк азрак юрганнан чыкса да ярый. Дус-дошман арасында да күркәмрәк булганы яхшы бит. Шәбрәк җиһаз белән барса, Галиябануның үзенә дә каениш арасында йөз аклыгы булыр.

Бәдри. Хәлдән килгәнчә тырышырбыз инде. Ничек тә Галиябануга сиздерергә ярый шул. Бездән шикләнеп тормасын. *(Чыга башлый да, яңадан килеп.)* Шуны әйтермен дигән идем әле, Галиябану суга-нигә төшкәндә киенебрәк, көязләнебрәк төшсен иде. Аны да аңлатып куй.

Галимә. Ул кадәресен электән үк әйтә киләм инде. Ул турыга үзе дә бик шәп ул.

Икесе дә чыгалар. Галиябану каршы очрый.

Галимә *(ишек төбендә)*. Кызым, самавыр куйгансыңдыр?

Галиябану. Кайнар да инде.

Галимә. Әтиең калага китә бит, йомышларың булса әйт! *(Китә.)*

Галиябану. Эм-м, бер-ике бармак тамбур җебе[1] алып кайт дисәм, ачуланыр микән? Шулкадәр кабаланып китәрлек башына нинди эш төште икән тагы?.. Китсен, китсен, бик яхшы. Җомга көн өйдә булмаганы яхшы. Су буенда иркенләбрәк йөрермен... И, ансы имгәк икән тагы, Хәлилдән яучы килеп өлгерми кала күр. Әти киткәнче килеп калсын иде инде...

---

[1] *Тамбур җебе* — чигү җебе.

Галимә керә.

Галиябану. Әни, этигә ике генә бармак тамбур җебе алырга кушсам, орышыр микән?

Галимә. Ник орышсын, орышмас. Тагы башка йомышларың булса да әйт. Җепне күбрәк кушсаң да зыян булмас әле... Сатингамы, бер затлырак нәрсәгә чиктерсәкме дип тә торам әле мин.

Галиябану *(куркып)*. Нигә ул?

Галимә. Нигә дип, синең нәрсәләреңне җитеш итәсем килә. Шундый йомышларың булса әйт дип исеңә төшерәм. Бердәнбер кызына атаң да каршы килмәс. Әле берәр пар кызыл чүпләм сөлге дә алсак микән дим. Атаң да әйтә, бердәнбер кызыбызны кеше арасында күркәм булырдай итеп хәзерли алсак икән, ди. Яшең дә җитмәде түгел; Ходай бәхетеңне бирсен инде.

Галиябану *(бик шикләнеп)*. Әле беркөн генә, һәммә нәрсәң җитеш инде, дип торадыр идең. Хәзер ник җитешмәс булды тагын?

Галимә. Аннан ни зыян? Уй бит ул үзгәрә тора. *(Көлебрәк.)* Атаң әйтә, яшьләр алар синең вакытыңа карамый, күңелләре бер нәрсәгә төшсә, аларны аерып булмый, ди. Форсат бар чакта, алдан хәзерләнеп торырга кирәк, ди. Ялгыз бер кызыбыз, без аның теләгенә каршы килеп йөрмәбез инде, үзе дигәнен эшләрбез, ди.

Галиябану *(үз-үзенә)*. Әллә болар минем эшемңе сизделәр микән? Кичә саксызрак кыйландык шул.

Галимә. Шунлыктан гына әйтәм аны, бернәрсәне теләсәң, эти-әни каршы килер дип торма дим. Үзең киячәк киемне үзең сайлаган яхшы, үзең торачак өйне үзең җыештырган яхшы, башка турыларда да шулай...

Галиябану *(үз-үзенә)*. Мөгаен, болар белгәннәр икән. Теләгемә каршы килмәүләрен белдерергә тырыша бит. Шулай булса, нинди бәхетле булыр идем.

Галимә. Бердәнбер кыз булгач, синең теләгең безнең дә теләк инде ул. Сөекле кызының теләген тутыра алса, ата-ананың бәхете шул.

Галиябану *(үз-үзенә, куанып)*. Ах, шатлыгымнан шашам инде, әйтми чыдый алмыйм. *(Анасына.)* Рәхмәт, әни, сиңа да, этигә дә... *(Читкә карап.)* Ничек кенә белдертим? Урыны килгәндә әйтеп каласы иде. *(Анасына.)* Минем... теләгемә каршы килмәсәгез,

бәхетле булыр идем. Нәрсә ясагыз дип кыстамыйм... тик... *(Әйтә алмый туктый.)*

Галимә. Безнең дә бар теләгебез синең бәхетле булуың. Сүзеңне әйтеп бетер, кызым... Миннән тартынма.

Галиябану. Минем киенү-ясанудан башка бер теләгем бар... Тик әйтергә генә оялам... Үзегез дә беләсездер инде...

Галимә. Үзең дә акылсыз кыз түгелсең. Нишләгәнеңне белеп эшләгәнсеңдер. Кыскасы гына, кызым, без синең ниятеңне белдек. Ходай ак тормышлар бирсен инде. *(Чыга башлый, ишеккә җиткәч.)* Атаң көтә, чәйгә чык инде.

Галиябану. Мин әти киткәч чыгам.

Галимә чыга.

Галиябану *(куанып, сикергәләп)*. И, мин нинди бәхетле, нинди бәхетле! Бу кадәр бәхетле булырмын дип уйламаган идем. Әтиләрне күндереп булмас дип куркадыр идем. Бу куаныч хәбәрне Хәлил белми бит әле. Бүген инде янына чыкмый калмыйм. Хәзер Хәлилнең солдатка алынмавын гына теләргә калды. Хәер, китсә кайтыр әле. Аныкы булып калсам, биш ел көтәргә дә риза. Ничек бу чаклы уңай гына булып чыкты. Хәлилне яратып йөргәннәрдер шул. Алар да Исмәгыйльгә бирәбез дип җанымны кыйнарлар дип котым чыгып торадыр иде; рәхмәт төшкерләре, үзләре үк юлны ачып бирделәр.

Бәдига карчык керә.

Галиябану *(каршы йөгереп барып)*. Әби, миңа яучыга килдеңме әллә?

Бәдига. Әйе, әйе, кызым, синең башыңны ашарга килдем.

Галиябану. Хәлилдән килгән булсаң ашый бир.

Бәдига. Хәлилдән, Хәлилдән. *(Утырып.)* Сине башкага әрәм итәмме соң.

Галиябану *(Бәдиганың аркасыннан кагып)*. Рәхмәт, әби. Тагын йөз ел тор!

Бәдига. Үһү-ү, син бигрәк күбәйттең. Бер унавына барып булса ярар иде әле.

Галиябану. Әни өйдә, хәзер җибәрәм.

Бәдига. Әниеңнәр ничек, күнәр җайлары бармы?

Галиябану. Күнә, күнә.

Бәдига. Ай җитез! Ул якны да ныгытып өлгергән.

Галиябану. Шулай итми ни аны. *(Чыга башлый да, кире килеп.)* Әй, әби, Хәлил миңа бер әйбер дә әйтмәдеме?

Бәдига. Әйтмәгән кайда, тау чаклы иттереп сәлам әйтте. Аннан соң, су буена уенга чыкмый калмасын, диде.

Галиябану. Ярый дип әйтте диерсең, яме? Мин әнине җибәрим. Әти киткәнче сөйләшеп калыгыз. *(Чыга.)*

Бәдига. Менә кыз дисәң кыз, чәчрәп тора. Уңган, җитез. Ул төс дисәң, юлында башыңны җуярсың. Хәлил белән икесе пар алма кебек пар китереп яратылганнар инде. Хәлил дә йокламаган: бөтен тирә-юнь егетләре күз тотып торган кызның күңелен бәйләп өлгергән. Дөньяны селкетеп торган Исмәгыйль сөйләнеп калды. Ә Хәлил сугып алды. Шулай итәләр аны... Чәчәк кебек кыз иде, ярый әле егетенә туры килде...

Галимә керә.

Галимә. Кунак бар икән, абайламый да калдым. Сау йөрисеңме?

Бәдига. Шөкер Аллага, үзең исән генә торасыңмы? Әле ниләр җимереп йөрисең?

Галимә. Әле үзен калага озатырга йөри идек тә...

Бәдига. Ә, алайса, минем йомышым ул киткәнче өзелергә кирәк иде. Мин сезгә зур гына бер йомыш белән килгән идем. Китеп бармадымы әле үзе?

Галимә. Юк, яңа киенеп чыкты әле.

Бәдига. Алайса, Галимәбану, күп сузып торырга вакыт юк, Бәдри киткәнче бер җавап белеп калырга кирәк. Мин сезнең кызыгыз Галиябануга яучы булып килгән идем. Үзегез дә белгәнсездер...

Шулвакыт Бәдринең арба белән чыгып барган тавышы ишетелә.

Бәдига. Китеп бардымы әллә?

Галимә *(сикереп торып, тәрәзәгә йөгерә; кычкырып)*. Син! Син! Син! Кара әле. Тукта әле! Атасы!

Тышта Бәдринең «тыр-р» дигән тавышы ишетелә.

Галимә. Тиз генә өйгә кереп чык әле. Бәдига абыстай килгән иде. *(Тәрәзәдән башын ала.)*

Бәдига. Керәме?

Галимә. Керә. *(Килеп утырып.)* Бодай салып барадыр иде әле, кичке базарга өлгерим дип бик ашыгып тора.

Бәдига. Тиз генә җавап бирегез, алайса.

Билләрен буып киенгән Бәдри керә.

Бәдри *(ачык йөз белән)*. Әә, исәнме, Бәдига абыстай, сау гына йөрисеңме? *(Ишек төбендә генә утыра.)*

Бәдига. Аллага шөкер. Беркөе генә кыштырдап йөрим шунда. Үзең гөрләтеп кенә йөрисеңме?

Бәдри. Бик әлхәмделилла әле. Менә калага китеп барам.

Бәдига. Шулай икән шул. Синең юлыңны бүлдердем. Мин сезгә бер хәерле эш белән килгән идем. Менә Галимәбануга әйтәм әле. Шуңа бер җавап әйтеп китсәң, калганы турысында соңынтын да сөйләшер идек...

Галимә. Галиябануга яучы булып килгән Бәдига абыстай...

Бәдига. Ашыгыч булгач, онытмас борын шуны да әйтим әле, яшьләрнең бер-берсенә вәгъдәләре дә бар икән. Инде эш сездән генә калып тора. Галиябану — җитез кыз ул, үзе дә бәлки әйткәндер әле дим. *(Көлеп.)* Бу чагында кызлар кыю булалар бит.

Бәдри *(куанып)*. Ай, Бәдига абыстай, син дә корыга гына йөрмисең. Ишеткәч үк, безне кызыбыздан аерырга йөрми микән дип эчем жу итеп киткән иде. Уйга килгән алга килә ди шул. *(Көлә.)*

Галимә. Кызлы өйгә Бәдига абыстай килеп керсә, тикмәскә булмый инде ул.

Бәдига. Әлхәмделилла, яучы булып бирдергән кызларым бары да ал да гөл булып гомер итәләр. Бәдига карчык башымны ашады, дигәнне бер дә ишеткәнем юк. Бер-берсенә тиң булмаганнарны яучылап та йөрмим мин. Әнә, түбән авылның Сәйфи мәзин, Аккерфек Вәли кызына яучы бул, дип ни тилмерде. Кит, кит, тилереп йөрмә, алма кебек кызны бер карачкыга димләр хәлем юк, дип кул гына селтәдем. Менә Галиябануны да тәвәккәлләсәгез, моннан да артык тиң килгән урын булмас инде. Хан кызын димләсәң дә оят китермәслек егет.

Галимә. Әйе, егеткә сүз әйтерлек түгел.

Бәдри. Әле ничә әйтсәң дә бер сүз, китәргә ашыгамын, сузып та, назланып та торырга вакытым тар.

Галиябануның күңелен дә белгән идек. Без кызыбызның теләгенә каршы килмибез. Үзләре табышкан, үзләре вәгъдә куешкан. Шулай булгач, Ходай бәхетләрен бирсен диюдән башка сүзебез юк.

Галимә *(күзләрен сөртеп)*. Ходай хәерле итсен инде!

Бәдига. Әйе, кыз баланы җиткәч тапшырган яхшы инде. Әле Галиябану бик бәхетле кыз икән, менә дигән егеткә бара. Икесе дә бәхетле балалар икән. Киявегез дә һәркемнең ышанычын казанган. Бик һәйбәт егет, авылда бер дип әйтерлек.

Бәдри белән Галимә куанычларыннан утырып чыдый алмыйлар.

Инде, алайса, юлыңнан туктатмыйм. Бәдри, бар, юлларың уң булсын. Бар, мин дә, кайтып, егетне куандырыйм. Юлдан күзен алмый көтә торгандыр.

Бәдри *(торып)*. Шулай, Аллага тапшырабыз инде. Вәгъдә. Мин иртәгә үк кайтырга тырышырмын. Башка турыларда шунда сөйләшербез.

Бәдига *(торып)*. Рәхмәт инде, сүземне кире кайтармадыгыз.

Галимә. Ай, кузгалма әле, чәй эчми китәргә ни.

Бәдри. Әйе, әйе, чәй эчерми җибәрмә.

Бәдига. Юк, юк, рәхмәт, утырмыйм. Куаныч хәбәрем бар, тиз генә берәүне шатландырасым бар, икенче юлы эчәрмен әле. Тиз кайт дип тилмереп калды. [...]

Галимә. Алай бик күңелсез була ич.

Бәдига. Утырган да, эчкән дә чак булыр әле. Инде үз кеше булдык. Хушыгыз!

Бәдри. Икенче килүеңдә, алайса, сый хәзерләп каршы алырбыз.

Чыгалар.

Галиябану *(йөгереп кереп)*. Бирделәр, «башымны ашадылар», рәхмәт төшкерләре! Менә хәзер мин Хәлилнеке... Утырдыңмы, Исмәгыйль!.. Шулай була ул. *(Тәрәзәгә барып.)* Әнә эти дә китте. Хәерле юл, эти, рәхмәт төшкере! Исән-сау кайт, эти җаным! Кадерлем! Акыллым!.. *(Йөгереп чыкмакчы була да, тукталып.)* Мин кияүгә ярәшелгән кыз, әни янына чыгарга да оялам инде. *(Йөгереп чыкканда, ишектә анасы белән бәрелешә.)*

Пәрдә төшә.

ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Су буенда таллар янында бер күренеш. Тал арасыннан Исмәгыйль килеп чыга.

Исмәгыйль *(урталыкта туктап).* Неужели бу хәбәр чын булыр?.. Чын булса бит, страм, валлаһи! Синең күз тотып йөргән, күз тотып кына түгел, минеке дип ышанып торган кызыңны икенче берәү кулыңнан тартып алсын, имеш. Алучысы кем тагын? Синең кулыңа су салырга да ярамаслык бер малай гына бит... Юк, мин моңа ышанмыйм. Мин барында, ничек аңа бирергә кыйсыннар? Мин ничә тапкыр сүземне ишеттердем бит аларга. Теләмәгән вакытта да миннән куркырга тиеш алар. Төшенмим... Мөгаен, мине котыртып әйткәннәрдер. *(Уйлап торып.)* Галиябануны алам дип йөрүем бөтен тирәгә җәелде. Әгәр чынлап та селтәп куйсалар бит, ачуыңнан шартларсың... *(Гайрәт белән.)* Юк, моңарчы бөтен тирәне селкетеп тордым. Моннан соң да миннән куркырга тиешләр. Әллә нинди бер малай минем белән ярышмаска тиеш! *(Кызу-кызу йөреп алып.)* Ник мин болай йоклап йөрдем? Ник күптән аталарына хәбәр бирмәдем? Мин шул үземнән башкага бирергә базмасларына ышандым. Әгәр биргән булып чыксалар? *(Кулын селтәп җибәреп.)* Хурлык, валлаһи! *(Арлы-бирле йөри.)* Юк, Галиябануның миннән башкага баруын уйларга да ярамый. Бу була торган эш түгел. Хәлилнең дә башы ике түгел, белә торып минем арага керергә... *(Читкә карап.)* Әнә Галиябану үзе килә... Нишләргә?.. *(Тиз генә тал арасына баса.)*

Көянтә-чиләк күтәргән Галиябану сәхнәдән үтә башлый.

Исмәгыйль *(чыгып).* Юлыңа гөлләр үссен, Галиябану.

Галиябану *(борылып, Исмәгыйльне күргәч, чыраен бозып).* Рәхмәт! *(Китмәкче була.)*

Исмәгыйль. Ник ул кадәр ашыгыч?

Галиябану. Кеше очраган саен туктый башласаң, көне буе йөрерсең.

Исмәгыйль. Минем янымда аз гына да торасың килмимени?

Галиябану. Ашыгам шул.

Исмәгыйль. Биш кенә минутка!

Галиябану эндәшми китә башлый.

Исмәгыйль *(омтылып, каты вә куркытырлык итеп).* Галиябану!

Галиябану туктап, хәкарәт[1] белән Исмәгыйльгә карый.

Исмәгыйль. Сезнең тирәдә козгыннар йөри, диләр. Расмы әллә шул сүз?

Галиябану. Рас иде дә, котылдым инде.

Исмәгыйль *(куанып).* Теләмәдеңмени?

Галиябану. Теләмәдем.

Исмәгыйль *(бик куанып).* Хәлилнеме?

Галиябану. Юк, Исмәгыйльне.

Исмәгыйль яшен суккан кебек була. Галиябану китә башлый.

Исмәгыйль *(тиз генә барып ябышып).* Галиябану!

Галиябану. Син миңа ябыша алмыйсың! Мин Хәлилгә вәгъдә бирдем.

Исмәгыйль. Алданасың!

Галиябану. Алдансам, мин сиңа үпкәләмәм.

Исмәгыйль. Юк, син минеке булырга тиеш... Син минеке бул!

Галиябану. Мәңге булмам.

Исмәгыйль. Кара, моның ахыры яхшы булмас!

Галиябану. Мин берәүгә дә начарлык эшләгәнем юк. Шунлыктан миңа берәү дә зыян итәргә батырчылык итә алмас.

Исмәгыйль *(ялыныбрак).* Галиябану җаным! Мине шул Хәлилдән ким күрәсеңмени? Үз бәхетеңне киртәләмә. Минем кемлегемне беләсеңме? Минем исемем ишетелгәндә, бөтен тирә халкы тетрәп торалар. Минем бөтен авыл халкын бармагымда уйнатырга кулымнан килә. Минем күңелемне егып, башкага китүнең ахыры бик яхшы булмавын уйлап кара.

Галиябану. Зинһар, Исмәгыйль абый, мине җәберләмә, мин Хәлилне сөям. Сиңа һич мәйлем юк. Юкка минем юлымны бума!

Исмәгыйль. Яхшылык белән күнмәсәң, нишләргә белермен.

Галиябану. Ходайдан курык азрак.

Исмәгыйль. Ачу килгән вакытта, Ходай истән чыга. Аннан да аң бул.

Галиябану. Хәтта минем синең белән сөйләшәсем дә килми. *(Китмәкче була.)*

---

[1] *Хәкарәт* — хурлау.

Исмәгыйль *(бик ачу белән)*. Мин сиңа китмәскә кушам.

Галиябану. Миндә синең эшең юк.

Исмәгыйль. Китә алмассың!

Галиябану. Артык тора алмыйм. *(Китә башлый.)*

Исмәгыйль, тиз генә барып, Галиябануның башыннан шәлен тартып ала. Көянтә-чиләкләре шалтырап җиргә төшә.

Зинһар, дим... *(Борылып килеп.)* Туктатма мине, бир шәлемне!

Исмәгыйль *(мыскыл итеп)*. Бар кит, ник китмисең?

Галиябану *(көянтә-чиләкләрен алып)*. Исмәгыйль абый, йөдәтмә мине юкка. Барыбер файда юк... Бир шәлемне.

Исмәгыйль. Хәлилгә барырга ашыгасыңмыни?

Галиябану. Зинһар дим, туктатма.

Исмәгыйль *(каршысында ялынып торган Галиябануны мыскыллап, шәл тоткан кулын бөеренә таянып, «Галиябану» көенә җырлый)*.

Җәйгә чыксаң, җилләр өчен
Җәй киләткә урыныңны;
Миннән артык яр тапмассың,
Бик күтәрмә борыныңны.

Галиябану *(тәмам аптырап)*. Теләсәң ничек итеп хурла, тик шәлемне бир!

Исмәгыйль. Көең бу җыр белән тагы да матуррак була икән, ә?

Галиябану. Зинһар дим, рәнҗетмә... Шәлемне бир!

Исмәгыйль *(кычкырып көлә)*. Бар, әнә теге чүплек башындагы өйдә сине килен итеп көтеп торалар, ди.

Галиябану. Миңа шул да ярый. Анда синең эшең булмасын.

Исмәгыйль. Йә, бар, ник китмисең? Түбәсез өйгә шәлсез килен дә ярый...

Шулвакыт Хәлил, йөгереп кереп, Исмәгыйль белән Галиябану арасына баса.

Хәлил *(Исмәгыйльнең кулыннан шәлен йолкып алып)*. Без аны синнән сорамабыз. Анда ни эшең бар, бәдбәхет, кара елан! Син безнең арага кермәкче буласыңмыни?!

Галиябану *(Хәлилнең кочагына атылып)*. Җаным, бәгърем, коткар мине!

Хәлил. Тыныч бул, Галиябану, аның белән сөйләшә белермен. *(Исмәгыйльгә.)* Исмәгыйль! Бел шуны: башың ике булса кер безнең арага! *(Галиябануны алып чыгып китә.)*

Исмәгыйль *(бик ачу белән карап калып)*. Әгәр шушы Хәлилнең кулыннан Галиябануны тартып ала алмасам, Исмәгыйль исеме миңа хәрам булсын! *(Нык-нык басып чыгып китә.)*

Дүрт-биш минуттан Хәлил белән Галиябану керәләр. Галиябану су җилкәләгән.

Хәлил *(моңаеп кына җырлап килә)*.

Аклы ситсы күлмәгемне
Саламын да киямен;
Ярым ятлар белән уртак,
Янамын да көямен.

Галиябану *(урталыкта суын җиргә куеп)*. Җаным, мин ул Исмәгыйль эшне чуалтыр дип куркам.

Хәлил *(юатып)*. Бернәрсә дә эшли алмас, бер дә кайгырма. Синең, минем ризалыкларыбыз өстенә, әти-әниеңнең дә күнүе белән булган эшне ун Исмәгыйль дә боза алмас. Бөтен авыл безнең якта. Ялгыз Исмәгыйль әллә кая бара алмас.

Галиябану *(бик борчулы)*. Белмим шул. Ул әллә нинди яла ягудан да тартынмас. Бигрәк яман күңелле кеше икән инде. Миңа эт кебек ябышты бит... Әллә ни, әтиләрне айнытмагае дип куркам.

Хәлил. Әтиләрең айныганнан аңа ни файда да, безгә ни зыян? Азрак безнең эш мәшәкатьлерәк чыгар, бары шул.

Галиябану. Безнең әти — бик аумалы кеше ул. Шунлыктан күңелем бик шикләнә башлады. Исмәгыйль, мөгаен, әтиләрне айнытыр.

Хәлил. Әйтәм бит, җаным. Алар айныганнан безгә ни зыян?

Галиябану. Ни зыян дисеңме? Элек Гыйльметтиннәр Фатыйманы бикләп куйган кебек, мине бикләп куярлар. Аннан Исмәгыйльгә никах укытырлар да төяп җибәрерләр.

Хәлил. Син әтиләреңне шуны эшләрләр дип үк уйлыйсыңмы?

Галиябану. Әти дә, әни дә Исмәгыйльгә сатылмагайлары дип куркам.

Хәлил *(уйга кала, бераздан)*. Соң нишлик дисең, Галиябану?

Галиябану. Зинһар, бер юлын тап! Минем акылым ирешми.

Хәлил. Алайса, менә нәрсә, Галиябану, без хәзер сабыр итеп торыйк. Әтиең каладан кайтсын. Әгәр Исмәгыйль чынлап эшне болгатып, әтиләрең айнысалар һәм ызалый торган булсалар, шул ук төнне Көмшәр авылына качарбыз да никах укытырбыз.

Галиябану. Алар бит мине бикләп куярлар.

Хәлил. Син, аларның айныганын сизгәч тә, алар яклы бул, мин Хәлилне ташладым, диерсең. Шуннан сине бикләмәсләр. Авыл тынгач, мин синең тәрәзәңә барырмын да, Көмшәргә сызарбыз.

Галиябану. Ярый ла син килсәң. Бер-бер сәбәп белән килә алмасаң?.. Мин аннан соң харап булам бит.

Хәлил. Юлыма таш яуса да бармый калмам, вәгъдә бирешкән чактагы, «сөйгәне өчен корбан булудан яшь егет баш тартырмы» дигән сүзне мин уйнап кына әйтмәдем. Тик үзең теге хәйләне онытма!

Галиябану. Ярый, мин күнәм. Синеке булып калыр өчен тау тишеп чыгарга да ризамын. Кинәт кенә бәхетле булдым дип куанган идем. Никадәр кыеннар, никадәр сүзләр ишетәсем бар икән әле.

Хәлил. Бәлки әле, бернәрсә дә булмас...

Пәрдә төшә.

ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

Ишегалды як өйнең түре чыккан Бәдринең бакчасы. Бер читендә сәке. Өстендә яңа жыеп бетеп килгән чәй урыны. Галимә поднос сөртә, Бәдри, сәкедән аягын салындырып, читтәрәк утыра. Кич.

Бәдри. Иртәгә иртүк Бәдига абыстай килеп тә җитәр. Әле без ул турыда бернәрсә дә сөйләшмәдек. Туйлыгына күпме, мәһәренә күпме сорыйбыз?

Галимә. Аларын үзе дә җиренә җиткереп эшләргә тырышыр инде. Исемен буярлык итмәс. Кем бүләкләре дигәндә, Исмәгыйль бүләкләре дип кычкырып торырлык итәр.

Бәдри. Юк, ул, хатын, алай дип кенә торырга ярамый. Дөрес, биткә кызыллык китерерлек итмәс. Шулай да булса, урыны килгәндә *(кулы белән күрәп күрсәтә)* чумырыбрак калырга кирәк. Бер эләктерсәң, шушы туй арасында эләктереп каласың аны. Кызны бер алып китсә, безгә шул бай кодасы булудан артыгы күп тәтеп бетмәс.

Галимә *(чынаякларны ашъяулык белән төреп куеп)*. Күпме сорарбыз соң?

Бәдри. Менә шуны шул билгеләп куясы иде.

Галимә. Без сорарбыз. Ә ул тагы да күбрәк бирергә уйлап торган булыр.

Бәдри *(торып йөри башлап)*. Әй, кадалгыры! Ансы бар икән тагы. Артык сорап ташласаң, әллә ни кияүне ачуландырып, эшне бозып кую бар. Чамалабрак сорасаң, аның күбрәк тә бирергә уе булганлыгын белеп, эч януы бар... Шайтан тигере, бу байга кыз бирү дә җиңел эш түгел икән.

Галимә. Шуның өчен дә үз иркенә генә куйыйк дим мин.

Бәдри *(башын кашып, уйланып)*. Үз иркенә генә куйыйк дисең дә, әгәр ул туйлыгына, мәһәренә нибарысы ике йөз сум гына биреп куйса?

Галимә. Ник, шул җитмимени? Туйга илле сум, мәһәренә йөз илле сум булса, башкаларның төшенә дә кермәгән ич әле ул...

Бәдри *(ачуланып)*. И чүпрәк баш, чүпрәк баш! Ташла ичмасам шул яулыгыңны! Бер кеше төсле уйлый алмассың микән? Соң, Исмәгыйль кебек бер байга кыз бир дә, имеш, ике йөз белән эш бетер... Бу хатын дигән каһәр суккан белән ни аны, ерак барырсыңмыни! Чыгарырга булса юмартлана: үзенә йон күлмәк тә кирәк, баласына камзул да кирәк, кодагыена фәләнчә кирәк. Ә керергә булса *(җилкәсен сикертеп)*, юк... Кайда әле үзләре табу чарасына керү, кешегә юлны буып йөдәтәләр. *(Кулын селтәп.)* Ичмасам, йөз илле сум туйлык, илле сум мәһәр дип тә әйтә белми бит...

Галимә *(ачуланыбрак)*. Йә, йә инде, күп җибәрелмә! Алай бик акыллы булгач, киңәшмәсләр аны. Миңа димәгәе өч йөз сум сора.

Бәдри. Өч йөз?.. Менә мин, алайса, мең тәңкә сорыйм... Ишетәсеңме? Мең! Аны өч йөз белән кала

торган булгач, Исмәгыйльгә бирмим дә, Галиябану кебек кызың барда йөз кияү табып була.

Галимә. Илаһи, ал гына, мин бер дә күпсенмим...

Бәдри *(җиңгән сыман)*. Алаймы? Акылга килдеңме? Мең сум диләр аны. Акылга китерер ул.

Галимә. Алай зурдан сорый белгәч, әзерли дә бел инде. [...]

Бәдри *(абайлап)*. Шундый ай яктысында нигә ут яндырып утырасың? Сүндер! Әле бит мең сум кулга кермәгән. Аннан соң көндез дә ягып утырырбыз.

Галимә *(сүндерә)*. Әле ай яңа гына күтәрелде бит...

Бәдри. Чү әле, чү! *(Агачлар арасыннан сузыла-сузыла каранып.)* Кем бу килә? *(Тагын азрак карап.)* Исмәгыйль. Тиз, тиз, хатын!.. Китик, Галиябануга килә.

Галимә *(сикереп торып төшәм дигәндә, ялгыш басып, җиргә каплана)*. Алла... *(Тора алмый ята.)*

Бәдри. И, чәнчелгән!.. Тиз тор инде, ни бака кебек җәелеп ятасың!.. *(Тартып торгызып, сөйрәп китә башлый. Галимә аксый-аксый йөгерә.)*

Исмәгыйль тавышы. Бәдри абзый, кайда качасың? *(Сәхнәгә килеп керә.)*

Бәдри белән Галимә туктыйлар.

Бәдри *(килебрәк)*. Ә... син икәнсең... Кемдер дип, усаллар-мазармы дип торам...

Исмәгыйль. Усал булсак та булырбыз шул.

Бәдри *(һи-һи-һи дип көлеп, бик тәлинкә тотарга тырышып)*. Без яшьләрнең мондый усаллыгын чит күрмибез... Яшь чакта шулай була инде ул.

Исмәгыйль. Нихәл, Галимә җиңги, эшләр гөрлиме?

Бәдри. Һи-һи-һи...

Галимә. Аллага шөкер, бик һәйбәт әле.

Исмәгыйль. Төн буенча бакчада икәү генә нидер серләшеп утырасыз.

Бәдри. Ни серләшик. Бар да шул инде... Әйе. Үзебезнең бәхетебезне, күргән илтифатларны сөйләшү. Тагы...

Исмәгыйль *(ачуын тыярга тырышып, мыскыл иткән сымак)*. Сез бик шат, Бәдри абзый! Куанычыгыз эчегезгә сыймагандай күренә.

Галимә. Ходайга шөкер итеп бетүдән гаҗизбез инде. Шундый зур эшкә кайчан куанмассың.

Бәдри. Һи-һи-һи... Куанычыбыз эчебезгә генә түгел, дөньяга да сыя алмый.

Исмәгыйль. Мин дә шулай дип ишеткән идем. Мөбарәк булсын туйлар!

Бәдри. Шулай инде, шулай... *(Галимә белән ишарәләр ясашып.)* Без сиңа комачауласак китик...

Исмәгыйль. Мин таракан булдым, ахры, сезгә.

Бәдри. Юк, юк. Алла сакласын!..

Исмәгыйль *(чак-чак үзен тыеп)*. Хәер инде, сезнең дөньяга сыймаган зур куанычыгызга тарлык ясыймындыр шул.

Бәдри. Алай дип әйтә күрмә. Без үзебез сиңа таракан булмыйк дибез.

Исмәгыйль *(сабырын җуеп)*. Рияланма юкка, Бәдри абзый! Бары да беленде инде.

Бәдри белән Галимә шикләнеп китәләр.

Бәдри. Ничек, ничек? Нәрсә беленде? Ни булды?

Исмәгыйль *(ачу белән)*. Ни булганы үзегезгә билгеле, нигә миннән сорыйсың аны! *(Кызу-кызу йөри башлый.)*

Галимә. И Ходаем, арага дошман кердеме әллә югыйсә?

Бәдри. Без бернәрсә дә белмибез, ни хәл бу, ә?

Исмәгыйль *(туктап, бик ачу белән)*. Син тиле, син аңгыра!

Бәдри бер сүз әйтә алмый калтырап кала.

Галимә *(елый башлап)*. И Ходаем, башы беткере! Дошман кергән икән арага...

Исмәгыйль. Ярый, ярый, дошман ук булыйм. *(Бармак селкеп.)* Тик белеп куегыз: мине дошман ясау белән файда итә алмассыз...

Бәдри. Исмәгыйль...

Исмәгыйль *(аяк тибеп кычкыра)*. Молчать!

Бәдри дер-дер килә.

Исмәгыйль *(гайрәт белән)*. Мине танымый йөрисез икән әле. Менә танырсыз, минем белән шаярасыгыз килгән икән... Постой! Мине Исмәгыйль диләр. Мин сезнең кадерле киявегез Хәлил кебекләрнең унавын бер бармакта биетәмен, беләсезме?

Бәдри }
Галимә } *(икесе бергә)*. Хәлил кияү? Ул ни дигән сүз тагын?

Исмәгыйль. Улмы? Галиябануны Хәлилгә ярәшкәнсез дигән сүз.

Галимә. Язмаганны, кем әйтә?

Бәдри. Менә тагын кирәк булса. Юк, юк!

Исмәгыйль *(ачуланып, кычкырып)*. Тагын нинди күзгә карап алдау! Менә мин әйтәм.

Галимә. Дошман сүзедер.

Бәдри. Сине алдаганнардыр. Хәлил дигәнне уйга да керткәнебез юк.

Исмәгыйль. Ә кызыгыз?

Бәдри. Кызыбыз да син дип үлеп тора.

Исмәгыйль *(кычкырып)*. Алдама!

Галимә. Соң, вәгъдә билгесе итеп үзеңә чиккән яулык та бирде ләбаса.

Исмәгыйль. Чиккән яулык?.. Алайса ул яулык Хәлилдә.

Бәдри
Галимә} *(икесе бергә)*. Ә? *(Бер-берсенә карашалар.)*

Исмәгыйль. Йә, тагы да әйтә торганыгыз бармы?

Бәдри. Ах, Исмәгыйль... Алайса без яңлышканбыз... Без син дип белдек.

Галимә *(өтәләнеп йөри)*. Харап кына булдык... Оятлы гына булдык...

Бәдри. Бу — ни дигән эш?.. Юк, юк, болай ярамый. *(Гайрәт белән.)* Бар, хатын, алып чык кызны монда! Мин кызымны андый урам көчекләренә тоттырып җибәрермен дип үстермәдем. Шундый егетнең мәйле барын белә торып, мин андыйларга күнә алмам. Бар, тиз алып чык! Мин аның белән сөйләшеп карыйм.

Галимә йөгереп чыга.

Исмәгыйль. Ул якны үзең кара, Бәдри абзый, мин китәм. Бәлки, әйләнеп килермен дә. Тик шуны яхшы бел: Галиябану неприменно миңа булырга тиешле. Сиңа яшерми әйтәм. Моңарчы алам дип йөреп, инде читкә җибәрү — миңа үлем белән бер. Монда минем Исмәгыйльлегем изелә. Мин, үземнең исемемне әллә нинди малайлардан таптатмас өчен, һәртөрле юлга керергә әзер. Галиябануны Хәлилгә биргәннәр, дип хәбәр чыкканга бер генә тәүлек булса да, миңа төбәп байтак сүз ишеттерделәр. Менә шундый ишеттерүчеләргә һәм ишеттерәчәкләргә минем җавабым Галиябануны үземә алу белән генә булырга кирәк... Якынрак кил, Бәдри абзый!

Бәдри якын килә.

Әгәр Галиябануны Хәлилдән айнытып, иртәгүк миңа никах укытып бирә алсаң, туйлык мәһәрләрдән башка үзеңә мең сум. *(Туп-туры Бәдринең күзенә карый.)*

Бәдри *(соңгы сүзнең дәһшәтеннән аптырап, ни әйтергә белми калып)*. Ә... е... е... ме-мең-мең тәңкә?

Исмәгыйль. Эшлисең бит, Бәдри абзый, шуны?

Бәдри *(күзләре дүрт булып)*. Булды, кыз синеке. *(Кулын бирә.)*

Исмәгыйль. Кара, сүзеңдә нык тор. Аларның вәгъдәләре бик нык. Син шуны җимерергә тиешле. Булдыра алмасаң, икегезгә дә яхшы булмас. *(Китә.)*

Бәдри *(күзләрен ялкынландырып)*. Мең тәңкә...

Галиябану белән Галимә керәләр.

Галиябану *(борчулы сында куркып кына)*. Мин нигә кирәк булдым?

Бәдри. Әле монда, кызым, булачак кияү дә бар иде. Шуңа күрә сине дә чакырткан идем.

Галиябану. Нинди кияү?

Бәдри. Үзеңнең булачак киявең, Исмәгыйль.

Галиябану *(куркып китеп, белешмичә)*. Исмәгыйль? Ул нинди кияү булсын?

Бәдри. Ник кияү булмасын, сине биргәч, кияү була инде ул.

Галиябану *(белешмичә)*. Бу нинди сүз тагын? Бер бирдегез бит инде.

Бәдри. Кемгә?

Галиябану. Хәлилгә.

Бәдри. Юк, без сине Хәлилгә биргәнебез юк. Исмәгыйльгә дип бирдек.

Галимә. Без синең тәрәзәңә килеп йөргән кешене Исмәгыйль дип белдек.

Галиябану. Ах, бу ни эш?!

Бәдри. Ни эш булса да, булган да үткән. Менә сиңа шул, син Исмәгыйльгә барырга тиеш!

Галиябану. Бәдига абыстайга да вәгъдә куеп җибәрдегез бит.

Бәдри. Анда да без Исмәгыйльдән килгән дип белдек.

Галимә. Тәрәзәгә килеп йөргән кешене Исмәгыйль дип белгәнгә, Бәдига абыстай яучы булып килдем дигәч тә, Исмәгыйль җибәргәнлегендә шик итмәдек.

Бәдри. Йә, үткән эшне күп сузма. Менә, Галиябану, яхшы әйткәнне тыңласаң шул, син тилелегеңне куй! Исмәгыйльгә бар!

Галимә. Карт көнебездә битебезгә оятлык китермә, кызым, үз бәхетеңне киртәләп куйма! Ходай сиңа бер кызга да бирмәгән бәхетен сузып тора.

Галиябану *(аптыраштан айный алмый)*. Әти, әни, зинһар дим, мине җәберләмәгез. Минем бәхетемә аяк чалмагыз.

Галимә. Юләрләнмә! Нишләп аяк чалу булсын ул! Сине бәхетле итәргә тырышабыз бит.

Галиябану. Мин аңа бармыйм... *(Исенә килеп, үз-үзенә.)* Ах, яңлыштым... Инде нишлим?..

Бәдри *(кычкырып)*. Мин барырсың дим!

Галиябану *(түзми)*. Кансыз ул, ерткыч!

Бәдри *(Галиябануның авызын басып)*. Тукта, яхшылык белән! *(Як-ягына карап алып.)* Тавышыңны чыгарма! Югыйсә тегеләй мин сине...

Галиябану *(гайрәт белән)*. Мин туктамыйм, мин Исмәгыйльгә бармыйм.

Бәдри *(кычкырып)*. Барырсың!

Галимә. Кызым, зинһар, тилермә! Шундый бер урынга бармыйм дияргә ничек телең бара? Шундый кеше сорап торганда, карышу көферлек булыр. Андый кешенең күңелен егуның куркынычы да бар бит.

Галиябану. Мин сөймәгән кешемә ничек барыйм?

Бәдри. Баргач сөярсең, карышма!

Галиябану *(ялынып)*. Әти җаным, булмый дим...

Бәдри. Тавышыңны чыгарасы булма, бәдбәхет кыз! Карышсаң, миннән яхшылык көтмә!

Галиябану. Нишлим соң?

Бәдри. Син Исмәгыйльгә бар!

Галиябану. Мин аңар барырга мәңге риза түгел.

Бәдри *(ачуыннан калтырап, йодрыгын Галиябануның баш түбәсенә үк китереп)*. Мин әйткәнгә күнмәсәң, җаныңны алырмын мин синең. Бармыйм дип авызыңны ачасы булма!

Галиябану. Үтерсәң дә риза булыр хәлем юк. Мин Хәлилнеке.

Галимә. Галиябану, зинһар дим, акылыңа кил! Алдыңдагы шундый ялтырап торган бәхетне дә күрмәслек дәрәҗәдә ул Хәлилнең ниенә ашкындың?

Ике матур, бер җиргә килеп, бәхетле була алмаслар дигән борынгылар.

Галиябану. Бәхетсез булсам, сезгә үпкәләмәм.

Бәдри *(җикеренеп)*. Тагын бер әйтәм, туктыйсыңмы?!

Галиябану *(елап)*. Әти җаным, кыстама мине...

Галимә. Кызым...

Бәдри *(кычкырып)*. Кысылма син! *(Төртеп җибәрә. Галиябануга.)* Әти, барам диген!

Галиябану елый.

Бәдри. Барырсың!

Галиябану. Булмый!

Бәдри *(өстенә барып)*. Булмыймы?

Галимә *(Бәдринең җилкәсенә ябышып)*. Атасы, атасы!

Галиябану. Булмый!

Бәдри *(кулына ябышып)*. Булмыймы?

Галиябану. Булмый дим...

Бәдри, бик ачуланып, гайрәт белән селтәп җибәрә, Галиябану атылып барып төшә.

Галимә. Юньләп...

Бәдри *(кычкырып)*. Тик тор, сиңа да кирәкме әллә?! *(Аны да селтәп җибәрә.)*

Галиябану җирдә яткан көе үксеп елый. Бәдри, күзләрен ямьсезләндереп, аңа карап тора.

Галиябану *(торып, акрынлап, өстерәлеп кенә барып, бер агачка сөялеп үз-үзенә)*. Инде нишлим? Әти хәзер җанымны алырга тора... Болай итеп кенә булмый икән... Әгәр Хәлил кушканча эшләсәм?.. Ул килми калса, бүген, иртәгә үк Исмәгыйльгә никах укытып куйсалар нишләрмен?..

Бәдри. Йә, кызым, күп уйланма! Инде акылга килмәдеңме?

Галиябану *(үз-үзенә)*. Күнәм инде. Моннан башка чара юк. *(Атасынарак бер-ике атлап.)* Инде... Ихтыярыгыз... Мин шуннан артык каршы тора алмыйм. Сез алай риза булмый торган булгач, карышудан файда чыкмас. Сез минем өчен кайсы яхшы буласын артыграк беләсездер.

Галимә. Менә рәхмәт, кызым! Күптән шулай гына әйткән булсаң, мондый күңелсезлекләр чыкмаган булыр иде. *(Аркасыннан сөя.)*

Бәдри *(тынычланып)*. Без бит синең бәхетең өчен тырышабыз... Ярый әле соң булса да акылга килдең, Исмәгыйльгә барырга риза булдың бит инде?

Галиябану. Сезнең теләвегезгә риза булдым. Ихтыярыгыз.

Бәдри *(каранып)*. Әнә Исмәгыйль үзе дә килә. Елаганыңны белдермә! Кара, уйлап сөйлә!

Исмәгыйль керә.

Исмәгыйль. Исәнме, Галиябану!

Галиябану баш ия. Эндәшми.

Бәдри *(ачык чырай белән)*. Насыйп булса, иртәгә никах укытырбыз инде, кияү.

Галиябану сискәнеп китә.

Исмәгыйль *(куанып)*. Эш булдымыни?

Галимә. Синең кебек егет булганда, бик куанып инде.

Бәдри. Бала бит әле, ялгышкан гына. Төшендереп биргәч, бик куанып риза булды.

Исмәгыйль *(иркәләп кенә)*. Шулаймыни, Галиябану туташ?

Галиябану эндәшми.

Бәдри. Ул ояла инде.

Исмәгыйль. Алайса, кулыңны гына бир!

Галиябану хәрәкәтсез тора.

Галимә, Бәдри *(икесе бергә)*. Кулыңны бир! Бир, кызым!

Галиябану *(кулын биреп)*. Җаның тыныч булсын!

Исмәгыйль. Менә рәхмәт.

Картлар куанышалар.

Исмәгыйль. Ярый, бүгенгә мин китәм. Калганы иртәгә. Хушыгыз!

Бәдри *(иелеп калып)*. Хуш, хуш! Аллага тапшырдык...

Пәрдә төшә.

Шул ук күренеш. Төн уртасы. Ай нурларын коя. Тынлык. Акрын гына Исмәгыйль керә.

Исмәгыйль. Йоклыйлар. Бөтен җир тынлыкка калган. Тик мин генә йоклый алмыйм. Менә тагы

монда килдем. Ник килдем мин монда? Төнлә ни бар миңа монда? Галиябануның бүлмәсенә керергәме?.. Юк... Мине монда көнчелек китерә. Галиябануны Хәлилдән көнләү китерә. Көнләү генә дә түгел, курку китерә... Кызның атасын сатып алдым. Кыз да инде чәпчи алмас. Тик иртәгә никахны беркеткәнчегә кадәр, Хәлилдән сакларга кирәк. Төнлә килеп, Галияне тагы айнытып йөрмәсен... *(Бик горурлык белән.)* И Хәлил, көчле белән көрәшмиләр аны! Күп телеңне тыймасаң, чәнчелеп төштеңме! Шулай була ул... Имеш, аны Галиябану сөя. Инде менә сөеп карасын. Мин аны ничек тота белермен. Әгәр юньгә килми икән, миңа нәрсә! Соңыннан ник миңа димәгәе чәнчелми... Миңа намус кыйбат. Миңа исемне җуймау кыйбат. Миңа Исмәгыйль отылды дигән сүзне ишетмәү кыйбат. Матурлыгы белән бөтен тирәдә дан тоткан кызның миннән узып башкага китүе — ул ни дигән хурлык... Менә нинди генә юл белән булса да, мин шул хурлыкны күтәрмәскә тиеш. Тәмам кармакка эләктергәнче кирәк булган сәбәпләрнең нindиеннән дә мин качмам. Йоклыймы икән үзе? *(Акрын гына барып, тәрәзәдән карап килә.)* Йоклый, ахры... Урынына йөзтүбән яткан. Елый-елый йоклап киткәндер. Әйдә ела! Кичә бик шәп идең әле. Ерак бара алмадың шикелле... *(Чыбыклар чытырдаган тавыш ишетеп.)* Бу ни?.. *(Тыңлап тора.)* Берәү килә, ахры. *(Чыбыклар арасыннан күрергә тырышып).* Берәү килә... Хәлилдер... Әгәр Хәлил булса?.. Мөгаен, шул булыр, кем килсен бүтән... *(Карап.)* Хәлил. Ярый, кил! Мин сиңа кемлегемне танытыйм. *(Кесәсеннән револьверын алып.)* Күп шаяра башласаң, мин сине моның белән дә сыйлый белермен. *(Агачларга ышыклана.)*

Акрын гына басып, як-ягына карана-карана, сакланып кына, Хәлил килеп керә.

Хәлил *(сәхнә уртасында туктап)*. Ни хәлләр бар икән бу йортта? Эшләр башкачага әйләнгән булып, саклап торып, харап итә күрмәсеннәр. *(Галиябану тәрәзәсенә барып сузылып карый, як-ягына карап алып, сакланып кына тәрәзәне чиртә.)*

Исмәгыйль револьверын тоткан килеш бик җентекләп карап тора. Хәлил, азрак күтәп торып, тәрәзә ачылмагач җырлый.

Тәрәзәгә егет килгән,
Йоклап ятма, гөлкәем;
Ябышып чыкмый үз-үзеңне
Утка атма, гөлкәем!
(Тагы чиртә, тәрәзә ачыла.)

Галиябану. Хәлил, килдеңме?

Хәлил. Йә, эшләр ничек?

Галиябану. И җаным, мине Исмәгыйльгә барырга күндерер өчен күрсәтмәгәнне калдырмадылар.

Хәлил. Мин әйткәнчә эшләмәдеңмени?!

Галиябану. Монда башта ук зур ялгышлык булган. Әтиләр мине Исмәгыйльгә бирдек дип белгәннәр. Мин моны ишеткәч, аптырап калып, нишләгәнемне дә белмәдем.

Хәлил. Менә кирәк булса! Соң, ничек бетте?

Галиябану. Риза булган булып, эшне чак юнәттем.

Исмәгыйль зур үзгәреш ясый. Ачуыннан нишләргә белми.

Хәлил. Мин атлар, кешеләр алып килдем. Куралар артында гына тора. Китик, алайса, тиз!

Исмәгыйль револьверын тотып, атылып чыкмакчы була. Тагы тыела.

Галиябану. Якын-тирәдә кеше-кара юкмы?

Хәлил. Юк, әйдә тизрәк!

Галиябану тәрәзәдән төшә, Хәлил күтәреп ала.

Исмәгыйль *(чыдый алмый өсләренә атыла язып)*. Бетерәм!

Галиябану. Беленмәсәк кенә ярар иде.

Хәлил *(Галиябануның беленнән алып)*. Хәерле сәгатьтә!

Галиябану *(кузгалмыйча)*. Бик куркам, беленмәбез микән?

Хәлил. Бернәрсә дә юк. Әйдә, дим, минуты кыйбат.

Галиябану. Кешеләр килеп тотсалар, нихәл итәрбез?

Хәлил. Галиябану, болай тору үзе куркыныч бит. Бер дә каушама, нык бул! Атла аягыңны! Ул михнәткә түгел... бәхеткә таба, аны анык бел!

Галиябану. Хәерле генә булсын инде!

Хәлил. Йә, киттек...

Галиябануның беленнән тоткан көе йөгереп китә башлыйлар. Исмәгыйль, револьверлы кулын кесәсенә тыгып, тып итеп алларына килеп баса. Болар кире чигенәләр.

Галиябану *(бик куркып).* Ах!

Хәлил *(курку-ачу катыш).* Ни кирәк сиңа?

Исмәгыйль *(бик каты ачу белән).* Җибәр Галиябануны!

Хәлил. Ник җибәрим мин аны?! *(Китмәкче була.)*

Исмәгыйль *(револьверын төзәп).* Кузгалма!

Галиябану. Һай! *(Куллары белән йөзен басып, Хәлилнең күкрәгенә каплана.)*

Хәлил. Куй! *(Куркып чигенеп китә.)*

Исмәгыйль. Бир яхшылык белән Галиябануны!.. Йә Галиябануны бирәсең, йә жаныңны!

Хәлил. Булмас нәрсә белән кыстама. Җибәр безне. Үзеңә дә файда юк.

Исмәгыйль. Минем файда, зыянымда синең эшең булмасын. Миннән йә Галиябануны, йә җаныңны биреп котыласың.

Хәлил *(бик аптырап).* Уйла, зинһар, Исмәгыйль. Мине үтергән белән барыбер Галиябануны ала алмыйсың бит...

Исмәгыйль. Анда синең эшең булмасын! Анысын мин үзем карармын. Син менә үз хәлеңне тикшер. Ташлыйсыңмы яхшылык белән, юкмы?

Галиябану *(чак кына башын күтәреп, револьверга күзен төшерми генә).* Зинһар, Исмәгыйль абый, безне җәберләмә!

Хәлил. Без кечкенәдән бер-беребезне сөеп вәгъдәләр бирештек. Сиңа көндәш булу дигәнне уйлаганым да юк. Син дә безне бикәргә харап итмә!

Исмәгыйль. Ник шунда Ходай үзе никахыгызны укып яратмаган. Ул сүзләрнең берсе дә колагыма керми хәзер. Тик сез минем алдымда калтырап торырга тиеш икәнне генә беләм һәм менә шуны күзем белән күреп торам. *(Револьверын Хәлилнең маңгаена ук китереп.)* Менә Исмәгыйльнең кулы бу җирдән вәгъдәләрегезнең көле күккә очканнан соң гына алыныр...

Галиябану *(хәлдән таеп).* Атма! Атма!

Исмәгыйль. Кит Хәлилең яныннан, ташла аны!

Хәлил белән Галиябану нишләргә белми аптырашып торалар.

Исмәгыйль *(аз гына көтеп тора да сул кулы белән Галиябануның кулына ябыша; Галиябану тартыла; көч белән йолкып алып, Хәлилгә).* Йә туры

гына чыгып кит, йә дөнья белән исәнләш! Бер минут срок сиңа...

Хәлил кинәт Исмәгыйльнең өстенә очып куна. Исмәгыйль атарга өлгерә алмый кала. Револьверы җиргә төшә. Икәү алыша башлыйлар. Ахыр Исмәгыйль, Хәлилне җиргә егып, өстенә атлана. Ләкин Хәлил җирдәге револьверны алып өлгерә дә яткан җиреннән өстендәге Исмәгыйльгә төзи.

Исмәгыйль *(кире чигенә биреп)*. Шаяртма дим минем белән!

Хәлил. Тор! Атам!

Исмәгыйль. Уйнама дим! *(Акрын гына тора.)*

Хәлил *(револьверны төзәгән килеш торып)*. Менә инде хәзер син минем кулда. Инде мин синең язмыш белән уйныйм. Бездән каласыңмы? Юкмы?

Галиябану *(Хәлилгә килеп ябышып)*. Ай, үзеңне харап итәсең. Ташла, зинһар! Атма дим, Хәлил! Ташла җиргә аны! Ташла, зинһар, ташла!

Исмәгыйль. Йә, күрсәт егетлегеңне.

Хәлил. Синең кебек этне атарга хурланам. *(Револьверны җиргә бәрә.)*

Исмәгыйль револьверга ташлана.

Ал, иманың булмаса, шул җиргә ташланган алтатарны!

Исмәгыйль. Кит, сөйләнмә! Тыясыңмы телеңне? Китәсеңме яхшы чакта?

Галиябану. Имансыз ук икәнсең!

Хәлил. Ник китим мин?!

Исмәгыйль. Китәсеңме дим?

Хәлил, ике бармагын авызына кабып, әче итеп сызгыра.

Исмәгыйль *(револьверын төзәп)*. Стоп! Ә, син шулаймыни?!

Галиябану *(кулын сузып, Исмәгыйльгә каршы йөгереп)*. Зинһар, Исмәгыйль абый!..

Исмәгыйль *(төртеп җибәреп)*. Кит моннан!

Галиябану *(аягына егылып)*. Кызган!

Хәлил. Ялынма ул эткә!

Исмәгыйль *(ачуыннан буылып)*. Ә, этме?!

Хәлил. Эт син! *(Кесәсеннән пәке чыгарып, Исмәгыйльгә һөҗүм итә.)*

Исмәгыйль. Мә, алайса! *(Атып җибәрә.)*

Хәлил чалкан килеп төшә.

Галиябану *(сикереп торып, әче тавыш белән кычкыра).* Ах!

Хәлилнең шаһитлары **Сибгать** белән **Хәмзә** йөгереп киләләр.

Хәмзә. Ни булды, ни булды?

Сибгать. Нишләде? Кем атты?

Хәлилне карыйлар. Хәлил газаплана. Исмәгыйль шашып кала. Качарга да, качмаска да белми. Галиябану Хәлилгә ташлана.

Хәмзә. Кем атты? Кемнән бу эш? *(Исмәгыйльгә бара.)*

Сибгать *(каты тавыш белән кычкыра).* Килегез! Кеше үтерделәр!

Исмәгыйль. Ник кычкырасың! Ул үзен үзе атты.

Галиябану *(күтәрелеп).* Хәлилне Исмәгыйль атты.

Исмәгыйль. Алдама!

Сибгать. Син аткансың, бәдбәхет!

Хәмзә *(читкә карап).* Бар, бар, Ибрай абзый, кире йөгер. Старшинаны чакырыгыз! Үтереш!

Исмәгыйль. Кара, миңа бәйләнмәгез!

Хәмзә. Хәзер күз алдында булган эшне танмакчы да буласыңмы? *(Барып ябыша.)*

Исмәгыйль *(селтәнеп).* Не смей миңа ябышырга!

Өй яктан күлмәк-ыштаннан гына **Бәдри**, эчке киемнәрдән **Галимә** йөгереп киләләр. [...]

Килүчеләр. Бу ни хәл? Ни булды? Нишләделәр? *(Хәлилне күреп чигенеп китәләр.)*

Галимә. Ай Аллам!

Бәдри. Бу ни эш? Бу кайсыгыздан?

Галиябану *(елап).* Хәлил җаным, үләсеңмени?..

Хәлил. Уф! *(Газаплана.)*

Хәмзә. Менә Хәлилне атканнар.

Бәдри *(Исмәгыйльне абайлап, үз-үзенә).* Ай, эшне бозган, ахры.

Йөгерә-йөгерә **старшина** һәм **ике кеше** керәләр.

Старшина. Нишләдегез? Ни булды, үтерешме?

Бәдри. Үзебез дә белмибез. Яңа чыгып шушы хәлне күреп торабыз.

Галиябану. Исмәгыйль атты. Тотыгыз атучыны!

Соңгы килгәннәр, гаҗәпләнеп, Исмәгыйльгә карыйлар.

Исмәгыйль. Минем атканым юк. Ул үзе атты.

Кайсылары Хәлилне барып карыйлар.

Старшина. Нинди эш бу? Өстендә булучы бармы? *(Хәмзәләргә.)* Сез монда кайчан килдегез?

Сибгать. Без әче сызгырган тавышны ишетеп килә идек. Килеп җиткәндә, алтатар шартлады. Без күргәндә, Хәлил шулай ята, Исмәгыйль, шашып, нишләргә белми торадыр иде.

Исмәгыйль. Мин атмадым. Миңа бәйләнмәгез.

Старшина *(җилкәсен сикертеп).* Гаҗәп! *(Хәлил янына барып.)* Җаны бармы?

Бер кеше. Бар.

Старшина *(Хәлил янында яткан пәкене табып алып).* Бу нинди пәке?

Исмәгыйль. Ул... пәке... Хәлил мине атмакчы булды да, мин, үземне саклар өчен, пәке алдым.

Галиябану *(кычкырып).* Ялган!

Старшина. Син сабыр ит.

Бәдри *(Галиябануга).* Тор, Галиябану, аннан! Сиңа алай утыру ярамый.

Галимә. Әйдә, Галиябану, өйгә керик.

Бәдри белән Галимә Галиябануны торгызалар.

Галиябану. Зинһар, ичмасам, соң сулуларында...

Бәдри *(ачуланыбрак).* Шаулама күп!

Старшина. Әйе, аны алып керсәгез дә ярый.

Хәмзә. Ник алып керергә? Бу эштә иң кирәкле кеше бит ул, алып китмәгез.

Бәдри ирексез туктый. Галимә Галиябануны тотып тора.

Старшина *(Исмәгыйльгә).* Ничек соң ул элек сине атмакчы булып, соңынтын үзе атылды?

Исмәгыйль. Мин сезгә үзе атылды дип әйтәм бит, нигә аны төпчеп сорыйсың? Мин үтергән дияргә сметь итәсезме әллә?!

Бер кеше. Исмәгыйль нигә алай эшләсен, әйе...

Старшина. Булуын булмас... та...

Галиябану. Аз гына Ходайдан куркыгыз, белә торып бер ерткычны яклыйсыз.

Бәдри. Тик тор дим.

Галиябану *(тайпылып, тырышып-тырышып).* Мине Исмәгыйльгә көчләп бирмәкче булдылар. Мин мәңге аңа булачак түгел. Үземне суга атып булса да, аңа бирелмәм. Мин Хәлилне генә сөям. Ул минем өчен үзен харап итте. Миңа биргән вәгъдәсен ул актык чиккә

кадәр саклагач, мин дә аның хакын мәңге сакләрмын. *(Галимәдән ычкынып, Исмәгыйльнең алдына ук басып.)* Әйт менә, мин үтермәдем дип, минем күземә карап, аны син үтердең! Син бит!

Исмәгыйль җавапсыз, Галиябануның күзенә карап торып калтырап китә.

Галиябану. Инде танмакчы буласыңмы? Аны син аттың! Син үтердең!

Исмәгыйль *(ирегeн җуеп)*. Әйе, мин үтердем.

Һәммә кешедә үзгәреш.

Бәдри. Ах, Исмәгыйль, бик зур хаталык.

Галимә. Өметсез үк икәнсең! Без сиңа бердәнбер алма кебек кызыбызны бирергә йөрибез тагы, син, алайса, кеше үтерүче икәнсең!

Исмәгыйль. Мин үтердем, мин аттым. Ачуымнан белешми аттым. Мин аны куркытмакчы гына булган идем, ул пәкесен чыгаргач, белешми атып җибәрдем.

Старшина *(бераз аптырап нишләргә белми торгач, кыймыйчарак)*. Алайса, без сине кулга алырга тиешлебез.

Сибгать. Үзе өстенә алып торганда, якламакчы буласызмы әллә?

Хәмзә. Тотыгыз атучыны!

Старшина *(Сибгатькә)*. Уйлап сөйлә, егет!

Хәлил. Уф!.. Үләм.

Исмәгыйль. Мин, бу эшне эшләвемә үкенеп, гаебемне муеныма алам. Судның туры хөкеменә бирeләм.

Старшина *(кешеләргә)*. Әйдәгез, без гаепләне алып китик!

Кешеләр Исмәгыйльне тоталар.

(Калучыларга.) Сез Хәлилне карагыз. *(Пәке белән револьверны ала.)* Өлгерсәм килеп җитәрмен, килә алмасам, өенә илтә торырсыз. Әйдәгез!

Китәләр.

Галимә. Без аңа кыз бирергә йөрибез тагы.

Бәдри. Шаулама инде!

Галимә *(Хәлилгә барып)*. Хәлил! Хәлил! Улым, хәлең ничек?

Хәмзә. Хәлил, Хәлил!

Башкалар да Хәлил янына җыела.

Хәлил. Үләм... *(Газаплана.)*

Галиябану *(елап)*. Хәлил, китәсең бит...

Галимә. И бичара, бичара. Болай ук булуын белмәдем лә, белмәдем...

Сибгать. Иптәш, Хәлил...

Хәлил. Галия... бану... *(Кулын суза.)*

Галиябану *(кулын тотып)*. Хәлил! Җаным!..

Хәлил *(газапланып күтәрелеп)*. Кил... Үләм...

Галиябану *(Хәлилнең башын кочагына алып, елап)*. Шулай ук аерылабызмыни?!

Хәлил *(өзеп-өзеп кенә)*. Инде үлсәм дә... үкенмим, Галиябану, сылуым... иркәм, җан... бирәмен... куе... ның... да... *(Үлә.)*

Галиябану. Үлде. *(Елый.)*

Галимә *(елап)*. И Ходаем, изге җаннардан ит!

Сибгать *(кулының тамырын тотып карап)*. И дускай, үлдең бит!

Хәмзә. Хуш, иптәш, мәңгегә!

Бәдри. Алып китәргә кирәк инде.

Галимә. Ипләп салыгыз әле.

Сибгать. Бәдри абзый, ат җигәргә кирәк иде.

Бәдри. Гыймади, бар, син тизрәк ат җик! [...]

Хәлилне сузып салалар.

Галиябану *(Хәлилнең янына тезләнеп)*. Хуш, җаным, Галиябануыңа кавышу шатлыгы урынына синең җеназаң өстендә елап утырырга туры килә инде. Хәлил! Күңелемнең иң тирән җиреннән, каршымда син бар вакытта гына килеп чыга алган, син «Галиябану» дип атаган көй минем бердәнбер юанычым булып калды. Моннан соң бу көйне сине сагынып җырлармын. Синең төсең итеп тотармын... Хәлил! Бу көйне синең өчен генә җырлый алган идем. Менә шушы җеназаң өстендә синең исемеңә мәңгелек бүләк итеп багышлыйм... *(Бу вакыт еракта скрипкада «Галиябану» көен уйнаган тавыш ишетелә. Һәммәсе дә тын гына тәэссер[1] белән тыңлап торалар. Бераздан Галиябану бик моңлы итеп кушылып җырлап китә.)*

---

[1]*Тәэссер* — әсәрләнү, дулкынлану.

Ак атласым җитмәде,
Алмас кайчым үтмәде;
Унөч яшьтән бирле сөешеп,
Күзебез күзләрдән китмәде,
Ходаем насыйп итмәде.

(Елап, Хәлилнең өстенә ава.)

Пәрдә төшә.

1918

Сораулар һәм биремнәр.

1. «Галиябану» драмасындагы конфликтны ачыклагыз. Үзара тартышта кемнәр нәрсә өчен тырыша?
2. Мәхәббәт — кешене күтәрә, үстерә, камилләштерә торган хис, дибез. Галиябану белән Хәлилгә карата бу фикернең дөреслеген раслагыз. Исмәгыйльнең Галиябануга мөнәсәбәтен сез ничек бәялисез?
3. Галиябану һәм Хәлил образларының беркадәр идеаллаштырылып бирелүен сезниләрдә күрәсез?
4. Хәлилнең үлеменә кемнәр ни дәрәҗәдә гаепле? Соңгы күренешне укыганда (яки спектакль караганда), кичергәннәрегезне үз сүзләрегез белән аңлатып бирегез.
5. Драма иске гореф-гадәтләрнең кайсы якларын кабул итмәү рухы белән сугарылган? Гасырлар буена килә торган гаилә тәртипләрен кайсы образлар гәүдәләндерә?
6. Ата-ана теләге белән генә кияүгә бирүне яки өйләндерүне сурәтләгән нинди әсәрләр беләсез? Аларның авторлары бу гадәт-йоланы хуплыйлармы, юкмы? Ни өчен?
7. Драмада икенче планда торган геройларны, ягъни ярдәмче персонажларны билгеләгез, аларга характеристика бирегез. «Бәдига» — гарәпчә «тәмле телле» дигән сүз. Язучы ни өчен карчыкка шул исемне куйган?
8. Әсәрдәге сәнгатьле детальләрне (хат, кульъяулык, шәл һ. б.) табыгыз. Аларның мәгънәсен, вакыйгалар үсешендә уйнаган ролен аңлатыгыз.
9. Драманың романтик рухы нинди алымнар һәм чаралар ярдәмендә барлыкка китерелә һәм көчәйтелә?

Мәхәббәт моңы

> Беренче мәртәбә диярлек һичбер буяусыз, саф булганча, үзләренең уен-көлкеләре, җырлары, музыкалары, гыйшыклары, интригалары, бәетләре, көрәшләре белән крестьян егетләре, крестьян кызлары бу әсәр аркылы безнең театр галәменә килеп керәләр.
>
> *Г. Ибраһимов*

Бу әсәрен Мирхәйдәр Фәйзи «Сәгадәтбану» исеме астында 1916 елның көзендә язып тәмамлый, әмма кат-кат төзәтә, икенче елны да әле үзгәрешләр кертә. Әсәрнең исемен дә алыштыра: мәхәббәтенең ахыры үкенечле беткән кызга «сәгадәт» (бәхет) сүзе, чыннан да, туры килми.

Пьесада Галиябану һәм Хәлил мәхәббәте тасвирлана. Укучыны да, пьеса сәхнәдә уйналган вакытта тамашачыны да шуның язмышы кызыксындыра, сөю хисе сокландыра һәм дулкынландыра. Дулкынландыра да, тетрәндерә дә, чөнки яшьләрнең сөешүләре тормышның кырыс сынавына дучар була. Гашыйкларның хисе сынауга түзә, ләкин вакыйга фаҗига белән тәмамлана.

Мондый фаҗигагә нәрсә китерә соң? Ягъни матур һәм үрнәк мәхәббәткә нәрсә каршы килә, туачак бәхетне нәрсә җимерә? Икенче сүз белән әйткәндә, драмада каршылык (конфликт) нинди җирлектә туа? Каршылыкка кергән көчләрне, шул көчләрне гәүдәләндерүче кешеләрне (персонажларны) ачыклагач, аларның теләк-омтылышларын аңлагач, моңа җавап бирергә мөмкин.

Үзәктә, билгеле инде, Галиябану образы тора. Әсәр юкка гына аның исеме белән аталмаган (шуның белән дә хатын-кызның зур ихтирамга һәм мөстәкыйльлеккә лаек булуы ассызыклана). Автор моннан тыш та аңа аерым илтифат иткән: моны раслаучы сыйфат-билгеләре бар. Кызның бик матур булуы өстенә, әтисе сүзләре белән әйткәндә, аңа «акылын, фигылен, белемен, җитезлеген, үткерлеген Ходай "мә сиңа" дип биргән дә куйган». Бөтен авылның моңына әйләнгән, соңыннан үз исеме белән атала башлаган көйне дә бит нәкъ менә Галиябану чыгарган. Бердән, бу факт-деталь ике яшьнең мәхәббәт хисе никадәр көчле булуын искәртеп тора. «Беркөн кайдан, күкрәгемнең кайсы җиреннән алып кына җырладым икән соң мин бу көйне?» — ди Галиябану. Җавап бер генә:

мәхәббәт рухландырган аны. Һәм, икенчедән, күркәм сыйфатлары өстенә Галиябану иҗатка да сәләтле кыз икән. Юкка гына автор аның исеменә «өстен» дигән мәгънә салмаган, күрәсең. «Галия» — гарәп сүзе. Ул — «бөек, өстен, югары» мәгънәсен, «бану» кәләш дигәнне аңлата.

Хәлил — һәрьяктан кызга тиң егет. (Гарәпчә «хәлил» — сөйгән яр, якын һәм чын дус.) Ыспай киенгән «матур егет» булу өстенә, ул — оста гармунчы, ә гармунчының ул заманнарда абруе бик зур. Ул батыр һәм тәвәккәл, сөйгәне өчен утка керергә дә әзер. Саф күңелле кешегә хас булган табигый горурлык та, башкаларга яманлык эшләми торган кешегә хас булган беркатлылык һәм тәҗрибәсезлек тә бар аңарда. Кулына револьвер эләккәч тә, аны җиргә ташлавы шул турыда сөйли. Югыйсә, бераз гына тәҗрибәсе булса, ул аны кесәсенә салып, кызны алып чыгып китәр иде.

Ике гашыйкның бәхетенә Исмәгыйльнең «Кыз минеке булырга тиеш» дигән теләк-ышанычы каршы төшә. Монда төп терәк һәм таяныч — байлык.

Әйе, байлык, акча һәр җәмгыятьтә зур көчкә ия. Югары әхлак, намус һәм зыялылык кебек сыйфатлар акчаны һәм байлыкны авызлыклап, файдалы, изге эшләргә юнәлтеп торалар. Ләкин еш кына байлык ияләре шундый сыйфатлардан мәхрүм булалар. Ни өчен? Чөнки еш кына байлык һәм акча михнәтсез рәхәт тормыш бирә. Бигрәк тә хәрам мал, тир түкми генә табылган байлык шулай.

Эшсез тормыш кешене еш кына рухи яктан гарипләндерә. Исмәгыйль — әнә шулай бозылган егет. Байлык биргән зур хакимият аның күңелен гарипләндергән, башкаларны буйсындырырга, аларның теләкләре белән исәпләшмәскә «өйрәткән».

Шулай да байлык үзе генә бу чын һәм саф мәхәббәт каршында хәлиткеч көч була алмас иде әле. «Аның кызыксыз байлыгына бер дә исем китми...» — дип кистереп әйтә Галиябану. «Кызыксыз», ягъни файдасыз, чөнки аның иясе юньле кеше түгел. Монда Исмәгыйльнең байлыгына ярдәмгә иске гореф-гадәтләр килә. Байлык, акча Бәдри белән Галимәбануны исертә, искелеккә, хатын-кызны колга әверелдерә торган гаилә тәртипләренә ябышырга мәҗбүр итә. Соңгысы мәхәббәт тарихын фаҗигале финалга китерә.

Шулай итеп, драмада **конфликт** байлыкка табынган, акча һәм дәрәҗә хатын-кызны бәхетле итә дигән иске караш-ышаныч белән кешедәге иң самими хисләрдән берсе булган

мәхәббәт арасында оеша. Искелек гәүдәләнеше булып Исмәгыйль һәм Бәдри тора.

Татар драматургиясе иң беренче әсәрләре белән үк хатын-кызга карата урнашкан иске карашларга каршы чыга. Мәсәлән, «Галиябану»га кадәр 30 ел элек басылган «Бичара кыз» (Габдрахман Ильяси әсәре) пьесасында үзәктә мәгърифәт һәм байлык бәрелеше тора, аң-белемле яшьләр җиңеп чыгалар. Байлыкка кызыгып ирексезләү хатын-кызны харап итә дигән фикер уздырыла.

Бәдри — гади бер крестьян. Ул — ипи-тозлык кына укый-яза да белә, тырыш, исәпле кеше. Хатынына һәм кызына карата да без аны начар яки тупас мөгамәләдә дип әйтә алмыйбыз. Аның байлыкка омтылуы, җае чыгып торганда, мең тәңкә эләктереп калырга тырышуы да табигый. Ләкин кызы язмышын хәл итүдә Бәдри иске тәрбия корбанына әйләнә, фаҗига булуга ярдәм итә. Ягъни Бәдри характерында (менәзендә) каршылыклар бар, бер Бәдридә ике Бәдри яши. Шулай да ул, Исмәгыйль кеше үтерер, шундый ерткыч булыр, дип башына да китерми. Әгәр дә мондый фаҗига буласын белсә, ул, айһай, кызын шулкадәр яратмаган кешесенә кияүгә чыгарга кыстар идеме икән?! Галимәбануга килсәк, ул Исмәгыйльгә турыдан-туры: «Өметсез үк икәнсең! Без сиңа бердәнбер алма кебек кызыбызны бирергә йөрибез тагы, син, алайса, кеше үтерүче икәнсең!» — ди; «Болай үк булуын белмәдем лә, белмәдем...» — дип өзгәләнә, Хәлилгә «улым» дип яратып эндәшә.

Димәк, Бәдри белән Галимәбану өчен дә беренче урында байлык түгел, ә миһербанлылык, кешелеклелек тора икән. Кыскасы, бу ике образда крестьян менәзендәге каршылыклар дөрес һәм тулы чагылыш тапкан.

Кеше үтерү Исмәгыйльнең үзе өчен дә көтелмәгән бер хәл булып чыга. Ул «шашып кала», соңыннан гаебен өстенә ала. «Мин аны куркытмакчы гына булган идем, ул пәкесен чыгаргач, белешми атып җибәрдем»,— дип аклана. Димәк, кешелек тойгылары бу егеттә дә бөтенләй үк үлеп бетмәгән икән әле.

Драматург аңлашылмаучылыкларга һәм төрле очраклылыкларга, сәнгатьле детальләргә зур урын бирә. Иң җитди аңлашылмаучылык,— әлбәттә, Бәдриләрнең баштан ук кызлары Исмәгыйль белән очраша дип уйлауларында. Үзләре уйлаганның тормышка ашуын шулкадәр нык телиләр алар, бу теләк ышанычка ук әверелә. Монда аерым очраклылыклар һәм детальләр дә ярдәмгә килә (Исмәгыйльнең ертып таш-

ланмаган хаты, чигүле кульяулык, яучының булачак кияү исемен атамавы һ. б.). Болар һәммәсе драмадагы вакыйгаларның тормышчанлыгын арттыра.

Мәгълүм булганча, реалист язучылар кешеләрне ничек бар, шулай сурәтлиләр. Ә романтиклар исә кешеләр ничек яхшы (яки начар) булырга тиеш һәм мөмкин, шулай үстереп, арттырып сурәтлиләр. Шул яктан килеп караганда, М. Фәйзи үз геройларын тормыштан бөтенләй үк аермаса да, кайбер сыйфат-фигыльләрен арттырып тасвир итә. Геройларның үзара мөгамәләләрен дә аерым урыннарда матурлап, нәфисләп күрсәтә. Мәсәлән, инде алда әйтелгәнчә, Галиябану һәм Хәлилне чибәр, уңган, тәвәккәл итеп сурәтләү өстенә музыкаль сәләткә ия кешеләр итеп бирә. Аларның үзара сөйләшүләре дә нәфис, нәзакәтле.

Әсәрнең музыкаль драма булуы да аның романтик рухын көчәйтә. Җыр текстларында, матур сүзләрдә кешегә, кеше хисләренә хөрмәт бөркелеп тора. (Исмәгыйль җырлаган бер куплетны искә алмаганда.)

Җыр һәм музыкага мөһим урын бирелгән «Галиябану» әсәре әдәбиятыбызда һәм театрыбызда яңа жанр төре ачып җибәрде: ул —бездә **музыкаль драманы** башлаган әсәрләрнең беренчесе һәм күренеклесе.

Сәнгатьчә эшләнеше камил булуы, кешене уңай сыйфатлары белән, матур итеп сурәтләве ягыннан М. Фәйзинең бу әсәре татар драматургиясендә күренекле урын тота. Ул бүген дә профессиональ сәхнәләрдә дә, үзешчәннәр тарафыннан да яратып уйнала.

Шәриф Камал

(1884—1942)

Татарда эшче сыйныф XX гасыр башында тәмам оешып җитә. Аның партияләре көрәш мәйданына чыга. Эшче сыйныфның тормышын үзенә төп тема итеп алган язучылар күренә башлый. Эшчеләрнең теләк-омтылышларын, яшәү үзенчәлекләрен, аерым җитешсез яклары белән бергә аларның күркәм сыйфатларын да сурәтләүгә алынган язучылар арасында Шәриф Камал күренекле урын били.

Шәриф Камалетдин улы Байгильдиев хәзерге Мордва Республикасының Пешлә авылында мулла гаиләсендә дөньяга килә. Башлангыч белемне үз авылларында ала, аннары күрше авыл мәдрәсәсендә укый башлый. Шуның белән булачак язучы кырыс табигатьле атасы тәэсиреннән котыла. Мәдрәсәне ташлап, ул Ригага, аннары Истанбул, Каһирә якларына китә. Ике ел укыганнан соң, туган якларына кайтып, мөгаллимлек итә. Яңадан чит җирләргә чыгып китә: шахталарда, балык промыселларында, тимер юл төзелешләрендә эшли. 1905 елгы революция давыллары вакытында Петербургка барып чыга, балалар укыта, «Нур» газетасында корректор[1] була. Белем алуын да дәвам иттерә, гимназиянең 4 сыйныфлык программасы буенча, үзлегеннән әзерләнеп, имтихан тапшыра.

Бу чорда Шәриф Камал беренче иҗат тәҗрибәләрен ясый. Шигырьләр һәм мәкаләләр язып, «Нур» газетасында бастыра, «Сада»[2] исемле шигырьләр китабын чыгара.

[1] *Корректор* — хәреф җыйганда киткән хаталарны төзәтүче.
[2] *Сада* — тавыш.

Иҗатын, туган авылына күченеп кайтып, балалар укытканда да дәвам иттерә. Ләкин инде ул хәзер проза жанрына күчә. 1909 елда беренче хикәясе «Уяну»ны яза, аны Оренбург шәһәрендә чыга торган «Шура» журналында бастыра. Озакламый без инде аның үзен дә Оренбургта күрәбез: өйләнеп, авылында беркадәр яшәгәч, Шәриф Камал Урта Азия якларына дип чыгып китә, ләкин юл уңаенда Оренбургка кагыла һәм шунда урнашып та кала, «Вакыт» газетасында корректор булып эшли башлый. Монда һәм Октябрь революциясеннән соң шәһәр янындагы Чебенле авылында ул 15 ел яши. Шул чорда иң күренекле әсәрләрен — күп санлы хикәяләрен, фельетон һәм мәкаләләрен, «Акчарлаклар» повестен һәм «Хаҗи әфәнде өйләнә» исемле комедиясен иҗат итә.

Язучы гомеренең соңгы еллары Казан белән бәйләнгән. Ул монда газеталарда, төрле оешмаларда эшли. Шул ук вакытта актив иҗат итә: «Таң атканда», «Матур туганда» романнарын, дистәләгән хикәя, 6—7 пьеса яза, матбугатта мәкаләләр белән чыгыш ясый. Татар әдәбияты һәм сәнгате өлкәсендә куйган зур хезмәте өчен аңа «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелә.

Бөек Ватан сугышын «Без җиңәчәкбез!» исемле ышаныч мәкаләсе белән каршылаган, «Ныклы адымнар» исемле яңа роман, «Сафура» дигән драма яза башлаган язучының йөрәге кинәт тибүдән туктый. 1942 елның декабрендә күп санлы укучылары аны соңгы юлга озаталар.

«Акчарлаклар» повесте турында

Язучы бу әсәрен 1914 елда бастырып чыгара. Аның үзәгендә — сезонлы эшчеләр. Алар Каспий буендагы балык промыселларының берсенә март ахырында килеп эшкә ялланалар, апрель ахырларына кадәр эшлиләр. Аннары, балык тоту вакыты үтеп монда эш беткәч, эш эзләп төрле җирләргә таралалар. Ләкин шул барлы-юклы бер ай эчендә алар берберсенә күнегеп, бер-берсенең гореф-гадәтләрен, әйбәт һәм начар якларын белеп-өйрәнеп, дуслашып өлгерәләр.

Повесть күләме ягыннан артык зур түгел. Әмма зур булмаган мәйданда да язучы төрле-төрле вакыйгалар оештыра, берничә характер тудыра, вакытлы эшчеләрнең уй-хыялларын, теләк-өметләрен ача, үзара мөнәсәбәтләрен җанлы итеп күрсәтә. Укучы берничә кеше белән якыннанрак таныша. Алгы планда тәвәккәл, намуслы һәм укыган Гариф белән мөлаем һәм

самими Газизә, аларның үзара мөнәсәбәте тора. Алар арасында бөреләнә генә башлаган мәхәббәт саф булып, кешене күтәрә торган матур хис-тойгы булып күңелгә сеңә. Тәҗрибәле, кешелекле Шәрәфи карт белән аның карчыгы — тугрылыклы һәм басынкы Сәгыйдә дә — чит-ят җирләрдә бәхет эзләп йөрергә мәҗбүр ителгәннәр. Соңгысы аларны Солдат һәм Сафа, Николай һәм Федор кебек «зимагурлар» белән якынайта. Барысын да берләштерә торган нәрсә исә — бәхет эзләү, тормышларын алга таба җайга салырлык акча эшләп табарга тырышу. Менә ни өчен мондыйлар ил буйлап сибелгәннәр, ныклы гына яшәү урыннары юк, бер урыннан икенче урынга күченеп, акчарлаклар кебек «очып» йөриләр икән.

Бәхеткә өметләре киселә торса да, вакыт-вакыт тупасланып китсәләр дә, эчеп исерешү кебек начар гадәтләргә бирелгәләп алсалар да, бу геройлар кешелек сыйфатларын җуймаганнар, кешелекле, эшлекле, эчкерсез һәм ярдәмчел булып гәүдәләнәләр. Алай гына да түгел, алар нәкъ менә шул сыйфатлары белән укучы күңеленә якын. Шул сыйфатлары белән татар халкының данын саклап, башка милләт вәкилләре алдында да үзләрен тиешле дәрәҗәдә тота беләләр. Промысел хуҗасы, мәсәлән, эшчеләр арасыннан татарларны танып алып: «Ә, князьләр икән... Яхшы халык... яратам мин аларны, эшчән булалар»,— дип билгеләп уза.

Повестьның сәнгатьчә эшләнеше ягыннан төп үзенчәлеге — кешенең эчке дөньясын төгәл ачып бирү. Автор, рухи кичерешләрне сурәтләгәндә, җанлы һәм җансыз табигатькә еш мөрәҗәгать итә. Монда ул уңышлы чагыштырулар таба, кеше белән табигать күренешен яки предметларны янәшә куеп сурәтләп, кеше психологиясен тулырак һәм тәэсирлерәк чагылдыра.

... Әнә әле эш башланмаган, балык күпме эләгер дә, акча күпме төшәр. Ләкин эшчеләрнең өметләре зурдан, әлегә якты. Шуны түбәндәге җөмлә шактый тулы чагылдыра:

«Сыек кына томан белән өртүле диңгез өстендә очынып йөргән акчарлакларның гыйгылдап көлгән шикелле үткен һәм күңелне кытыкландыра торган тавышлары диңгез өстендә асылынып торган әллә нинди тылсымлы сарайлардан ишетелгән шатлык шаркылдауларына охшый иделәр».

Алга таба акчарлаклар да әйтерсең бу кешеләрнең өметсез теләкләренә төшенәләр, аларның җанын аңлыйлар. Шуны әсәрнең уртасында язучы болай сурәтли:

«Очы-кырые күренми җәелеп яткан матур диңгез өстендә әллә нихәтле акчарлаклар, өермәгә эләккән яфраклар төсле, буталып

очыналар һәм, акылдан шашкан кешечә эчләре катып көлгән яисә үчегеп ярсыган шикелле гыйгылдап, йөрәкләрне кытыкландыралар. Әллә алар шушы сәләмә кешеләрнең дә аларның үзләре кебек оча алмауларыннан һәм тамаклары өчен борыннары белән җиргә абынып тырмануларыннан көләләр, әллә болар балыкны бетерәләр дип көнләшә һәм үчегеп елыйлар...»

Ә инде балык сезонын ябып, башка чит-ят тарафларга юл тоткан эшчеләрнең җимерелгән хыял-өметләрен түбәндәге күренеш ачык чагылдыра:

«Диңгез өстендә сирәк-саяк акчарлаклар күренгәли; алар, ак канатларын селтәп-селтәп, бер югары, бер түбән очып, тонык һәм эчпошыргыч тавыш белән елаганга да, көлгәнгә дә охшашлы гыйгылдап-гыйгылдап кычкырыналар... Газизә хәзер аларны карамый, ул диңгез кырые буйлап очмыйча гына китеп барган «канатсыз акчарлаклар»ны гына карый иде... Тик боларның тавышлары гына, үкереп елаган шикелле булып, аның колагында чыңлый иде».

Әсәр 11 бүлектән тора. Аларның һәрберсенә исем куелган. Бу исемнәрдә бәхет эстәп йөрүчеләрнең өметләре дә, эчке дөньялары, рухи халәтләре, кичерешләре дә чагыла: «Диңгез көлә», «Яшь күңел», «Йокла, бәбкәм», «Мин сине көтәрмен» һ. б.

Дәреслектә повестьның «Егет елый» исемле бүлеге генә алынды.

АКЧАРЛАКЛАР

Егет елый

Невод[1] сала башлаганнан соң, бер атна буе эшләр бер көйлерәк барды: балыкның чыгуы биш-алты тачкадан артмады. Невод һәркөн ике мәртәбә салына, җил булып, диңгез дулкынланыбрак китсә, бер белән генә дә калына иде...

Беркөн төш алдында, беренче неводны чыгаргач, нык кына җил кузгалды. Көн иртәдән бирле болытлы булып, инде диңгездә давыл булырга охшый иде, шунлыктан барактагы егетләр, бүген инде икенче мәртәбә невод салынмас дип уйлап, төш ашыннан соң кайсы йокларга ятты, кайсылары шашка уйнарга тотындылар.

---

[1] *Невод* — җылым, балык тота торган зур ятьмә.

Бервакыт Исак барак ишеген ачты да аптыраган тавыш белән киреле-соңлы җикеренергә тотынды:

— Чыгыгыз, әйдә тизрәк! Неводка әйдә! Аркан ычкынган! Неводка тизрәк! Неводка, дим! Уят шуларны!.. Тизрәк әйдә!.. Давыл кузгалды!

Ул ишекне япмыйча ук, тавышлый-тавышлый китеп барды. Сафа белән Хәйрулла шашка уйнап утыра иделәр.

— Аптырадыңмыни, шайтан! — диде Сафа.— Давыл кузгалса, невод салдырмыйлар аны! Бәдбәхет!

Гариф өч-дүрт иптәше белән алдан китте. Башкалар да, кискен җилгә ян биребрәк, бөкрәйгән көе, тегеләр артына ялганган иделәр. Лабаз артыннан әйләнеп үткәч, кинәт бик газамәтле[1] күренеш алдына чыктылар. Диңгез кузгалган... Күз күременчә зур су түтәлләре, ак күбекләр пошкырып, бер-берсен куа киләләр... Күктә каралҗым болытлар ага, диңгез артларын соры томан каплаган...

Солдат кычкырып җибәрде:

— Их! Карагыз, көймәне кайда илтеп ташлаган!

Сафа алга карады да күтәренке тавыш белән:

— Неводны харап итә, егетләр! — диде. Һәм үзе, Николайны иңсәсеннән этеп, сикерә-сикерә йөгереп, неводчылар җыелган җиргә китте. Вал янында һичкем юк, неводчылар, гадәттә, невод чыга торган урыннан йөз илле саженьнар[2] чамасы ерак киткәннәр иде.

Сафа артыннан башкалар да йөгерешеп киттеләр. Тик Николай белән Хәйрулла гына, кешегә иярмәгән булып, бер үк көйгә, йөгермичә генә, селкенә-селкенә бардылар. Азрак баргачтын, алар да юыртып киттеләр.

Неводчылар янына иң элек барып җитүчеләр Сафа белән Гариф булды. Исак белән Шәрәфи агай һәм Абрам да анда иделәр. Гадәттән тыш аптырау, кычкырыш бара иде. Читтән биш-алты саженьлап эчтә невод көймәсе әллә ничә уңайга бәргәләнеп, чайкалып тора, көймәдә биш-алты кеше — невод салучылар, йомычка кисәгенә ябышкан булдыксыз һәм кызганыч тараканнар шикелле, аумаска, ычкынып китмәскә тырыша иделәр. Ухылдап торып килгән дулкыннар,

---

[1] *Газамәт* — тантана, мәһабәт.

[2] *Сажень* — озынлык үлчәве берәмлеге, 2,13 метр чамасы.

бер бәреп, көймәне югары сикертә, кире кайтып, комга утыртып куя, тагын бәрә дә тагын сикертеп җибәрә... Койрыктагы курщик[1], бер кулы белән руль тоткасына ябышып, аяктан егылмаска тырыша, икенчесен бутап-бутап, бар көче белән кычкыра, кемнедер сүгә. Монда Исак үзалдына, кеше саен, акылдан сапкан кешечә җикеренеп йөри, кеше саен бәйләнә.

Гариф, Шәрәфи карт янына барып:

— Нәрсә ул, ни булган? — диде. Теге, салкын кан белән генә:

— Арканны ычкындырганнар, курщик тагын дүрт ишкәкче сорый, баручы юк! Эт эткә, эт койрыкка җибәрә...— диде.

Гариф кинәт, кирәкле хәбәр ишеткән төсле, күзләрен уйнатып:

— Мин барам! — диде. Һәм сикереп үк су янына йөгерде. Шәрәфи агай, ашыгып ук:

— Тукта әле,— дисә дә, тегеңәр ишеттерә алмый калды. Артыннан барып тотарга кешеләрдән яхшысынмады. Шулай да акрынлап барып, кешегә сиздермичә, тегенең чабуыннан тарту нияте белән урыныннан кузгалып, тегеңәр юнәлгән иде, ни күрсен: дулкын эчкә кайткан арада, Гариф, сикереп торып, көймәгә ташланды һәм көймәнең читенә барып асылынды... Көймәдәгеләр аны тартып алырга маташканда, тагын килеп дулкын бәрде дә Гарифны муеннан ук эләктерде; шулай да ычкындырмыйча, аны көймәгә тартып алдылар. Аңар иярүчеләр дә тиз табылды, бер-бер артлы өч кеше, шундый ук маневрлар ясап, көймәгә керделәр. Җансыз сөяк кебек чайкалып торган шактый зур көймә кирәкле кешеләрен алгач та җанланды: өч пар ишкәкне алты кеше бер уңайга күтәреп сала башлагач, ул, килешсез кара бер җанвар кебек, дулкыннар белән көрәшә-көрәшә, эчкә таба үрмәләп китте. Ул, читтән ераклашкан саен, көчсез һәм кызганычрак күренә, гүя хәзер батарга, югалырга тора иде. Бераздан соң бер батып, бер калкып уйнаган кармак калкавычы рәвешендә генә күренә башлады.

Җил улый, сызгыра, диңгез һаман дулкынлана, дулый бара иде.

---

[1] *Курщик* — невод (җылым) көймәсен турылаучы.

Исак белән Абрам халыктан читтәрәк йөреп торалар, неводчылар, бергәрәк җыйналып, шау-шусыз гына карап торалар, диңгез дулкыннары арасында бата-чума күренеп барган иптәшләрен күздән югалтмаска тырышалар. Гарифның иптәшләре дә, аптыранып, Шәрәфи агай янына җыелышканнар, аның авызына карыйлар, ул акрын гына Исакны сүгә:

— Кабахәт нәрсә, хәерсез! Ничек буласы төш вакытында ук билгеле иде бит. Кирәкми дим, невод салдырма, давыл күтәрелә! Юк, тыңламый бит, шайтан! Менә хәзер дә аркан ычкынган икән, бер яктан гына тарттырасы, ярты сәгатьтә эш бетә! Исак Абрамеч, дим, шулай гына итик! Юк, имеш, алай невод ишелеп, чуалып бетәр... Невод чуала дип, кешеләрне күрәләтә батарга җибәрә, мәлгунь!

Ул, бераз туктап торгач, көлгәнрәк тавыш белән:

— Ул, йөзе кара, шушы минутта да балык өчен тырмана, невод чуалуы сылтау гына... Бер яктан тартып невод бер дә чуалмый... Аны ул үзе дә белә... Тик әле балык килеп тыгылмасмы дип уйлый! Ну әле аңар иртәрәк шул,— диде.

— Балык булса соң, аңар нәрсә? — диде Солдат.

— Аңармы нәрсә? Пае[1] бар ич, юккамы шулхәтле тырыша дип беләсең? Ул үзе өчен тырмана, господин унтер. Менә элекке курщикны җибәреп карар идең шундый җәһәннәмгә, «пошел ты к чорту» дип кенә җибәрер иде үзен! Монысы бозау шул, хәерсез... Үзенең иптәшләренә бугазын ертканчы акыра да, хуҗага яхшы күренә, имеш, дурак касалапый! Гариф тагы нәрсәгәдер юләрләнеп китте. Минем аңар ачуым килә! Тотып та өлгерә алмадым, ичмасам...

Сафаның көләч йөзе үзгәргән, уйчан һәм кайгылы төс алган иде, ул кинәт кенә:

— Батарлар микәнни? — диде.

— Ходай язмасын, батмасыннар иде дә... Әнә карагыз, нишләтә көймәне! Рулевой авызын ачмаса, шулай да котылырлар... Инде авыз беләнрәк караса — бетте диген! Борылганда дулкын буена калып, шомарак әйләнмәделәрме — бәрә дә каплый! Шома маташканда, бу давыл гына әле ул хәтле куркыныч түгел...

---

[1] *Пай* — өлеш.

Николай, руслар арасыннан аерылып, болар янына килеп туктады һәм Исак белән Абрамга таба карап алды да, нык кычкырмыйча гына:

— Дурак безнең артельщик,— диде.— Ул төшмәсә, тегеләр берсе дә төшәселәр түгел икән...

Ул, тавышын тагын да акрынайтып:

— Беләсез, тегеләр нәрсә, ди... Әгәр көймә кайтмаса, әнә теге ике господинны, буып, суга ташламакчы булалар,—диде.

Шәрәфи агай, әкрен генә борылып, тегеләр ягына карады да, бик читен бер мәсьәлә турысында уйларга керешкән төсле иттереп:

— Әһем...— дип алдына карады.

Солдат Николайга:

— Һәммәбезгә дә каторга ич ул чагында...— диде.

Николай, җавап бирмичә, иңбашларын гына тартты. Шәрәфи агай, җилгә каршы торып яшьләнгән күзләрен кул аркасы белән сөртеп, бераз вакыт алга таба карап торгач:

— Кайтырлар, Алла боерса... Инде борылганнар да бугай... Карагызчы яхшылап,— диде.

Еракта дулкыннар арасында бер югалып, бер калкып торган көймә һаман да бер урында төсле күренә, кырыйга елышканлыгы да, эчкә таба китеп барганлыгы да күренми иде. Шәрәфи карт аның кире борылганын болай чамалап кына әйткән иде, күрәсең.

Байтак вакыт шулай тынычсызланып торганнан соң, кешеләргә җан керә башлады: көймә кайтып килә иде. Көймә һәм көймәдәгеләр тере күренәләр, юлны кыеграк тотып, лабазга таба чыгарга азаплана иделәр.

Инде Шәрәфи агайның да чырае ачылды:

— Маладис, Әндрюша! — дип, койрыкчыны мактап куйды. Көймә һаман якынлый иде; ул тискәре һәм усалланган дулкыннар белән җан-фәрманга көрәшеп килә; бер дулкын сыртыннан алга сикереп киткәндә, икенчесе, бәреп, аны артка чигерә, ул тагын алга үрмәли, тагын сыртка күтәрелә, тагын сикерә, тагын үрмәли иде... Шәрәфи карт, баскан җирендә тора алмый кулларын уыштырып:

— Ризамын, егетләр! Шулай кирәк! Юләр бул да егет бул. Батып калсагыз сүгәр идем, инде, афәрин, шайтан икәнсез! — дип сөйләнә-сөйләнә йөри иде.

Хәзер инде көймә булдыксыз, кызганыч ябалак кебек түгел, йөрәкле карчыга шикелле матур һәм сөйкемле күренә иде. Көймәдәге егетләр дә көчсез һәм йомшак тараканга түгел, гайрәтле үткен кырмыскаларга охшый иделәр.

Гөрләвек дулкыннар арасында зирәк кош кебек очакалка килгән көймә, кылкынып ук көтеп торган халык алдына килеп, көчле бер дулкын селтәве белән кырыйга үрләшеп, шып итеп туктады. Арттан килгән дулкыннар да инде аны кузгатып ала алмый иделәр...

Исак, аларның күңелләрен күтәрер өчен:

— Молодцы, ребята! — дип кычкырган булды. Ләкин аңар әһәмият бирүче булмады; тавышын ук яратмый иделәр... Халыкның бер өлеше тиз-тиз генә көймәне корыга сөйри башлады, бер өлеше валга йөгерде. Тачкачылар Гарифны урап алганнар иде. Ул утырып итекләренә тулган суларны түккәч, Шәрәфи агай, аны читкәрәк тартып:

— Күлмәк-ыштан бармы? Тиз генә барып алмаштыр... Булмаса, мин бирим... Бездән барып ал...— диде. Гариф оялгансыман көлемсерәде:

— Бар, Шәрәфи абзый, үземдә бар, борчылмагыз, зинһар...— диде.

— Ну бар, тиз генә алмаштыр да безгә кил, ишетәмсең, йомыш бар... Йөгер инде, әйдә, тиле.

Николай чын эч фикере белән:

— Аңарга хәзер берәр чәркә аракы кирәк иде. Юкса, шиксез, бизгәк эләктерә! Исак ул коры теле белән генә мактаган була, хәерсез! — диде.

Гариф көймәдә бертуктамый көч биреп ишкәнгә күрә кызган иде. Көймәдән төшкәч тә, ул кадәр салкынлык хис итмәде. Әмма баракка килеп кергәч, баракның бушлыгы, шакшылыгы, нар буена җәелгән салам урыннар, озын такта өстәл буенда чәчелеп яткан чүп һәм икмәк валчыклары, нәкъ уртада асылынып торган иске лампа, диңгезгә караган бер генә тәрәзә, әлхасыйль[1], баракның барлык эч күренеше гүя аның йөрәгенә боз булып утырдылар. Ул калтырана, туңа башлады. Бигрәк тә тәрәзәнең бозылган бер күзеннән улап кергән җил тавышы белән бергә тонык һәм тирәннән гөжләп килгән дулкын тавышлары, аның

---

[1] *Әлхасыйль* — җыеп әйткәндә, кыскасы.

эчен чымырдатып, чәчләрен терпәйттерә иделәр. Ул коры күлмәкләр киеп алгач, Солдатның баш очындагы запас чолгауларын һәм дә үзенең, иске генә булса да, коры һәм йомшак пальтосын бик зур рәхмәт хисе белән, әүвәлгеләрне итек астыннан, соңгыны күлмәк өстеннән эшкә кертте. Һәм дә тиз үк Шәрәфи агайның җылы һәм уңайлы өен күңеленә китерде...

Ул баракта чыккач, үткен җил улавы арасыннан диңгез гөрләүләре белән бергә неводчыларның һай-һу тавышлары ишетелеп, аның күңелен әллә нишләтеп, борчып җибәрделәр; кешеләр ду килеп акыра-бакыра вал әйләнәсендә йөгергәндә, диңгез «чылбырдан котылган аждаһа» кебек котырганнан-котыра барганда, ул ялгыз гына, хәстә кеше кебек, пальтога төренеп йөрсен, имеш...

Бара-бара җилгә янтыгы белән әйләнеп көлемсерәде дә,якыннан барган бер иптәшенә сөйләгән кебек: «Бабай һәйбәт кеше безнең... Теләсәң күлмәк-ыштан да киертә! Әх, бабай, бабай, күп яшә!» — диде. Ул бер исәп белән туры неводчылар янына китәргә дип тә уйлаган иде, ләкин картның чакыруын илтифатсыз калдырырга уңайсызланды.

Бу ишектән керүгә, Шәрәфи агай, кадерле бер кунак көткән кебек, каршы ук алды.

— Әйдә, Гариф, әйдүк, туган,— диде.

Газизә бер читтәрәк нәрсәдер тегү, чәнчү белән утыра. Карчык анасы самовар куеп маташа иде. Шәрәфи агай аларга бүгенге эш буенча да Гарифның юләр егетлеген сөйләгән, ул ишектән кергәч тә, гүя көтүдән адашкан тәкә кайтып кергән кебек булды. Карчык белән Газизә аңа гаҗәпләнгән сымак көлемсерәп карадылар. Гариф бераз кызарынды. Өстәлдә ярты савыт аракы, бер чәй чынаягы утыра иде. Гариф утырмас борын ук Шәрәфи агай бәрәкәтле генә иттереп чынаякны тутырып куйды да, җитди генә чырай белән:

— Әйдә, эчеп җибәр шуны! — диде.

Гариф, аның күзләренә карап, аптыраган сымак:

— Юк, Шәрәфи абзый, мин бит ул нәрсәне эчми идем,— диде. Ул ялганлады; электән эчкәли иде. Әмма хәзер хатын-кыз алдында уңайсызланды. Аларның яхшы карашларын сындырырга теләми иде.

Карт, эшлекле кыяфәтен бозмыйча гына, чынаякны моның борын төбенә үк сузып:

— Дару өчен, юләр! Юкса хәзер бизгәк эләктерерсең... Эчеп җибәр, җылынып китәрсең,— дип, бик кыска бәйләнде. Шулай да Гариф тагын бераз сатулашмыйча эчәргә яхшысынмады:

— Юк, Шәрәфи абзый, миннән булмый...— диде. Карчыкка карап: — Бер дә эчкәнем юк иде шул, апай! Ничек итеп эчәсең аны!..— диде.

Карчык, чын эч фикере белән:

— Шулай шул, балакай, яхшылар эше түгел инде...— диде.

Карчык сүз кушкан арада, чынаяк Шәрәфи агайның үз иреннәре арасында бушатыла иде. Ул тиз генә тозга басып икмәк катысы капты да, хатынына әйләнеп:

— Заруры бит бу, юләр! Бизгәк эләктерсә яхшымы булыр? Шушы салкында муеныннан суга чумды бит ул! Бир әле монда борыч савытын... Бераз борычлап җибәрик!..— диде.

Газизә, тиз генә торып, борыч савытын табып китерде. Карчык, нәрсәгәдер, өстәлгә бер чәй кашыгы китереп куйды.

— Кашыкның кирәге дә юк... Без аны болай гына эшлибез... —дип сөйләнә-сөйләнә, Шәрәфи агай элек чынаяк төбенә бераз борыч сипте, аннан соң аракы салды.

Гариф көләсе килеп, эченнән: «Җыйнаулашып дарулагач, инде карышып торырга килешмәс»,— дип уйлады. Алар әле Шәрәфи карт белән икесе дә утырмаганнар; өстәл янында торып, аяк өстендә генә сатулаша иделәр. Бу юлы инде Шәрәфи агай, эшне пешкәнгә санап, чынаякны сузды һәм, катгый иттереп:

— Тот әйдә, шифасы белән! — диде. Үзе, утырып, бер карт доктор клиентына караган төсле, Гарифка күз текте.

— Менә шулай! Башка вакытта эчмә, кирәге юк! Инде заруры булгач, Ходай үзе дә кичерсә кирәк, вәссәлам! — диде.

Гариф эчкәчтен чыраен сытып, күзләрен кыскалап, йөзен каплаган булып кыланган арада, карт, кемнең дә кыставын көтмичә, тагын бер чынаяк эчеп алды. Һәм шешә төбендәге барлык аракыны бушатып, тагын Гарифка сузды. Гариф та, сандык өстенә утырып, бу юлы инде борычларга-ниләргә дә эшне тәрәмәде.

— Менә шулай,— диде карт,— бизгәк ул — кабахәт нәрсә, Ходай сакласын, бер эләктереп алдымы, тиз генә җибәреп булмый аны!... Диңгез ул — кабахәт! Менә мин үзем дә әллә кайчаннан бирле эч белән азапланам... Нишләмәк кирәк,— бер-ике йотым нитәсең дә, аз гына уңайланган шикелле була... Ә син юеш киемнәреңне нишләттең? Баракта? Юк, алай ташларга ярамый, анда кипми ич алар, ичмасам, кухняга элеп куярга кирәк, әйбәтләп кипсеннәр...

Гариф урыныннан торды.

— Син чыгасыңмы, Шәрәфи абзый? — диде.

— Чыгып карарга кирәк...

Карчык, йомшак кына тавыш белән:

— Чәй эчмисезмени? — диде.

— Юк инде, Гариф барып ятсын,— диде карт.— Минем дә эшем баррак, үзегез генә инде әйбәтләп эчәрсез... Чикмәнне генә бир дә, без чыгыйк.

Ишегалдына чыккач, Шәрәфи агай чикмәнне Гарифка тоттырды.

— Бар, әйбәтләп кенә төренеп ят! Кичрәк Солдат белән икәү чәйгә килерсез,— диде.

— Юк, мин инде җылындым, тегендә бармакчы идем...

— Анда синең кирәгең юк, во-первых, и сиңа хәзер җил дә ярамый... Бар да әйбәтләп кенә төренеп ят! Менә анысы шифага булыр!..

Гариф карышмады, тагын баракка китте.

Барак тагын шулай ук ямьсез, кызганыч, буш көе тора. Ватылган тәрәзә күзеннән һаман да шулай җил ыжгыра. Җил улаган арада, әллә кайлардан гөрләп килгән тонык һәм көчле дулкын тавышлары ишетелә иде. Аның зиһене чуалмаса да, буын һәм әгъзаларында ул шактый какшау һәм калтыранганлык сизә иде. Солдатның иске шинелен салам өстенә салып, үзенең пальто кисәге һәм картның чикмәне белән баштан ук ябынып ятты. Яткач та, бик арыган кешенең йомшак һәм уңайлы урынга сузылганда хис итә торган бер рәхәтлек тойгысы аның күңелен тутырды. Гүя әллә нинди бик килешсез бер эш, төзәтүе мөмкин булмаган бер хатасы барлык зиһененә килеп, кинәт борчыла башлады. Газизәнең җитди генә чырай белән өстәлгә борыч савыты куйганлыгын, карчыкның чәй кашыгы алып килгәнлеген күз алдына китерде... Алар шул

чагында нәрсә уйладылар икән? Гарифның юри генә риаланганын[1], әлбәттә, сизгәннәр булыр. Инде карчык каршында аның «балакайлык» мәхәббәте, Газизә каршында «Гариф абзый»лык хөрмәте бөтенләйгә югалгандыр шул...

Көн әле кич булмаса да, Гарифка төн кебек тоела иде. Ул чикмәнгә бик нык төренгәнгә күрә, тәрәзәдә улаган җил һәм дулкын гөрләүләре аермачык ишетелми. Тик әллә кайсы почмакта, гүя әллә кем акрын тавыш белән, ярсуланып-ярсуланып, бертуктамый елый иде... Аһ, мескен, кем соң син?.. Гарифның әнкәсе генә шулай елый иде... Әнә аның әткәсе — кара күзле, таза гәүдәле, исерткечкә мөбтәля[2] мулла... Ул балаларын, якыннарын бик сөя, ләкин аны сөюче юк... Менә ул базар авылыннан пар ат яллап кычкыра, җикерә, җырлап кайта... Әнкәсе тавыш чыгармый, бер җирдә качып, әкрен генә елый... Менә мәчеттә тавыш чыгып, ул намаз укытмыйча, күзләрен бөтенләй кан басып өйгә кайткан... Тагын әнкәсе елый... Менә кешеләр икендегә җыела. Ул керми, ак күлмәкчән ишегалдында тезләрен кочаклап, һич хәрәкәтләнми утыра; аның «указы» алынган... Әнә ул хәстә, балаларын чакырып-чакырып берәмләп үбә, салкын куллары белән башларыннан сыйпый... Менә аның урынын тартып алган «сары җиләнле мулла» инде аның җеназасы өстендә иелеп, бөгелеп, әрле-бирле йөгерә... Бу чагында инде әнкәсе тавышсыз түгел, өзелеп-өзелеп тавышлап ярсый...

Гариф шушы күңелсез хатирәләргә бирелеп торган чагында, кинәт ишек ачылып, аны сискәндерде. Чикмәнне азрак ачып карагач, бераз аптырап китте: Газизә кергән иде.

— Гариф абзый, йокламыйсың икән... Юеш әйберләреңне әнкәй сораган иде, кухняга илтеп җәясе үзләрен...— диде.

Гарифның бер читкә ташлаган тужуркасы белән күлмәкләрен Газизә җыештырып алып чыкканда, Гариф утырган җиреннән:

— Мәшәкать булыр, борчыласыз, Газизә... — дип сөйләнеп калды.

---

[1] *Риалану, риялану* — ясалма кылану.

[2] *Мөбтәля* — дучар булучы.

Газизә чыгып киткәч, ул беркадәр аптыранган рәвештә ишеккә карап торды-торды да тагын бөркәнеп ятты. Кайсыдыр почмакта әллә нинди моңлылык эчендә һаман бернәрсә елый иде. Ләкин бу юлы аның елавы Гарифның күңеленә тупас өметсезлекләр, ачы кайгылар салмый, бәлки аның күңелен әллә нинди билгесез бер шатлык катыш эч өзгеч моң һәм ләззәт белән тутыра иде. Аз гына элек Гарифны кара хатирәләр, тупас өметсезлекләр белән газаплаган шушы билгесез моңлылык гүя аны юата, иркәли, шатланырга, шатланып, үзе белән бергә еларга куша...

Киң күкрәкле, юлбарыстай көчле һәм матур егет иске чикмән астында әкрен генә елый иде.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Ш. Камалның үз тормышы һәм хикәя-повестьларында сурәтләнгән вакыйгалар арасында сез нинди дә булса бәйләнеш күрәсезме?
2. Сезонлы эшчеләрнең тормышы, шөгыльләре, өметләре турында сөйләгез. Ни өчен без әсәрдә «бәхет эзләү темасы чагыла» дип әйтәбез?
3. Җылымны алырга киткән көймәне, андагы ишкәкчеләрне тасвирлаган урыннарны табып укыгыз. Чагыштыруларны үз сүзләрегез белән аңлатыгыз. Алар Гарифка да карыйлармы?
4. Арканның ычкынганын белгәч, Сафа «күтәренке тавыш белән: Неводны харап итә, егетләр!» — ди. Гариф та, «кирәкле хәбәр ишеткән төсле, күзләрен уйнатып: Мин барам!» — дип, көймә янына йөгерә. Бу күңелсез хәбәр ни өчен шундый рухи күтәренкелек тудыра соң? Язучы болар белән ни әйтергә тели? Аңлатып бирегез.
5. Бүлектәге беренче һәм өченче өлешләргә исемнәр куегыз.
6. «Елау — күңелне сафландыручы хис», «Елый белү — нечкә күңелле булу билгесе» дигән темаларга фикер алышыгыз.
7. Геройларга характеристика бирегез.
8. Эшчеләрнең тормыш шартлары турында сөйләгез.
9. Шәриф Камал — хикәяләү остасы; шуны раслагыз.
10. Бүлектәге эпизодларга таянып, «Егет кешене кыюлык бизи» дигән сочинение языгыз.

Егет ник елый?

Бу бүлекнең исеме үк кешедәге рухи халәтнең ни дәрәҗәдә киеренке булуына ишарә итеп тора. «Егет» һәм «елый» сүзләренең янәшә килүе сискәндереп җибәрә: ни өчен елый әле егет кеше? Чыннан да, Гариф кебек эчкерсез һәм кыю кешене бу хәлгә нәрсә китереп җиткергән?.. Күренеп торган дошманнары да юк...

Без алда әсәрдәге төп персонажлар арасында Гарифны да күрсәткән идек. Ә менә бу бүлектә ул чын мәгънәсендә үзәктә, чөнки укучы аның турында моңарчы белгәннәренә яңаларын өсти. Егет турындагы имеш-мимешләр ачыклана, менәзендәге (характерындагы) яңа сыйфатлар ачыла. Гариф, чыннан да, мәхдүм (мулла малае) икән. Аның ил буйлап бәхет эзләп йөрүенең сәбәпләре бар икән: әтисе эчүчелеккә бирелеп, указы алынган, аннары үлгән. Егет йә шул хурлыкны күтәрә алмаган, яисә, гаиләләре хәерчелеккә төшеп, әнисенә һәм туганнарына ярдәм итү максаты белән, акчалы эш эзли. Ул башкалар арасында зыялы һәм укыган булуы белән аерылып тора (аны юкка гына артель башлыгы итеп куймыйлар). Бу, күрәсең, гаилә тәрбиясеннән дә килә: Гариф нечкә күңелле, йомшак һәм итагатьле, хискә бирелүчән.

Бу бүлектәге вакыйга-сурәтләрне берничә өлешкә, төгәлрәге, өчкә бүлеп карарга мөмкин. Беренче күренеш Гарифны эш-хәрәкәте ягыннан тәвәккәл һәм кыю, хәтта бераз башсызрак та итеп күз алдына бастыра. Котырган диңгезгә керергә беренче булып ул ризалык бирә, башкалар аңар ияреләр. Бу өлештә автор хикәяләүне әйтерсең лә үзе алып бара, вакыйгаларга читтән торып бәя бирә. Гарифлар утыргач, «йомычка кисәгенә ябышкан булдыксыз һәм кызганыч тараканнар шикелле» күренгән балыкчыларга җан керә. Дүрт батыр ишә башлагач, «җансыз сөяк кебек чайкалып торган шактый зур көймә... килешсез кара бер җанвар кебек, дулкыннар белән көрәшә-көрәшә, эчкә таба үрмәләп» китә. Эш башкарылганнан соң, исән-имин кайтып килүче көймә дә икенче кыяфәткә керә: «Хәзер инде көймә булдыксыз, кызганыч ябалак кебек түгел, йөрәкле карчыга шикелле матур һәм сөйкемле күренә иде. Көймәдәге егетләр дә көчсез һәм йомшак тараканга түгел, гайрәтле үткен кырмыскаларга охшый иделәр». Һәм бу, иң беренче, Гариф аркасында. Баштарак Гарифны юләргә чы-

гарган Шәрәфи карт та соңыннан: «Шулай кирәк! Юләр бул да егет бул!» — дип, аны хуплый.

Икенче күренешне шартлы төстә «Шәрәфи агайлар өендә» дип исемләп булыр иде. Монда инде вакыйганы сөйләүне-хикәяләүне автор шундый итеп алып бара ки, әйтерсең лә Шәрәфи карт гаиләсенә дә, өй эченә дә, аракы эчү күренешенә дә Гариф күзеннән торып карый. Бу картинада Гарифның итагатьле, бераз оялчан булуы, олыларны хөрмәт итә белүе күренә. Хәтта аның «аракы эчкәнем юк» дип хәйләләве дә егетнең әйбәт менәзенә күләгә төшерми. Укучы Гарифның рияланып маташуы хатын-кызга хөрмәт белән караудан гына килә икәненә яхшы төшенә.

Гарифны тулырак гәүдәләндерү ноктасыннан торып карaганда, барактагы күренеш характерлы. Әгәр дә алдагы ике өлештә без егетне күбрәк эш-хәрәкәттә, үз-үзен тотышында күрсәк һәм бәяләсәк, хәзер инде төп игътибар аның уй-фикеренә, хатирәләренә, эчке кичерешләренә, ягъни рухи хәленә юнәлтелә. Хикәяләүдә объектив сурәтләү өстенлек ала. Бу — тулысы белән психологик картина. Кешенең рухи халәтен тасвирлауда, нечкә күңел тирбәлешләрен күрсәтүдә язучы бик оста эш йөртә. Күңелсез хатирәләрнең егет хәлен авырайтуын ул болай сурәтли: «...әллә кайсы почмакта, гүя әллә кем акрын тавыш белән, ярсуланып-ярсуланып, бертуктамый елый иде... Аһ, мескен, кем соң син?.. Гарифның әнкәсе генә шулай елый иде...»

Әтисе турындагы яисә әнисенең үксүе хакындагы авыр истәлекләрме егетне еларга мәҗбүр итә? Бу табигый да кебек. Туганнарны сагыну кемне генә елатмый?! Ләкин егет алар хакимлегеннән арынган инде. Аны инде Шәрәфи картка, Сәгыйдә карчыкка карата, кешелекле булулары өчен, рәхмәтлелек хисләре били. Иң мөһиме, аны караңгы уй-фикерләрдән Газизәнең килеп керүе коткара. Менә шунда язучы Гариф күңелендә кызга карата бөреләнгән олы һәм саф хиснең тылсымлы көчен гәүдәләндерә. Кеше күңеленең нечкәлеге, сизгерлеге төгәл әйтеп бирелгән: «Аз гына элек Гарифны кара хатирәләр, тупас өметсезлекләр белән газаплаган шушы билгесез моңлылык гүя аны юата, иркәли, шатланырга, шатланып, үзе белән бергә еларга куша...» Укучы моның мәхәббәт икәненә, кешене күтәрүче, илһамландыручы, яхшырак итүче мәңгелек хис икәненә төшенә, билгеле. «Киң күкрәкле,

юлбарыстай көчле һәм матур егет» нең «иске чикмән астында әкрен генә» елавын бөтен күңеле белән кабул күрә, егетнең бу мизгелдәге йомшаклыгын ул гафу итә генә түгел, уртаклаша да.

«Акчарлаклар» повесте Шәриф Камал иҗатында гына түгел, татар әдәбиятында да күренекле урын тота. Аның «Егет елый» исемле бүлеге кеше күңеленең байлыгын, матурлыгын тасвирлап бирүдә язучының никадәр оста булуын раслап тора.

Һади Такташ
(1901—1931)

Татар поэзиясенең күренекле вәкилләреннән берсе — Һади Такташ. Тукай һәм Рәмиевләрдән килә торган традицияләрне дәвам итеп, ул татар шигыренә зур яңарыш рухы өрде.

Сыркыды авылы (хәзерге Мордва Республикасы) крестьяны Хәйрулла гаиләсендә 1901 елның 1 гыйнварында дөньяга килгән малайга Мөхәммәтһади дип исем куялар. Малай кече яшьтән үк укырга-язарга маһир була. Беркадәр вакытлар үз авылларында, аннары 30 чакрым ераклыктагы Пешлә авылы мәдрәсәсендә белем ала. Ләкин бераздан аңа, тормышлары авырайган әти-әнисенә ярдәм итү өчен, Бохарага китеп, хезмәтче малай булып эшкә ялланырга туры килә.

Һади әдәбият белән бик яшьли кызыксына башлый. «Минем шагыйрьлегемә әниемнең дә зур тәэсире бар»,— дип язган шагыйрь. Аның әнисе Шәмсениса Сыркыдыда укый-яза белүче биш хатын-кызның берсе була. Ул кышын балалар укыткан, авылдашларына хатлар язышкан, читтән килгән хатларны укырга булышкан. Җырлар, бәетләр чыгарган. «Әни хәзер дә әле миңа хатларын җырлар белән яза»,— ди шагыйрь үзенең истәлегендә.

Бохарада Һади белемен күтәрергә омтыла, телләр өйрәнә, күп укый, спектакльләр куюда катнаша. Иҗади тәҗрибәләре дә шунда башлана: беренче шигырьләрен яза, «Төркестан сахраларында» исемлесен 1918 елның 21 гыйнварында газетада бастырып та чыгара.

Һади Такташ ил буйлап күп йөри: Сыркыдыга кайтып укытучылык итә, Оренбургка барып чыга, анда газетада эшли,

аннары Ташкентка китә, әдәбият укыта, журналда секретарь була. Казанга кайткач театрда, аннары «Чаян», «Азат хатын» һ. б. журналларда эшли. Ләкин кайда гына булмасын, кем генә булып эшләмәсен, шигырь язуын дәвам иттерә. 1922 елдан алып Казанда яшәгән чорында (ул 1931 елның 8 декабрендә вафат була) аның иҗаты аерата активлаша. Бер-бер артлы шигырь һәм поэмалар җыентыклары, хикәяләре басылып чыга, драма әсәрләре сәхнәләрдә уйнала, тәнкыйть мәкаләләре һәм публицистик язмалары белән көндәлек матбугатта бик еш катнаша.

Һ. Такташ әсәрләрендә: кеше азат булырга, җир йөзендә тигезлек хөкем сөрергә тиеш, дигән гомумкешелек фикерләре уздыра, абстракт образлар, романтик бизәкләр белән эш йөртә.

Аерым кимчелекләренә дә карамастан, Һади Такташ — татар әдәбиятын яңа идеяләр һәм әдәби геройлар белән баеткан олы шагыйрь. Бигрәк тә шигырь төзелешен һәм образлылыкны баетуга ул үзеннән зур өлеш кертте. Аның традицияләре тәрбиясендә татар шагыйрьләренең берничә буыны үсеп чыкты.

АЛСУ

Урам ташларына карлар ява,
Кар томалый чана юлларын,
Карда шуа-шуа Алсу килә,
Җиң эченә тыккан кулларын...
Җилгә каршы җылы сулышлары
Туңып бөдрә чәчен ак ясый...
Юл буена аны тирги-тирги,
Сүгенә-сүгенә кайта Газзәсе:
«Алсу, тукта инде, акыллым,
Абау,
Тагын карга батырдың!..» —
Ул үпкәләп читкә китә. Аны
Алсу тагын ялынып чакыра:
«Кил, уйнамыйм, бетте...
Кил инде!»
Үзе — килсә, карга батыра.
Салкын карга басып Алсу килә,
Үзе көлә,
Үзе сөйкемле,

Үзе усал,
Үзе болай бер дә
Усал түгел кебек шикелле...
Урам шаулый-шаулый төн уздыра,
Кемнең монда кемдә эше бар?
Һәрбер җылы тунлы кешеләрнең
Җылы бүрке, торыр төше бар...
Тик чаттагы бабай — «барабыз»ның
Бик үк әйбәт түгел тормышы,
Һәр көн таңнан алып кичкә кадәр
Салкын урам — торган урнысы.
«Җанкисәгем, бабай, «барабыз!»
Атың белән сатып алабыз,
Студентта акча бик күп була,
Әй,
Ун тиенгә илтсәң, барабыз!..»
Алсу, бүлмәсенә керү белән,
Өске киемен салып ташлады;
Ватык көзгесенә карый-карый,
карлы чәчен сүтә башлады...
«Газзә, кара: ничек минем чәчләр
Бер-берсенә ябышып туңганнар...»
«Карлы чәчләр сиңа килешә, Алсу,
Үз чәчеңнән матур булганнар...»
Алсу күзен алмый, үзен карый:
Үзе матур,
Үзе сөйкемле,
Үзе усал,
Үзе болай бер дә
Усал түгел кебек шикелле...

Аңа бүген әллә нәрсә булган:
Бер җырлыйсы килә, бер көлә.
Бер онтылып, кинәт керфекләре
Бер ноктага килеп төртелә...
«Ташла әле, Газзә, зачетыңны,
Их, үбәсем килә үзеңне,
Ну, үбәсем килә үзеңне...
Тыңла инде бер кат сүземне?..»
Газзә, ирексездән эшен ташлап,
Сүгенә-сүгенә килә янына:
«Тфү, каһәр суккан!
Ачуың килмәгәе,

Тоз саласың инде каныма!
Син шул, кызый, үзең зачетыңны
Бик соң хәзерләргә башлыйсың,
Үзең бездән алда биреп ташлыйсың,
Ә без...»
Ул Алсуга ачу белән карый,
Тик ачуы бик тиз басыла.
Алсу бала кебек елмая да
Иңнәренә килеп асыла...
Газзә түзми, аның сүзен көтә,
Үзе уйлый зачет бирәсен...
Алсу көлә-көлә күзенә карый,
Соң ул аңа нәрсә сөйләсен?
Сөйләсенме матур яшьлегенең
Зур елларга туры килүен,
Сөйләсенме җирне, бүгенгене,
Бар нәрсәне өзелеп сөюен...
Һәр кояшлы иртә аның өчен
Яңа уйлар алып китерсә,
Бүгенгенең һәрбер матурлыгы
Үзе белән аны исертә...
Шуның өчен бүген ул төн белән
Бер хат язды карты исменә,
(Карты кемдер...)
Кәкре юллар ясап,
Сызып-сызып алды тиз генә.
Хатның соңгы юлы:
«...Бик сагынсаң,
Хатым бассын күңлең ярсуын,
Бик бәхетле синең Алсуың...»
Хаты белән бергә яңа төшкән
Рәсемен салды үзенең картына,
Кулына соңгы кабат рәсмен алып,
Шул сүзләрне язды артына:
«Бу — Алсуың синең,
Күрәсеңме,
Нинди матур булып утырган.
кара, башкаларга мине алыштырма,
Кадрем белеп яшә, чукынган!..»

Коридордан басып Алсу килә,
Үзе матур,
Үзе сөйкемле,

Үзе усал,
Үзе болай бер дә
Усал түгел кебек шикелле...
Ул дәрескә бүген бик соң килде,
Әллә кайда йөреп кичеккән.
Үзе соңга калган,
Үзе әле
Көлә-көлә керә ишектән...
Үзе дәрес тыңлый,
Үзе бер дә
Тыңламаган кебек итенә,
Үзе профессорның дәресен яза,
Үзе аның борнын кәкре итеп
Төшреп куя дәфтәр читенә...
Үзе зачетларын хәзерләргә
Барыннан да соңрак тотына,
Үзе зачетларын башкалардан
Алдан бирә, алдан котыла...

Һәрбер нәрсә аңа, күп көч куймый,
Әллә ничек җиңел бирелә,
Янар яшьлегенең алсу таңы
Үтмәс төсле булып күренә.
Ул үзенә үзе хуҗа бүген,
Үзе акыллы, үзе сөйкемле,
Үзе усал,
Үзе болай бер дә
Усал түгел кебек шикелле...

1929

Сораулар һәм биремнәр.

1. «Алсу» поэмасын эпизодларга бүлеп карагыз. Аларның һәрберсе Алсу менәзенең кайсы ягын чагылдыра?
2. Шигъри юллардан файдаланып, Алсуның портретын сурәтләгез.
3. Алсуның иренә язган хатын үз сүзләрегез белән шәрехләгез (җентекләп аңлатыгыз). Хаттагы юлларда вульгар[1] сүзләр юкмы? Алар нинди мәгънәдә кулланылган?
4. Газзә биреләчәк зачетын уйлап пошынганда, Алсуның күңелен нинди хисләр били? Поэмадан шул урынны табыгыз.

---

[1] *Вульгар* — тупас.

5. Әдәби әсәрдәге төп идеяне ачып бирегез.
6. Поэманы яттан өйрәнегез.

Яшьлек яме

Революциядән соң илдә кайбер күренешләр барлыкка килде һәм үзгәрешләр башланды. Болар бигрәк тә 20 нче елларда сизелде. Мәдәният өлкәсендә уңышлар күренде, яңа театрлар, газета-журналлар, нәшриятлар ачылды. Хезмәт иясе өчен белем алу мөмкинлеге артты, гомумән, гади кешенең тормышта урыны ныгый башлады. Мондый хәлләр халыкның күңелен күтәрә, кәефен яхшырта, киләчәгенә ышаныч тудыра иде.

«Алсу» поэмасында шагыйрь әйтергә теләгән төп фикер дә шуннан гыйбарәт: җәмгыятьтә гади кешегә юл ачылды, язмышын үзенчә кору мөмкинлекләре туды. Яшьләргә дә үзләренчә итеп, белем алып, сөеп-сөелеп яшәргә иркенлек бирелде. Аерым алганда, моңарчы кимсетелеп килгән хатын-кызга «үзенә үзе хуҗа» булырга, җәмгыятьнең ирекле әгъзасы булырга мөмкинлекләр ачылды. Бу фикерләр студентка Алсу образы ярдәмендә, аның көндәлек тормышыннан берничә эпизодны сурәтләү аркылы бирелә.

Алсу — яшьлеге һәм мәхәббәте белән канатланган, гомумән, тормышка гашыйк меңнәрчә яшьләрнең берсе. Шаян, үткен, сәләтле. Героинядагы бу сыйфатларны автор төгәл шигъри юллар, ачык образлар, гади һәм җанлы сүз тезмәләре ярдәмендә ача.

Алсуның тышкы кыяфәте һәм рухи дөньясы артык киң итеп тә, җентекләп тә сурәтләнмәгән. Шулай да укучы күңелендә аның образы бик тә ачык гәүдәләнә: бөдрә чәчле, матур, сөйкемле, һәрчак көләч... Болары — аның портреты, тышкы кыяфәте. Алсуның эчке дөньясы, үзенә генә хас гадәтләре турында күбрәк әйтелгән. Һәм алар аның эш-гамәлләре ярдәмендә ачылган. Әнә ул иптәш кызы Газзәне карга батырып «җәфалый», димәк, чая һәм наян. Әнә алар «барабыз»[1] бабайны ирештерләр: «студентта акча күп була» диләр дә... бары тик 10 тиен генә тәкъдим итәләр. Җорлык һәм шаянлык... Ул да булмый, тагын ахирәтенә бәйләнә башлый: «ташла әле,

---

[1] *«Барабыз»* — атлы извозчик («такси»).

Газзә, зачетыңны...» Дәрес-лекциягә соңарып килүе белән дә, профессорның көлкеле рәсемен ясап, дәрес тыңламаган булып утыруы белән дә Алсу яшьлеге ташып торган, тиктормас, шат күңелле булып гәүдәләнә. Һәм шундый эпизод-күренешләрне шагыйрь бик тә уңышлы рефрен[1] белән җөпләп куя:

...Үзе сөйкемле,
Үзе усал,
Үзе болай бер дә
Усал түгел кебек шикелле...

Димәк, Алсу — үткен, кирәк икән, усал да, шаян һәм акыллы, эчкерсез, бераз гына бала-чагарак та; үз-үзенә соклану кебек, матур хатын-кызга хас гадәт тә аңа ят түгел. Иң мөһиме, ул — яшәвеннән, тормыштан канәгать, чөнки «ул үзенә үзе хуҗа бүген».

Яшьлек һәм мәхмббәтнең матурлыгын, кабатланмас үзенчәлекләрен кат-кат җырлаган Һади Такташ бу поэмасы белән яшьләрнең якты рухи дөньясын, оптимизмын чагылдыра.

КИЛӘЧӘККӘ ХАТЛАР

(кыскартып алынды)

Хатның адресы

Бу хат киләчәкнең билгесез бер
Кешесенә атап язылган.
Исеме безнең чорга мәгълүм түгел,
Фамилиясе — баба ягыннан
Нигъмәтуллин булыр.
Хатны алырга тиеш булган ул кешенең
Исемен,
Адресын
Белмим.
Шуның өчен хатны ачык язам,
Аны һәркем укый алачак.
Хатым, бәлки, кулдан кулга күчеп,
Ул кешене эзләп табачак.

---

[1] *Рефрен* — шигырьнең кабатлана торган бер өлеше (яки юлы).

Беренче хат

Сез бу хатны минем укыганда,
Мин бик күптән үлгән булырмын,
Еллар бер-бер артлы үткән булыр,
Исмем сезгә җитмәс — онтылыр...
Ләкин
Теләкләрем минем сезнең чорда,
Сезнең кырда чәчәк атачак,
Җансыз гәүдәм шушы теләкләргә
Азык булып җирдә ятачак...
Миннән соң туачак җырчыларның
Даны күмәр минем атымны,
Ләкин
Еллар, сезгә зур бер легенданы
Саклап алып барган шикелле,
Алып барыр шушы хатымны...

Безнең хисләр сездә кабатланмас,
Сез ул хисләр белән янмассыз,
Безнең бөек чорның каршылыклы
Кешеләрен аңлый алмассыз.
Без үткәннең каты җиңелүе,
Бүгенгенең җиңеп килүе
Көрәшендә
Артык ашкынулы
Хисләр уты белән янабыз;
Без яңа җир,
Яңа кеше өчен
Җирдә зур дау алып барабыз...
Бу хат, сезгә барып ирешкәнче,
Сезгә мирас булып калачак,
Җир өстендә
Безнең колонналар
Соңгы крепостьны алачак!..
Бу фронттан бер хат:
Бу хат минем
Күкрәк хисләремнең җылысын
Саклый алып сезгә илтсә дә,
Сәламнәрем барып җитсә дә,
Сез бу хатны минем укыганда,
Мин бик күптән үлгән булырмын,
Еллар бер-бер артлы үткән булыр,
Исмем сезгә җитмәс — онтылыр...

Кемлегемне,
Нәрсә эшләвемне
Язмыйм сезгә;
Дөресен әйтәм,
Мин гомеремдә
Бик күп анкеталар тутырдым,
Һәрбер анкетамны тутырганда,
Теләгәнчә алдап утырдым...
Бу шаянлык өчен гаепле мин
Төрле чиновниклар алдында,
Ләкин
Анкеталарда бик күп алдасам да,
Җырларымда — һичбер вакытта...
Ә бит
Һәр дәвернең үзенең чире була
(Һәрбер чирнең була докторы),
Һәр заманның була үзенә күрә
Сволочы (каһәр суккыры)!
Кичерегез,
«Сволочь» дип безнең заман халкы
Начар кешеләрне йөрттеләр,
Еллар оныттырыр...
Ләкин
Алар безнең
Теңкәбезгә тиеп беттеләр...
(Хатларымда шушы кешеләрнең
Кайберләрен язып үтәрмен,
Аңлатмалар биреп китәрмен...)

Икенче хат

Сезгә хат язарга утыру белән,
Кинәт хат язуны
Артык зур эш диеп санадым,
Сезгә язар өчен зур фикерләр,
Проблемалар эзләп карадым...
Ә беләсез, нинди уйга килдем:
Сезнең заман халкын
Минем «философлык»,
«Даһи җырчы» булу белән дә
Шаккатырып булмас
(Аннан,
Даһилык та
Сирәк йөри минем тирәмдә...).

Бер чакны без шулай Горький белән
Бер мәҗлестә бергә утырдык,
Әллә ничек аның сул ягына
Туры килде минем урындык.
Горький — безнең чорның зур әдибе,
Аның даны
Бөтен планетага таралган,
Ә мин үземне бер бик кечкенә
Кеше итеп сиздем аңардан...
Башта аның белән сөйләр өчен
Зур гакыллы сүзләр эзләдем,
Тирләп беттем...
Ә соңыннан инде түзмәдем,
Башта булган гади уйлар белән
Башлап алып киттем сүземне,
Ә бераздан яхшы ук акыллы бер
Кеше итеп сиздем үземне!..
Сезгә хат язарга утыргач та,
Үземне мин
Шундый ук бер хәлдә санадым,
Сезгә язар өчен айлар буе
Проблемалар эзләп карадым.
Ә соңыннан
Минем проблемалар сезнең өчен
Кызык булмас диеп уйладым.
Шуның өчен мин бу кыска хатта
Зур фикерләр алга куймадым...
Дөрес,
Без сыйныфлы тормыш ярларыннан
Сыйныфсызлык ягына күчәбез,
Һәрбер проблеманы үзебезнең
Файдабызга карата чишәбез.
Бездән алда булган җәмгыятьнең
Тормыш шартларына яраган
Һәрбер караш, һәрбер проблеманы
Без төзибез баштан, яңадан.

Бездә
Сыйнфый көрәш хәзер фронтлардан
Бөтен почмакларга күченә;
Һәр гаилә ике каршылыкның
Берләшүен ала эченә...
Күптән түгел мин бер алтмыш яшьлек

Мохтар картны юлда очраттым,
Махра борып икәү сөйли торгач,
Колхоз хәбәрләрен сораштым...
Ул авылда тырышып колхоз төзегән,
Оештырган ярлы, ялчыны,
Шул эш өчен аны кочагыннан
Мәхрүм иткән сөйгән карчыгы...
«Бар, колхозың белән йокла»,— дигән,
Өч-дүрт айлар
«Җылы куенын» карчык ачмаган...
Мохтар бабай ялгыз йокласа да,
Колхозын ул ташлап качмаган...
Бездә һәр гаилә хәзер каршылыклы,
Бик күп кешеләр икегә бүленә.
Мохтар бабай сөйли:
— Мин,— ди,— менә
Дошман булып йөрим үземә...
Элек чакта мин бер кеше идем,
Хәзер, малай, миндә ике «мин»,
Берсе менә аның коммун яклы,
Икенчесе каршы, суккин сын!
Мин аңардан:
— Ничек алай?— дигәч,
Ул бер кызык мисал китерде:
«Пример, без колхозга кергәч, ат-туарлар
Һәммәбезнең кумәк ителде...
Әйтик,
Аны шулай эшләү кирәклекне
Гакыл белән мәгъкуль күрәсең,
Ә эчеңнән һаман:
«Бу бит әле
Минем ат»,— дип йөри бирәсең...
Туры килгән чакта «үз атыңа»
Азыкны да мулрак бирәсең.
Пример,
Бервакытны шулай сабан өсте,
Кырда бергә сабан сөрәбез,
Минем атым юаш булганлыктан,
Бер малайга җигеп бирәбез.
Малай алда йөри, мин артыннан,
Үзем йөрим, үзем сагалыйм,
Минем атны суга-нитә калса,
Тотып яңакларга чамалыйм...

Малай, дөрестән дә, сугып куйды,
Белмәмешкә башта салыштым,
Тагын суккан иде,
Түзәлмәдем,
Якасына барып ябыштым...

Ә берчакны минем атым үлде,
Карчык елый, карчык үкерә,
Атсыз нишләрбез, ди, чәчен йолкый,
Үрле-кырлы, малай, сикерә...
Мин үзем дә башны аска салдым,
Нишләрмен, дим, хәзер эчемнән,
Атның бергәлек ат булганлыгын
Тәки чыгарганмын исемнән...
Колхозчылар килеп кергәч кенә,
Исемә төште ялгыз түгелем,
Шатлыгымнан коммун була яздым,
Шундый күтәрелде күңелем!..
Әгәр шунда, пример, ялгыз булсам,
Нишләр идем ялгыз берүзем?
Менә бит ул күмәк хуҗалыкның
Файдалыгы кайда, иккүзем!..»

Бездә һәр гаилә хәзер каршылыклы,
Бик күп кешеләр икегә бүленә;
Мохтар бабай кебек күпләр әле
Үзе дошман бүген үзенә...

Безнең гомер бөек планетаның
Шау-шулы бер чорына очрады,
Планетада бүген зур дау бара,
Ыгы-зыгы
Килеп тора бөтен почмагы.
Мин бу дауның үткән тарихына,
Бездән алда булган чорына
Туктап тормыйм,
Бары бүгенгене
Сюжет итеп алам җырыма.
Ә бүгенге—
Сыйнфый катлауларның
Соңгы каты көрәш заманы;
Без, искене җимереп, планетада
Тигез тормыш,

Матур,
Яңаны
Төзү уе белән янабыз.
Һәм без шуның өчен илебездә
Зур тазарту алып барабыз!..

1931

Сораулар һәм биремнәр.

1. Әсәрнең буеннан-буена килә торган бер образ бар. Ул кем образы?
2. Шагыйрь сезнең күзаллавыгызга нинди кеше булып килеп баса? Аның менәзенә хас сыйфатларны күрсәтегез.
3. «Хатның адресы» дип исемләнгән кереш өлештә нинди сәнгатьле алым кулланылган? Ничек уйлыйсыз: хатның адресаты, чыннан да, Нигъмәтуллин фамилияле кешеме икән?
4. «Беренче хат»та бирелгән төп фикерне әйтегез. Чорның каршылыклы, авыр булуы нидән килә? Ни өчен автор ул чорны «фронт» дип атый?
5. Шагыйрь җырларында алдашмавы турында искәртә. Аның тугры сүзле булуы киләчәк буыннар өчен мөһимме?
6. «Икенче хат»ның эчтәлеге нинди вакыйгаларны үз эченә ала?
7. Шагыйрьнең М. Горький белән сөйләшеп утыруын сурәтләгән өлешне шәрехләгез. Лирик герой нинди кеше?
8. Мохтар карт образына характеристика бирегез. Картның колхозга булган өмет-ышанычлары бар яктан да үзләрен аклыймы?
9. Шагыйрьнең сыйнфый көрәшне зурлавы хата түгелме, һәр җирдән дошман эзләү урынлымы?
10. Әсәрдән сынландыру, чагыштыру, гиперболага мисаллар табыгыз.
11. «Киләчәккә хатлар»дагы үзәк идеяне ачып бирегез.

Чор тудырган хыяллар

«Киләчәккә хатлар»— татар совет поэзиясендәге уңышлы поэмаларның берсе. Аның уңышы фикер тирәнлегеннән, лирик чигенешләрнең, автор уйлануларының тәэсирле булуыннан да, үзенчәлекле характерлар һәм шигъри бизәкләр байлыгыннан да оеша. Шуның белән бергә әсәрдә Һ. Такташның кайбер мәсьәләләрдә бүген бәхәсле һәм хәтта ялгыш табылган фикердә торуы да күренә.

Поэма, иң беренче, төзелеше ягыннан үзенчәлекле. Ул хатлар рәвешендә: шагыйрьнең киләчәк, үзеннән соңгы буыннарга мөрәҗәгате, аларга үз заманы турында сөйләве төсендә язылган. Бу — авторның укучыларына әйтергә теләгән фикерен ансат һәм үтемле итеп җиткерү өчен эшләнә. Ә төп фикер исә түбәндәгедән гыйбарәт: шагыйрь гаять катлаулы, даулы һәм каршылыклы чорда яши. Аның үзәген сыйнфый көрәш тәшкил итә. Бу көрәш һәр өлкәдә эзен салып калдыра, һәр кеше күңелендә тирән хисләр кузгата.

Әсәрен автор беренче, икенче, өченче хат дип бүлекләргә бүлә. Һәр хатта бер-ике очрак алына, шул очрак-вакыйга үзәгенә бер-ике персонаж куела.

Менә «Беренче хат». Шагыйрь бу хатны ни өчен язган? Нинди максат белән язган? Монда үзәк фикер шул сорауларга кайтып кала. Инде әйтелгәнчә, хатлар язылган чор — гаять катлаулы, авыр еллар. Ул еллардагы кешеләр күңелен биләгән уй-теләкләр һәм хисләр киләчәк буыннар өчен билгесез булып калырга яки дөрес аңлашылмаска мөмкин.

Безнең хисләр сездә кабатланмас,
Сез ул хисләр белән янмассыз,
Безнең бөек чорның каршылыклы
Кешеләрен аңлый алмассыз,—

дип борчыла хат авторы. Ә бит «бөек чор» кешеләре киләчәк буыннарга бәхетле тормыш яулап алу өчен көрәшә:

Без яңа җир,
Яңа кеше өчен
Җирдә зур дау алып барабыз...

«Зур дау»ның нигезен сыйнфый көрәш билгели. Байлар һәм ярлылар, хуҗалар һәм ялчылар, җир биләүчеләр һәм крестьяннар, завод-фабрика тотучылар һәм эшчеләр арасындагы көрәш... Сыйнфый азатлык өчен көрәшүчеләрне автор, гомумиләштереп, «сыйныф» дип атый, аның «бөек көрәшен» яклый.

Төрле анкеталардагы сорауларга алдашып җавап бирүдән дә тайчанмаган шагыйрь җырларында хакыйкатькә һәрчак тугры булуын искәртә. Шуңа күрә дә аның бу хаты, аны язарга мәҗбүр иткән хисләр —чын дөреслек, дип раслый ул.

«Икенче хат»та да автор сыйнфый көрәшнең авыр һәм газаплы булуын тагын да, кат-кат раслый. Массаларның төп теләген, омтылышын ул түбәндәгечә әйтеп бирә:

Без, искене җимереп, планетада
Тигез тормыш,
Матур,
Яңаны
Төзү уе белән янабыз.
Һәм без шуның өчен илебездә
Зур тазарту алып барабыз!..

«Зур тазарту» сәясәте, сыйнфый көрәш идеологиясе җәмгыятьнең һәр өлкәсен, һәр гаиләне, хәтта аерым кешеләр күңелен дә биләп алган, ди шагыйрь. Моның ачык мисалы — Мохтар карт белән булган хәл, шул турыда аның сөйләве. Монда заманның каршылыклы һәм катлаулы икәне җанлы сурәтләнә. Иң зур каршылык сыйнфый көрәш шартларында кеше күңелендәге бүлгәләнүдә күренә. Мохтардагы бер як күмәклекне, күмәк хуҗалыкны, ягъни колхозны яклый. Икенче якта кешедә гасырлар буе ныгып килгән, шәхесне хезмәткә дәртләндереп торган хосусыйлык тора. Шул елларда илдә өстенлек алган карашларга буйсынып, шагыйрь күмәклекне алга куя. Бергәләшеп хезмәт итү, җитештерү коралларын, атларны уртак ясау яхшы, дигән фикер уздыра. Бүген исә мондый карашның, мондый сәясәтнең хата булуы, илне уңышка алып килмәве ачыкланды.

Мондый карашның дөреслеге шикле булу Мохтар карт монологында да чагылып кала. Атны үзенеке дип уйларга күнеккән, ул үлгәч борынын салындырган Мохтар аның хәзер инде колхозныкы икәнен исенә төшергәч шатланып китә. Димәк, беркемнеке дә булмаган, ягъни уртак мал үлсә дә, артык кайгырмаска була икән. Бу бит, ахыр чиктә, кешедә җавапсызлык тәрбияли, күмәк хуҗалыкка да, уртак мал-туарга да төкереп карауга, хуҗасызлыкка китерә. Ул елларда мондый ихлас күңелдән ышануларның ялгыш булуы бүген безгә мәгълүм инде. Бүген без хосусыйлыкны яклыйбыз.

Поэманы башыннан ахырына кадәр сугарган, сыйнфый көрәшнең зарурлыгын раслаган фикерләр дә чордан, дөресрәге, большевиклар партиясе алып барган сәясәттән килә. Крестьянның иң эшчәнен кулак дип дошман ясауны да чор хатасы дип карарга кирәк. Кулакларга каршы алып барылган һәртөрле эзәрлекләүләрне хуплап тасвирлау да — чор фаҗигасенең Такташ иҗатында чагылуы ул.

Поэмадагы мондый мотивларны бүгенге югарылыктан торып кире каккан сурәттә дә, Һ. Такташ каләменең сәнгатьчә сурәтләү көчен күрми мөмкин түгел. Кеше күңеленең

нечкәлеген, заман билгеләрен сурәтләүдә шагыйрь зур уңышка ирешә. Хат язарга ниятләгән һәм илдәге вакыйгаларга үз карашын белдергән лирик герой да, Мохтар карт та, җанлы булып, үзләренә генә хас сыйфатлар белән гәүдәләнәләр. Хәтта монологта күренеп кенә калган тырмачы малай да, Мохтарның карчыгы да укучы хәтерендә урын алалар. Такташ рефрен, сынландыру һәм чагыштыру кебек ысуллардан оста файдалана, шигырьнең оригиналь формасын тудыра.

* * *

Идея — әсәрдә уздырылган фикер яки фикерләр җыелмасы. Ул аерым вакыйгаларны, эчке кичерешләрне, кеше менәзен яки табигать һәм җәмгыять күренешләрен сурәтләү ярдәмендә җанландырып, гомумиләштереп бирелә.

«Алсу» поэмасында үзәк идея — яшь кешенең тормышка һәм кешеләргә якты, мөлаем мөнәсәбәте, оптимизм.

«Киләчәккә хатлар» әсәрендә идея катлаулырак. Ул тирән эчтәлек ярдәмендә белдерелә. Төп фикер: илдә сыйнфый көрәш барган шартлар каршылыклы һәм авыр, кешеләре дә катлаулы. Ләкин аларның теләкләре изге һәм ихлас күңелдән кылган эш-гамәлләре яхшылыктан тора. Мондый үзәк идеядән тыш әсәрдә ярдәмче идеяләр дә бар. Мәсәлән, «чуар чор» кешеләре арасында урын алган бюрократлык, ялкаулык, тупаслык, ялагайлыкка каршы көрәш үзәк идеяне тулыландыра.

Гомәр Бәширов
(1901—1999)

Татар язучыларының күбесе барыбызга да мәгълүм мактаулы исемнәрне йөртә: әйтик, Габдулла Тукай, Муса Җәлил, Гаяз Исхакый исемендәге премия лауреатлары. Рәсми карарлар белән махсус комиссия тарафыннан бирелә торган дәрәҗәле исемнәр янында халык үзе күтәреп алып, үзе сайлап куйган дәрәҗә бар — халык язучысы, халык шагыйре. Мондый хөрмәткә, халкының, милләтенең рәхмәтенә Тукай лаек булды. Үзе исән чагында ук ул бу дан-хөрмәтне берникадәр белеп, тоеп яшәде. Бәхетле язмыш ул шулай танылу!..

Өлкән буын язучыларыбыздан Гомәр Бәширов — яше белән дә, саллы хезмәте, әдәбиятта тоткан урыны белән дә — безнең олуг аксакалыбыз иде. Ягъни халык үзе аңардан киңәш сорап мөрәҗәгать итәрлек акыл иясе булды ул. Борынгыдан шулай килгән: һәр ыругның аксакаллары, гыйлем ияләре булган, алар тормыш тәҗрибәсен, яшәү мәгънәсен чагылдырып торганнар...

Гомәр Бәширов 1901 елның 7 гыйнварында Казан губернасы Арча волосте Яңасала авылында крестьян гаиләсендә туа. Авыл мәдрәсәсендә белем ала. 1919 елда Урта Бирәзә мәктәбендә балалар укыта. 1920 елдан ул гражданнар сугышының ут-ялкыннарын үтә. Бу елларның тарихы булып «Сиваш» повесте языла (1937 ел). 1924 елдан башлап, махсус белем алганнан соң, халык судьясы булып эшли, 1932 елдан ул инде әдәбият, иҗат дөньясында— газета, журналларда, китап нәшриятында.

Бөек Ватан сугышы чорында «Совет әдәбияты» журналында җаваплы редактор, Татарстан радиокомитетының баш редакторы булып эшли. Сугыш елларында Г. Бәширов «Намус» романын яза. Күп телләргә тәрҗемә ителгән бу әсәрне укучылар яратып укыйлар.

1953 елда ул Татарстан Язучылар берлегенең идарә рәисе итеп сайлана, җәмәгать эшләре башкара. Күп санлы хикәяләр, җанлы әдәби процесска караган мәкаләләр яза. Халык иҗатына балачактан килгән җанлы бер мөнәсәбәт нәтиҗәсе булып «Туксан тугыз мәзәк», «Мең дә бер мәзәк» җыентыклары басылып чыга.

Язучы иҗатының зурлыгы, байлыгы ул яшәгән еллар саны белән генә билгеләнми, әлбәттә. Әмма бер гасыр диярлек гомер кичергән Гомәр ага Бәширов — тулы мәгънәсендә татар әдәбиятының мактанычы, горурлыгы. Бер гасырлык тормыш юлы үткән, бөтен гомерен татар әдәбиятын үстерүгә багышлаган язучыбызга СССР Дәүләт премиясе (1951 ел) һәм Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе (1996) бирелде. Аның һәр әсәре — укучысы өчен яшәү мәктәбе. Мәсәлән, «Җидегән чишмә» романы — табигать язмышының халык рухы белән никадәр тыгыз бәйләнгәнлеген тасвирлаучы әсәр. Язучының «Туган ягым — яшел бишек» дигән автобиографик повестенда халык рухының иң матур образлары, тормыш, яшәү төшенчәләренең иң тулы чагылышы гәүдәләнде. Хәзер шул әсәрдән өзекләр белән танышырбыз.

ТУГАН ЯГЫМ — ЯШЕЛ БИШЕК

(әсәрдән өзекләр)

Эзләр

(Кереш)

> Үткәндәгеләргә игътибар — мәдәнилекне кыргыйлыктан аерып торучы күркәм сыйфат ул.
>
> *А. С. Пушкин*

Ел саен диярлек мин авылыма кайтып киләм. Кайтам да үземнең балачак, үсмер чак эзеннән, бергә уйнап үскән иптәшләрем, туганнарым, яраткан кешеләрем эзеннән йөрим. Тау астындагы чишмә суларын татып карыйм, урманнарга сугылам, «диңгез

күзе»н карап узам. Әлек пар нарат үсеп утырган тау битенә җиткәч, һәр кайтуда туктап: «Бикәби, син кайда?»— дип дәшәсем килә. Янәшәдәге иске зират каеннары моңа каршы, җилгә башларын игәләп: «Күптән монда инде Бикәбиең, күптән»,— дип шаулап куялар.

Малай чакта куна йөргән аланнарга, үзем печән чапкан болыннарга, иген кырларына барып чыгам. Шунда минем яшьлек дусларым, кадерле кешеләрем аерата юксындыра башлыйлар. Күңелне тынычландыру өчен генә булса да: «И-һи-и! Хәкимҗан, Нимҗан, Әхәт абый, Әхмәт?!»— дип аваз салам. «Күптән юк шул инде алар,— дип җавап бирә авылдашларым.— Әхәт абыең, акларга каршы сугышканда, Сарапул тирәсендә вафат. Хәкимҗан туганың ком чүлендә барган сугышларда һәлак булды. Нимҗан дисәң, ул бичара Бөек Ватан сугышында үлеп калды».

Беләм мин боларны, беләм. Ләкин минем хәзер барыннан да бигрәк замандашларымның игелекле эзләрен күрәсем килә.

Әмма як-ягыма җентекләбрәк, игътибар беләнрәк карасам, ни күрәм: бар икән бит аларның эзләре, игелекле гамәлләр дәвам итә икән!

Бу әсәр, нигездә, бер авыл тормышыннан алып язылган. Яңасала зур авыл түгел. Шулай да ул Казан ханлыгы заманыннан бирле үк яшәп килгән бик борынгы авылларның берсе булганлыктан, җирендә-суында, тормыш-көнкүрешендә, риваятьләрендә халкыбыз тарихыннан хәтсез күп кадерле эзләр саклый алган. Ул эзләрдә халкыбызның асыл сыйфатлары чагыла. Алар тапкыр һәм зирәк сүз булып, үзәк өзгеч җыр моңы яки дәртле бию көе булып, гүзәллеккә сокланучы үткен күз нуры яисә игелекле гореф-гадәтләр, тырышлык һәм эшчәнлек рәвешендә әледән-әле балкып чыгалар.

Бу кыйммәтле рухи хәзинәбезнең бер өлешен генә булса да әсәремә теркәп калуым белән мин үземне бәхетле саныйм.

Г. Бәширов

Җирән кашка сагышы

I

Аякны-кулны, ботны-чатны дигәндәй, малайларча як-якка ташлап, өйалдында йоклап яткан чагым. Бервакыт йокы аралый әнинең кытыршы кулы белән башымнан сыйпавын тойдым, ягымлы тавышын ишеттем:

— Тор инде, улым, тор, бик озак йокладың. Әнә Хәкимҗаннар әллә кайчан урамда инде...

Колагым ишетә, әмма күзем ник кенә ачылсын! Йокының татлы ширбәте бөтен тәнемә таралган да шундый рәхәт эчендә оетып яткыра, минем, бу рәхәтне качырмас өчен, хәтта кыймылдап кына да карыйсым килми.

Бераздан әни йомшак кына тагын бер дәшеп куйды. Минем дә инде йокы бераз ачыла башлады. Урамда ат пошкырганы ишетелде, арба кигиләрен чыгырдатып, ниндидер бер юлаучы узды. Ишегалдында, тыелып кына, «авыз эченнән» генә бия «шыркылдап» куйды. Бу аның ашарга биргәндә үзенчә рәхмәт әйтүе. Нигә бу вакытта, көпә-көндез, ат өйдә икән?..

Торырга вакыт икәнен дә чамалыйм. Әмма ул чагында наянлыкны белә башлаганмын инде, ахрысы. Шуның өстенә, бераз иркәләнәсем килебрәк тә ятам. Ник дисәң, олылар иртәдән кичкә кадәр гел аяк өстендә, гел эштә. Кайчан тагын шулай баштан сыйпыйлар бит әле.

Менә ачык ишектән әти тавышы колакка чалынды:

— Һи! Бу малай һаман тормыймыни әле? Нигә уятмыйсың? Белми ята ошай*. Бия аңа колын алып кайтты бит!

Колын! Шуны гына ишетүем булды, ялт итеп сикереп торуым булды. Шулай булмыйча соң! Авыл малаеның иң мавыктыргыч, иң матур хыялларыннан берсе шул колын ләбаса инде!

Ишегалдына йөгереп чыксам, шатлыгымнан телдән кала яздым. Әнә ул, әнә мин көткән колын! Үзе җирән, аркасыннан бармак иңлеге коңгырт тасма сузылып киткән, алгы аякларының балтырына тикле ак оек

---

* Белми ятканга охшый.

кигән. Маңгаенда озынча йолдызы да бар. Таяк шикелле нечкә һәм озын, әмма хәлсез аякларын бик сәер итеп дүрт якка тырпайткан да имгән булып маташа.

Минем янда гына, кулын артка куеп, колыннан күзен алмыйча, әти елмаеп тора. Ул да бик куанган.

— Безнең бия,— ди,— бер бик матур колын алып кайтасы килеп, күптән үк эзләнеп йөри башлаган иде инде.

— Ник элегрәк алып кайтмаган соң?

— Һе, ансат кына сиңа! Мондый матуры еш очрыймыни аның? Менә кичә болынга кунарга төшкәч, шушы ак оеклысын туры китергән дә ияртеп үк кайтасы иткән...

Биягә минем шундук күңелем йомшап, карашым яхшырып китте. Болай югыйсә ул мине бик үк санламый да, янына җибәрмәгән чаклары да булгалый. Җитмәсә, бер күзенә ак төшкәнлектән, күрше малайлары үртәп җен ачуымны чыгаралар:

— Сезнең атыгызның бер күзе өшегән! — диләр.

Менә хәзер мин аларның авызларын ачарга да ирек бирмим. Өшегәнме? Өшегән булса да, колынның әнә ниндиен алып кайткан!

Әмма кара бия минем шикелле йомшак күңелле булып чыкмады. Мин колынны аркасыннан сыйпамакчы булып «бәһ-бәһ» дип янына бара гына башлаган идем, бия, яман да ачуланып, колакларын шомартты, дәү сары тешләрен ыржайтып, ашардай булып башын миңа таба айкады.

Әти мине тиз генә үз янына тартып алды:

— Чү! Якын барасы булма! Ачуын китерәсең,— диде.

Берәр атнадан без бияне җиңелрәк эшләргә җиккәли дә башладык. Йә урман аланыннан, аз гына салып, печән алып кайтабыз, йә җиңелчә генә тегерменгә барып киләбез. Безнең колын ул вакытта бик куркак иде әле. Берәрсе катырак кычкырып җибәрсә, йә шакылдап капка ябылса, колын «дерт» итеп сискәнеп китә; юлга чыктыңмы, тәртәгә орынып кына йөри. Әгәр атлы кеше очраса, йә берәр капкадан эт-мазар өреп чыкса, куркынып, шундук анасының күкрәгенә сыена торган иде.

Өммикамал апай зәңгәр сатиннан муенса тегеп биргәч, колынның муенына кечкенә генә шөлдер тагып

җибәрдек. Колын башын селкеткән саен, ул шундый сөйкемле тавышлар чыгара, әйтерсең чың-чың итеп берьюлы әллә ни тикле көмеш тәңкә коела.

Хәзер мин, бүтән уеннарымны онытып, көннең көнозын колын тирәсендә бөтерелә башладым. Әүвәле башта, күз тимәсен өченгә, колынның маңгай чәченә артыш ботагыннан нәни генә тияк ясап тактым, ялына аллы-кызыллы чуклар бәйләдем.

Иртә тордыммы, иң беренче куанычым шул: ипи йомшагы эләктерәм дә колын янына чыгам. Баштарак ул, якын-тирәдә кеше күрүгә, тизрәк анасына барып сыена торган иде. Тора-бара акрынлап ияләнде. «Бәһ-бәһ!» дип дәшүгә, колакларын торгызып, борылып карый торган булды. Бераздан кыйгачланып, матур гына уелып кергән борын тишекләрен селкеткәләп, ипи иснибашлады. Аннары тагын да кыюлана төште. Көл төсле зәңгәрсу-соры, хәтфә кисәге шикелле йомшак иреннәре белән уч төбеннән ипи сыныклары эләктереп алырга өйрәнде.

Хәзер инде җирән кашка миннән курыкмый. Ялларын, маңгай чәчләрен сыйпаганда, зәңгәрсу күзләрен әллә кайларга төбәп, тын гына рәхәтләнеп тора иде. Мин аңа, тизрәк үссен дип, өйдәгеләрдән яшереп кенә, апара эчертәм, җай килгән саен, ипи сыныклары каптырам.

Ике-өч айдан колыныбыз зерә дә чаяланып китте. Ул хәзер инде, элекке шикелле, тәртәгә ышкылып йөрми, эт өргәннән дә курыкмый. Кая ул! Хәзер инде ул башын аска иеп, «салып егам!» дигәндәй, алгы аяклары белән яный-яный, пыр туздырып, этләрнең үзләрен куып йөри. Капка ачылдымы, иң элек ул чыгып чаба. Колынның, сабыйлык җиңеллеге белән, койрыгын-ялын тузгытып, сикергәләп уйнап йөрүен карап тору үзе бер рәхәт була. Әй берзаман муенын кәкрәйтеп, койрык чәнчеп, төп-төз тояклары белән тып-тып басып юыртып китә, агай! Колаклар шәмәргән, күзләрендә ут! Бераз барган саен: «Күрдегезме мине!» — дигән сыман бөтен гәүдәсен катырып, әле бер якка борылып карый, әле икенче якка. Ул да түгел, дәү айгырлар шикелле, гайрәт белән борынын киереп, пошкырып куйган була, йә борынын күккә чөеп, алтын ялларын җилфердәтеп кешнәп җибәрә. Көмеш кыңгыраулар чыңлый диярсең.

Әти, яшькелт-зәңгәр күзләрен кыса төшеп, тавышсыз гына көлә:

— Әй, юеш танау, әй, кыланчык! — Аннары, дилбегәсен тартып, биягә чөңгереп куя.— На, әйдәсәнә, атлар-атламас ниямәрсә тыңлап барасың? Колыныңны мактаганнымы?.. Уңган мал булыр, боерган булса! Алдан да чаба, күкрәге дә киң, торыгы да озын...

Мин инде киләсе елга, колын тайдан кырыкмышка чыккач, аңа атланып Убырышный* һәм Мунчалка дигән урман аланнарына ат ашатырга йөрүләр, анда барганда малайлар белән узышулар, җәйнең эссе көннәрендә зират астындагы тегермән буасында аны коендырып кайтулар турында да хыяллана башлаган идем. Әле ул гынамы? Язгы Сабан туйларында, ялына кулъяулыклар тагып, мәйданга атланып чыгасың. Ул чагында инде җирән кашканың каеш йөгәне дә булыр, йөгәнгә җиз тәңкәләр тезелгән булыр. Әти, кырыкмышны җигәргә өйрәтер өчен, кечкенә камыт белән кечкенә генә чана да әмәлләп бирер. Кем белә, ул вакытка кадәр, бәлки төсен дә үзгәртер әле. Йә кызгылт-җирән булыр, йә туры төскә керер...

Әмма көз көне, кырпак төшеп кар яуганны көткән бервакытта, колыным базарга барган җиреннән әйләнеп кайтмады. Мин аңа нидер булуын биянең авыл буенча кешни-кешни кайтуыннан ук сизенгән идем. Ул ишегалдына кайтып кергәч тә тынычлана алмады. Бөтен көченә кешни дә, капкага таба борылып, колакларын торгызган хәлдә, байтак вакыт тыңлап тора. Колын җавап бирмәгәч, тагын кешни...

Минем: «Колын кая?»— диюемә берәү дә җавап бирмәде. Әти, миңа аркасы белән борылып, атны тугаруын дәвам итте. Әтигә атның кешнәве дә ошамый иде булса кирәк, аңа да кычкыргалап алды. Мин нидер булуын сизенеп еламсырый башлагач түзмәде, дилбегә башын селкеп күрсәтте.

— Туктыйсыңмы син, юкмы? Менә күп шыңшысаң!..

Мин үземне кая куярга да белмәдем. Бөтен дөньямны авыр кайгы басты, колын булмагач, бернәрсәнең дә кызыгы калмаган иде. Бер ишеккә, бер тәрәзәгә

---

* *Убырышный* — алпавытларга түләнә торган оброк сүзеннән килеп чыккан булса кирәк.

атылып, ярсый-ярсый, аранда кара бия кешни, лапас артында, тыела алмыйча, мин елыйм. Шунда әни килеп чыкты.

— Тукта, улым, тагын булыр колының, булыр,— диде, башымнан сыйпап, аркамнан сөйде.— Менә күрерсең, бия тагын алып кайтыр, боерган булса...

Миңа авыз ачып сүз әйтүе дә кыен, елый-елый сулкылдап беткән идем.

— Кайчан? — дип кенә сорый алдым.

— Язган булса, яз көне! Быел булмаса яренгә*.

Колынсыз калу хәсрәте бераз гына җиңеләя төште. Шул вакытта кабынып калган якты өмет озак еллар күңелне балкытып торды: кара байталыбыз җәйнең бер кояшлы иртәсендә болыннан, теге чактагы шикелле, тагын бер матур колын ияртеп кайтмасмы икән?

Мин шул бәхетне чын күңелдән ышанып зур булганчы көттем.

II

Ниләр генә күреп үсмәде безнең яланаяклы, юеш борынлы кыбырсык токым! Сәке өстендә шуа башлаганнан алып үз көнеңне үзең күрә башлаганчы тормыш сине кырык сират күпереннән кичерә. Әле иркәли ул сине, әле яңаклап ташлый, бер көлдерә, бер елата, бер алдын күрсәтә, биш артын күрсәтә. Чыдамлыгың белән әрсезлегең җитә икән, кояш астында син дә урын аласың. Булмый икән... азмыни зиратта кечкенә түмгәкләр?

Һи, авыл баласының күргәннәре!

Тәпиеңә басып, ара-тирә урамга чыккалый башладыңмы, чирәм өстеннән елан шикелле ысылдап килеп, күршенең ата казы, кара көйдереп, ботыңны тешләп китә. Алдыңа-артыңа карамыйчарак йөрисең икән, урамнан узып барышлый, чокыр Мөхәммәтҗаннарның Дүрткүзе, шыпырт кына капка астыннан чыгып, утыргычыңны каптырып ала да, соңыннан әллә никадәр вакыт утыра алмыйча азапланасың. Абзарда сине тәкә сөзеп ега, лапас астына керсәң, коточкыч кабарынып, дулап, өстеңә чеби анасы ташлана. Көтү

* *Яренгә* — киләсе елга.



кайтканда урамда калсаң, үкерә-үкерә артыңнан килеп, келәт хәтле мир үгезе котыңны ала.

Синең башыңнан узганнарны тавык чүпләп бетермәс! Яз көне аягың чебили. Агачка йә коймага-мазарга менгәндә, табаныңа бармак буе шырпы кадала. Әрәмәләр арасында, күпер асларында, әвеннәрдә, печәнлекләрдә, очырмаларда кайнаша торгач, аяк бармакларың каный, балтыр итләрең, терсәкләрең суела, «җан дусларың» белән бәргәләшә-сугыша торгач, иреннәрең ертыла, борыныңнан кан китә.

Шулай да, авыз күтәреп, өеңә елап кайтмыйсың. Чөнки сине: «Ай-һай лабаса, кыйнаганнар икән бит!» — дип, берәү дә кызганып каршы алмаячак. Хәтта киресенчә. Ешрак елап кайта башласаң, җебеп торган өчен, бераз «өстәп» чыгарырга да күп алмыйлар.

Нишләсен малай, изелеп төшсен, үпкәләсен, җыласынмы? Күз яшен күрсәтсә, иптәшләре үк тешләрен ыржайтырга тора, малай-шалай арасында яманаты чыга. Бик үзәгенә үткәндә дә, ул, тешен кысып, борынын тарткалап кына уздыра. Кайсыбер ярасына төкерә, йә булмаса җыен ертылган, суелган урыннарны төзәтә торган шифалы «сыекча» сиптерә. Ярылган-тишелгән урыннарга яфрак яба, олылардан күрмәкче, үрмәкүч оясы ябыштырып куя. Тере тәннең ямаулыгы үз өстендә, диләр бит. Карыйсың, бераздан, язгы кичнең юка бозы шикелле, яраның өстен күренер-күренмәс юка гына элпә тартып, чыйратып та өлгергән...

Әмма андыйларның күбесе соңыннан сагынып сөйләргә генә кала. Алар тора-бара күңел хәзинәсендә сабый чакның таң яктысы төсле саф һәм үтәдән-үтә күренмәле якты шатлыклары белән кушылалар.

Хәер, чын-чыннан бәхетле булыр өчен, нindидер матур төшләр күреп, чырык-чырык көлә-көлә йоклар өчен, сабыйга күпме генә кирәк соң? Урамнан узучы атлының посынып кына чанасы артына утырып бара алсаң, соңыннан егылып калсаң да — шуңа башың күккә тия. Яисә менә кышын тау шуулар...

III

Кышкы кичләрнең балалар өчен иң күңелле, иң куанычлы сәгате, ихтимал, шәфәкъ батканнан соң

башланадыр. Су буйларына, тау битләренә — бөтен тирә-якка тын гына, йомшак кына кызгылт караңгылык иңә. Шуа торган Кабак тавында казылмаларны да, калкулыкларны да аера алмый башлыйсың. Өйләрдә әллә кайчан ут алдылар.

Соң инде, соң. Кайтырга вакыт. Көмеш бизәкле зәңгәр чиләкләрен сайрата-сайрата, чишмәдән су китерүче кызлар да туктады. Ат чишмәсендә сызгыра-сызгыра, атын эчерткән иң соңгы егет тә бая ук менеп китте. Бик соң инде. Инде без генә, чана шуучы малайлар гына калдык. Аларның да, уенга әлмәшләнеп, күзенә ак-кара күренми башлаганнары гына.

Инде чәнәшкәнең* арты да әллә кайчан каерылып төшкән. Киез итек белән бияләйләр дә гел боз гына. Бүтәнне әйткән дә юк, шуып төшкән саен егыла-мәтәлә торгач, чалбарларга тикле сыгып ташлардай булган. Кайткач орыш әләгәсен дә белеп торасың. Шулай да кайтып кына булмый бит. Булмый!

Талчыккан аякларны көч-хәл белән атлап, мышкылдап, чәнәшкәләребезне тау башына сөйрибез. Әмма берсенең дә кайтыр исәбе юк.

— Тагын бер генә шуыйк инде!..— диләр.

Ләкин ул тагын бер генә булып калмый, ике дә, өч тә, биш тә булып китә...

Кабак тавының өстенә үк менәсең дә чәнәшкәңне аякларың белән этәреп кузгалып китәсең. Түбәнгәрәк төшкән саен, чәнәшкәң һаман кызулый бара. Колакларыңда җил уйный, битеңә зәһәрле салкын бәрә. Яр кырыенда утырган тәбәнәк баганалар, җелт тә җелт килеп, егылышып кына калалар. Рәхәт! Чәнәшкәң оча гына. Менә гел шулай очасы да очасы, рәхәтне бик озакка сузасы килә.

Менә син бер малайны уздың, менә икенчесен дә артта калдырдың. Син, шул рәхәтнең муллыгына түзә алмыйча, алдагы малайны да узып китәчәгеңә нык ышанган хәлдә, ташып торган бер җилкенү белән кычкырып җибәрәсең:

— Һәәә-й-йт! Кагы-ы-ыл!..

Шулай да иң кызыгы, үзенең рәхәте белән тынарыңны буа торганы алда әле. Тауның буеннан-буена

* *Чәнәшкә* — кечкенә чана.

шулай буран уйнатып, сызгырып шуып төшәсең-төшәсең дә, кинәт берзаман җирдән аерылып, чын-чыннан очып китәсең! Инеш буендагы вак таллар, күпер төбендәге кар өемнәре аста кала, җиң очларыннан, изүләреңнән, бишмәт итәгеңнән җил бәреп керә. Очу рәхәтеннән хәтта йөрәгең кысылып килә, күзләрең йомыла. Күзләреңне ачканда, син инде боз өстендәге тирән карга чумган буласың. Авызың-борының кар, муеныңа, җиң эчләренә кар тулган.

Синең артыңнан, куанычыннан кычкыра-кычкыра, чыелдый-чыелдый, иптәшләрең коела башлый. Кайсы, чәнәшкәсеннән атылып китеп, башы белән чума, кайсыберсе өстеңнән очып уза, иптәше өстенә барып төшә. Тик ничек кенә туры килгәндә дә үпкәләштән дә, ачуланыштан да түгел. Кая ул ачулану, кая ул үпкә-сапка! Бөтенесе уһылдый, көлә, кычкырып җибәрә. Берсе кар астына киткән сыңар итеген, чәнәшкәсен тартып чыгара, бүтәне бүреген каккалый. Тыныбыз-өнебез бетеп, беребезне беребез бүлдерә-бүлдерә куанырга, мактанышырга тотынабыз:

— Күрдеңме: минем чәнәшкә кайларга очты!

Безнең күрше Хәкимҗан ни тешләк малай инде. Башка вакытта аның сүзен эскәк белән тартып чыгарырга кирәк. Монда ул булып ул мактанмыйча түзеп кала алмый:

— Һи, менә мин ул! Минеке әнә кая барып төште!

— Ә мин выжт Ахунҗан яныннан!

— Әйе! Синең тимерле булгач та!..

Бил тиңентен кар ерып, мышный-мышный текә ярдан күпер өстенә менәбез. Анда тагын да шул ук сүз:

— Тагын бер генә! Әйеме?

— Әйдә, әйдә!..

IV

Тик өйалды баскычына аяк баскач кына искәрәсең: киез итекләрең бөгелми, баскан саен таеп китә, бишмәт итәкләре шакраеп каткан да як-якка тырпайган, берәр нәрсәгә бәрелүгә, калай шикелле шыңгырдап тора. Бияләйләр ишек тоткасын тота алмый. Бөтен өс-башың каткан, тик борын асты гына җепшек...

Баскычларны яман да шак-шак китереп, үзем белән бер көтү суык ияртеп, ишектән килеп керүгә, иң элек яшь әтәч булып апай ташланды:

— Ә, кайттыңмы, эшем кешесе? Әле ярты төн дә җитмәгән ич, тагын йөрисең калган!

Миндәге кайнарлык әле һаман да сүрелмәгән. Дәртле уенның әле генә татыган рәхәте, бөтен тәнемне биләп, үзалдына кинәндереп, күңелләрне җилкендереп тора. Мин үземне, абый укыган китаптагы шикелле, әле генә сугышта булып чыккан, дошманны җиңеп, шәһәрләр алып кайткан батырдан бер дә ким хис итмим. Әйдә, бәйләнә бирсен!..

Апай кеше бик чая тотынса да, әти белән әни алдында аның кул белән шаяра алмасын әллә каян белеп торам. Минем күз әти белән әнидә. Әни өс-башыма карап алды да башын чайкады, «атаң алдында күп боргаланма» дигәндәй ым кагып, тизрәк чишенергә кушты. Әти миңа юньләп карамый да, аның үз эше эш. Ул верстагы янында, бармак юанлыгы калын зәңгәр карандаш белән, рамга ярасы такталарын сызгалый. Ара-тирә янында басып торган шәкерт абыйга берәр сүз әйтеп куя. Әһә, менә кечкенә абый да кайткан. Ул, миңа борылып:

— Нихәл? — диде, бүрегемне чөйгә элде. Бу Хәмзә абыйның минем белән исәнләшүе дә, үзенә күрә минем хәлемне белешүе дә инде. Бу атнада минем әле аны беренче генә күрүем. Ул бүген кичкә таба гына Курса мәдрәсәсеннән ялга кайткан. Болай булгач, бүген кече атна икән, китап укый торган кич.

Ләкин куанырга иртәрәк булган икән. Мин җәһәт кенә почмак якка узыйм дисәм, апай мине ишек төбенә кире чигерде.

— Кая керәсең юган идәнне таптап?

Ул гына да түгел, зур ачылган күзләре белән, шаккатып, минем бүген беренче генә тапкыр киеп чыккан өр-яңа киез итекләремә текәлеп, кычкырып куйды:

— Әнекәем! Карагыз әле, күрегез әле бу тамашаны! Нишләттең ул итегеңне, ә?!

Каян гына күреп алды соң әле бу апай! Карасам, үзем дә шаккаттым. Итегемнең кунычлары ак килеш калса да, түбән ягы тоташ пычракка баткан, буялып, бозланып каткан. Нигә болай булуы шунда гына исемә төште.

Гыйбаш абыйдан алып кайтканнан соң, мин, яңа итегемне киеп, сөенче алырга дип күрше Хәкимҗаннарга кереп киттем. Башта ак өйләренә сугылдым.

Хәкимҗанның бабасы пеләш Миңлебай, шөшлесе белән шак та шок суккалап, түр якларында чабата ясап утыра. Кашлары җимерелгән, такыр башын чабатасына игән. Ник, ичмасам, күңел өчен бер генә күтәрелеп карасын! Хәкимҗан, минем янга кермәкче булып, ишектән борынын гына суза башлаган иде, Миңлебай бер генә тамак кырды. Хәкимҗан шундук өреп очырган шикелле юк булды.

Көтеп-көтеп тә Миңлебай карт итегемә карамагач, ас өйләренә кереп киттем. Тик анда да юлым уңмады. Бозау имезергә дип, ас өйләренә сыер керткәннәр икән. Ул аркылы баскан да уздырмый гына бит. Мин сыер койрыгы янында никадәр генә лышык-лышык борынымны тартып торсам да, итегемне анда да күрүче булмады...

Аннан чыккач, малайлар тавышын ишетеп, инеш буена йөгердем. Күрсәтмичә ничек җаның түзсен! Итегем шундый ак, шундый матур, андый итек бер генә малайда да юк!

Яннарына барып баскач, малайлар итекне күреп шаккаттылар:

— Ай-ай! — диделәр.

...Ул арада апайның шау-шуына әти дә борылып карады. Карандашын верстагына куйгач, аның урынына аршын аламы дип күзне мөлдерәтеп торганда, ул, сәкегә утырып, тезләренә таянды.

— Йә, юеш борын, әйтеп кара! Мондый коры көнне андый пычракны каян эзләп таптың? Йә! — диде.

Әтинең күзләренә карап булмый иде. Мин, башны иеп, сүзсез калдым.

— Йә! Телеңне йоттыңмы әллә?

Нишләптер сүзем чыкмый башлады. Әтинең кулы верстактагы аршынга сузылган кебек күренгәч, ничектер, үзеннән-үзе инеш буе, анда көлеп торучы Закир абый, аның көлгәндә ике катлылана торган сәер ирене күз алдыма килде.

— Закир абый...

— Ниямәрсә «Закир абый»? Нишләтте Закир абыең?

Әтинең кулы аршынга сузылмаган икән, тавышы да ул кадәр үк рәхимсез түгел шикелле.

— Ни, Закир абый безне инеш өстеннән сикертеп уйнатты.

— Катмый калган турысыннанмы?

— Ие...
— Сикердегезме соң?
— Ни, иң башта Нимҗан сикерде, ул суга барып төшкәч, бүтәннәре курыктылар.
— Син курыкмадыңмы?
— Башта мин дә курыктым анысы. Итекне дә кызгандым. Ялгыш кына суга төшсәң!.. Тик шунда олырак малайлар, һәммәсе бердәй, үчекләргә тотындылар:
— Үзе яңа итек кигән булган, үзе сикерергә дә курка!
— Әй, бигрәк йөрәксез малай икән бу Гумәр!
— Тап-тар инеш! Шуңа да йөрәге җитми...
— Һи, минем андый яңа итегем булса! — ди берсе, олтан салган итеген күрсәтә.— Минеке шикелле иске итек сикерәмени ул!
Аларга да әллә ни исем китмәде. Тик менә Закир абый сүзләре генә әллә нишләтеп җибәрде. Бер малай да сикермәгәч, ул, кулын селтәп, безнең яннан китә үк башлады:
— Әй, сездән буламыни ул? Андый батыр малайлар безнең очта бармыни соң! Җыен куркак, җыен тавык йөрәк!..
...Әти бармаклары белән верстагында тукылдап алды:
— Шуннан соң сикердең дә суга барып төштеңме?
Мин башымны гына идем. Малайларның егылышып көлүләрен дә әйтәсем килмәде.
Аларга көлке, ә мин тубык тиңентен суда. Мин еларга ук җитешкән идем инде, Закир абый тартып чыгарды.
— Кем басты итегеңне? — ди.
Мин, еламсырап:
— Гыйбаш абый...— дидем.
Ул бөтенләй күңелләләнеп көлеп үк җибәрде. Аның ирене әллә ике, әллә өч катлы булып сырланып чыкты.
— Һи, юләр! Гыйбаш баскан итеккә су үтәмени? Бигрәк тә яңа чагында!..
...Тау шуа башлагач, мин боларның һәммәкиен дә оныткан идем инде.
Әти нигәдер миңа түгел, апага ачуланды.
— Ниямәрсә карап торасың? Чишендер! — диде.

Сандугачны кем үтергән?

I

Мин белә башлаган вакытларда әти илле яшьләрдән узган киң җилкәле, таза гына бер кеше иде. Коңгырт кара чәчендә бер генә бөртек агы да юк, тавышы калын, вак кына тешләре ап-ак булып, тезелеп кенә торалар. Әмма шул матур тешләрнең җемелдәп яктырып китүен, әти кешенең рәхәтләнеп көлүен бәйрәм кебек әллә нидә бер генә, бик тансыкка гына күрә идек.

Ул йомшаклыкны, изелеп торуны, җебегәнлекне һич тә яратмады. Уңмаган, булдыксыз кешеләрне җене сөйми, андыйлар белән алыш-биреш итәргә дә теләми, исәпләшми дә иде.

Миннән олы абый Хәмзә белән җәй көнне лапаска печән өяләр иде. Әти астан печән биреп тора, абый өстә өеп тора. Әти зур сәнәк белән күп итеп биргәнлектән, абый аны тартып өлгерә алмый иде.

Әтинең:

— Җебегән! — дип кычкыруы булды, сәнәк белән бәреп җибәрүе булды. Абый дөпелдәп ишегалдына килеп төште.

Өйдән төсе киткән әни йөгереп чыкты, мин куркуымнан елап җибәрдем. Әмма абый шактый ук биектән егылса да, аягына торып басуга, әти аңа:

— Тиз бул! — дип кенә дәште.

Мин аның нинди генә кыен чакларда да зарланганын белмим. Иң каты авырган вакытында да ыңгырашканын ишетмәдем.

Кыш уртасының яман да котырынган көннәреннән берсе иде. Тышта буран улый, өйдә морҗалар үкерә. Тәрәзәләр шакыраеп каткан, бернәрсә күренми.

Менә караңгы да төште, кич булды. Өйдә ут алдылар. Әти һаман юк та юк.

Әни күршеләргә кереп, сорашып та чыкты. Һәммәсе кайтып беткәннәр. Тик базар юлында әтине бер генә кеше дә күрмәгән. Әни минут саен ишегалдына, капка төпләренә чыгып керә. Еларга җитешеп, нишләргә белмичә, уһылдарга, арлы-бирле сугылырга тотына:

— Ходаем, дөньяның асты өстенә килә, тыннар буыла. Күзләрне ачып булмый. Ниләр генә булды икән? Нишләп кайтмый икән?

Без, бала-чага, мәче балалары сыман бер-беребезгә сыенып, сәке өстендәге ястык тирәсенә укмаштык.

Тышта, ишегалдында, әллә нәрсәләр, әллә кемнәр, дию пәриедәй дулап, үкереп, бөтен нәрсәне кырып-җимереп йөриләр сыман. Хәтта абзардагы терлекләргә дә әллә ниләр булыр шикелле.

Бервакыт күземне ачып җибәрсәм, ишектән бөтен өйне тутырып, башта ургыла-ургыла салкын болыты бәреп керде, аннары шул болыт эчендә дәү бер гәүдә күренде. Әмма аның өсте-башы гел кар гына, бите белән маңгае урынында тоташ боз гына иде. Кечкенә сеңлем куркуыннан чырылдап җибәрде. Әни, аһыл-дап, каушап, елый-елый, нәрсәләрдер чишәргә, шушы карлы-бозлы куркыныч өем эченнән әтине йолып алырга кереште. Әтинең киемнәрен, бүрек белән итекләрен көчкә салдырды, сакал-мыегына, кашларына каткан бармак калынлык боз кисәкләрен ватып-ватып алды. Боларны карап тору гына да куркыныч иде. Аннары аны бик озак удылар, кайнар чәйләр, тагын әллә нәрсәләр эчерттеләр.

Әмма иртә белән мин торганда, ул инде тагын верстагы янында эшләп маташа иде.

Үз бакчабызда әти үстергән кишер, чөгендер, кәбестә кебек яшелчәдән әни телең йотарлык тәмле бөккәннәр, бүтән төрле ризыклар пешерә, ә без аларны бик рәхәтләнеп, мактый-мактый ашый идек. Ләкин ни хикмәттер, шул яшелчә белән җимеш бакчаларына су сибәр вакыт җиттеме, һәркайсыбыз чыгып таярга җай эзли иде. Чыннан да, иптәшләрең шау-гөр килеп уйнап йөргәндә, көтү кайткан вакыттан алып караңгы төшкәнче, кечкенә арбага җигелеп, сәгатьләр буе тау астыннан су ташып кара әле! Инеш шактый ук ерак, тау текә, мичкәләр авыр иде.

Безнең урам буендагы агач бакчасына, әллә андагы яман да учарланып үскән шомырт агачына, әллә карт миләшкә сандугач ияләнгән иде. Аны ел саен көтеп ала торган булдылар. Кичләрен, якын-тирә күршеләр белән капка төбенә җыелып, сандугач сайравын тың-лыйлар. Әгәр берәр кичне сандугач моңы ишетелми торса борчыла башлый торганнар иде.

Җәй башының бер иртәсендә сандугачны үле хә-лендә таптылар. Миңа, яланаяклы пырдымсыз малайга, монда искитәрлек берни дә юк иде. Бакчаларда, әвен

тирәләрендә андыйны азмы очраткан! Әтинең зур гәүдәсе, сакаллы башы белән шушы кеп-кечкенә кошчыкның үле гәүдәсе өстенә иелүен, аны дәү куллары белән кадерләп тотуын күрүгә, мин сәерсенеп калдым.

— Кайсы имансызның эше бу? — ди әти.— Кемгә дөнья тарайган? И нәләт! Муеннары сынгыры!

Озак кайгырышкан, уйлашканнан соң, сандугачны Әхәт үтергәндер дигән фикергә килделәр. Әхәт кичен апай белән сөйләшеп утырганда, сандугач тавышы боларга сөйләшергә уңайсызлаган да, янәсе, егет аны агач башыннан бәреп төшергән була.

Шулаймы, түгелме, анысын берәү дә күрмәгән. Әни, башын чайкап уйланып торганнан соң:

— Ай-һай! Ул аңа тоттырырмы икән? — дип шикләнә башлаган иде, әти аны ярты сүздә бүлдерде:

— Бүтән кем булсын! Бүтән кемгә кирәк? Шул кансыз! Шул зимагур!— диде. Әхәтне кат-кат сүгеп ташлады.

Сандугачны шомырт төбенә әти үз кулы белән күмде, каберен учлары белән тигезләп куйды. Әхәтләр ягына йодрык күрсәтеп тагын бер янап алды:

— Бер килеп капмассыңмы әле, ристан! Мин сине!..

Әти лапас тирәсенә китеп күренмәс булуга, өйдән, елардай булып, апа килеп чыкты. Әнинең иңбашына ябышып:

— Нахак бит, нахак! — дип пышылдады.— Ходаем! Белмәгән, күрмәгән көйгә! Нишләп ул тисен? Ничек кулы барсын? Юк, юк! Килгәне дә юк, тигәне дә юк! Ул андый да түгел! Нахак бу! Нахак!..

Күреп торам, әни ышанырга да, ышанмаска да белми иде.

— Тик торганда ник үлгән соң?

— Мин каян белим? Йә карчыга типкәндер, йә әҗәле җиткәндер.

Әни белән апай шуның белән баш ватып торганда, күрше кызлары, койма ярыгыннан пышылдап, мине үз яннарына дәштеләр. Ярыктан күзләрен елтыратып, берсен берсе бүлдереп мине юмаларга тотындылар:

— Гумәр җаным! — диләр болар.— Шул тирәдән эзләп карасана: сандугачның йонымы, йә булмаса берәр каурыемы төшеп калмадымы икән?.. Бик тә кирәк иде, бик тә!

Мин моның сәбәбен соңыннан гына белдем: сандугач канаты сөйдергеч икән! Әгәр сандугачның йә каурые, йә йоны белән егетнең берәр җирен сыйпасаң, ул егет кызны тәкатьсез булып ярата башлый икән...

Сораулар һәм биремнәр.

1. Ни өчен атка мөнәсәбәт шулай җылы, ягымлы булган? Колынга, эти-әнисеннән бигрәк, Гомәрнең сөенүен аңлатыгыз.
2. Халык авыз иҗаты һәм матур әдәбият әсәрләреннән ат образына бәйлеләрен исегезгә төшерегез. Аларда бу образга нинди мәгънәләр салынган?
3. Бүлекнең исеменә игътибар итегез: сагыш, автор фикеренчә, һәр тереклек иясенә хас. Шулай да колыннан аерылу сагышы, Гомәр күңелендә бик тирән эз калдырып, ни өчен бик озак сакланды икән?
4. Автор «яланаяклы, юеш борынлы токым» дигәндә кемнәрне күздә тота, бу сүзләргә нинди мәгънә сала?
5. Авыл баласының күргәннәре ниндирәк яктылыкта сурәтләнә? Бу чынлап та зарланумы? Кем мәҗбүр итә аларны шул «җәфаларны» чигәргә: эти-әниләреме, башка кешеләрме, тормыш шартларымы, үзләреме?
6. Сезнең дә дөньягызны онытып уйнаган чакларыгыз булдымы? Шулай мавыгуны ничек аңлатыр һәм бәяләр идегез? Тау шууның рәхәтен тасвирлаган урынны кабат укып, хикәяләү осталыгына игътибар итегез. Яраткан уеныгыз турында башкалар кызыгырлык итеп сөйләп карагыз.
7. Өй, гаилә җылысы ничек тасвирланган, шуңа игътибар итегез. Ата-ана һәм балалар мөнәсәбәтендә кайсы якларны аерып әйтеп була?
8. Киез итекләрен пычратып кайткач, Гомәрне этисе ачуланмый. Нигә дип уйлыйсыз?
9. Бәшир абзыйның холкы турында сөйләгез. Аның нинди сыйфатларын аерып әйтеп була?
10. Сандугач үлеменә бәйле хәлләрдән нәрсә аңладыгыз?

Язгы Сабан туйлары

I

Сабан туен, язның бу шау-шулы, ыгы-зыгылы һәм шатлыклы якты бәйрәмен, без, малайлар, кар җепшекләнә башлагач ук көтәргә тотына идек. Менә шәкерт малайлар мәдрәсә белән ике арада шакы-шокы агач башмак сөйри башлый, мәдрәсәдән кайтышлый

урам тутырып кар атышалар. Ул чагында инде күз «тышта кала», күк йөзенә күтәрелеп карасаң, күзләрең чагыла. Тыкрык буендагы сәрви агачында боргалана-боргалана эшләки сайрый: «Эшләки, эшләки, эшләмәсен хаста ки»,— ди. Җимеш бакчасына, түр тәрәзә каршындагы миләшкә, шомырт агачына кызылтүшләр килә.

Беркөнне йокыдан торуыңа, укалы муеннарын елтыратып, сыерчыклар кайтып төшкән була. Алар ерак илләрдән кайта торгач, бик арыганнар, ябыгып беткәннәр. Шулай да өйләренә кайту шатлыгыннан сайрамыйча түзә алмыйлар. Чыгалар өйләрдән апайлар, җиңгиләр, бала-чагалар. Китә куану, соклану. Кайсы карда ауный, кайсы:

— Авырлыкка — җиңеллек! — дип сикергәләргә тотына.

Беркөнне карыйсың, мәчет янындагы мәйданда кар эреп беткән дә ашъяулык кадәр генә җир чыккан. Салкын кар суы ялан аякны өтеп-өтеп ала. Соңыннан аягың чебилисен дә, моның өчен өйдәгеләрдән эләгәсен дә беләсең. Шулай да кайсы гына малайның, аяк киемен салып ыргытып, шул юеш, йомшак җир өстендә эссе табага баскандай сикергәләгәне юк икән?..

Менә тагын беркөнне, кичкә таба, тау астындагы тын инешкә кинәт әллә ни була. Ул авыр эшкә тотынган сыман уфылдый, көчәнергә керешә. Ул да түгел, кыш буе өстен каплап, тынын буып яткан калын бозны шатыр-шотыр китереп ватып ыргыта да кабарынып, бүртенеп өскә бәреп чыга. Килеп чыга да,— күрәсең, яз кояшы аның башын әйләндерә торгандыр,— ул шундый котырына, тилерә башлый. Шашынудан кая барып бәреләсен белмичә, башта авыл уртасындагы күпергә, аннары зират янындагы тегермән буасына ташлана. Берни дә каршы тора алмый котырынган ташуга! Юлында нәрсә очрый, һәммәсен җимереп вата да сыпырып кына алып китә: карт өянкеләрне сындырып ыргыта, күпер төбендәге тау-тау тирес, кар, боз өемнәрен кубарып ала, иске мунчаларны, печән кибәннәрен агызып китә.

Шул көннән башлап авыл тынлыгына яңа аваз өстәлә: ташу шаулавы. Иртән торып чыгасың — шаулый, төнен тыңлыйсың — шаулый. Китә шуннан салам яндырып ут көймәләре агызулар, китә су буенда чыр-чу килеп сикерешү, шаярышулар.

Ул арада инде түбәрәк урыннар бөтенләй ачылып, җир өсте ала-кола була, тик басу юллары гына, эреп бетә алмыйча, боргаланган соры елан булып, сыртларын тырпайтып яталар. Сәрви агачларының ябышкак бөреләре бүртеп чыга. Кыяр-кыймас кына борын төртә башлаган чирәмлектә малай-шалай Сабан туе алдыннан көч сынашырга тотына. Бер мактанчыграгы, икенчесенең каршысына басып, нәкъ әкият батырлары сыман:

— Алыштанмы, салыштанмы? — дигән була.

Каршы чыгасы малайның да сер бирәсе килми. Ыштанын күтәргәләп, йә бүреген төзәтеп:

— Алыштан да булыр, салыштан да!..— дип куя.

Бер-берсенең биленнән кысып алалар да әй тотыналар әйләнергә, күтәреп алырга, чалкан ятып баш аркылы чөяргә! Әйтерсең чын көрәшчеләр.

Шулай бөтен дөньяны онытып көрәшеп ятканда, кайсыдыр:

— Кыр казлары! — дип аваз салды.

Бөтенебез күккә текәлдек. Анда берни дә күренми иде әле. Менә тыңлый торгач, Яурышкан ягыннан моңсу гына, юаш кына каңгылдаган тавыш ишетелде. Аннары үзләре дә күренә башладылар. Әллә ни арада авылның олысы-кечесе капка төпләренә, баскыч алларына чыгып басты. Һәммәсе, кулларын маңгайларына куеп, күктәге матур булып тезелеп килгән өчпочмакка карыйлар, кадерле кунакларны каршы алгандай, йөзләре шатлык белән балкый.

— И мескеннәрем, кайлардан кайталар бит!

— Әнә нинди арганнар!

Кыр казлары, зур өчпочмак булып тезелгән килеш канатларын салмак кына җилпеп, авыл өстенә якынлашып киләләр, бераз барган саен, әле берсе, әле икенчесе, авыл кешеләренә сәлам биргәндәй:

— Кый-гак! Кый-гак! — дип куя иде.

Минем «Әгәр санасаң, адашалар икән!» дигәнне ишеткәнем бар иде. Шуның дөресме, юкмы икәнлеген бик беләсем килде дә яшеренеп кенә санарга керештем. Унбишкә кадәр санавым булды, өчпочмакның бер канаты чыннан да чуалып алды. Минем бармакларым бөгелеп, иреннәрем селкенгәнне Шәйхи күреп алган икән, ул мине каты гына төртеп җибәрде.

— Санама диләр сиңа! Күрмисеңмени, әнә адаштырасың! — диде.

Күктән килгән моңсу тавыш йорт казларын әллә нишләтеп җибәрде. Алар югары очтан түбән очка кадәр бөтен авылны яңгыратып каңгылдарга тотындылар.

— Кый-гак, кый-гак!

Алар күккә карап әсәрләнәләр, шундый матур тезелешеп очкан кыргый туганнары янына күккә менәргә теләгәндәй, урам буенча оча башлыйлар. Әмма бераз очып баргач ук туктыйлар да туганнарының артыннан: «Хушыгыз инде, хушыгыз»,— дигәндәй, нәүмизләнеп кычкырып калалар.

— Кый-гак!!!

— Кый-гак!!!

Сабан туеның көн саен якыная баруын кешеләр генә түгел, хәтта атлар да сизә. Яшь айгырлар, байталлар, чабыш атлары, аран тәрәзәләреннән башларын сузып, кырлардан, болыннардан агылган бераз юеш, бераз җылымсарак яз һавасын озак-озак исниләр. Исниләр дә дәртләнеп, җирсеп кешнәргә тотыналар.

Мәйдан тотасы атларны бер эшкә дә җикми башлыйлар. Эчләре җыелып килсен, сулышлары иркен булсын өчен, аларга ипи белән солы гына ашаталар. Койрыкларын кыска гына бәйләп, аякларын «кыздырырга» йөртәләр. Алар басу юлы буйлап иртүк чыгып китәләр дә, әллә кайлардан әйләнеп, тирләп, тартылып, тез тиңентен пычракка батып, көндез генә кайталар.

Чабыш атлары узып барганда, без, уеннарны онытып, тып-тын кала идек. Шулар арасында кайсыдыр канатлы тулпар булса? Ул канатын беркемгә дә, хәтта хуҗасына да күрсәтми икән. Тик төнлә йоклаганда гына иркенләп канатын җәеп сала, ди. Шуның өчен шул: төнлә белән ат янына чыкканда, ерактан ук тамак кыргалап, дәшкәләп, ничек тә тавыш биреп барырга кирәк. Югыйсә кинәт өстенә барып чыксаң, ат канатын җыярга өлгерә алмый икән дә, канатын кеше күрсә, гарипләнеп кала икән. Аннан соң гомер буена мантымый, имеш, ди.

Әнә сөйлиләр бит. Әллә безнең авылның, әллә Каенсарның бер кешесе шулай дәшми-тынмый гына аранга барып кергән икән, атының канатларын җәеп йоклап яткан чагы булган. Шуның аты телгә килеп әйткән, ди:

— И Сәйфетдин, Сәйфетдин, үз бәхетеңнең үзең кадерен белмәдең. Моннан соң гомергә дә юньле ат

чырае күрмәссең,— дип. Үзе бераздан ук чирләп үлеп тә киткән, ди.

Канатлы ат, әкияттәге корчаңгы тай шикелле, күрер күзгә бик тә ябык, бер дә күз төшерерлек, кеше кызыгырлык булмый, имеш, ди. Без, ике күзебезне дүрт итеп, шундыйрак атларга текәләбез: шунысы түгелме икән, әллә менә монысымы икән?.. Ник алай дисәң, һәр малайның күңел түрендә мавыктыргыч бер яшерен уе бар: ул, шундый тулпарга атланып, әллә кайларга, ниндидер бер ямьле, матур дөньяга очасы бар кебегрәк сизенеп йөри...

II

Иртәгә Сабан туе дигән кичне кем генә тыныч йоклый алды икән! Көне буе урамнан кайтып кергән юк, телең чыгардай булып арылган. Инде күзләрең дә йомылып, йоклап та барасың. Юк бит! Йоклыйм гына дигәндә, күрше малайларының Сабан туена дип тектергән яңа күлмәкләре, камзуллары йә булмаса яңа кәләпүшләре күз алдына килә. Кайсысының кәләпүше чем-кара, кайсысының зәңгәр хәтфәдән. Чуклы кызыл кәләпүш булса, анысы инде бигрәк тә күзне кыздыра. Сузылып кына үзеңнең әзерләп куйган киемнәреңне капшап карыйсың да авыр сулап куясың.

— Йокла, улым, йокла,— ди әни.— Юып җибәргәченнән, хәзер синең кәләпүшең дә бер дә, ичмасам, яңадан ким түгел!

Өммикамал апай белән алар казанда иртәгә бала-чагага өләшәсе күкәйләрне суган кабыгы салып буяп маташалар.

Койма буеннан, чулпыларын чылтыратып, үзара көлешә-чыркылдаша, кызлар узып бара. Баш очындагы тәрәзәдән язгы җылымса җирнең бераз гына татлырак, бераз гына ниндидер үлән исләрен дә хәтерләтә торган ягымлы исе бөркелә башлый да, шушы рәхәткә тирбәлеп йоклап та китәсең.

Иртә белән шыгырдап ишек ачылган тавышка уяндым. Кая ул бүтән көннәрдәге шикелле киерелеп-сузылып, иркәләнеп яту! Күлмәк белән чалбарны эләктереп сикереп тә төштем, аннан-моннан юынгалап киенеп тә алдым.

Таң белән тормакчы булып ятсам да, барыбер соңга калганмын. Әни кемнәр беләндер сөйләшә, ишек

янында кемнәрдер кыштырдый. Аларның шәүләләре генә күренә. Ник дисәң, әле яктыра гына башлаган. Бүтән көнне булса, болай караңгыда кармаланмаслар, ут алган булырлар иде. Әмма мин бүген юри ут кабызмыйлар дип уйлыйм. Чөнки әгәр лампа яндырсаң, Сабан туе иртәләрендә генә була торган бу үзалдына бер моңсу соры тынлык юкка чыгар да, бәйрәм куанычының кайсы ягыдыр китек булыр кебек иде.

Әнә тагын бер төркем килеп керде. Әни күчтәнәчләрен ала да ишек янында шәүләләре генә шәйләнеп торган эреле-ваклы балалар каршысына килеп баса:

— И оланнар, сезне кем балалары дип кенә әйтим соң? — ди.

Тегеләрнең тыелып кына хихылдаулары ишетелә. Шаян гына балалар тавышы:

— Танымыйсыңмыни? — ди.— Бәдерниса белән Хәерниса, Халисә белән Мәликә ич без!

Әни бот чабып үкенергә тотына:

— Әй Аллам, менә син! — ди.— Оятлы була язганмын лабаса! Үзебезнең кызларыбыз икәнсез ләбаса!

Берсе артыннан берсе икешәр, өчәр, дүртәр булып керә торалар, күчтәнәч алып чыга торалар. Аларның якынлыкларына карап, әни күбесенчә кызыл башлы тастымалдан әтмәлләгән кечкенә капчыкларына йә йомырка, йә кызыл билле прәннек, йә ак төш салып чыгара. Туган-тумача, кардәш-ыруга кергәндә, үзеңә дә шундыйрак күчтәнәч бирәләр. Базар прәннеге алырга, йә ак төш пешерергә хәленнән килми икән, төш дигәнне арыш онынннан да куырып куялар. Сабан туенда нинди генә күчтәнәч бирсәләр дә гаепләштән, үпкәләштән булмый. Хәзинәдә бары. Бары — бергә, югы — уртак. Ни генә булса да — ихлас күңелдән.

Шулай таң тишегеннән торып, күрше-күләнгә, аргы һәм бирге очтагы кардәш-ыруга кереп-чыгып йөри торгач, кояш чыга, көн була. Апай пешергән бәйрәм коймагын аннан-моннан гына капкалап, урамга ашыгасың.

Капка төпләре тулы бала-чага. Китә мактану, китә кәперенү. Кем күпме йомырка җыйган, кызылы күпме дә бишние күпме? Әчтерхан чикләвеге белән конфетлар кемнәргә эләккән? Мактанчыграк малайлар күкәйләрен көрәшчеләр кебек чарт та чорт маңгайларына бәреп

ваталар да шундук мүкелдәтеп ашап та куялар. Маңгай кызара кызаруын, кайчакта күбеп тә чыккалый. Һи аның ише генә! Сабан туе бит!..

Тагын бераздан урамнар атларының ял-койрыкларына кызыл чуклар таккан егетләр, яшүсмер малайлар белән тула. Алар, йорттан йортка кереп, шаугәр килеп, йомырка җыеп йөриләр. Шул арада гармун тартып җырлап та җибәргәлиләр.

Әмма болар һәммәсе дә Сабан туеның бисмилласы гына әле. Безнең Арча ягында Сабан туеның каймагы, иң шау-шулы, иң күңелле өлеше, көрәш белән чабышларның да иң кәттәсе икенче көнне башлана иде.

III

Менә берзаман югары очтан, үзенең салпы колаклы, дәү корсаклы дәү алашасына атланып, бер төркем яшьләр белән Гыйбаш абзый килеп чыга. Аның кулында озын гына ап-ак сөян колга. Бүген алар ике Сабан туе арасында килен булып төшкән яшьләргә, җиткән кызларга гына туктыйлар.

Мин үзем күбесенчә Гыйбаш абзый тирәсендәрәк бөтерелә идем. Зерә дә кәмит кеше ул Гыйбаш абзый. Кайчан гына булмасын, башына тузмый да, яңармый да торган шул ямьшәйгән ак киез эшләпәсен, өстенә ачык изүле зәңгәр киндер күлмәген, кара камзулын кияр дә аның өстеннән озын киндер алъяпкычын ябар. Аягында Сабан туе хөрмәтенә әле беренче генә тапкыр киеп чыккан озын кунычлы ап-ак оек, өр-яңа чабата. Дәү битле, озын гына итләч борынлы, түгәрәк сакаллы, борын эче белән тыңкышланып сөйләшүче аз сүзле, салмак кына бер пошынмас бәндә.

Сабан туенда йомырка белән сөлге-тастымалны — анысын инде, ташка тамга салган,— һәр елны ул җыя. Җир бүлгәндә, печән өләшкәндә, шобага белән сажин таяклары да аның кулында. Тик аның белән генә бетми әле. Гыйбаш абзый, халыкка йөрергә якын да, җайлы да булсын дип, тау кырыйларын казып, яңа юллар сала, кырын-ярын юлларны әледән-әле тигезләп тора, язын-көзен томалана башлаган чишмәләрне тазарта, «мал эчерергә дә кирәк, урак өстендә үзебезгә дә су якын булыр» дип, әллә кайлардагы басу түрләрендә яңа чишмәләр казый. Бу изге хезмәтләре өчен

аңа рәхмәт яудыралар, ул салган яңа юлларны «Гыйбаш юлы» дип йөртәләр.

Олылар, мыек астыннан гына елмайгалап, аның киез итекне бик оста басуы турында да сөйлиләр. Гыйбаш баскан итек, никадәр генә озак киелмәсен, берничек тә тузмый, дөресрәге, бөтенләй туза алмый, кешенең гомере буена җитә, ди. Тик шул ягы гына шәп үк түгел, диләр, ул баскан итекне киюче бик сирәк була икән. Ник дигәндә, Гыйбаш абзый йонны да алып кала, басып бирергә вәгъдә дә итә, тик басарга гына ашыкмый. Кайчакларны аның вәгъдәсе хәтта әллә ничә елга сузыла, йонны чормада көяләр турап бетерә, ә итек дигәнең һаман басылмый да басылмый. Шунысы кызык: аннан барыбер өмет өзмиләр, хәтта ачуланмыйлар да, тик көяләргә азык итеп, яңа йон гына китерәләр.

Хәзер менә шул абзый, җиткән кызлар, киленнәр саен туктый торгач, ялкау алашасына чөңгерә-чөңгерә, безнең капка төбенә килеп туктады.

Безнең апай, сөлге-тастымал сугуы, төрле йорт әйберләрен оста чигүе белән дан тоткан кыз булганлыктан, бүтәннәрдән уздырып, Сабан туена ел саен бирәр зат әйбер бүләк итә торган иде. Менә хәзер дә капка төбенә килеп бөялгән егетләр, атларын биетеп, тәрәзәгә карый-карый, яман да телләренә салынырга тотындылар:

— Кая соң, Өммикамал өйдәме? Сөлгеләре чөйдәме?

— Егетләр! Бәшир абзый үзе чыккан, зурлаган!

— Зифа тәтәй, нихәлләр? Көттегезме? Без килдек!

Әни, авызын каплый төшеп, елмаебрак өйалды ишегеннән карап тора.

— Шуңа сәерсенеп торам,— диде әти.— Яшь килен безгә төшмәде ич, әнә күршедә! Монда ялгыш туктадыгыз түгелме?

Алдарак торган егетләр көлешеп алдылар.

— Ха-ха-ха! Инде дә, Бәшир абзый, хитри син! Була дигәндә генә борып җибәрмәкче! Бер дә ялгыш түгел, тач өстенә бастырдык.

— Шулаймы икән?!

— Өммикамалның бүләге бөтен Сабан туена ямь бирә!

— Кая соң үзе, ник чыкмый?

Апай әллә кайчан ук әзер иде. Ул, шәльяулыгының бер почмагын авызына кабып, йөзен бераз яшеребрәк чыкты. Бүләк итәсе чигүле ашъяулыгын, ике башыннан тотып, баш очына күтәрде. Куе яшел болын уртасында зур чәчәк түтәле, почмакларында да шундый аллы-кызыллы чәчәкләр үсеп утыра.

Моны күрүгә, егетләр, берсен берсе бүлдереп, бүләкне мактарга тотындылар:

— Егетләр, монда карагыз!

— Ай-ай-ай! Иллә дә зурладың, Өммикамал!

— Күзләрнең явын алырлык!

— Җепләре ефәктәндер моның, инәләре көмештер!

Кайсыберсе шау-шу арасында:

— Бәрәкалла, ай рәхмәт! — дип кычкырып җибәрә.

— Бер урынына ун булсын, эшләрең гел уң булсын!

Бер кызмачарагы, әллә этине күрмичә, әллә юри күрмәгәнгә салынып:

— Өммикамал җаным! Атаң матур кияүгә бирсен! — дип кычкырды.

Аннан иелә-сыгыла көлделәр. Мыек астыннан гына эти үзе дә елмаеп куйды.

Апайның өсте-башы матур, йөзендә шатлык уйный. Ул хәзер бирәүдән дә битен яшермичә, мактаганга кинәнеп, бөтенесенә елмаеп тора иде. Бәлки, ул арттарак басып торган Әхәт абыйга шулай елмайгандыр?..

Сораулар һәм биремнәр.

1. Яз килүе тасвирланган урында табигать һәм кешеләр аерылгысыз бер тереклек, бер-берсен аңлый, тоя белгән җан ияләре булып күз алдына килә. Сез дә үзегезне сокландырган табигать күренешен хикәяләп карагыз. Ташу акканны, кыр казлары кайтканны күргәнегез бармы?
2. Атның канатлы булу ихтималлыгына ышану каян килә? Нигә аны канатлы итеп күз алдына китергәннәр? Сез, гомумән, могҗизага ышанасызмы, ул ышану нигә кирәк дип уйлыйсыз?
3. Сабан туен көтеп алу, аңа әзерләнү, бәйрәмгә үзең катнашуның никадәр дулкынландыргыч һәм әһәмиятле булуына игътибар итегез. Сабан туена әзерләнгәндә, нинди эшләр башкарылырга, гомуми кабул ителгән нинди кагыйдәләр үтәлергә тиеш, санап карагыз.
4. Сабан туенда һәркем ниндидер осталыгы белән күренеп калырга тырыша. Сезгә кемнәр аеруча ошады? Сабан туе бәйрәменә сез нинди өлеш кертер идегез?

Орлык чыккан көн

I

Менә тагын бер кыш узды. Миңа җиде тулып килә.

Беркөнне кичке чәй вакытында әти гел миңа күз салгалап утырды. Табын яныннан торып киткәннән соң, мин тегесен алып, монысын кузгатып, верстак тирәсендә кайнашканда да, каш астыннан гына гел мине күзәткән кебек күренде.

Мин инде, ул-бу кузгалганчы, мыштым гына чыгып таярга җайлашып, ишек янына ук барып җиткән идем, әти кырт кисте:

— Йөрисе түгел! Җитте сиңа! Ят та йокла. Иртәгә тырмага чыгарсың.

Әһә! Иртәгә орлык чыгарасы көн икән. Әйтәм аны, әни бүген көне буе печәнлектә йомырка җыеп йөрде. Әйтәм, әти белән абый, бәйрәмгә әзерләнгәндәй, ишегалларын, урамнарны себерделәр, сабан белән тырмаларны, барлык кирәк сбруйларны хәстәрләп куйдылар. Бөтен өй эче мунча кереп юынып чыкты. Апай самавырны агартып, аңа йолдызлар төшерде, идән-сәкене юып чыгарды. Ишегалды белән өй эче үзенә күрә бер бәйрәм төсе алды.

Мин шундук, тәүфыйклы малай кыяфәтенә кереп, чишенергә тотындым. Менә нилектән әти шулкадәр сынап караган икән! Бу малайның буе-сыны, җегәре-мазары ничек, тырмага кушарлык рәте-юне бармы, булдыра алырмы, дип чамалаган икән. Дөрес, минем моңарчы да тырма тырмалаганым, хәтта сабан артыннан да йөргәнем бар. Тик ул бит йә әтигә, йә абыйга ияреп кенә. Ә монда инде үзең баш, үзең муен. Үзең башлыйсың, үзең түгәрәкләп тә куясың.

Мин иртәгә, чәчү башланган көнне, иртүк торып олы кешеләр белән чәй эчүләр, басуга чыгып китүләр турында йоклаганчы хыялланып яттым. Иртә белән әни, мөгаен, каймаклы катык ашатыр, бәлки, коймак та пешерер әле... Бер-ике йомырка эләгә дә эләгә инде. Арчып урталай ярасың да тоз сибеп ашап җибәрәсең. Шул киселгән җиренә азрак атланмай да тидереп алсаң, телеңне йотарлык ук була да бит...

Болай кыр эшендә йөргәч, син инде олы кешеләр рәтенәрәк керәсең. Юкса бит...

Әйтергә генә ансат, җиде тутырып килүемә карамастан, минем һаман да үз иманам* юк иде әле. Дөрес, әти дә, бүтәннәр дә минем үземә моны сиздермәскә тырышалар. Шулай да ул турыда әледән-әле сүз чыкмыйча калмый. Берәр читтән килгән кунак, сүз арасында:

— Иманагыз икәү генәмени? Ир-ат сездә өчәү ләбаса. — ди.

— Менә кече улыбыз җир өләшкәннән соң туды да җирсез калды шул!

Әле мин генәме! Апай да шундый ук кыенлыкны кичерә бит. Эшнең иң авыры әни белән апай өстендә. Арыш белән сабан ашлыгын уру, чүп утау, киндер, җитен йолку, бәрәңге алу, киндер чылату, ашлык сугу, терлек карау, җеп эрләү, киндер сугу, су китерү, мунча ягу, өйне җылытып, җыештырып тору — тагын әллә ниләр, әллә ниләр! Әмма аларның да җире юк. Әнә моны бирәү дә аның исенә төшермәсен, әнә ул минем шикелле оялчан да булмасын. Шулай да кайвакытларны апай түбән карап, вак-вак кына капкалап утырса, шуңа кимсенәдер шикелле тоела иде.

Болай тырмага йөри башлагач, мин апай өчен дә эшлим була бит инде.

Әни, капканы ачып, игеннәргә уңыш, безгә җиңел аяк, хәерле юл теләгәндә, әтинең чырае караңгы түгел иде.

— Шулай булсын! — диде.

Хәер, иртәсе дә караңгы чырайлы, эленке-салынкы түгел, бик ягымлы, бик тә ямьле булып, матурланып килә иде.

Төрле йортлардан арбаларына тырмаларын, сукаларын, орлык ашлыкларын төяп, безнең шикелле сабанчылар чыгып килә.

— Әти, күкәй кемгә эләгер икән, ә?! — Орлык чыгарган көнне иң беренче очраган кешегә йомырка бирергә кирәк. Борынгыдан килгән гадәте шундый. Капканы чыгуга, әти як-ягына каранды да:

— Кем булсын? Әнәтерәк! — диде.

Югары очка таба карасам, аннан әлеге шул салпы колаклы күк алашасына атланып, Гыйбаш абзый төшеп килә. Әти аңа тубалдан ике йомырка алып сузды:

---

* *Имана* — патша вакытында бер җанга тигән җир һәм шуннан түләнә торган налог.

— Гыйбадулла! Гел мач кына килеп тора инде үзеңә! Чәчү йомыркасы сиңа эләкте бит! Әллә югыйсәм исеннән сизәсеңме син? Ә?!

Гыйбаш абзый көлеп җибәрде:

— Һы-һы-һы. Бәхетле... нинең борыны очында бер ашарлык ризыгы йөрер, ди. Шуның шикелле...

Шундук, мыш-мыш килеп, йомырканы капкалап та алды. Җир өстенә барып җиткәч, эти, уртагарак кереп, бер йомарлам туфрак алды да аның җылылыгын чамаларга керешге. Ул аны әле бер кулында, әле икенчесендә кысып карады. Аннары, җиңен сызганып, беләгенә куйды, борынына якын китереп иснәп алды. Әти туфракны шундый ипләп, күзләрен йома төшеп, шундый ихлас күңел белән тәмле итеп иснәде, аның бераз җылымсарак төче исе хәтта минем борыныма да килеп кергәндәй тойдым. Әле моның белән генә канәгать түгел иде. Менә ул як-ягына каранды. Бүтән елларны ул җирнең чәчәрлек булып җылынганмы, түгелме икәнлеген җиргә утырып карап чамалый торган иде. Әмма бу юлы якын-тирәдә кешеләр күп булганлыктан, алай итәргә кыймады булса кирәк. Җир өстенә чүгәләгән килеш, кулындагы туфракны бер болай, бер тегеләй китереп, «бүреге белән» киңәшергә тотынды.

— Һм, җылы төшеп җитмәгән шул...— дип сузды.— Бүген үк чәчкәндә, тишелә алмыйча сөтләнеп ятмагае, бозылып. Ярый ла җылытып җибәрсә! Чәчми торсаң, соңгарак калуы бар... Бишектәге бала инде. Җылы кирәк, җылы!..— Шулай байтак икеләнеп утырганнан соң, шактый ук күтәрелеп җылыта башлаган кояшка күз салды, күрше-тирәдәге чәчүчеләргә карап алды да аягүрә басты.— Аллага тапшырдык!

Тубалга бодай тутырды да аның өстенә әни пешереп җибәргән дистәдән артык йомырканы салды. Тубалны муенына асканнан соң, җир башына барып баскач, йөзен төрле якларга боргалап, җилнең кайсы яктан исүен чамалап торды.

Минемчә, һава тып-тын, җил бөтенләй юк шикелле иде. Биткә дә бәрелми, атның ял-койрыгы да, юл кырыендагы әремнәр дә селкенми. Әмма эти кулын көньякка таба күтәреп торганда нидер чамалады, күрәсең.

— Алай икән,— диде. Авызын кыймылдатыр-кыймылдатмас кына бисмилласын әйтеп, беренче адымын

атлады.— Хәере белән. Бала-чага, терлек-туар бәхетенә...— дип пышылдады.

Бер уч сипкән саен, орлык чажылдап тубалга бәрелә дә чәчрәп җир өстенә сибелә. Селтәнгән саен, туфракка бер-ике йомырка барып төшә. Борынгыдан калган йоласы шундый: беренче көнне орлык белән бергә күкәй дә чәчәргә кирәк. Шулай итсәң, игеннәр уңышлы була, бөртекләре шушы йомырка шикелле эре була, ди. Бабайлар шулай әйтеп калдырган...

Һәр елны җир өстенә беренче булып барып басканда болай гына ярамый икән, эшкә керешер алдыннан җиргә сүз әйтергә кирәк була икән. Әни миңа шуларны өйрәтеп җибәргән иде. Шул сүзләрне әйтә-әйтә, мин дә тырма белән җир өстенә кереп киттем:

— Җир, җир, көчем бир, алты атның көчен бир, алтмыш арба арыш бир!..

Әйтеп бетергәч кенә искәрдем. Әни миңа арыш чәчкәндә әйтә торганны өйрәткән, ә без бодай чәчәбез...

Әти тубалындагы йомырка дүрт-биш селтәнүдән артмады.

Алар, туфрак өстенә чит-ят нәрсә булып, тегендә дә монда агарып күренәләр иде. Әти, чәчүеннән туктап, аларга кызганган сыман карап торды да миңа баш какты:

— Җыеп ал!

II

Аргы баштан чәчеп килгәндә, әтинең нигәдер чырае бозылган иде. Ул тубалын куйды да, сукрана-сукрана, адымлап җир башын үлчәргә тотынды:

— Ай бу ач күзне! Ай бу туймас күзне!

Шулвакыт күрше өлешкә малае белән Галимҗан абзый килеп туктады. Гадәттәгечә, «Алла куәт бирсен»не әйткәннән соң, җир башына карый-карый, мескен бүреген салып, шуның тышкы ягы белән тирләгән башын сөртергә кереште. Анның аты да җирән, малае белән үзе дә кызгылт башлы иделәр. Бактың исә, Сарник дип йөртүләре дә шуннан килеп чыккандыр әле.

Әти аның үзенә дә, малаена да икешәр йомырка суздың:

— Аша, Галимҗан, аша! — диде.— Йоласы шулай. Орлык чыккан көн. Тик кеше хакына кермә, гадел бул!

Галимҗан абзый, сөртенүеннән туктап, башта авызын ачып калды:

— Син әллә нәстә әйтәсең түгелме, Бәшир абзый... Берүк, Аллам сакласын.

Әти, аның сүзенә игътибар итмәстән, кулын артына куйган килеш, күршесенә:

— Аллаң сакламаган шул, Галимҗан! Беләмсең, иң изге әйбер ниярсә дөньяда? Гаделлек! Пәйгамбәрләр дә шулай дигән, бабайлар да! Гаделлек! Үл, кырыл, утка ян, тик гадел бул! Гадел бул, Галимҗан! — диде.

Галимҗан бүреген бер алга китереп, бер артка чигереп маташты.

— Болай анысы Аллага шөкер дигәндәй... Берәү дә әйтмәс...

— Әйтергә туры килә шул менә. Болай да чытырдатып кыстылар бит инде, чыкмаган җан гына бар.— Әти кулларын айкап алпавыт җирләрен күрсәтте.— Әнә теге якта безнең җирдә албасты булып Цызган алпавыт ята, бу якта Черпак алпавыты. Шуның өстенә тагын син минем җирне ярып ал ди, мин синекен. Аннан кемгә ни файда? Кайсыбызның арт ягына... кояш чыга?

— Туктале, кем, Бәшир абзый, әйтеп сөйләш: нәстә булган?

— Менә ниямәрсә булган!

Әти Галимҗан җире башыннан киерелеп-киерелеп җитез генә адымлап китте.

— Менә карап тор! Синеке унсигез ярыммы? Әле ике чабата иңлеге артыгы да бар. Инде менә безнең җирне үлчик... Унбиш, уналты ярым! Унҗидегә дә тулмый. Кая киткән моның бер адымы? Синең комсызлыгың бу, Галимҗан! Югыйсә бит икебезнең дә җир бертигез булырга тиеш!

— Соң бит, Бәшир абзый, адымның ниндие булмый, дигәндәй...

— Алып батыр адымы түгел, кеше адымы. Ниярсәгә хәрәмлисең, Галимҗан, нишләп кеше хакына керәсең?

— Ялгыш кынадыр ул, Бәшир абзый, хаталык белән генәдер. Менә бу җирән шайтан ызан сызганда синең җиргә таба каергандыр...

Әтинең ачуы торган саен күперә бара, аның саен күзләре усалрак карый. Ул катырак кычкыра башлады.

— Һай, Галимҗан, һай бу килде-китте лыкылдаучы телне! Ир кеше сүземе шушы?! Соң алай булгач, ул җирән шайтаның ялгышып ник үз җиреңнән миңа бирәр адым каермаган?!

— Ис тә китмәле инде, күрше, шаклар катмалы!

— Юк, Галимҗан, син исең-һушың китмичә, ир кеше булып, чын дөресен генә әйт әле! Нишләп син Бурсык юлында ике адым, Бөйдә буенда адым ярым минем җирдән ярып алдың?

Сарник йомырка кабыкларын бармаклары арасында чытырдатып читкә ыргытты.

— Әйтәм, Бәшир абзый, билләһи менә ихлас күңелдән, тәүбә итеп әйтәм. Дөреслеккә күңел бик дөрес минем, бик! Күңелдә, ичмасам, тузан кадәр дә үпкә юк! Җир башына килеп җиткәч, күңел әйтә: кеше өлешенә кермә, Галимҗан, яхшы түгел, язык була, ди. Ә кул дигәнең, каһәр суккыры, тарта да төшерә алашаны читкәрәк. Күңел җир буенча сызланып бара: «Һай, дөрес булмады бу, Галимҗан, язык инде бу, кеше хакына керелде ләбаса, тукта, икенче әйләнмә»,— ди.— Сарник шап иттереп күкрәгенә сугып алды.— Юк бит, әйтә торып тыңламый нәфес! Тыңламый! Тагын читкә тарта алашаны! Икенче әйләнүдә тагын бер төрән иңлеге каерып ала! Аптыраш менә шуңа, Бәшир абзый, прәме аптыраш!

Әти, коңгырт мыекларын сыпырган булып, тубалына иелде. Мин аны көлемсерәгән сыман күрдем.

— Күңелең эшеме, кулың эшеме, анысын үзең төпченерсең. Минем җиремне үземә кисеп бир!

— Чәчелгән булса дамы?

— Шулай, орлыгы кергән булса да! — Әти, тубалын алып, яңадан җир башына барып басты.— Әгәр тыңламыйсың икән, анда инде үпкәләштән булмасын! Иген өлгергәч, өч җирдән бер арба ашлыгыңны төйим дә китәм. Менә шулай, Галимҗан күрше!

Әти шулай диде дә тубалын асып чәчәргә тотынды. Сарник, җир башларын үлчәштереп, арлы да бирле сугылгалап йөрде дә, эшкә тотына алмыйча, авылга кайтып китте.

III

Әти алдан чәчеп бара, мин аның артыннан тырмалап барам. Әлеге шул бер күзе «өшегән» кара бия, башын

чайкый-чайкый, бәкәленнән туфрак ерып атлый. Ат артыннан, җир өстенә буйдан-буйга дымсу эз калдырып, тимер тешле агач тырма сөйрәлә. Берничә адым гына арткарак калып, кортлар чүпли-чүпли, бик зур эш кыргандай түшләрен киереп, каргалар бара.

Ындыр артыннан Ышна елгасына кадәр бөтен тирә-як сабанчылар белән тулган. Кайсы сукалап маташа, кайсы тырмалый. Төрле якта сабаннар челтери, ара-тирә атлар пошкырып куя. Әле уңда, әле сулда бары сабан ашлыгы чәчкәндә генә әйтелә торган үзенә бертөрле ат куу, ачулану, орышу, сызгыру тавышлары ишетелеп тора:

— Әйдә, малкай! На-а-а!

— Карасана, һәйт!

— Фит, фит, наян, атлабрак!

Сука белән җир ертучы агайлар тагын да үзләренчәрәк. Бераз гына читкә тайпылдымы, илереп атларына җикеренәләр:

— Ягалай! Үләт себергере!

— Буразна!

Урман бөтенләй үк яшелләнеп җитмәгән әле. Аңа күгелҗем төс кенә кергән. Тик каен күбрәк булган урыннар гына бераз яшелләнеп килә. Тавышлар тынып торган арада ул яктан, тонык кына булып, күкеләр кычкырганы ишетелә. Олы кешеләр әйтә, күке тавышы ишетелә башлагач, аю да арт санын суга манчып ала, ди. Шуннан соң безгә дә су коена башларга ярый икән.

Шушы йөз төрле авазның һәммәсе өстендә сабанның сайрар кошы — тургайлар тавышы яңгырый.

Безнең җир башына, пар ат җиккән сабан сөйрәтеп, Әхмәт килеп туктады. Ул быел яздан көзгә кадәр Бикбулатларга хезмәтче булып ялланган. Ашау байдан. Сеңлесе белән энесенә көз көне берәр күлмәк, үзенә бишмәтлек алып бирәсе икән.

Әхмәт, кулын кашы өстенә куеп, күккә текәлде. Аның сипкелле бите бик сөйкемле булып балкый, күзләре кысылып килгән. Әйтерсең дөньяда аннан да бәхетлерәк беркем дә юк. Шулай тыңлады да:

— Әллә бөтен басудагы тургай сезнең җирегез өстенә җыелган инде! — диде.

— Юк, һәр агайның баш түбәсендә икешәр, өчәр тургай эленеп тора бугай,— дидем.

— Их, ничек кенә әйтеп бирәләр, ә! Менә шулар шикелле моңлы итеп җырлый белсәң, ә?!

— Син болай да матур җырлыйсың. Ишеткән бер хатын-кыз җыламыйча түзә алмый.

— Ә боларны менә җылатмасалар да тыңлавы рәхәт. Белсәң иде, нәрсә дип сайрый икән алар?

Тургайлар, сайрый-сайрый күтәрелеп, төклетура хәтле генә булып калдылар. Ә шулай да тавышлары баш очында гына яңгырый иде. Миңа алар кояшның яктылыгына да, көннең матурлыгына да куаналар, менә бу кешеләрнең шулай тырышып-тырышып җир сөреп ятулары да аларның күңеленә хуш килә шикелле иде.

Безгә бик тә рәхәт иде. Тик шунда Бикбулат үзе килеп җитте:

— Нәрсә син терәлеп каттың! — дип кычкырды.— Эшеңне кем эшләр?!

Җир башыннан эти тавышы ишетелде:

— Нәрсә карыйсың! Кая кереп барасың?

Әлеге шул юньсез кара бия! Кырын-кырын атлый торгач, чыга да китә эздән. Дилбегәне болгый-болгый кычкырып җибәрдем:

— На-а! Менә салырмын берне сырт буйлап!

Бераздан эти икенче җиргә китеп барды.

— Төшкә тикле өч катлап бетерергә кирәк!— диде.

Хәзер инде җир башыннан узучылар минем үземә дәшәләр иде:

— Алла куәт бирсен!

Минем дә үземне хәзер олы сымаграк тотасым килә. Тырма артыннан атлый биреп:

— Исән бул! — дип узам.

Зуррак малайлар минем олыларча алдыма киндер алъяпкыч ябып чыгуыма, ат артыннан дилбегә каккалап, сызгыргалап баруыма елмаебрак узалар. Усалраклары, синең атыңа таба кулы белән күрсәтеп, нидер булган кыяфәт белән, бик каты кычкырырга тотына:

— Әнә, әнә! Төште, төшеп калды!

Шуңа алданып, атыңны туктатсаң, җитмәсә тагын:

— Кая? Нәрсә? — дип тә сорасаң, бөтен басуга көлкегә каласың. Алар шундук авызларын ерып көлә башлыйлар:

— Ябалак, байгыш! Күрмисеңмени? Кара биянең тизәге! — дип кычкыралар.

Әти теге җирдән әйләнеп кайткач, як-ягына карана-карана җирнең түбән башына төшеп китте. Акрын гына ул бара, аның артыннан тырмалап мин барам. Әллә күрә минем ничек тырышуымны, әллә юк.

Безнекенә башташ икенче бер өлешкә төшеп җиткәч, әти, башын чайкап, телен чартлатырга тотынды:

— Әй-әй-әй! Кем эше булды бу?

Бу җирне әле күптән түгел генә Минзай дигән малай тырмалап киткән иде. Ул үзе бот буе гына булса да, кулыннан килмәгәне юк. Бик шәп гармун уйный, кубыз чиертеп кызлар биетә. Балавызлаган җепне карындыкка тартып, ике йорт арасына суза да иптәш малайлары белән шуннан гына сөйләшә.

Менә шул Минзай тырмалаган җиргә күзе төшкәч, әтинең чырае яктырып китте:

— Кара син малай актыгын, ә! — диде, сакал очын сыйпаштыргалап, тигез генә булып тезелеп киткән тырма эзләренә соклангандай, җир башында арлы-бирле йөргәли башлады.— Һе! Эшен китергән бу. Мамык иткән бу җирне! Кара син, ә! Ник бер генә кисәкле балчык калсын! Менә уңа инде монда иген!.. Тәгаен!..

Минзай җире бер башыннан икенче башына кадәр бик тигез итеп пөхтәләп, тарак белән тарап чыкканга охшый иде.

Мин тиз генә үз җиремә борылып карадым. Шунда миңа бик тә күңелсез булып китте. Җир өстендә ат башы тикле кантарлар турсаеп тора. Тырма бөтенләй сәлам бирмичә чи калдырып узган урыннар да бар. Менә тамаша! Ничек күренмичә калганнар диген син!

Әти Минзайны һаман мактый да мактый:

— Менә бу эш тек эш инде! Тырма эзләрен буйдан буйга ничек кенә тездергән! Бур җебе белән сызганмыни! Җир башын кара син, җир башын! Машина белән чикмән якасы каеган шикелле! Шундый да матур иттергән!

Үзем тырмалаган җир торган саен сөйкемсезрәк булып күренә башлады. Минем хәзер үз җиремә карыйсым да килми иде. Шушы кара шайтан аркасында гына инде бу! Ул йөрде өшегән күзен акайтып, тегендә дә монда боргаланып!

Әмма никадәр генә атка сылтасам да, күңелнең бер төше үземнең дә гаеп барлыгын сиздереп тора. Көнчелек тә кытыклый башлады. Сүзем сүз! Барыбер Минзайныкы шикелле итеп тырмалап куям! Барыбер!

Төштән соң шулай тырмаладым да.

Дөрес, әти минем эшне алай ук үтереп мактамады. Аның җир башыннан мыек астыннан гына елмаеп узуы да миңа бик җиткән иде.

Ул көнне кич йокларга яткач, күз алдында алай да, болай да килеп, гел тырмалаган җир әйләнеп торды. Тырма үрле-кырлы сикерә, тырма артыннан очсыз-кырыйсыз вак балчык тасмасы, тип-тигез тырма эзләре агылып бара иде.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Гомәрнең олылар белән бергә крестьян тормышындагы бик әһәмиятле эшкә — чәчүгә катнашуы нинди хисләр белән тасвирланган? Аның куануының сәбәпләрен аңлатыгыз. Имана дигән сүзне ничек аңладыгыз? Ни өчен җирнең һәр адымы исәптә һәм кадерле булган?
2. Хатын-кыз башкарырга тиешле эшләрне, авыл тормышы белән бәйле хезмәтне санап чыгыгыз. Бүгенге тормыш белән чагыштырып карагыз, нинди үзгәрешләр күрәсез? Шәһәр һәм авыл тормышларын чагыштырыгыз, табигать белән мөнәсәбәт кайда ныграк сакланган? Ни өчен?
3. Чәчүгә чыгасы көнне изге итеп, бәйрәмгә әзерләнгәндәй әзерләнгәннәр. Тормышны матурлап, хезмәтне олылап торган бу гадәт бүген югалып бара. Ни өчен дип уйлыйсыз? Саклап калып булыр идеме аны?
4. Тагын нинди йолаларга игътибар иттегез? Бабайлардан калган йолаларны саклау нигә кирәк?
5. Бәшир аганың гаделлек турында әйткән сүзләренә игътибар итегез. Нигә әйтә ул аларны? Җир күршесе Галимҗан белән сөйләшкәндә, аларның нинди сыйфатлары ачыла?
6. Гомәрнең җиренә җиткереп тырмаламавын күргәч, Бәшир абзый нинди тәрбия алымы куллана, үтемле буламы ул хәйлә?
7. Гомәр кайсы ягы белән этисенә охшаган? Аның өйдәгеләргә, авылдашларына, табигатькә, тормышка мөнәсәбәте нинди? Ничек шулай оста итеп, барысын да аңлатырлык сүзләр табып сөйли белә икән ул?

Кунак кызлар килде утырмага

I

Югары очка да килгән кунак кыз, түбән очка да. Әти Казанга солы белән киткәч, безгә дә килеп төште. Ник дисәң, гадәте шулай. Көз ахырында аның үзенең бик сөйкемле бер вакыты бар.

Атналар буе, вак иләктән иләгәндәй, төтәсләп торып үзәккә үткән, кибәннәрнең ялгауларына яшел ямаулыклар үстергән бетмәс-төкәнмәс көзге яңгырлар туктаган. Әниләр елмаюы кебек ягымлы җылы көннәре, көмеш тоҗымнары, салкын төннәре белән әбиләр чуагы да узып киткән. Төнлә белән өй түбәләренә, капка башларына — бөтен җиргә җем-җем иткән ап-ак кырау төшә, агачларга бәс бәйләнә. Көзге пычракта бозылып калган урамнар, юллар, бөтен казылмалары, кисенте һәм чокырлары белән бер төн эчендә шакыраеп каталар. Урамнан узган арбаның дөбердәве бөтен авылны яңгырата.

Бөтен дөнья боеккан. Келәт кәрнизендә, кызыл тәпиләрен корсак асларына яшереп, күгәрченнәр бөрешеп утыра. Агач ботакларындагы кабарынкы йонлы мескен чыпчыклар, төшенке тавыш белән:

— Суык-суык, суык-суык! — дип зарланалар.

Менә тагын берәр атна уза. Кояш көн саен соңгарак калып чыга башлый. Югарырак күтәрелергә иренеп, түбәннән генә әйләнә дә тизрәк төшеп китәргә ашыга. Көннәр тагын да суытарак төшеп, инешләргә боз ката. Картлар, бишмәт өстеннән билләрен буып, бияләй киятәр дә, озын таякларга таянып, уҗым басуына чыгып керәләр.

— Ат аягы батарлык түгел инде, катырган,— диләр.— Уҗымның тамыры өзелмәс. Әйдә, ку малтуарны уҗымга!

Хәзер инде «арба да түгел, чана да түгел». Арба җиксәң тәгәрәми, чана җиксәң шумый.

Менә беркөнне иртән торып чыгасың — бөтен дөнья ап-ак! Йомшак кар өстенә каз-үрдәк тармаклы-җәпләкәле беренче эзләрен салып киткән. Кич-иртә урамнан шыгырт та шагырт аяк тавышлары ишетелә башлый.

Менә кайчан кузгала төрле өмәләр: каз өмәсе, сүс өмәсе, тула өмәсе. Шул вакытка турылап, күрше

авыллардан кунак кызлар килә. Байга да килә, ярлыга да. Кунактан кунакка гына, бәлештән коймакка гына йөреп, өч-дүрт көннән үк китеп баручылар да, быелгы шикелле корылык булган елларны якты чырай, сөтле чәйгә дә риза булып, унар, унбишәр көн утыручылар да булгалый. Кунак кыз дигәндә, бары — бергә, югы — уртак, ничек туры килсә дә гаеп ителми.

Безнең кунак кызыбыз яшь кенә иде әле. Чәче Яңасала кызларыныкы кебек кара йә коңгырт түгел, бодай саламы төсле.

Бите дә түгәрәк түгел, ак та, озынчарак та, күзләре дә күк төсле. Сөрмә тартмый, иннек-кершән сөртенми. Иреннәре болай да бөрлегән төсле, бит урталары, багъ алмасыдай, үзеннән-үзе алсуланып тора. Исле сабын белән бик матурлап битен юып, чаршау артында чәчен тарап үрә дә, мәрҗәннәрен асып, көмеш балдакларын киеп, чулпыларын чылтыратып, тик йөри бөтен өйне балкытып.

Беренче көнне иртән торгач, коймагын ашап, чәен эчкәннән соң, тәрәзә янынарак утырды да кунак кыз, урамнан узучы яшь-җилбәзәккә күз аткалап, пирчәткә бәйли башлады. Шунда өйдәгеләр белән тәмле генә әңгәмә куерып китте. Ике якның да нәсел-нәсәбе, әби-бабайлардан башлап яңа туган сабыйларгача, бөтенесе телгә алынды.

Инде иген-тарулар дип әйтеп әйткәндә, анысының куанырлыгы юк икән. Арыш белән бодай, бик үк дан булмасалар да, шулай да ачка үтерерлек үк түгел. Әмма бодай белән солы бер дә куандырмаган. Борчак орлыгын гына кайтарган, карабодайны инде анысын әйтәсе дә юк; чәчәктә утырганда ук эссе куырган. Шулай итеп шул, бәйрәм-сәйрәм, кунак-төшем булганда, Кибәхуҗа кешесенә газиз кунакларны карабодай коймаклары белән сыйлаулар быелга насыйп булмыйрак тора икән әле.

Бер алдын күрсәтсә, биш артын күрсәтеп, гел айкалып кына тора дөньялары. Әле игеннәр уңмый, әле терлек үләте килеп баса. Каян алырга, нишләргә? Ярты авыл тегүгә чыгып китә. Кайсыберсе, очын очка ялгый алмый, башын ташка орырдай булып йөри-йөри дә, тәрәзәләренә такта кадаклап, бөтенләй әллә кай җәһәннәмгә олага. Йә күмергә анда, йә Себергә. Тик, әйтәләр бит: «Кая гына барсаң да, кара сакалың

үзеңнән калмый»,— дип... Менә шулай инде Кибәхуҗа хәлләре, тәтәй генәм.

Таллыклар арасыннан чылтырап аккан инеш кебек, ашыкмыйча гына, тирбәлә-тирбәлә генә аккан бу озын-озак әңгәмә берзаман тына. Кунак кызыбыз, көн урталары җиткәндә, битен яңадан юып киенеп ясанырга тотына. Озак та үтми, ул йә апай, йә әни белән, зур урамнан буй-сын күрсәтеп, туган-тумачаларга чәйгә барып кайта. Йә берәрсе аны каз өмәсенә дәшә.

Ул килгәннән бирле, абый яңа күлмәк, яңа чалбарларын киеп, гел елмаеп кына йөри. Карап торганым бар: чыгар-чыкмас мыек сыман нәрсәсен ничә тапкыр көзге алдында сыпыргалап карады.

Кунак кыз килгәннән бирле, ишек белән капкага да тынгылык юк, һич кенә дә ябылып тормыйлар. Кичкә керсәң, тәрәзә тирәсендә гел кыштыр-мыштыр егетләр кайнаша.

Инде кояш бераз гына кичкә авыштымы, китә киенү-ясану, кичке су китерүләргә хәстәрләнү. Бер кереп, бер чыгып, тыз да быз күрше кызлары кайнаша башлый. Кузгала пышылдаулар, чыркылдаулар, китә дәртләнеп нидер көтү, нидер өмет итү, киңәш-табыш итү.

— Кайсы күлмәгеңне киясең? Башыңа нәрсә ябасың?

— Карале, кызлар! Ак катамны кисәм килешерме әллә карасын киимме?..

Шул арада, бер-берсенең колакларына үрелеп, нидер пышылдап алалар, нәрсәгәдер ымлап, берсенә берсе күз кысалар. Ул да булмый, кесәләреннән ат күзе тикле генә көзгеләрен чыгарып матурлана башлыйлар...

III

Менә көн кичкә авышты. Инеш буйларына үзенә бертөсле йомшак кына зәңгәрсу әңгер иңә башлады.

Тыкрыктагы борылмалы сукмактан, кыр казлары шикелле, берсе артыннан берсе тезелеп, чуп-чуар кызлар төркеме килеп чыкты. Иң алда, билгеле, кунак кыз. Аның артыннан чибәррәк, чаярак, өлкәнрәкләре, иң арттан, зур атларга ияргән кырыкмышлар кебек, бөтенләй яшь кызлар. И чибәр киенгәннәр дә инде! Бигрәк тә кунак кыз. Башында кәшимир шәл, өстендә иңбашлары күпертмәле зәңгәр жикет, аягында сай

гына кунычлы ак киез ката. Аның йөзен яшелле-зәңгәрле, аллы-шәмәхә дебеттән ясалган чәчәк сыман нәрсә матурлап тора.

Бүтән кызлар һәммәсе дә көянтә башларына берәр, икешәр каз элгәннәр, ә кунак кызның куллары буш. Ул бәрән йоныннан гына бәйләнгән нечкә челтәр кунычлы ап-ак пирчәткәсенең бармак очлары белән генә авызын каплаган. Күпереп торган сыек зәңгәр күлмәгенең итәкләре карга тиеп керләнмәсен дипме әллә үзенә шулай килешлерәк тоелгангамы, сул кулы белән аз гына күлмәк итәген күтәргән. Вак-вак кына, чеметтереп кенә атлап, буен-сынын матур гына уйнатып төшеп килә, агай, без күзләребезне ала алмас булдык.

Башка кызларның да өсләрендә гел яңа күлмәк белән кешелеккә генә киелә торган яхшы бишмәт йә жикет, башларына күзеңнең явын алырдай аллы-яшелле шәлләр бөркәнгәннәр. Исең китмәле!

Казларны юып, келәт киштәсенә менгереп элгәннән соң, кызлар эре көмеш чәчәкләр төшерелгән яшел, зәңгәр чиләкләр белән чишмәгә су алырга төшәләр. Китә шуннан су ташу! Дүрт тапкыр да, биш тә, әллә ничә дә төшәләр. Өйдәге савытлар тулгач, мунча казанына, ул да тулгач, ат улакларына, сыер тагаракларына ташыйлар. Анда да салыр урын калмагач, күршедәге карчык-корыны, өлкәнрәк яшьтәге җиңгиләрне су белән күмәләр.

Күпер төбендәге егетләр һаман уйный да җырлый. Яннарыннан узган саен, кызларга берәр шаян сүз әйтеп йә булмаса күз кысып, каш сикертеп калалар.

Менә кызлар, бер кулларын көянтәләренә салган килеш биеп кенә атлап, берсе артыннан берсе таудан менеп киләләр. Күкрәкләрен киерә төшкәннәр, нечкә билләрен боргалап, сыгылдыргалап, иңбашларын сизелер-сизелмәс кенә биетеп менәләр. Шундый җиңел итеп, шундый өздереп атлыйлар, аяклары җиргә дә тими. Әйтерсең иңбашларында буш чиләкләр генә: шундый оетып юргалыйлар, чиләкләрендәге суның ичмасам тамчысы гына да селкенми.

Кызлар яулык читләрен тешләп, битләрен аз гына каплаган сыман булып узсалар да, аларның да күзләре уйнаклый. Сәхипҗамал шикелле чаяраклары үзләре дә каш сикертеп алалар. Кайсы кашын сикертә, ничек

сикертә? Аның да рәте бар икән. Уң кашын сикертсә: «Ярый, уйлап карыйсы булыр»,— диюе икән. Инде иреннәрен кысып, сул кашын сикерттеме, анысыннан рәхим-шәфкать көтмә, ди. Анысы: «Саруымны кайнатып, аяк арасында буталып йөрисе юк!»— дигәне була икән.

Тауны менеп җитәрәк туктыйлар. Күпер төбендәге егетләргә карый-карый, бер-берсенә шыпырт сүзләр әйтәләр дә чырык-чырык көлешеп алалар.

— Тагын төшәбезме әле? — ди кунак кызы.

Әллә ничәсе берьюлы:

— Төшәбез, төшәбез! — диешәләр.

Мин тавышсыз-өнсез торган Хәкимҗанның янтавына төртеп алам:

— Синеңчә, кайсысы бигрәк тә матур?

Күрәсең, берсен генә әйтсә, бүтәннәрен кимсетү шикелле тоеладыр, ул бераз башын чайкап тора:

— Барысы да матур, һәммәкие дә...

IV

Мин Фазуллаларга йөгердем. Нишләрләр икән, керерләрме икән кызлар, юкмы икән?

Фазулла өстенә өр-яңа зәңгәр сатин күлмәк, башына хәтфә кәләпүш кигән. Аның ягыннан, мул булып, ислемай исе аңкып тора. Ишек ачылуга, әсәрләнеп миңа текәлде:

— Кермиләрме әле, юкмы?

Мин ике төрлерәк аңларлык итеп башымны селкеттем.

Гыйльми түти өйнең ике ягын да пөхтәләп җыештырып куйган. Түр яктагы мендәр-ястыклар өстенә бик матур чиккән япма каплаган. Үзе яхшы күлмәкләрен киеп, башына ак яулык япкан. Ул яшь килен төшерәсе каенанай кебек дулкынлана. Әле улының алдына япкан чуар юрганын, мендәрләрен төзәткәләп чыга, әле кече якның ишегенә элгән эре чәчәкле алсу чаршауны киңәйтебрәк ачып куя. Гыйльми түтинең йөзендә сүз белән генә әйтеп бетерүе мөмкин булмаган тирән хәсрәт белән моң күләгәсе бар. Авыру улының тыштагы аяк тавышларын түземсезләнеп тыңлавына күз салганда, аның иреннәре дерелди башлый иде. Янымнан узышлый колагыма пышылдады:

— Ярабби, күңелләренә мәрхәмәтләр салып, кереп кенә чыксаларчы! Керә алмасалар, бигрәк тә нәүмиз була инде!..

Минем тамак төбем әллә нишләп куйды. Менә бит... Аңа кунак кыз сүзләрен ничек әйтим? Телем үзеннән-үзе бөтенләй бүтәнне тезәргә тотынды:

— Әйттем, Гыйльми түти, әйттем. Керми калмаслар, Гыйльми түти, тәгаен керерләр!..

Менә урамга шәфәкъ нуры иңә башлаганда, тыкрыкта бик күп аяк тавышлары шыгырдарга тотынды. Ул да түгел, капка ачылып китте, ишегалдына кызлар тавышы кереп тулды.

Фазулла тетрәнеп китте:

— Әни, яндыр утны!

Гыйльми түти кабаланып кучкардагы утырма лампага ут кабызганда, өйгә чиләк-көянтәләр белән берсе артыннан берсе биш-алты кыз кереп тә җитте. Алар белән бергә, салкын һава кушылып, яңа киемсалым исе, иннек-кершән исе килеп керде.

Кызлар, көр тавыш белән, һәммәсе берьюлы хәл белергә тоындылар:

— Исәнмесез, саумысез?

— Әйбәт кенә торасызмы?

— Гыйльми түти! Шунда берочтан сине дә сулы итик дип йөрүебез инде бу!

Гыйльми түти, нишләргә белмичә, каушап арлыбирле килде:

— И җанкисәкләрем! Ниләр генә әйтим?! Нинди изгелекләр белән генә кайтарыйм?!

Авыл кызлары шаулап сөйләшә-көлешә су бушаткан арада, кунак кыз, кыюсызланып кына, почмак якка борылды. Кибәхуҗаларча ягымлы гына көйли төшеп, бәгырьләрне эретеп җибәрердәй йомшак тавышы белән, Фазуллага дәште:

— Нихәлләрең бар соң, Фазулла абый? Ходаем, шулай сырхаулап торасыңмыни? Менә син, ә? Тизрәк сихәтләнә күр инде!..

Почмак яктан җавап булмагач, мин: «Фазуллага берәр хәл булдымы икән әллә?» — дип, чаршау кырыеннан эчкә күз салдым. Фазулла зур булып ачылган, тирәли зәңгәрләнеп торган коточкыч күзләре белән йотардай, суырып алырдай булып, кунак кызның алсу битенә, зифа буй-сынына текәлгән дә катып калган.

Аның кансыз иреннәре өзлексез кыймылдый, әмма тавыш чыкмый. Хәзер тагын да озынаеп киткән ябык йөзендә гаҗәпләнүме, сокланумы, каушаумы билгесе булып, әллә еламсырау, әллә көлемсерәү шәүләләре уйный иде.

Өй эче тып-тын. Кызлар, кыенсынып, кайсы тәрәзәгә борылды, кайсылары пирчәткәләрен кияргә тотындылар.

Кунак кыз, почмак якка текәлгән килеш, арты белән чигенде-чигенде дә кинәт өйалдына чыкты һәм битен каплап иңрәп куйды:

— Абау, Ходаем, күзләре!..

Фазулланың шунда гына теле ачылды. Кызлар чыгып киткәнче әйтми калмагаем дигәндәй, каударланып:

— Әт-тә-тә! Менә бит, ә! Э-э-э, рәхмәт төшкерләре! — дип куйды.

V

Әни, өмәче кызларны сыйларга дип, каз итеннән, үпкә-бавырыннан мул итеп аш белән бәлеш пешергән. Мин моны өйалдына кайтып кергәч, исләреннән үк сиздем. Әллә кайчаннан бирле өзелеп ашыйсы килә иде. Авызга су тулды, түземлегем төкәнеп, сәкегә барып утырдым.

— Әни, ашыйсым килә, үләм!

Әни, җиңнәрен сызганып, күлмәк итәкләрен югары ук кыстырган хәлдә, мич алдында кайнаша. Аның битләре кызарган, борынына, ияк очларына вак кына тир тамчылары сарылган.

Менә ул кинәт сагайды, мич авызына башын суза төшеп, юка гына борын канатларын тетрәндереп иснәде дә кабаланып табагачына тотынды.

— Ай, Аллам, хур булдым! Бәлешем көйде!

Ул, елардай булып, табаны алга тартты. Әмма бәлешнең бары артыграк кызара гына төшүен күргәч, лып итеп йөзлеккә утырды.

— Уф, котларым гына алынды, тез буыннарыма тикле хәлсезләнде! Нихәлләр генә иткән булыр идем!..

Мин тагын бер тавыш бирдем. Ахрысы, әни мине шунда гына шәйли башлады. Кабык шикелле булып бозланып каткан бишмәт итәкләремә, идәндә шакы-шокы килгән итегемә күз салды да телен чартлатты.

— Кайда йөрдең? Ник, ичмасам, аз гына булышмадың, ник утын гына булса да кертмәдең? — дип орышып ташлады.

Монысы дөрес түгел иде. Әни югында мин утын да керттем, йомышка да йөрдем, мал-туарның да ашарына салдым. Шуны әйтеп кенә торганда, ут капкандагыдай кабаланып, бик күп савыт-сабалар күтәргән апай килеп керде. Анысы тагын да уздырды:

— Әле, җитмәсә, тел кайтарып торасыңмы? Буталма аяк астында! — дип, аркама төртеп алды.

Мин, үпкәләп, югары өйнең мич башына менеп яттым. Апай түр якта, шау-гөр килеп, кунак кызларны каршы ала, мин гарьләнеп ятам. Ничек үпкәләмисең? Нахак бит, нахак! Иш янына куш булып, бүтән үпкәләр дә өстәлде. Апайның әлек тә урынсызга кул озайткалаганы бар. Менә тагы! Мине әти дә, бүтәннәр дә яратмый, юк, яратмый. Узган Сабан туеннан бирле нәрсә генә алып биргәннәре бар? Тырнакка әллә ничә тапкыр күгәрчен сөте төште. «Яңалыкка бу, берәр яңа кием киясең бар икән»,— диделәр. Бар, пычагым! Чалбарның тез башындагы бияләй хәтле ямауга күз төште, өстемдәге камзулым да бик искергән шикелле күренә башлады, түбәтәй дә ямьшәйгән булып чыкты. Мин хәзер шәкерт кеше, мәдрәсәдә укыйм, әнә кунак кызлар килде. Бу өс-баш белән ничек оялмыйча кеше күзенә күренәсең?

Мин хәзер үземә үзем бик кызганыч тоела башладым. Күз белән борын арасына килеп бөялгән бернәрсә сыгылып чыгарга, ачыттырып, сыкрандырып күздән тамарга җыена. Шулай да әллә елак савыты тулып җитми, әллә ничек. Яшәреп җитсә дә, ява алмыйча азапланган яңгыр болыты шикелле, тик ятам мөлдерәп.

Шунда аяныч кыяфәте белән Фазулла абый, аның кунак кызны күргәндә тораташ булып калуы күз алдыма килде дә елап та җибәрдем.

Кайнар күз яшьләре ага да ага, өмәче кызлар күңеллерәк көлешкән саен, алар мулрак коела.

«Ярар, ярар,— дим эчемнән генә.— Сезгә рәхәт, сез, шау-гөр килеп, уен-көлке сөйлисез, сыйланасыз, ә мин менә елап ятам.

Ичмасам: «Безнең Гумәр кая икән, аның карыны ач түгелме икән?» — дип кенә әйтүче дә юк. Әни булып, әни... Ярар, ярар...»

Мин инде «Ай-һай, ялгыш булган лабаса» дип кызгануларыннан өмет өзә башладым. Болай беркем дә ишетмәгәнгә, үзем өчен генә елап ятуым тора-бара үземә үк ошамый башлады. Шулай да күңел язылмый, үпкә дигәннәре болай гына йотылмый иде.

Шулвакыт апай итек кунычлары арасыннан миңа шактый ук зур бәлеш төбе суздым.

— Йә, җитте сиңа! Егет кеше алай елак булмый! — дип пышылдады.

Мин «дырт» иттереп артым белән борылдым. Ачуым ачу! Ялынсын әле.

Тагын байтак вакыт узды. Әмма берсе дә ялынмады. Апайның икенче пышылдавына әйләнеп карамыйча булмады. Бу юлы аның кулында кызыктырып каз боты тырпаеп тора, үзе ягымлы гына, хәйләкәр генә елмая иде:

— Үпкәләгән кешегә үпкә пешереп ашатырга кирәк тә инде... Әллә моны гына кимерәсеңме? — дигән була.

VI

Шулай елмая-елмая сыйланганнан соң, мин инде апайга үпкә сакламый башладым. Әмма тез башын каплабрак олы якка чыгып барганда, ул мине, коры гына тотып, тагын кире борды:

— Нәрсә калган сиңа кызлар арасында! — диде.

Бүлмә тактасындагы ботак тишегеннән нибары бер генә күз белән карый аласың алуын да. Шулай да...

Кызлар ни арададыр табынны җыештырып алганнар да хәзер әнә кич утырырга әзерләнәләр. Кечкенә көзге тирәсенә өелешеп, өс-башларын төзәтәләр, купшыланалар. Ул тәрәзә тирәсендә бөтерелүләр, бер-берсенең иңбашларына кулларын салып назлану, иркәләнүләр, күз кырыйларын тәрәзәгә сирпеп алып үзара пышылдашу, чыркылдап көлешүләр... Харап инде. Кызларның шул булыр инде. Аларның һәркайчан безгә әйтми торган үз серләре була. Шуңаргадыр инде, юа җыйганда да, җиләккә-мазарга барганда да безнең ишеләрне ияртмәскә тырышалар. Алай шыпыртлап, нәрсә турында сөйләшәләр икән алар?..

Ул да түгел, көлешә-көлешә, идәндәге киезгә тезелештеләр. Апай, шкафка сөялеп, табышмак әйтергә тотынды:

— Җомак әйтәм, җөмен тап! — диде.— «Ука-ука тыш кына, тәкә төшкән инешкә, тапар идем бәлешкә, күрмәдеңме, Бибешкә?» Нәрсә ул?

Кызлар «м-м» ди-ди башларын иеп уйлашып утырдылар, тик берсе дә таба алмады. Тынлыкта тик Мәликәнең чарт та чорт сагыз чәйнәве генә ишетелеп торды.

— Кайда була ул? Җирдәме, күктәме, судамы, корыдамы?

— Һәммәки җирдә дә! Менә бүген без аның апаларын суеп ашадык.

Кызлар, куркынышып, кулларын селтәделәр:

— Кит аннан, юләр! Авызыңнан җил алсын! Әллә нәрсә әйтәсең!

Мәликә түшәмгә карап торды-торды да авызын ерып көлеп җибәрде:

— Ә, белдем, белдем — үрдәк.

Әле берсенә, әле икенчесенә карап алды да кунак кыз да телгә килде:

— Безнең Кибәхуҗа табышмаклары ошармы икән? — диде.— Минем дә берәү истә бар. «Кечкенә генә тирән күл, тирәк аның эчендә, ефәк кигән, калфак кигән кызлар аның эчендә, биленә кылыч бәйләгән егетләр аның эчендә».

— Һай, җаныем, инде дә матур икән бусысы! —диде Сәхипҗамал.— Кызлары да бар, егетләре дә шунда гына! Тик нәрсә генә икән ул — егетле-кызлы табышмак?

Апай, аның җилкәсенә сугып:

— Егетләрне бер дә телеңнән төшерми башладың. Берәрсен көтәсеңме әллә югыйсә? — диде.

Сәхипҗамал, чыркылдап:

— Юк ла инде! «Үзем күптән атлы-тунлы, күршеләрне кайгыртам»,— диләрме әле? Кунак кызыбыз: «Егетләрегезне күрсәтмәдегез! Күпсендегез!» — дип үпкәләп китмәгәе дим.

— И күрше, борчылма, башка кайгың булмаса, йөзләреңне саргайтма. Менә килеп җитәрләр!

Шуны гына көткәндәй, урамнан җыр тавышы ишетелде:

Елтыр-елтыр утлар яна,
Бездә түгел, кантурда:
Безнең күңел зурда түгел,
Унсигез яшьлек матурда.

Кунак кыз, оялчанланып, читкә борылды. Сәхипҗамал, наян елмаеп, каш астыннан гына апай белән Мәликәгә күз салды. Бу җырны ошатмаулары аларның чырайларыннан ук күренеп тора иде.

— Һи, мәхәббәтсезләр, сайлаган булалар тагын! — диде апай.

Аста ишек дөбердәттеләр. Моны ишетүгә, кызлар, бераз каушый төшеп, көзгедән каранырга, бит-күзләрен төзәтергә керештеләр. Апай, алмаш-тилмәш бармак очларына төкереп, кашларын сыпырып алды.

Әмма әни егетләр кертүгә бик озак риза булмый торды:

— Ярый ла кеше теленә эләкмәсәк! Кунак кызның атын-чуын чыгармасалар! Ул-бу булса, йә урлап китсәләр, нихәлләр итәрбез!..

Шулай да «чит егетләр юк, туганнар белән күршеләр генә» ди торгач, күнде тагын.

VII

Егетләр биш-алты гына иде. Закир белән Хисам, әлеге Әхәт абый, алар артыннан, үзенең никрут иптәшләрен ияртеп, Хәмзә абый кайтып керде.

— Сыярдае керде, сыймаганы үкчәсен ялтыратты,— диде ул, мәгънәле генә итеп Әхәт ягына карап алды.

Егетләрнең кайсы шкаф янына, кайсы стена буена утырдылар. Әхәт абый кызлар янына, түргәрәк узды.

Кунак кыз, битен шәльяулыгы белән каплый төшеп, читкә таба борылып утырган иде. Шулай да ул Закир белән Хисамга, Әхәтнең килешле таза гәүдәсенә, матур гына саргылт мыегына яулык кырыеннан ярыйсы ук кызыксынып карап торды. Мәликә пирчәткәсен бәйли. Сәхипҗамал зәңгәрләрен егетләрнең әле берсенә, әле икенчесенә тәгәрәтә. «Унсигез яшьлек матур» дигәннәре кунак кыз белән ул бит инде, ул!..

Кунак кызының йөзен күрер өчен, егетләр әле бер яктан, әле икенче яктан үрелеп карадылар да, ул һаман да яшеренгәч шаяртырга керештеләр. Закир абый, икеөч катлы иренен ялмаштырып:

— Бер күрергә зар-интизар булып, ничә көннәр көтәбез! — дигән булды.— Бу Кибәхуҗаларның бәгыре шулай бик каты микәнни?

Аңа Хисам ялгап җибәрде:

— Чишмә янында ялгыш кына бер тапкыр шәл чите ачылып киткән иде. Ай бирде, кояш алды...

— Кибәхуҗа кызлары бик назлы була диләр. Бәлкем, чыбылдык эчендә генә үскәндер ул?

Алай да булмагач, Закир абый бәет көйләргә тотынды:

Хан кызы, ач ишегең, мин керием,
Синең йөзең нурлы диләр, мин күрием!

Кунак кызы авыз эченнән генә көлеп җибәрде. Ул ым кагуга, аның урынына апай җавап бирде:

Минем йөзем күреп сиңа нидер файда,
Кичләрдәге тулган айны күрмисеңме?

Закир абый тагын әйтте:

Хан кызы, ач ишегең, мин керием,
Синең сачең кара диләр, мин күрием.

Аңа тагын апай җавап бирде:

Минем сачем карасына ни диярсең,
Базарларда кара ефәк күрмисеңме?

Кунак кыз һаман да йөзен күрсәтми иде әле. Болайга киткәч, Сәхипҗамал да кушылды:

— Карап-карап торам да, булмый сездән! — диде.— Бу сиңа, Әхәт абый, Сабан туе түгел, ничек әләкте шулай күтәреп бәрә алмыйсың! Табаларга май кирәк, һәрбер эшкә җай кирәк. Кунак кызны күрер өчен, тел ачкычлары кирәк!

Әхәт:

— Тел ачкычлары табылыр...— дип кесәсеннән актара башлады да кызарынып туктап калды. Аннан тагын бер көлделәр.

— Кесәләрегез сай булса, телдә инде бар өмет! — диде апай.

Мәликә белән Сәхипҗамал, икесе бердәй, остарып:

— Әйе шул! —диештеләр.— Болардан он да юк, җон да юк, берсенең бер һөнәр күрсәткәне юк.

Әхәт баядан бирле күзен алмыйча апайга карап тора иде.

— Син җырлыйсы җырлар минем битемә язылмаган,— диде апай.

Әхәт шаярып кына котылмакчы булды:

— Җырларым чабата кесәсендә калган бит, төртенеп киткере...

Апай, ни сәбәпледер, тагын Әхәткә бәйләнергә тотынды:

— Җырламасаң, ичмасам, бер бие!

Аңа бүтән кызлар да каныга башлады:

— Шул буй-сының белән бер һөнәр дә күрсәтмәсәң, оятыңа көч килер!

— Әйтмәсәң дә! Сабан туе батыры да бит әле син!

Әхәт, гармунчыга күз кысып, бишмәт төймәләрен чишеп җибәрде. Гармун уйный башлауга, кәләпүшен кыңгыр салып, биленә таянды да, иңбашларын сизелер-сизелмәс кенә сикертеп, тып та тып идән уртасында әйләнергә тотынды. Идән такталары шыгыр-шыгыр килде, шкафтагы савыт-саба чылтыр-чылтыр итте, түшәмгә эленгән унлы лампа, «төшәм, төшәм!..» дигәндәй, куркынып күзен йомгалый башлады. Түбән өйдән әни, «артык кыланмагыз!» дигәндәй, багана какты. Апай уены-чыны белән Әхәтнең аркасына сугып алды.

— Аю! Чамалап! Өйне җимерәсең!

Әхәт абый, торган саен дәртләнә барып, чебеш алырга җыенган тилгән сыман, кунак кыз тирәсендә бөтерелә башлады. Шулай иңбашларын биетеп әйләнгәләде дә, башын тегеләй-болай боргалый торгач, кинәт кенә сузылып, кунак кызның шәльяулыгын тартып алды. Кунак кыз сискәнеп китте. Битен куллары белән капламакчы булса да тыелып калды.

Егетләр берсен берсе бүлдереп сокланырга, телләренә салынырга тотындылар:

— Сөбханалла, машалла, күз тимәсен башала!

— Кояш чыктымы, ай калыктымы? Күзләр чагылып китте!

— Әйтәм җирле сагындырып кына ачылды, зерәгә генә түгел икән, әй!

Хисам абый, кунак кызның матурлыгына исе киткәндәй, күзен алмастан, аның янынарак барып утырды. Сәхипҗамал аны читкәрәк куган итенде:

— Ул кадәр челәеп карама, оялтасың! — диде.

— Тимә син, тимә! Килешә ул аңар!

Әнә күрәсеңме? Кызаргачыннан тагын да матурланыбрак китте!

— Тфү диген, юньсез! Күз тидерерсең!

Әллә шаярта Хисам, әллә чыны шулай, ул кунак кызга әллә ничек, йотып алырдай булып текәлгән иде.

1968

Сораулар һәм биремнәр.

1. Ничек уйлыйсыз: кунак кызлар ни өчен теләсә кайчан түгел, ә елның билгеле бер вакытында килгәннәр? Ул кайсы вакыт? Кунак булуның нинди тәртипләре, кагыйдәләре булган? Ул ни өчен Бәшир абзый базарга киткән чакка туры килгән?
2. Кунак кызлар килү нигә бөтен авылга ямь биргән?
3. Кунак кызның Фазуллаларга керү-кермәве ни өчен аның әнисен шулай дулкынландырган? Гомәр нигә Фазулланы бик кызгана?
4. Апасы ачулангач, әнисе дә нахакка орышып ташлагач, Гомәрне сез дә кызгандыгызмы? Игътибар итегез әле: ул матур итеп, «җиренә җиткереп» үпкәли, үзенеңниләр кичергәнен безнең дә күңелләрне кузгатырлык итеп сөйләп бирә.
5. Халык сөйләменнән, аның иҗатыннан күчкән сурәтләү чараларын табыгыз. Халыкның рухы, тарихы әсәрдә кайсы яклары, нинди сыйфатлары белән тасвирлана?
6. «Халкымның күңел байлыгы» дигән темага сочинение языгыз.

Тургайлар телендә язылган әсәр

Әсәр турында сөйләгәндә, без иң беренче чиратта «Сүз нәрсә турында бара?», «Нәрсә тасвирлана?» дигән сорауларга җавап эзли башлыйбыз. Язучының нинди тормыш материалына мөрәҗәгать итүе, әйтергә теләгән фикере әһәмиятле, әлбәттә. Шулай да чын сәнгать әсәрен аның ничек тасвирлануы, язучының сурәтләп бирү осталыгы, сүзнең тәэсир көче билгели.

Гомәр ага Бәшировның бу әсәрендә, темасын атап әйтсәк, революциягә кадәрге тормыш турында сүз бара дип әйтеп була. Гадәттә, бу чорны «авыр», «рәхимсез» дигән сүзләр белән «бизибез». Ә бу әсәрне укыганда, безнең күз алдыннан никадәрле матур күренешләр тезелеп үтте, һәр чорда тормышның үз матурлыгы бар икәнлегенә ышандык.

Туган як — яшел бишек. Язучылар туган җир, туган туфракның яңа төсмер, мәгънәләрен таба торалар. Гомер үткән саен, тәҗрибә туплап, кадерен белеп язалар. Биредә исә үзе дә әле бишектән бик ерак китмәгән 6—7 яшьлек Гомәр сөйли, сабый йокысының тәмен, дөньяларны оныттыра торган уенның сихри көчен менә әле генә тоеп торган Гомәр сөйли. Әмма шул ук вакытта без бу әсәрне кеше гомерен иңләп алырлык олы җанлы, тәҗрибәле, уйлана һәм уйландыра белә торган талантлы әдип язганлыгын да беләбез. Әсәрнең һәр

бизәге, тормышны төсләргә, авазларга, моңга әйләндергән теле сихерле. Хисләр, тойгылар йомгагыннан торган малай үзе дә — бер матурлык чыганагы. Аңа карап үзебезне таныйбыз: без дә нәкъ шулай һәр туган яңа көнгә исебез китеп куана, могҗизалар көтә идек. «Әсәр нәрсә турында?» дигән сорауга шуңа күрә тагын бер җавап өстәп куябыз: ераграк калган саен сагындыра торган балачак турында, сабый чакның таң яктысы кебек саф, үтә күренмәле шатлыклары турында да бу әсәр. Әлбәттә, Гомәр үзе, әти-әнисе, туганнары, дуслары турында яза. Шулай да туган як дигән төшенчә барыбызны да дулкынландыра, берләштерә. Гомәр туып үскән Яңасаланы, Арча якларын күргәнебез булмаса да әйтә алабыз: бик хикмәтле икән бу яклар, һавасында ук халык рухы яшиме, ашаган ризыгында, эчкән суында берәр шифа бармы: әллә нинди «уңдырышлы туфрак» бу якларда — Габдулла Тукай, Сибгат Хәким, Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиев, Рафаил Төхфәтуллин кебек талантларга бишек булган бу төбәк дип уйлыйсың.

Гомәрнең бишеге безне дә тирбәтә: изрәп йоклауның тәме, тау шууның шигърияте, күңел хәзинәсе булып мөлдерәмә ташып торган шатлык-куанычлар; Сабан туе, каз өмәләре, кунак кызлар килү, кич утырып китаплар уку, эшкә ярый башлавыңны аңлау горурлыгы. Үткән заманда калса да, күңелдән китми торган матурлык бу.

Шулай да тормышны алып баруы авыр. Никадәр хезмәт, тырышлык куярга кирәк, санап кына чыкканда да хәйран калырлык. Кешеләрнең түземлеге, шулай тиешлеген аңлап, хезмәттән зарланмыйча яшәүләре сокландыра. Хезмәткә олы хөрмәт кешенең үзен, аның кадерен саклап тора. Бәшир агай да, тормыш авырайган саен, тырышлыгын арттыра: аның уңганлыгына, чыдамлыгына сокланмый мөмкин түгел. Тормышның, яшәүнең бозылмаска тиешле кануннары бар икән. Шуларның тагын берсе, бик әһәмиятлесе — гаделлек. Ул — иң изге нәрсә, аны безгә бабайлар мирас итеп калдырган, һәркем үз гомерен яши, ләкин бит без миллион еллардан бирле килгән тормышны дәвам итәбез. Ул өзгәләнмәсен, тәртибе югалмасын өчен, гаделлек сакланырга тиеш. Гомәрнең этисе бер адым җир турында гына түгел, әнә шул зур мәгънәдәге гаделлек турында сөйли. «Язык», «гөнаһ» дигән сүзләр дә шуңа күрә үз мәгънәләрен югалтмыйлар.

Тагын бер якка игътибар итми калмыйбыз: авылда тормыш, крестьян хезмәте табигать кануннарына көйләнгән. Бәйрәмнәрнең дә үз вакыты, үз тәртибе бар. Теләсә кайчан кунакка йөрү әдәпсезлек, тәрбиясезлек, кешеләрне эштән бүлү, үзең дә эшсез йөрү булыр иде. Көтеп алынган кунак кыз, үз кадерен, үз вакытын белеп кенә килгән кунак кыз, шуңа күрә дә бик кадерле; кунак кызы үз матурлыгы белән генә түгел, әнә шул гадәтләргә хөрмәт саклаганга күрә дә матур бит. Табигать кешеләрнең кәефе белән дә идарә итә, дөресрәге, аларны аерып та булмый. Беренче күк күкрәүгә, кыр казлары кайтуга, шаулап аккан ташуга кешеләрнең куанычы да, шатлыгы да сабыйларча самими, алар да табигатьнең үзе белән кушылып китәләр. Табигать белән исәпләшү, хөрмәт итә белү — халык әхлагы. Кабул ителгән кагыйдәләр, гореф-гадәтләр әсәрдә шулкадәр ихтирам, изге бер хис белән сурәтләнгәннәр ки, халыкның рухи сәламәтлеген нәкъ шулар саклап торганлыгына бөтен күңелең белән ышанасың.

Игътибар иттегезме: әсәрнең эчтәлеген бер вакыйгага бәйләп кенә сөйләп чыгып булмый. Аны, моңлы көй тыңлагандагы кебек, балачак хатирәләрен тагын бер кат кичереп карагандай укыйсың. Теленә, сүзнең җемелдәп торган мәгънәбизәкләренә сокланып укыйсың. Тормышның һәр көн-мизгеленә шулкадәр дә җаның-тәнең белән бирелеп куана белү булыр икән! Җирнең, мал-туарның, эшнең, шулкадәр дә олылап, кадерен белү булыр икән! Яз килгәнгә, сандугач сайравына, кошлар кайтуына шулай сабыйларча куана белгән, шатлыклары, өйгә сыймыйча, урамга ташып чыга торган шулкадәр дә сабый җанлы кешеләр булыр икән! Атның канатлы булу ихтималына да ышанып, һәр җан иясенә кадерләп карый белгән, булганның кадерен белеп, яхшыга ышанып, шулкадәр дә өмет белән яши белү булыр икән!

Менә шулай соклану, моңланулардан, сагыну-сагышлардан үрелгән ул туган як бишеге. Шул бишектә тирбәлгән бәләкәй Гомәр үзе дә, зур гомер юлы үтеп, халык язучысы, олы әдип булып танылды.

Муса Җәлил
(1906—1944)

Муса Җәлил — гражданлык батырлыгы өчен дә, иҗади уңышлары өчен дә югары бәяләнгән тарихи шәхес. Ул хәзерге Оренбург өлкәсенең Мостафа авылында Мостафа абзый гаиләсендә дөньяга килә.

Муса Җәлил шагыйрь буларак 30 нчы елларда ук танылa. Аның шигырь һәм поэмалары бер-бер артлы басыла. «Хат ташучы» поэмасы, «Алтынчәч» либреттосы[1] сугыш алды еллары әдәбиятының күренекле әсәрләре рәтеннән урын алды.

Шагыйрьнең сугыш елларындагы иҗади батырлыгы гражданлык батырлыгы белән үрелеп бара.

Сугыш башлангач та армиягә алынган М. Җәлил командирлар әзерли торган курсларда укый, өлкән политрук дәрәҗәсе ала. «Батырлык» («Отвага») исемле фронт газетасына хәрби хәбәрче итеп билгеләнә. 1942 елның җәендә Волхов фронтында барган каты сугышлар вакытында ул хезмәт иткән гаскәри часть чолганышта кала, шагыйрь, каты яраланып, дошман кулына төшә, лагерьга озатыла.

Фашистлар совет әсирләрен үзләре ягына авыштырып һәм һәртөрле легионнарга берләштереп фронтка озатырга, аларны туган илләренә каршы сугыштырырга омтылалар. Меңәрләгән татар, башкорт һәм башка төрки халыкларның уллары кебек, М. Җәлилне дә шул язмыш көтә.

Аның татарда абруе зур, танылган шагыйрь булуын, Казанда опера театры ачуга өлеш кертүен, Татарстан Язучылар

[1] Бу либреттога композитор Нәҗип Җиһанов опера язды.

берлеген җитәкләвен фашистлар беләләр. Җәлилне үзләренә карату өчен, алар нияләр генә эшләми: аңар яшәү өчен бөтен шартлар һәм, яңа әсәрләр язса, бастырып чыгару мөмкинлеге тудырыла. Әмма Җәлил гадәти булмаган, зур фидакярлек һәм тәвәккәллек сораган карар кабул итә: риза булган булып, дошманга каршы астыртын көрәшергә план кора. Монда ул үзенә фикердәшләр һәм дуслар да таба. Җәлил һәм аның көрәштәшләре (бүген аларны җәлилчеләр дип йөртәләр) фашистларга каршы яшерен эш җәелдерәләр. Әсирләр һәм легионерлар арасында фронттагы чын хәлләр турында әйтеп, ярдәм көрәшкә өндәп, фронтка җибәрелгән сурәттә үзебезнекеләр ягына чыгарга чакырып үгет-нәсыйхәт алып баралар. Листовкалар тараталар, концертлар, спектакльләр оештыралар. Меңәрләгән әсирне рухи ныгыталар, күңелләрен күтәрәләр, җиңүебезгә ышаныч һәм яхшы кәеф тудыралар. Мондый тырышлыклар бушка китми: мәсәлән, 1943 елның язында безнең партизаннарга каршы дип җибәрелгән татар батальоны баш күтәрә, офицерларын юк итеп, белорус партизаннарына кушыла. Мондый хәлләр тагын да кабатлана.

Җәлилчеләр тагын да зуррак планнар коралар: әсирләрне кораллы күтәрелешкә әзерлиләр. Ләкин восстание башларга берничә көн генә калганда, бер сатлык җан оешманың серен чишә. Җәлилчеләр кулга алына һәм төрмәгә ябыла. Бу—1943 елның августы була.

Тикшерү эшләре 1944 елның мартына кадәр бара, суд була, һәм Муса Җәлил белән аның ун көрәштәше (алар арасында танылган балалар язучысы Абдулла Алиш та бар) үлем җәзасына хөкем ителә. Тагын 5 ай үлем көтеп үтә, җәлилчеләр монда да тиңдәшсез рухи ныклык күрсәтәләр. 1944 елның 25 августында хөкем карары җиренә җиткерелә: Плетцензее төрмәсендә 11 патриотның башы киселә.

Шундый авыр шартларда яшәгән: башта әсирлектә җәфаланган, аннары дошман оясында куркыныч эш алып барган, соңыннан елдан артык төрмәдә интеккән шагыйрь сәнгатьчә югары, оптимистик рухлы әсәрләр иҗат итәргә үзендә көч таба. Хәтта баш өстендә үлем балтасы торганда да, ул шаян шигырьләр яза. Моның өчен нинди рух ныклыгы кирәк! Моның өчен үз эшеңнең хак булуына ни дәрәҗәдә инанган булу кирәк!

М. Җәлил әсәрләре шундый ныклык рухы белән сугарылганнар. Аларда туган иленә ахыргача бирелгән солдат-шагыйрьнең эчке кичерешләре тулы чагыла. Ул кичерешләр

фронтта һәм дошман тылында сугышучы барлык совет солдатлары өчен дә уртак.

ТИК БУЛСА ИДЕ ИРЕК

(җыр)

1

Карлыгач булса идем,
Канат кагынса идем,
Җидегән йолдыз батканда,
Чулпан йолдыз калыкканда,
Туган илем, якты өем,
Очып сиңа кайтыр идем,
Сызылып таңнар атканда.

2

Йә булсам алтын балык,
Ак дулкыннарын кагып,
Ярсып дәрья акканда,
Ташып ярдан ашканда,
Таң сөмбелем, нечкә билем,
Йөзеп сиңа кайтыр идем,
Күлне томан япканда.

3

Булсам җитез аргамак,
Көмеш ялымны тарап,
Таң җилләре искәндә,
Үләнгә чык төшкәндә,
Чулпан кызым, таң йолдызым,
Чабып сиңа кайтыр идем,
Гөлләр хуш ис сипкәндә.

4

Юк, барсыннан да элек,
Тик булса иде ирек,
Кылычым булса кынымда,
Карабиным кулымда,
Сине саклап, туган җирем,
Мин ирләрчә үләр идем
Данлы сугыш кырында.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Җырда лирик герой һәм шагыйрь хисләренең бердәмлеге ничек чагыла?
2. Икенче куплеттагы образ-картинаны гади җөмләләр белән сөйләп бирегез. Табигать күренешләренең сыйфатларын әйтегез.
3. Җырдагы чагыштыруларны, эпитетларны табыгыз. Халык поэзиясендә кулланыла торган образларны күрсәтегез.
4. Җырның төп фикерен үз сүзләрегез белән әйтеп бирегез.

Җырга әйләнгән гомер

Җыр итеп язылган бу шигырь әсирлектә газап чигүче, ләкин рухы сынмаган кешенең иң зур теләген чагылдыра. Ул теләк — ирек; тоткын һәр көн, һәр сәгать ирек турында хыяллана. Әнә, җырда әйтелгәнчә, ирекле кеше теләсә нәрсә эшли ала. Ул, карлыгач кебек, туган өенә очып кайта ала. Туган ил ярларына, кадерле кешесе янына дәрьялар кичеп, балык кебек йөзеп кайтырга да мөмкин. Җитез аргамак шикелле чабып кайтсаң да була. Ләкин... юк! Болар,— билгеле, һәммәсе дә татлы хыяллар. Шулай да тоткын шагыйрьнең иң зур теләге болар түгел әле. Минут саен, атналар, айлар буе бәгырьне телә торган теләк бар. Бу — иреккә чыгып, кулга корал алу һәм ил-җирне басып алган, тыныч халыкны җәберләүче, кешене әсир итеп җәфалаучы дошманга каршы чыгу. Теләкләрнең бу соңгысы шул дәрәҗәдә мөһим һәм көчле ки, шагыйрь иле өчен, туган җире өчен аны саклап үләргә дә әзер.

Шигырь халык җырлары рухында язылган. Автор татар халык авыз иҗатында киң кулланыла торган сурәтләү чараларына, образларга, тел-стиль алымнарына, чагыштыруларга иркен мөрәҗәгать итә. Җырның һәр куплеты кечкенә бер картина-күренеш тудыра. Карлыгач, канатын җилпеп, Җидегән йолдыз баткан, Чулпан йолдыз калыккан матур вакытта, ягъни сызылып таң атканда, **якты өй кебек Туган илгә** очып кайта ала. Яки менә тагын бер образ. Күз алдына гөлләр хуш ис таратып, үләннәр, чык бөртекләре белән бизәнеп утырган таңда көмеш ялларын җилфердәтеп чабып баручы җитез аргамак килеп баса. Әгәр дә тоткын ирекәге шундый аргамак була алса, үзе өчен таң йолдызына тиң булган кызы янына (исеме дә Чулпан бит!) чабып кайтыр иде. Беренче өч образ-картина төп теләкнең олылыгын, изгелеген, яктылыгын раслый: **тик булса иде ирек!**

Шулай да җырдагы бу образлар, соңгы куплеттагы фикерне укучыга үтемлерәк җиткерү өчен, кереш ролен генә үтиләр. Алар тоткынның йөрәк сызлавы, сагышы, омтылышы ни дәрәҗәдә көчле булуын аңлату өчен, укучыны төп фикерне кабул итәргә әзерләү өчен дә кирәк. Кош булып, балык яки аргамак булып туган җиргә, сөйгән кешеләр янына кайту хыялы никадәр матур һәм көчле булмасын, иректән файдалану мөмкинлегенең иң изгесе — дошманга каршы сугышу. Барыннан да элек, шуны тели тоткын шагыйрь. Бу куплетта лирик геройның яу кырында дошман белән бил алыша алмау үкенече тулы чагыла.

СОҢГЫ ҖЫР

Җир йөзе шундый киң,
Күңелле һәм якты!
Тик төрмәм караңгы,
Ишеге йозаклы!

Күктә бер кош оча
Югары, югары!
Мин ауныйм идәндә,
Кулларым богаулы.

Тышта бер гөл үсә,
Яңгырга коенып;
Мин кибәм, мин сулам,
Төрмәдә боегып.

Мин беләм: бик татлы
Да яшәү тойгысы!
Тик инде мин үләм,
Бу җырым — соңгысы!..

Сораулар һәм биремнәр.

1. Лирик герой эләккән шартларны үз сүзләрегез белән тасвирлагыз.
2. Шигырьдә капма-каршылык ничек туа? Аның кеше кичерешләрен сыйфатлаудагы ролен күрсәтегез.
3. Шигырьдә сынландыруга мисаллар табыгыз.
4. Ни өчен бу әсәрдә лирик герой шагыйрьнең үз хисләрен тулы чагылдыра дип әйтәбез?

* * *

Шигырь, күрәсең, М. Җәлилнең тоткындагы иң авыр көннәрендә язылган. Бәлкем, бу — үлем җәзасы турында хәбәр ителгән көннәрдер... Тоткынның хәле авыр, аның күңелен газаплы уйлар баскан.

Шагыйрь әдәбиятта иркен кулланыла торган капма-каршы куюу (контраст) алымына мөрәҗәгать иткән. Җир йөзе киң һәм якты, ә тоткын утыра торган төрмә бүлмәсе караңгы, алай гына да түгел, аның ишеге йозаклы. Иректә, югарыда очучы кош белән куллары богаулап ташланган, идәндә аунаучы кеше дә капма-каршылык тәшкил итә. Тыштагы гөл белән сулырга мәҗбүр ителгән тоткын язмышы да бер-берсеннән кискен аерылалар. Нәтиҗәдә укучы тоткын хәленең никадәр авыр, үкенечле булганын ачык күз алдына китерә. Лирик геройның алдагы көне өметсез, фаҗигале. Ул соңгы сулышларын ала, тәрәзә аша гына булса да ирекә карый, андагы яктылыкка, кошка, гөлгә кызыга,— ул соңгы җырын яза. Боларны белгәч, укучы тетрәнә, сызлана. Кешене болай газаплауга, кеше язмышы белән уйнауга карата аның күңелендә нәфрәт һәм каршылык уяна.

СЕРЛЕ ЙОМГАК

Әкияттәге серле йомгак булып
Тәгәрәде тормыш сукмагым,
Озак бардым; ахры, көн батканда,
Шушы йортка арып туктадым.

Әкияттәге дию патшасыдай,
Йорт хуҗасы чыкты каршыма.
Балта аскан, бөркет үләксәсен
Бүрек итеп кигән башына.

Әкияттәге төсле тимер капка,
Күз кадәрле тишек капкада.
Дию карап һәр көн шул тишектән
Корбаннарын санап мактана.

Дию өчен көн дә йөз учакта
Кәбаб кыза адәм итеннән;
Шушы йортта икән кара бәхтем,
Мине илдән тартып китергән.

Эх, сез, шомлы әбием әкиятләре,
Кая сезгә җиту чынлыкны?!
Сүз җитәрме сөйләп аңлатырга
Бу йорттагы вәхшәт, коллыкны!

Кая гына аяк атласаң да,
Саклый монда дию тозагы.
Һәр тыкрыкта үлем күләгәсе,
Һәр ишектә коллык йозагы.

Шундый тәртип монда: акылы барның
Балта белән башын чабалар.
Ишекләре бикле килеш яна
Карт аналар, бала-чагалар.

Дию өчен зифа билен бөккән,
Мәхрүм булып аштан, иректән,
Илләреннән куып китерелгән
Хөрмә кебек кызлар, егетләр.

Йөрәк елый, таныш яңакларда
Канлы яшь һәм сулган төс күреп.
Күргәннәрем шомлы әкият кебек,
Кичергәнем авыр төш кебек.

Нәүбәт җитәр миңа, тик мин үлгәч,
Җырларымны минем кабатлар
Мин юлымда туктап назлап үткән
Гөлҗимешләр, гөлләр, наратлар.

Әкияттәге серле йомгак булып,
Җырым калды сүтелеп юлымда.
Сез табарсыз килеп шушы эздән
Мине соңгы йөрәк җырымда.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Шигырьнең сәнгатьчә эшләнешендә үзенчәлекләрне күрсәтегез.
2. Әкият формасы һәм аннан алынган образлар әсәрдә нинди максатка хезмәт итә?
3. Шагыйрь нәрсәгә борчыла һәм нәрсәгә ышана? Ни өчен ул җырларын гомер йомгагы дип саный?

4. «Җырларым» шигырен искә төшерегез. «Җырларым» һәм «Серле йомгак» шигырьләрендә сез нинди уртаклык һәм аерымлыклар күрәсез?
5. Шигырьне яттан өйрәнегез.

* * *

Шигырьдә халык авыз иҗаты, аерым алганда, әкият мотивлары көчле яңгырый. Адәм ите ашаучы дию, аның канлы йорты, тимер капка, юл күрсәтеп тәгәрәүче тылсымлы йомгак... Мондый әкият образлары һәм детальләр шагыйрьгә үзенең тоткынлыктагы хәлен, азат халыкны кол иткән дошманны, аның вәхшилекләрен сынландыру өчен кирәк. Һәм автор моңа ирешә дә. Фашистлар кулында газапланучы кешеләр, аларга карата дию пәриенеке кебек мөгамәлә укучы күңелендә кызгану да, ачу да, нәфрәт тә уята. Кешеләрнең җәфалануларын күреп җаны әрнегән лирик геройның кичерешләре безгә дә күчә.

Бусы — шигырь эчтәлегенең бер катламы, автор уздырган бер фикер. Анда тагын бер мөһим фикер (идея) бар. Анысы турыдан-туры лирик геройның үз хәле белән бәйле.

...Тоткын шагыйрь, фашистлар яклы булган булып, аларга каршы яшерен көрәш алып бара. Ләкин моны үзебезнекеләр белерме, чын дөреслек өскә чыгып, аны «сатлык» тамгасыннан котылдырырмы? Шагыйрь аны белми. Сугышка кадәр илебездә киң җәелгән шикләнүчәнлек, кешегә ышанмау кебек хисләрнең аяныч хәлләргә китерергә мөмкин икәнлегенә ул төшенә. Әгәр дә аны, чынлап та, фашистларга сатылган дип уйласалар?! Аның саф исемен һәм әдәби мирасын гына түгел, туганнарын һәм якыннарын да ниләр көтә! Ләкин аның бик ныклы, ышанычлы таянычы бар: ул—җырлары.

Һ. Такташ әйткәннәрне искә төшерик:

Анкеталарда бик күп алдасам да,
Җырларымда — һичбер вакытта...

Муса Җәлил дә — җырларында һичбер вакыт алдашмаган шагыйрь. Зур бәхетсезлеккә каршы, «Моабит дәфтәрләре» илгә әйләнеп кайта алмады, каядыр югалды, дип фараз кылыйк. Шундый сурәттә дә, М. Җәлилнең 20 нче еллардан ук башланган поэзиясе шагыйрьне сатлык итеп, азатлык идеалларына хыянәт итәрлек кеше дип санарга һич ирек бирми. Чөнки бу чорда ук инде М. Җәлил — азатлык җырчысы. Туган илен

өзелеп сөйгән, халкына ахыргача бирелгән, җырларында ихлас күңелле булган шагыйрь. Патриотлык рухы белән сугарылган поэзия иясе. Ә инде «Моабит дәфтәрләре»нә кергән әсәрләре патриотизм, азатлыкка тугрылык, дошманны күралмау, коллыкка нәфрәт хисләре белән тулы. Аларда икеләнү, каушаппуркып калу, җиңүебезгә шикләнү чагылмый. Бу яктан андагы шигъри юллар — чын мәгънәсендә гомер сукмагына тезелгән якты маяклар. М. Җәлил биографиясе турында бөтенләй хәбәрдар булмаганда да, алар буенча барып, чын патриот узган гомер юлын билгеләргә мөмкин. Менә ни өчен М. Җәлил үз шигъриятен «серле йомгак» дип атый, көрәш юлын дөрес яктыртуда җырларына шаһитлык ролен тапшыра, аларга ныклы ышаныч белдерә.

САНДУГАЧ ҺӘМ ЧИШМӘ

(баллада)

1

Таң атып, нурлары
Үпкәндә кырларны,
Чишмәләр, күлләрне
Һәм калын урманны,

Сандугач, уянып,
Канатын кагына
Һәм карый, ашкынып,
Тын урман ягына.

Ул якын сердәше
Чишмәне сагына;
Таң кошын юксынып,
Чишмә дә зарыга.

Сихерле тормышы
Бу ике гашыйкның
Кабынды мәхәббәт
Утында яшьлекнең.

Бәйләде аларны
Ялкынлы саф сөю;
Саф сөю алдында
Нечкәреп баш ию.

Һәр иртә Сандугач
Чишмәдә коена.
Бу аңа чиксез зур
Дан булып тоела.

Иркәли таң кошын
Зөбәрҗәт тамчылар.
Әйтче, бу күренешкә
Сокланмый кем чыдар?!

2

Таңнарның берендә
Иркә кош — Сандугач,
Уянып карангач
Һәм канат кагынгач,

Килде тиз сердәше
Чишмәгә...
Тик аның
Кайгылы моң баскан
Чәчәкле буйларын.

Чишмә тын; ул көлми,
Тибрәнми, селкенми;
Акбүз таш өстендә
Тамчылар сикерми.

Болганып каралган
Көмештәй саф суы;
Уйлары таралган,
Йөрәге — ярсулы.

Сандугач аптырап
Сорашты дустыннан.
Һәм әйтте сердәше
Дип: «Кичә шушыннан

Үтте ил дошманы,
Яшеренеп, яр буйлап,
Минем саф, шифалы
Суымны агулап.

Канечкеч юлбасар,
Ул кача артыннан
Аны нык күзәтеп
Килгән яшь батырдан.

Ул белә батырның
Инешне кичәсен
Һәм, сусап, минем саф
Суымны эчәсен.

Ул, эчкәч, агудан
Шул минут үләчәк.
Ә дошман котылып,
Талап көн күрәчәк.

Әйт, нишлик, сердәшем?
Әйт, нишлик, акыллым?
Ничек соң коткарыйк
Илебез батырын?»

Сандугач аз гына
Уйланып торды да
Җанланып эндәште
Чишмәгә тын гына:

«Кайгырма, күз нурым!
Ул килсә эчәргә,
Коткарам мин үзем,
Мин беләм нишләргә!»

3

Килде ил батыры
Мылтыктан, кылычтан,
Йөрәге һәм анты
Катырак корычтан.

Илгә саф мәхәббәт
Ярсыта йөрәген,
Дошманны юк итү —
Аның бар теләге...

Ул арган, алҗыган
Татып яшь ачысын,
Ах, әгәр булсачы
Бер генә тамчы су!

Ул күрде Чишмәне,
Төште тиз атыннан,
Әлсерәп үзәген
Көйдергән ялкыннан.

Ул теләп эчәргә
Чишмәгә омтылды.
Шулвакыт Сандугач
Сайрарга тотынды.

Ул сайрый, Егетнең
Алдына ук кунып,
Ул сайрый, нәрсәдер
Сөйләгәндәй булып.

Ул сайрый ялкынлы
Саф сөю турында
Һәм сөйгән йөрәкнең
Ярсуы турында.

Ул мактый көрәштә
Кабынган тормышны,
Дан белән суланган
Иң соңгы сулышны.

Ул мактый дустына
Бирелгән күңелне,
Ул сөйли сөюнең
Җиңгәнен үлемне.

Ул сөйли чын дуслык,
Тугрылык турында,
Нинди көч бу кошның
Ялкынлы җырында!

Тик Егет аңламый
Телен таң кошының,
Тойса да йөрәге
Хисләрен дусының;

Серле җыр иң нечкә
Кылларын күңелнең
Чиртсә дә, ул сизми
Килгәнен үлемнең.

4

Эчәргә дип, Егет
Чокырга иелә
Һәм кипкән иренен
Чишмәгә тигерә.

Шулвакыт кош аның
Ирененә сугыла,
Бер тамчы эчә дә
Чишмәгә егыла.

Сөйгәне куенында
Соңгы кат талпынгач,
Шат, мәгърур һәм батыр
Җан бирә Сандугач.

Ә Чишмә, чайкалып,
Ярларга ташлана.
Урнында тик көйгән
Кап-кара таш кала.

Яшь Егет аз гына
Торды да инештә,
Таң калып бу серле
Һәм гали күрнешкә,

Чишмәне калдырып,
Атына атланды.
Юлбарыс шикелле
Дошманга ташланды.

Ул сизде күңелендә
Иң гали хисләрнең
Өр-яңа көч белән
Кабарып үскәнен.

Ул улы хөр илнең
Һәм бөек атаның,
Ялкынлы йөрәктән
Ул сөя Ватанын.

Яшәде ул сөеп
Һәм үләр беркөнне,
Нәкъ мәгъруր Сандугач
Һәм Чишмә шикелле.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Баллада турында VI сыйныфта өйрәнгәннәрегезне искә төшерегез. Бу әсәрнең балладага хас нинди сыйфатлары бар?
2. Әсәрдә халык авыз иҗатыннан алынган образларны һәм хәлләрне атагыз. Аларны җанлы һәм җансыз табигатьне чагылдыручыларга бүлегез.
3. Ил батырына бәя бирегез (аның портреты, характер үзенчәлекләре, максаты һ. б.). Дошманны ничек бәяләр идегез?
4. Баллададагы шартлы образларга, эш-хәрәкәткә, нәтиҗәгә мисаллар китерегез.
5. Әсәрнең дүрт өлешенә дә исемнәр куегыз. Һәр бүлекчәдәге төп вакыйганы күрсәтегез. Алардагы үзәк образны билгеләп буламы?
6. Балладаның төп фикерен (идеясен) әйтеп бирегез.

* * *

«Сандугач һәм Чишмә»— татар әдәбиятында баллада төренә караган күренекле әсәрләрнең берсе.

Баллада — әдәбиятның борынгы жанрларыннан. Аңа үткен драматик яки фаҗигале хәлләргә корылган булу, сюжетының кискен һәм хәрәкәтчән үстерелеше хас. Фантастик предмет һәм детальләрдән, халык авыз иҗатындагы образлардан һәм күренешләрдән файдалану, шартлылыкка күп урын бирелү кебек сыйфатлар да аның үзенчәлекләрен тәшкил итә. Балладада арттырып тасвирлау һәм гомумиләштерү кулланыла.

Ни өчен автор әсәрен «Сандугач һәм Чишмә» дип атаган? Җанлы табигать вәкиле Сандугач укучы аңында сөюне, мәхәббәткә тугрылыкны гәүдәләндерә. Таң җырчысы, матурлык, нәзакәтлелек билгесе буларак, ул халык шигъриятендә киң урын ала.

Җансыз табигать вәкиле буларак, Чишмә исә сафлык, чисталык образы төсендә шулай ук фольклордан килә. Балладаның беренче бүлекчәсе шушы ике символик образ арасындагы якынлыкны, аларның бер-берсенә соклануын, бер-берсен хөрмәтләвен сурәтләүгә багышланган; ул вакыйгаларга кереш ролен уйный. Сандугач белән Чишмәгә кешеләргә хас сыйфатлар бирелгән: уйлый, аңлаша, хис итә белү һ. б. Сыйфатларның да иң гүзәлләреннән берсе булган сөю хисе аларның дуслыгын бизи, югары күтәрә, яшәүләренә мәгънә һәм ямь өсти.

Беренче бүлекчәдәге лирик сурәтләнештән аермалы буларак, икенче бүлекчәдә драматизм үстенлек итә. Дошман агулап киткән Чишмә үзенең каралган суы (ягъни пычранган сафлыгы) турында түгел, ә суын эчеп агуланачак ил батыры турында хәсрәтләнә. Монда Чишмә — үзәк образ, аңардан тирән хисләр ургыла. «Канечкеч юлбасар», «талап көн күрәчәк» дошманга булган нәфрәт аның «йөрәген ярсулы» иткән. Сандугач, ниндидер карарга килеп, Егетне коткарачагын әйткәч, укучының кызыксынуы арта: ни булыр?

Өченче бүлекчәдә вакыйга үстерелә. Дошманны эзәрлекләүче Егетнең кыскача гына тышкы кыяфәте бирелә, һәм асыл максаты әйтелә. Егет агулы суны эчмәсме? Аңар Сандугач ничек ярдәм итәр?

Сандугач башта табигать үзенә бүләк иткән тылсымлы көчтән файдаланып карый: сайравы белән Егетнең игътибарын агулы судан читкә юнәлтмәкче була. Аның сайравы беренче нәүбәттә сөю турында, кешене югары күтәрүче, аның яшәвен бизәүче ярату хисе, бу хискә тугрылык турында. Бердән, Егетне кисәтмәкче булса, икенчедән, ул Чишмәгә үзенең сөюе хакында сөйли, бу хискә ахыргача бирелгәнлеген белгертә. Әйтерсең лә Егетнең аны аңламаячагын белә, җанын фида кыласын әйтеп, сөйгәне белән саубуллаша, һәм, чыннан да, аңар соңгы чараны сайламый булмый. Илгә, җиргә, табигатькә, аның гүзәл гәүдәләнеше булган Чишмәгә зур зарар салучы дошман җиңелсен өчен, Егет исән калырга тиеш! Сандугачның соңгы гамәле буларак үлеме азатлык хөрмәтенә бирелгән корбан булып укучыга көчле тәэсир итә, кызгану һәм тетрәнү хисләре тудыра. Бу үлемнең табигать һәм илнең имин яшәве өчен булуы соклану да уята. Бу хәлгә тетрәнгән Егетнең яңа көч алуы һәм рухлануы укучы күңелендә теләктәшлек тәрбияли. Патриотизм хисе югары ноктага җиткерелә, Туган ил азатлыгы өчен фидакяр көрәшнең изгелеге раслана.

Нурихан Фәттах
(1928—2004)

Татар әдәбиятына 70 нче елларда гаҗәеп бер яңарыш килеп керде. Татар халкының үткәне, тарихы белән кызыксынучы галимнәр, зыялылар, язучылар: «Без кемнәр? Каян киләбез? Кая барабыз?»—дип халкыбызның милләтебезнең хәле, язмышы турында уйлана башладылар.

Фикер җебе аларны ерак тарихка алып китте. Киләчәкнең нинди буласын чамалап булган кебек, бүген мондый хәлдә яшәүнең сәбәпләрен дә без үткәннән эзлибез. Ераккарак китеп караган саен, карашлар киңәя. Күз күреме генә җитми, хыял зирәклеге, күңел сизгерлеге, акыл көче дә күбрәк кирәк була. Менә шундый сыйфатларга, фикерләү дәрәҗәсенә нигезләнгән тарихи романнар иҗат ителә башлый. Дөрес, татар әдәбиятында моңа кадәр дә тарихи романнар язылды. Г. Ибраһимов, М. Галәү, И. Гази исемнәре, әсәрләре безгә таныш. Ә менә бу яңалары халыкның милли аңын үстерделәр. Зур хакыйкатьләр ачу, мәңгелек белән бәйле фикерләр әйтү, нәтиҗәләр ясау өчен, зур мәйданга — ерак һәм мавыктыргыч тарихлар киңлегенә чыктылар.

Зур гражданлык батырлыгы, фәнни белем һәм иҗади тәҗрибә, фикер кыюлыгы сорый торган бу өлкәгә гаять үзенчәлекле язучы, талант иясе Нурихан Фәттах беренчеләрдән булып аяк басты.

Нурихан Садрилмән улы Фәттахов Башкортстанның Яңавыл районы Күчтавылда туа. Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Мәктәп елларыннан ук китап белән сихер-

ләнгән Нурихан Татарстан китап нәшриятында редактор булып эшли, район газетасында журналист-тәрҗемәче хезмәтен үти. Шулай да төп һөнәре итеп язучылык эшен сайлый. Каләмен сынап караган беренче әсәрләре — шигырь һәм хикәяләре — мәктәп чорында ук языла. Исемен танытканнары исә үзенә бик таныш булган, үзе кичергән вакыйгалар турында. «Сезнеңчә ничек?» романы студентлар тормышын сурәтли, «Бала күңеле далада» исемле зур романын чирәм җирләрне үзләштерү чорында үзе дә Павлодар өлкәсендә яшәп, өйрәнеп яза. Тарих туфрагын каплаган бу чирәм җирләр, дала киңлекләреннән өермә булып үткән ерак бабаларыбызның язмышлары язучы хыялын уяткандыр, бөркетләр күтәрелгән биеклекләр аның талантын ныгыткандыр. Кешенең хис-кичерешләрен тоя белү, аны тасвирларлык сүзләр табу, күңел дөньясын корып куя белү — иҗат кешесе өчен зарури сыйфатлар. «Мөдир Саҗидә» повестенда Нурихан Фәттахның бу яктан да осталыгы күренде.

Тарихи романнары исә — аның үз иҗатында гына түгел, бөтен татар әдәбиятында зур вакыйга булган әсәрләр.

Тарихны ул «кулына алып» та карый — археологик экспедицияләрдә күп катнаша, хәзер барыбызга билгеле һәм кадерле булган Болгар шәһәренең һәйкәлләрен өйрәнә. Ул укып, өйрәнеп чыккан китаплар да шактый зур бер китапханә тәшкил итәр иде. Тарихи вакыйгаларны белү, материал туплау гына да җитми, сәнгать әсәре тудыру, нәкъ менә шул чорны җанлы итеп тергезү өчен, аның үзенә хас үзенчәлекле теле дә кирәк. Романнарны укып чыккач, хәйран каласың: нинди байлык, хәзинә икән бу сөйләм теле, хикәяләү теле. Менә шул рәвешчә, өч профессиягә ия булып — тарихчы, тел белгече, художник-язучы булып өлгергәч, Нурихан Фәттах тарихи романнар иҗат итә: «Итил суы ака торур» (1970), ике китаптан торган «Сызгыра торган уклар» (1977, 1991). Боларга өстәп аның «Кол Гали» трагедиясен һәм «Ерак еллар авазы», «Шәҗәрә» дигән фәнни хезмәтләрен дә искә алсак, язучының иҗатын тулырак күз алдына китерербез.

Әдип эшчәнлеген югары бәяләп, аңа Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелде (1994 ел), «Татарстан Республикасының халык язучысы» дигән мәртәбәле исемгә лаек булды (1998 ел).

ИТИЛ СУЫ АКА ТОРУР

(өзекләр)

Менә тагын яз җитте. Кышкы озын төннәрдән соң, каты салкыннардан, ачы бураннардан соң тагын яз килде. Тәбәнәк, болаңгыр күктә ягымлы кояш күренде; тирә-якны яктыга, куанычка күмеп, җирдәге барлык терегә күз кысып, шаярып, кайнар укларын яудырды. Калын кар астында басылып яткан тигезлекләр, калкулыклар, урманнар, чокыр-чакырлар... әкренләп-әкренләп авыр йөктән арына бардылар. Кыш буена тынып торган җирнең өсте озакламый өтәләнгән тунын салып ташлады. Сыртларда яшел үләннәр мыек төртте. Яр буйларында тал бөреләре күзләрен ачтылар. Басулардан, үзәннәрдән челтерәп беренче сулар акты.

Сулар акты... Аҗун[1] яралганнан бирле, сулар кая таба аккан булса, быел яз да сулар шул бер якка юнәлделәр. Инешләр, елгалар, ермаклар, ташулар...— барысы да Чулман атлы олуг суның кочагына омтылдылар... кушылдылар, көчәйделәр, ургып-шаулап, алга ыргылдылар. Чулман исә ерaклардан, якыннардан җыеп алган язгы суны, сыяларны[2], бозны-карны тагын ары алып китте. Кайдадыр кояш баешта, кыялы ярлар янында олуг Чулман үзенең бөек туганын очратырга тиеш. Алар шунда кавышалар, бергәләшеп, кочаклашып, көн ягына юл тоталар. Кайнар ком, кояш илендә, тау-ташлар, камышлар илендә, Итил-Чулман суын ямансулап, иксез-чиксез тиңгез, төпсез тиңгез көтеп ята. Хазар тиңгез көтеп ята. Анда изге Хазар җире, анда изге каган[3]...

Сулар ага... Җир йөзендә сулар бертуктаусыз агалар да агалар. Җәй агалар, яз агалар, көз агалар... Агымсулар кешеләрнең чир-чорларын, кайгыларын, язык-ларын алалар да еракларга — упкыннарга, чоңгылларга ыргыталар. Агымсулар җир өстенең чүп-чарларын, үлекләрен юып алып, үзләрендә юк итәләр. Шулай ел да җир яңара, җир яшәрә.

Җир яңара, җир яшәрә... Өзелмичә, туктамыйча, бөек Чулман кебек, Итил кебек, көн-төн җирдә тормыш ага.

---

[1] *Аҗун* — дөнья.

[2] *Сыя* — язгы ташу вакытында елгада ага торган каты кар.

[3] *Каган* — борынгы төркиләрдә дәүләт башлыгы, хан, патша.

Яз килде, яз!..

Киң Чулманга — кояш белән, ай-йолдызлар белән яшьтәш Чулманга ашыгып төрле яктан сулар ага...

Язгы йолык туен кешеләр кояш көткән кебек көтеп алалар иде. Бу көнгә һәркемнең яшерен уе-теләге була. Авырулар, явыз ияләргә йолык биреп, чирдән котылу, языклылар языктан котылу турында уйлап юаналар иде.

Йолык туеның кайчан буласы билгеле булгач та, катау кешеләрен күңелле бер күтәренкелек биләп алды. Кешеләр бу олы көнне тиешенчә каршылау, тиешенчә озатып җибәрү өчен җыена да башладылар: өлкәннәр йолыкка биреләсе терлек-туар турында, аш-су турында кайгырттылар, яшьләр көн-төн үзара бәйге тоттылар: ук аттылар, сөңге чөйделәр, төрлечә көчләрен сынаштылар.

Иртәгә туй була дигән көнне катау кешеләре мунча керделәр, баштанаяк таза киемнәрен киенделәр — кышкы чирләрдән, языклардан, кайгылардан арыну шуннан башланды. Аннары, артыш яндырып, өй эчендәге почмакларны, абзар-кураларны төтәсләделәр: күздән кереп калган явыз ияләрне куалап чыгардылар.

Икенче көнне барлык катау кешеләре — яше-карты, тазасы-чирлесе — башка көннәргә караганда иртәрәк тордылар. Кояш чыкмас борын ишекләр, капкалар ачылды. Олуг Чулман аръягыннан, су астыннан чыгып килгән кояшның беренче яктысын кешеләр, җиргә яланаяк баскан килеш, йөзләрен көнчыгышка төбәгән килеш, елмаеп-куанып каршыладылар. Ырудашлар бер-берсен яңа туган көн белән котладылар, бер-берсенә изге теләкләр белдерделәр.

Кояш су астыннан чыгып бер-ике таяк күтәрелгәндә, сөрәнчеләр, Яр-капкага җитеп, кире борылдылар. Күрән би урдасы янында аксакаллар төркеме туктап калды. Би өендәгеләр дә быргы уйнап җибәрделәр, байракларын күтәрделәр. Капка сакчылары каерып имән капкаларны ачтылар. Капкада би углы Тотыш күренде.

Атасы кебек, ул таза, эре сөякле иде. Тик аңа караганда ул буйга тәбәнәгрәк, иңбашка киңрәк. Борын асты әле аның яңа гына караеп килә. Бүгенге көндә караңгы чырайлы булу язык саналса да, алсу иреннәре

кысылган, матур кара кашлары җыерылган. Җылый-җылый күз төпләре кызарып беткән. Ул — кайгылы, ул — ачулы, ул ярсулы иде. Сул кулына яшел төстәге язгы йолык байрагын тоткан, уң кулына үзенең сөеклесен — Йолдыз-кашканы җитәкләгән. Бүген ул туй башчысы санала. Аксакаллар кебек, ул да бүген баштанаяк актан киенгән. Биленә аның көмеш аеллы киң каеш буылган, муенына көмеш чылбыр белән ыруның сакчысы — кечкенә алтын бүре башы тагылган.

Яшь чибәр җегет Йолдыз-кашка белән икәүләп капкадан чыкты да, тирә-якта җыелып өлгергән кешеләрнең берсенә дә карамыйча, төп юлга төште. Углы артыннан ук капкадан Күрән би чыкты. Койтым бикә, бинең башка хатыннары, балалары, туганнары чыкты. Ыру башы белән Койтым бикәгә урам яктагы сигез аксакал кушылды. Барысы да, үзләренең урыннарын белеп, би артыннан, аксакаллар артыннан ияреп бардылар. Ясанган, бизәнгән, куанып елмайган кешеләр төркеме, көчле бер агым булып, урамнан Басу-капка ягына юнәлде.

Тотыш җитәкләгән яшь айгыр искиткеч матур. Ул уттай янып торган җирән төстә. Маңгаенда уч төбедәй генә ак табы — йолдызы бар. Аның күкрәге киң, нечкә, нык аяклары озын. Ялт-йолт килеп, очкынланып торган күзләре зур, матур. Атлаганда аның аяклары җиргә дә тими шикелле — биюче яшь кызлар кебек, ул шундый җиңел, шундый матур атлый. Бүген аны кыз куенына керәсе кияүдән дә болайрак төзәндергәннәр иде. Өстенә аның ука белән матур итеп каелган күк төстәге зур япма салганнар. Япманың читчитләреннән көмешләнгән ал, кызыл, сары чуклар асылынып тора. Япма өстенә сырлап, бизәп эшләнгән кечкенә генә, җиңел генә ияр салынган. Яллары, койрыгы аның матур итеп таралган, бизәлгән.

Барлык кешенең күзе бары Йолдыз-кашкада гына булды. Алар аңа, сокланудан бигрәк, куркып, аптырап карадылар. Күрән бинең мактанычы, яшь Тотышның куанычы булган атаклы чаптарның бүген менә йолык туенда чалыначагына беркемнең дә ышанасы килмәде. Бу ничектер башка сыймый торган, аңлап булмый торган нәрсә булып тоелды. Тик шулай да бу турыда беркем дә ачыктан-ачык әйтергә батырчылык итмәде.

Икенче көнне, таң атар-атмас борын, Күрән белән капка төбенә Утташ кам килеп җитте. Ул чамадан тыш ачулы иде. Үзен капкадан кертергә теләмәгән сакчыларга ул яман сүзләр әйтте. Сакчылар аңа бинең йокыдан уянганын көтәргә куштылар. Утташ кам теләсә дә, теләмәсә дә көтәргә тиеш булды.

Би аны үзенең ак өендә каршы алды.

— Нишләп бик иртә? Бер-бер эш чыктымы әллә? — диде ул, бабасының таң тишегеннән килеп җитүен ошатмыйча.

— Чыкты, кияү! — диде Утташ кам, ачуыннан бүреген салырга да онытып.

Аның болай сөйләшүе, җимерелгән йөзе бинең күңелендә йокымсырап яткан кире тойгыларын уятып җибәрде.

— Син бик тупас күренәсең, кам баба,— диде ул, коры гына, урынына утырып.— Сал башыңны, утыр, сөйлә.

Утташ кам башындагы бүреген тартып алды да күрсәтелгән урынга терәлгәндәй итте.

— Эш чыкты, би... кияү! — дип кычкырды ул, чәрелдек тавыш белән.— Ниндидер явызлар изге наратны... бөтен ыругның изге сакчысын, яклаучысын мыскыллаганнар! Тәүбә! Тәүбә! Изге аланны бозганнар, би! Изге Кайракканның йөзенә төкергәннәр! Тәүбә! Тәүбә!

— Кемнәр?! Кайчан?! — диде би, коты алынып.

— Кемнәр, имеш! — дип чәрелдәде Утташ кам, күз яшьләренә буылып, бизгәк тоткандагы сыман калтыранып.— Килмешәк Койтым кырнакның игелексез Тотышыннан башка кемнең шуңа кулы барсын?!

Би ап-ак булды. Шуннан соң ул бурлаттай кызарынды, еш-еш тын алып, йокысы качып бетмәгән усал күзләреннән куркыныч очкыннар чәчрәтеп, урыныннан торды да җентәс шәрә кулын ашыкмыйча гына алга сузды, бабасының сакалыннан учлап тотты.

— Аңлатыбрак сөйлә! — диде ул.

Өлкән камның тары бөртегедәй елтыр күзләре чәчрәп чыгардай булып акаеп калды. Кайнарлыгы, ачуы-ярсуы шундук юкка чыкты, бөтен явызлыгы, бергә җыелып, кинәт каядыр эчкә төшеп китте. Теле тотлыгып, беравык эндәшә алмый торгач, ул, этенә-төртенә:

— Б-б-бүген иртән б-б-барсам...— диде.

— Шуннан? — диде би, аның сакалын бушаткандай итеп.

— Ш-шуннан...— диде Утташ кам.— Из-зге нарат төбендә... ч-ч-чүмәлә дисәң, ч-чүмәлә түгел... у-утын дисәң, утын түгел... Йә Тәңрем!! Үле бүреләр өелеп ята! Кайсын ук белән, кайсын кылыч, сөңге белән... Унлап-унбишләп! Бүре каны койганнар! Изге җиргә, изге нараткаебызга... бүре каны койганнар!

Утташ кам, сакалы ычкынгангамы, изге наратны кызганыпмы, кычкырып җылап җибәрде.

Күрән би, яшен суккан кебек, телсез-өнсез калды: бу, чыннан да, коточкыч иде, бу, чыннан да, беркайчан да булмаган, була алмастай яман бер эш иде.

— Чумаклар[1] түгел микән? — диде ул, аптырап, бабасының җирәнгеч йөзенә карамаска тырышып.— Әллә җөфүтләр[2], румнар[3] микән?

— Язык! Язык! — дип такмаклады Утташ кам, тынычлана алмыйча.— Башы аягы астына гына килсен! Кулы корысын! Күзе корысын! Йөргән җирендә җир йотсын!

— Кемне каргавыңны әйтеп карга,— диде би, кашларын җыерып.

— Тотыштан башка...— диде киребеткән кам, үксеп.

Күрән би, ике куллап, бабасының иңбашларыннан кысып тотты да, күзләренә карап:

— Күрдеңме? — диде, әкрен генә.

«Юк» дигәнне аңлатып, Утташ кам башын чайкады.

— Күрүчеләр булганмы? — диде би.

— Юк,— диде кам, мыгырданып.

Күрән би җиңел сулап куйды, маңгаена бәреп чыккан тир бөрчекләрен учы белән сыпырды да Утташ камнан читкәрәк китте, кинәт авырта башлаган эчен тотып, йөзен чытып, кояш яктысы төшкән төннек аша беравык тышка карап торгандай итте. Шуннан соң ул яңадан Утташ кам янына килде:

— Бу турыда беркемгә лыгырдыйсы булма! — диде ул, боерып, янап.

---

[1] *Чумак* — мөселман динендәге кеше.

[2] *Җөфүт* — яһүд динендәге кеше.

[3] *Рум* — рум (грек), ягъни христиан динендәге кеше.

Кешеләр торып йөренә башлаганчы дип, ашыгып, Күрән би белән Утташ кам ике колны алдылар да келәүлеккә киттеләр. Изге нарат төбендә, чыннан да, таудай булып бүре үләксәләре өелеп ята иде. Шунда ук, наратның икенче ягында, берни булмагандай, Йолдыз-кашка басып тора. Аландагы үгез, тәкә карачкыларының барысы да ботарланып, теткәләнеп беткән. Бу, билгеле, изге бүреләрнең генә эше түгел, монда тагын изге булмаган ике аяклы бүренең дә бик каты эшләгәне күренеп тора иде. Ул ике аяклы бүренең кем булуы турында күңеленнән әз генә дә шикләнмәсә дә, Күрән би, үләксәләрне күргәч, аһ-ваһ килде.

— Кемнең йөрәге җиткән моңа! — диде ул, шаккатып.— Ничек җир күтәрә ул кешене?! Тәңрем, кичер аны бу языгы өчен![1]

Коллар бүре үләксәләрен, шулай ук барлык карачкыларның сөяк-санакларын урман арасындагы тирән чокырга илтеп ташладылар. Берәрсе ялгыш күрә-нитә күрмәсен дип, Күрән би үләксәләргә ут төртергә кушты.

Өенә ул бик күңелсезләнеп кайтты. Кайткач та Койтым бикә белән Тотыш угланны үз янына чакыртты.

— Кем эше булыр икән бу? — диде ул, авыр гына, изге аланда күргәннәрен сөйләгәч.

— Мин! — диде Тотыш, өй эчен яңгыратып.

Ул алай кычкырып та әйтмәде бугай әйтүен, шулай да ата белән анага аның бу «мин» дигәне күк күкрәве сыман булып ишетелде. Койтым бикә чак-чак кына артына аумады. Күрән би тораташтай катты да калды.

— Син... син...— диде ул, тотлыгып.— Беләсеңме шуны... бөтен ыруга... атаңа-анаңа каргышы төшәр!..

Кинәт ишек ачылып китте, күзе-башы акайган яшь сакчы, тамак ярып:

— Сөенче! — дип кычкырып җибәрде.— Киләләр! Каеклар килә!

---

[1] Төрки халыкларның күбесендә бүре изге саналган, чөнки, ышану буенча, төрек ыруларының нәселе, имеш, бүредән башланган. Романда шуңа ишарә.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Язгы табигать күренеше ничек, нинди сүзләр белән тасвирланган? Кояшка, суга, җиргә кешеләрнең мөнәсәбәте нинди, без гадәтләнгәнчәме?
2. Йолык туеның мәгънәсен ничек аңладыгыз? Хәзер дә аңа охшаган бәйрәм бармы?
3. Романда сүз кемнәр турында барачак? Геройларның исемнәренә игътибар итегез, хәтерләп калыгыз.
4. Бу өзектә нинди хәл тасвирлана? Күрән би һәм Утташ кам ни өчен шулкадәр борчуга төшәләр? Тотышның ни өчен алай эшләвен аңладыгызмы? «Язык» нәрсә диган сүз?
5. Башлам өлешеннән үзегезгә ошаган урыннарны дәфтәрләрегезгә күчереп алыгыз яки ятлагыз.

Үргә таба әкрен генә кыймылдап, унлап-унбишләп каек килә иде. Аларның кем каеклары икәнлеген әле бик үк аерырлык та түгел иде. Шулай да, ни генә булмасын, алар киләләр иде! Астан — Болгар ягыннан, Хазар ягыннан, кояшлы Хәрәземнән йә булмаса ерак Румнан, Багдад якларыннан киләләр иде!

Каекларның килүе турыдагы кү[1] тиз арада бөтен катауга таралды. Кешеләр ашыгып Яр-капкага агылдылар, ябырылып, койма өстенә менделәр, каргу, сырган башларына үрмәләделәр, текмә араларына кысылдылар. Койма сакчылары кешеләрне әле бер җирдән, әле икенче җирдән кудылар, шулай да артык усаллык та күрсәтмәделәр — катауга ерактан каеклар килүе Күрән би өчен генә түгел, башкалар өчен дә зур куаныч иде.

Би дә, бикә дә шундук терелеп киткәндәй булдылар. Бүреләр кайгысы, Тотыш кайгысы онытылды, бөтен катауны, бөтен өй эчен көндезге кояштай якты куаныч биләп алды. Әйе, киләләр, соңлап булса да киләләр. Соң булса да уң булсын... Төкле аяклары белән!

Борыннан, койрыктан казаяклар аркан ыргыттылар, уртадан басма суздылар. Каек, күпер читенә терәлеп, чайкалудан туктап калгач та, унлап кеше аягүрә басты. Кыска итеп киселгән сакал-мыеклы, озынча битле, очкынланып торган шаян, тере күз карашлы чандыр бер кеше, елмаеп, Акбүре ыруының башы алдында бүреген салды, башын иде. Күрән би белән чагыш-

---

[1] *Кү* — хәбәр.

тырганда, ул бик яшь күренә иде. Күп булса, аңа утыз биш-кырык яшьләр чамасы булыр.

— Казаяк ыруының башы Ямгырчы би синең җиреңә килде,— диде ул, Күрән бигә эндәшеп.

— Илме, яумы? — диде Күрән би.

— Ил! — диде Ямгырчы би.

— Төкле аягың белән, туганым Ямгырчы би! — диде Күрән би, бозылган йөзенә елмаю билгесе чыгарып.

Ашыкмыйча гына ул атыннан төште. Койтым бикә дә, бинең башка хатыннары белән балалары да, аксакаллар да — барысы да атларыннан төштеләр, бер тирәгәрәк җыелдылар.

Кунаклар үз каекларыннан өч тартма төшерделәр. Тартмаларын ачып, Ямгырчы би Акбүренең өлкәннәренә бүләкләр өләшә башлады: Күрән бигә кышкы төлке тун белән бүрек бирде, Койтым бикәгә шулай ук тун бирде, көмеш беләзек бирде. Башкаларга да шактый өлеш чыкты. Кайберсенә — күлмәк, кыекча, кайберсенә итек-читек, беләзек, йөзек, муенса ише нәрсәләр тиде. Кунакларны каршыларга төшкән кешеләрнең берсе дә бүләксез, кучтәнәчсез калмады. Акбүреләрнең күңелләре куаныч белән тулды. Салкын, кырыс чырайлар яктырып китте — Ямгырчы би үзе белән бүләкләр генә түгел, әйтерсең көньяк җылысын да алып килгән иде. Кызыл Яр катауга килгән бер генә кунакның да әле беркайчан да бу чаклы күп бүләк өләшкәне юк иде бугай. Менә, ичмасам, юмарт икән, менә, ичмасам, бай икән бу Ямгырчы би!

Казаяк ыруының башы Ямгырчы би белән Кызыл Яр катауга йөзләп кораллы ир килгән иде. Йөзләгән ир арасында бер хатын-кыз да бар. Ул да булса Ямгырчы бинең кызы Тәңкә иде.

* * *

Казаяк ыруы белән Акбүре ыруы арасында борын-борыннан туганлык яшәп килгән. Алар икесе дә бер тамырдан — Ак хан йортындагы[1] Ак җылан ыруыннан аерылып чыккан булганнар. Ак ханның тамыры үзе бөек төрек бөдүнен[2] барлык җир-суларга, барлык

---

[1] *Йорт* — дәүләт.

[2] *Төрек бөдүне* — а) төрек — гомумән төркиләр; б) бөдүн — халык, улус.

илләргә, телләргә баш ясаган бөек Көн каган углының углына тоташкан булган. Казаяк белән Акбүре ырулары кайчандыр Чулманның түбән агымында — Итил белән Чулман бергә кушылып, өчпочмак ясаган иркен җирләрне биләгәннәр. Бер-берсе белән алар җир-су өчен дә, терлек-туар өчен дә ызгышып-талашып яшәмәгәннәр. Киресенчә, бер-берсенә кыенлык килсә, үләт, кыран килсә, шундук булышка ашыкканнар. Шуның өстенә алар йорт башы Ак ханның иң көчле, ышанычлы ыруларыннан саналганнар.

Шулай итеп, ике ыру кешеләре, кайгы, талау күрмәенчә, тыныч кына, тату гына тормыш кичергәннәр. Тик шулай да мондый тыныч, тату тормыш мәңгелек булмаган. Көннәрдән бер көнне — моннан бик күп еллар элек — язгы сулар китеп, җирләр кипкәч, көн ягыннан Итил буйлап кара яу басып килгән. Кара яуның башында явыз Кара хан торган. Аның кешеләре бик күп булган. Алар көчле булганнар. Аларның укларына, сөңге, кылычына каршы беркем, берни каршы тора алмаган. Язгы ташкын суны берничек тә тотып торып булмаган кебек, Кара ханның чирүен дә беркем, берни тоткарлый алмаган.

Соңгы орышта олуг йортның башы Ак хан кергеннәргә тоткын булган. Ханның, балаларының, туганнарының башын чабып өзгәннәр. Шулай итеп, тамырга балта чабылган, йорт-ил юкка чыккан. Исән калган ирләр, куркып-каушап, кайсы кая качып киткән. Кайберәүләр, башын саклап, Кара ханга бил бөккәннәр.

Әйе, Ак хан йорты юкка чыккан. Ирләр үлгән, ирләр качкан, Кара ханга бил бөккәннәр. Тик шулай да үтә батыр ирләр килмешәккә баш бирергә теләмәгән. Туган җирен-суын ташлап тәлим[1] кеше, төмән[2] кеше югарыга — төн ягына күчеп киткән. Шуларның беренчесе акбүреләр булган. Казаяклар, Кара ханга калан[3] түләп, Чулман-суның түбәнендә, уңъяк ярда торып калган.

Бер-берсеннән бик еракта булсалар да, акбүреләр, казаяклар элегрәк бер-берсе белән аралашып торалар

---

[1] *Тәлим* — күп.

[2] *Төмән* — бик күп.

[3] *Калан* — сугышта җиңелүче җиңүчегә түли торган еллык салым, ясак.

иде. Болгарлар белән ара өзелгәч, алар белән дә өзелде. Өченче ел инде Күрән бинең бер генә Казаяк кешесен дә күргәне юк иде. Болгарларның борын төбендә генә борынгы ата-баба җирен биләп яткан бай, атаклы Ямгырчы би әнә үзе килгән.

Ник килгән ул монда? Нинди җилләр, нинди уйтеләкләр куалаган аны монда — киң Чулманның салкын агымына каршы?

Казаяклар өчен Күрән би үз урдасында киез тирмәләр кордырды, казан асарга дип, бер көтү сарык, бер көтү җылкы бирде. Шул ук көнне ул олы кунакның үзен, кызы Тәңкәне, тагын берничә якын кешесен үзенә кунакка чакырды. Авыр, озын юлдан соң кунаклар бераз тын алдылар, ашадылар-эчтеләр дә җыйнаулашып мунчага киттеләр.

Мунча икенче көнне дә ягылды, тик монысы, юынудан бигрәк, сөйләшү-аңлашу өчен булды.

Казаяклар белән буласы зур сөйләшүгә Күрән би акбүреләр ягыннан Койтым бикәне дә алды. Сөйләшүдә тагын Утташ кам белән Майчан аксакал да, Күрән бинең өлкән угыллары Акбога белән Котан да катнашты. Ямгырчы би үзе белән бары ике генә юлдашын алып килде.

Сүзне ул бик ерактан башлады: ике ыруның борынгыда бер-берсенә кардәш булуларын, элекке иркен тормышны, Ак хан, Кара хан турындагы бабайлар сүзен — барысын да искә төшерде дә, әкренләп-әкренләп, бүгенге көнгә күчте. Акбүреләр аны тыныч кына тыңлап утырдылар.

— Син, Күрән би, базарганнарны көтәсең булыр? — диде ул кинәт болай гына, сүз арасында гына сөйләгән сыман.— Көтмә. Быел алар килмәячәк.

Акбүреләрнең колаклары үрә торды.

— Ник килмәсләр икән? — диде Күрән би. Олы кунак беравык көттерергә кирәк тапты. Аннары әкрен генә, үз-үзенә ышанып:

— Алмыш хан сезне... безне буып үтермәкче була,— диде.

Мунчада, сүнәр-сүнмәс янган учак янында, тагын да ныграк тынлык урнашты.

— Ничегрәк бумакчы була инде ул... аты корыгыры... ни... Алмыш хан? — диде Майчан аксакал бераздан, исен җыеп.

Ямгырчы би, күрәсең, кирәкле сүзен таба алмыйча, тыныч утыргандай итте дә, тагын да ерактан урамакчы булып:

— Моңарчы сез иректә яшәдегез...— диде.

— Без әле дә иректә,— диде Котан углан, аның сүзен бүлеп.

Аның шулай кирәкмәгәндә өлкәннәр сүзенә кысыла торган бер тыйнаксызлыгы бар иде.

— Иректәсен иректә дә...— диде Ямгырчы би, Котан угланга каршы килеп,— сату-алусыз, сартларсыз ирекнең кемгә кирәге бар.

Акбүреләр җиңелчә генә гөрләшеп алдылар.

— Сартларга да, Алмышка да безнең кендек бәйләнмәгән,— диде Күрән би, кисәк кенә авырта башлаган эчен тотып.— Кендек безнең үз җиребездә. Сартлар килмәсә, без үзебез барырбыз аларга!

— Коры җирдәнме? — диде Ямгырчы би, күрәләтә шикләнү белдереп.— Тау-ташлар, сазлык-баткаклар ашамы? Үз җирегездән чыгу белән, сезне кыргый башгыртлар кырып ташлаячак.

— Ташламаячак! — диде Күрән би, үртәлеп.— Элек тә булган мондый эшләр. Безнең бабайлар коры җирдән барганнар көньякка. Күп көч белән. Ник безгә бармаска?! Ул тиреләрне су төбенә салмам ла мин!

Быел астан базарганнар килмәгәнгә аның эчтән януын, тик тыштан гына мыс бирмәскә[1] тырышуын Ямгырчы би сизми калмады.

— Ышанам сүзеңә, Күрән би,— диде Ямгырчы би, өзелгән сүзен ялгап,— ата-баба йөргән юл булгач анысы... Шулай да ата-баба юлы белән генә йөреп булмый. Безгә инде, өндә аю яткан кебек, урман арасында качып-посып ятарга ярамый. Болгарлардан куркып инде туганлыкны да онытып бетердек: бер-беребезгә барышмыйбыз, килешмибез... Йортың-илең белән кырылып ятсаң да, сиңа булышка кул сузучы беркем юк.

Акбүреләр башларын иеп тыңлап утыруларында булдылар. Кая бора соң бу сүзне? Ни әйтмәкче була бу шулай да?

Ямгырчы би җентекләп акбүреләргә карап чыкты, тирән итеп тын алды да:

---

[1]*Мыс бирмәү* — сер бирмәү.

— Уем шул,— диде,— Алмыш хан көчәйгәнче, безгә берләшергә кирәк, Күрән би! Без — Ак хан токымнары! Бөтен Чулман бер булып, безгә болгарларга каршы чыгарга кирәк. Бүре безне берәм-берәм тотып ашаганчы, тупланып, безгә аның үзен ашарга кирәк! Менә шуңа килдем дә мин сезгә, туганнар, акбүреләр. Сез көчле, бай. Бөтен Чулман буенда сезнең кебек көчле ыру юк. Сез кузгалсагыз, башкалары да кузгалачак.

— Алай микән? — диде Күрән би, эчен уып.

— Алай! — диде Ямгырчы би.— Күтәр байрагыңны, күтәр кылычыңны, Күрән би! Бөтен Чулман синең кул астына җыелачак. Синең тамырларда, минем тамырларда изге бабайлар каны ага. Борынгы ханлык тамыры турыдан-туры безгә тоташа. Мин сине үземнән өстен итеп, өлкән итеп таныйм, Күрән би!

— Таныйбыз, таныйбыз! — диделәр Ямгырчы бинең юлдашлары.

— Болгарларның муенын сындырсак, Иске йортның... Чулман йортның ханы ясыйбыз сине, Күрән би! — диде Ямгырчы би.

— Ясыйбыз, ясыйбыз! — диделәр аның юлдашлары.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Акбүре һәм Казаяк ыругларының туганлыгын ничек аңлыйсыз? Ни өчен Казаяк ыругы Акбүре ыругын үзеннән өстен дип санаган?
2. Сәүдәгәрләрнең килүе таралып яшәгән ыруглар өчен нигә бик әһәмиятле?
3. Кунакларны каршы алу, кунак итү, бүләк өләшү күренешләре нинди гореф-гадәтләр турында сөйли? Казаяклар нинди максат белән килгәннәр?
4. «Илме, яумы?» дип кайсы очракта сорыйлар?

Өлкәннәр Тотышны шулай башсыз дип, явыз дип уйласалар да, үзен ул бер дә алай дип белми иде. Ул яшь иде, көчле, кыю иде. Аның бертуктаусыз каядыр йөгерәсе, чабасы килә, нидер эшлисе, кырасы-ватасы килә. Аның йөрәге беркайчан да тынгы белми шикелле. Шуңа күрә дә ул үзенең көчен, ярсу тойгыларын кая куярга белмичә интегеп бетә. Шуңа күрә дә ул, ачуы килеп, йә үзенең яшьтәшләрен тукмап ташлый, йә булмаса ат атланып чаба, уктан ата, сөңге чөя иде. Инде ул да булмаса, Чулман ярындагы текә кыяларга,

биек агач башларына менеп, кош ояларын туздыра, төрле куркыныч уеннар эзләп таба иде.

Куркып-өркеп, кыерсытылып яшәгән ананың улы да баштарак куркып-өркеп үсте. Аннан да бигрәк, ул үзенең «кырнак баласы», «кимчелекле бала» икәнлеген аңлап үсте. Аның моңа ачуы килде, күңеле кырылды. Аның үч аласы килде, үги анасы Әдидән, әледән-әле үзен кыерсыткан туганнарыннан, яшьтәшләреннән бик каты итеп үч аласы килде. Кукрәгендә, беләгендә көч барлыгын тоя башлагач, ул, бер дә юктан кабынып китәргә генә торган ярсуына, кимсенү тойгысына ирек биреп, үзен кыерсытучыларны еш кына тәпәләп тә ташлады. Кыйналган яшьтәшләренең шулай ук ачулары килде. Алар, аның юкка-барга үртәлүен күреп, тагын да ныграк үчекләделәр. Соңга таба, Тотыш углан үсә төшкәч, аның туганнарының телендә «юлбасар», «башкисәр» кебек сүзләр ешрак кабатлана башлады. Андый сүзләрне өлкәннәр дә бик теләп кабатладылар.

Өлкән хатын Әди кинәт чирләп китеп, кулыннан эш китә башлагач, Койтым бикә башын күтәрде. Бинең үзен башкаларга караганда ныграк яратканлыгын ул инде күптән белеп, тоеп килә иде. Бу аңа икеләтә көч бирде. Ул инде үзен дә, улын да юкка-барга кыерсыттырмый башлады. Киресенчә, элеккеләрнең үчен кайтарырга теләп, көндәшләрен, әкренләп-әкренләп, ул үз кулына ала барды. Әди үлмәс борын ук инде, ул өй эчендә бөтенесенә баш булып өлгергән иде.

Әйе, искәрмәстән Койтым бикә бөтенесен үз кулына алды куйды. Тик Тотышны гына ул тулысынча буйсындыра алмады. Үсмер Тотыш, җегет Тотыш, беркемгә дә баш имичә, койрык тоттырмыйча, үз көенчә яши бирде. Элеккеге ачы тойгыларга, үпкә-әрнүләргә яшьлек тилелеге, яшьлек кайнарлыгы өстәлде. Яшьтәшләр дә, өлкәннәр дә әле булса аңа чит кеше, ят кеше итебрәк карауларында булдылар. Әле булса ул моны сизеп-тоеп яшәде, әле булса үзен никтер, ни өчендер кыерсытылган итеп белде.

Атасы аңа быел беренче тапкыр ышанып эш йөкләде: кыш көне ул, этләр җигеп, кораллы йөз ир белән, илле йөк тавар белән төн кешеләренә сату-алуга барды. Атасы аны юри җибәрде, сынап карау өчен... Аннары ул аның көченә, кыюлыгына да ышанды... Шулай ук аның бу улында баш та юк түгел иде.

Кыш көнендә бер дә кояш чыкмый торган дөм караңгы төн иленнән, боз иленнән Тотыш углан биш ай дигәндә кире кайтып төште. Чаналарга таудай тире төяп, бер тиенен, бер кешесен, бер этен дә югалтмыйча, баеп, кырысланып, олыгаеп кайтып төште. Моңа тикле «шар тибүдән» башканы белмәгән «башкисәр юлбасар» угланның исән-аман кайтып керүен күреп, бөтен катауның исе китте. Ата белән ананың исә куанычы эченә сыймады. «Булдырдың, улым! — диде аңа атасы.— Синең кебек чакта атай мине дә шулай тавар белән җибәргәние. Каты буранга юлыгып, этләрне, йөкләрне югалтып, кешеләрне туздырып, ярты юлдан кире кайттым. Болай булгач, атаңны уздырдың, улым».

Атасыннан мондый мактау сүзләре ишетеп, Тотыш угланның күзләренә яшьләр килде. Туганнан бирле бу аның, атасыннан гына түгел, анасыннан кала барлык өлкәннәрдән ишеткән беренче мактау сүзе булгандыр. Ата белән угыл арасындагы салкынлык, кырыслык шул көннән соң әйтерсең мәңге юкка чыкты. Шул көннән соң Тотыш углан атасына Тәңрегә табынган кебек табына башлады.

Ул әйтерсең кинәт үсеп китте. Күңеле белән, уйтеләкләре белән үсеп китте. Ул үзен, өлкәннәргә тиң итеп, алар эшли алган барлык эшләрне эшләрдәй чын ир итеп тоя башлады. Атасы белән анасының киләсе көзгә Биар ханының кызына өйләндерергә җыенуларын белгәч, аның чын-чынлап түбәсе күккә тиде. Тиздән, тиздән ул өйле, хатынлы ир кеше булачак! Тиздән, тиздән ул да, кеше арасына кереп, үзенең сүзен әйтә алачак — аның белән санлаша башлаячаклар! Барлык ирләр кебек, ул да киңәшләрдә, корылтайда катнаша алачак, кулына корал тотып, сакта-каравылда торачак.

Беренче тапкыр бүген күк күкрәде, яшен яшьнәде. Урамнардагы, ишегалларындагы, басулардагы барлык кешеләр, болыннардагы көтүчеләр, урманнардагы агач кисүчеләр, яр буендагы балыкчылар, каекчылар — өлкәннәр, бала-чагалар, тазалар, авырулар — барысы да, барысы да, күк күкрәвен ишетеп, җиргә егылдылар. Көтүдәге атлар, сыер-сарыклар ашауларыннан туктап калды, этләр, чинап, кешеләргә елыштылар.

Каяндыр көн яктан — Чулманның күкселләнеп яткан иксез-чиксез киңлеге өстеннән, ямь-яшел болыннар, куе урманнар өстеннән башланган яшенле күкрәү, дөбер-шатыр килеп, ачулы мыгырданып, Кызыл Яр катау турысына килеп җитте. Куар оган[1], утлы кылычы белән селтәнеп, биек яр башындагы чыршылыкка сыенган ниндидер албастыны сугып үтерде дә ашыгып төн ягына таба китеп барды. Язгы сулар белән дә агып бетмәгән чир-чорлар, айналар, албастылар — барысы да, Куар оганның бөек чирүеннән куркып, чит җирләргә, чит илләргә юл тоттылар.

Яшенле күкрәү узып китү белән, кешеләр сикерешеп җирдән тордылар, бер-берсен котларга, куанышып биергә, такмакларга тотындылар. Күп тә үтмәде, томалап яңгыр килеп җитте. Яңгыр шактый озак яуды. Ачык җирдә калган кешеләр манма су булдылар. Тирмәдәгеләр, каралты-курадагылар исә яңгыр астына үзләре чыгып бастылар. Беренче язгы яңгырның игеннәргә, чирәмнәргә генә түгел, барлык терекленкә — кешеләргә, терлек-туарга, киекләргә дә ассуы бар иде.

Шулай итеп, Акбүре иленә җәй килде, җылы килде. Яңгыр туктагач та, кешеләр, куанышып, тирмәләргә ашыктылар, учакларын тергезеп җибәрделәр. Чыр-чу килеп, урамда балалар чабышып йөрде. Әле анда, әле монда көлгән тавышлар ишетелде. Кичкә таба күңел ачу башланып китте.

Бөтен ыру кешеләре онытылып беренче яңгыр туен иткәндә, Күрән би урдасында ашыгып юлга җыендылар.

Ерак юлга чыгу алдыннан яшенле яңгыр явып узуны Күрән би изгегә юрады. Караңгы төшү белән, ул каекларга соңгы кирәк-яракларны төятте дә Талкысыкка Тотыш углан янына чыкты. Ул аңа ак юл теләде, тагын үзенең киңәшләрен, теләкләрен кабатлады, аны күкрәгенә кысып, озак кына ычкындырмыйча торды.

— Иртәгә таң ату белән кузгалыгыз, углым,— диде Күрән би, күз яшьләрен сөртеп.— Исән-сау әйләнеп кайтсаң, көзгә башлы-күзле итәрмен. Кайгырма — Тәңкә синеке булыр.

---

[1] *Куар оган* — төрки халыкларда яшен алласы.

— Атай, күрерсең менә!.. Моннан соң беркайчан да... Ышан, атам, миннән дә тугрылыклы улың булмас! — диде Тотыш, дулкынланып.

— Ышанам, улым,— диде ата кеше.— Күңелем тыныч. Мин сиңа ышанам, улым.

Иртән аны ниндидер дөбердек уятты. Шыбыр тиргә баткан килеш ул сикереп торды, кылычына тотынды, аннары, калтыранып, ишек артындагы дөбердеккә колак сала башлады. Кем булыр бу? Нәрсә кирәк бу авыкта[1]? Кояш әле чыкмаган, әле бик иртә булырга тиеш.

— Кем бар анда? Нәрсә кирәк? — дип кычкырды ул, күпмедер тыңлап, көтеп торганнан соң, ишеккә якынаеп.

— Бу мин, каравыл Чынташ! — диде тыштагы ир кеше.

— Ни булды? Ник дөбердәтәсең? — диде би, ишек биген ычкындырып.

— Улакчы[2] килде, улакчы! — диде Чынташ.— Ашыгыч битек[3] китергән. Менә.

Би каравылчы кулыннан битекне тартып алды да шартлатып ишеген япты, биген яңадан элдерде. Битекне ул ачу белән идәнгә атып ормачы булды. Каравылчының «ашыгыч» дигән сүзен исенә төшергәч, бу уеннан кире кайтты. Төнлек янына килде дә, вак-вак пыяла кисәкләре аша үткән таң яктысында ал тамга сугылган, җеп белән кысып бәйләнгән күн тышлы битекне кулында әйләндергәләп карады. Аннары җепне теше белән өзде, аксыл каен тузына төрек иҗекләре[4] белән язылган түбәндәге сүзләрне укыды:

«Атай! Алмыш хан килә. Төшкә монда булыр. Үзән аша күпер салалар. Көче күп. Мин Чулманга чигенәм. Шуннан кайтырмын.

Алай башы Күзәмеш улан».

Күрән бинең чәчләре үрә торды. Күрән бинең куллары, аяклары калтыранды. Суларга тын җитмәде,

---

[1] *Авык* — вакыт. Хәзерге телдә «беравык» формасында сакланып калган.

[2] *Улакчы* — ашыгыч хәбәр китерүче.

[3] *Битек* — хат, язу.

[4] *Иҗек* — хәреф.

уйларга уй җитмәде. Аның тиз генә өстен-башын киенеп, коралларын алып каядыр чыгасы да килде, хатыннарын, балаларын, ырудашларын булышка чакырып, бөтен катауга, бөтен җир-суына сөрән дә саласы килде. Кулына утлы куздай пешерә торган битекне тотып, ул әрле-бирле йөренде, тешләрен шыгырдатты, башындагы чәченә ябышты, ыңгырашып-ыңгырашып алды. Идәнгә егылды да ике кулын күккә сузып, күз яшьләрен түгеп ялвара башлады.

— Тәңрем! Ата-баба ияләре! Көч бирегез, кыюлык бирегез! Яу килә, яу! — диде.

Яу килә, яу! Алмыш хан килә! Коры җирдән, Чулманның уң ягыннан, урман-сазлар аша, елгалар, чокырлар аша чиру килә!

Булмас ла! Туктале, ялган түгел микән бу? Берәрсенең коткысы түгел микән? Котан өйдә юк, Акбога өйдә юк. Күп ирләр Тотыш белән ерак юлга чыгарга тиеш. Катауда җитәрлек сакчылар да юк. Нинди яу ди әле ул мондый чакта!

Туктале, тукта... нәрсә бу? Шулай итеп, Акбүренең көне беттемени? Шулай итеп, Утташ камның каргышлары барып иреште микәнни?

О Тәңрем! Изге ияләр! Кичерегез... коткарыгыз Акбүрене бу кыраннан, бу талаудан!

Баштанаяк коралланган, көр-таза атларда нык утырган ул ят кешеләр, ягы кешеләр ашыкмыйча гына, иркен, тыныч кына киләләр иде. Алар күп иде, бик күп иде. Кечерәк төркем-төркем булып, җир астыннан чыккан сыман, сырт итәгеннән менә тордылар, тигез җиргә җәелә тордылар. Бераздан алар богдай чәчелгән җир өстен бөтенләй каплап алдылар. Шул ук мәлдә, тыелгысыз бер көч булып, тигез җиргә җәелеп аккан язгы ташкын булып, катауга таба басып килделәр. Тигез, ачык ялан күз алдында атлар, кешеләр белән тулды. Тигез, ачык күркәм яланда — катаудагы меңләгән күзләр алдында — әйтерсең тиз арада кара урман калкып чыкты, әйтерсең берничек тә үтеп чыгып булмастай тау-таш калкып чыкты!

Акбүреләр, койма өстендәге калку урыннардан, ук атар өчен уелган уемнардан, каргу, сырган башларыннан, өй түбәләреннән, багана башларыннан аларның шулай бөтен җирне иңләп, ябырылып килүләрен тын да алмый күзәтеп тордылар. Меңләгән

тимер, җиз, көмеш коралларның, киемнәрнең кояшта ялт-йолт килүеннән кешеләрнең күзләре чагылды; тимер чыңлаган, тояклар дөпелдәгән, атлар кешнәгән тавышлардан колаклар тонды. Бертуктаусыз кыймылдаган, ашкынган, тыелгысыз авырлыкның шаушуына бөтен җир өсте дер селкенеп торды.

Беркайчан бу тикле көч, бу тикле яу күрмәгән акбүреләр куркуларыннан өнсез калдылар. Озакламый менә шул санаусыз ягы белән очрашырга тиеш булган батыр ирләрнең маңгайларына салкын тирләр бәреп чыкты, аркаларыннан табан очларына куркыныч кымырҗык йөгерде.

Байракларын югары күтәреп иң алдан килгән ирләр төркеме, катауга бер ук[1] чамасы килеп җитмичә, сөрелмәгән, чәчелмәгән тигез җирдә туктап калдылар. Арттан килүчеләр дә, алдагыларга якынлашып, шулай ук туктый башладылар. Акбүре кешеләренә аермачык булып аларның йөзләре, киемнәре күренде: аларның янау, көлү сүзләре ишетелде.

Юлның ике ягына да тезелгән ир-атлар кинәт кыймылдап куйдылар, як-якка тайпылгандай иттеләр. Юлда, тар аралыкта яхшы акбүз атка атланган бер кеше күренде. Бу кеше йөзләгән, меңләгән ир-атлар арасында таудай калкып, ерактан ук күзгә ташланып тора иде. Ул бик таза, көчле кеше күренә иде. Башындагы алпагы да, күбәсе дә, калканы да аның көмештән, алтыннан ясалган иде. Озын муенлы, биек, таза атының йөгәне, ияре, өзәңгеләре шулай ук алтын-көмеш белән бизәлгән иде. Күбә өстеннән ул ал төстәге бөркәнчек ябынган иде. Кара сакал-мыегы аның кыска итеп, түгәрәкләп киселгән иде. Аның болай да киң, түгәрәк бите шунлыктан тагын да түгәрәк булып, табактай зур булып күренә иде.

Эре сөякле, бай киемле бу ир-ат Алмыш хан иде.

Ул, атын әкрен генә атлатып, бераз юл буйлап килде дә байраклы төркемнән алдарак туктап калды. Ул арада аның артында, юлда албалап[2] берничә ат җигелгән арба күренде. Арбаны ачык җиргә туктаттылар да, берничә кеше, ашыгып, аннан төргәкләр,

---

[1] *Бер ук* — атылган бер ук ераклыгы.

[2] *Албалап җигү* — атларны бер-бер артлы тезеп җигү.

баулар, казыклар ала башладылар. Тиз арада хан тирмәсе — җаваҗ корылды. Җаваҗның акбүреләргә караган ягы ачык калдырылды.

Менә хан атыннан төште, катау ягына карангалап, җаваҗга керде, түргә[1] утырды. Ханның якыннары шулай ук атларыннан төштеләр, җаваҗ тирәсенә җыелдылар.

Яшь, тук көрән атка атланган бер яшь ир байракчылар төркеменнән аерылды да катауга таба чабып китте. Атта чабып барган уңайга ул җәясенә ук утыртты. «Һай» дип бер кычкырды да акбүреләр ягына атып җибәрде. Төз атылган ук Басу-капка янындагы каравыл өенең ишек башына килеп кадалды.

Сакчылардан берсе, сикереп, укны тартып алды; алды да йөгереп аны Күрән бигә илтеп бирде. Укка каен тузы бәйләнгән, тузга шундый сүзләр язылган иде:

«Мин, Болгар йортның башы Алмыш хан, синең җиреңә килеп урда кордым. Атам Шелкә үлгәч, син, минем колым Күрән би, өч җыл миңа калан түләмәдең. Шуны алырга килдем. Өч көндә бирмәсәң, катавыңны җир итәм, ыруыңны юк итәм. Ил белән бирәсеңме, яу беләнме?»

Нинди күп алар шулай да! Шул тикле ерак җирдән юллар ярып, күперләр салып килгән бу чирүнең, күрәсең, балтачылары да күптер. Ур аша күпер салып, катауның капкасын җимереп, яндырып керү аларга берни тормас. Шулай булгач... катавың белән, ыруың белән бергә кырылуга караганда, сораганын биреп котылу яхшырак булмасмы?

Соңгы көннәрдә бик нык йончыган, тиешенчә йокламау аркасында йөзе агарынып калган би аксакалларга, кораллы ирләргә күтәрелеп карады.

— Нишлибез? — диде ул, карлыккан тавыш белән.

Башкалар да үзләренә шул ук сорауны бирделәр. Тик беркем дә турысын гына ярып сала алмады. Бармакның кайсын тешләсәң дә авырта иде, ничек кенә боргалансаң да, башыңа таякның юан башы төшәчәк иде. Тынлык шактый озакка сузылды. Беренче булып Утташ кам авыз ачты.

— Туганнар, ырудашлар! — диде ул, кычкырып.—

---

[1] *Түр* — м о н д а: тәхет мәгънәсендә килә.

Мин сезгә әйтә килдем. Мин сиңа да әйттем, би! Колак салмадыгыз. Инде менә күреп торасыз: Тәңренең каргышы, авыр кылыч булып, баш өстебездә уйнап тора. Көн-төн эшләнә торган языкларыбыз өчен килгән талау бу! Мондый чакта, куркыныч килгәндә... бөтен ыруның язмышы кыл өстендә торганда... безгә йолык бирергә кирәк! Башкача котылу юк!

— Йолык! Йолык! — дип кычкырдылар Утташ кам янындагы кешеләр.

Тагын авыр тынлык урнашты. Тимер кораллар кулларны, иңбашларны асып төште, тимер киемнәр башларны, күкрәкләрне кысты. Күрән би изүен чишеп җибәрде, авыр кашлары астына яшеренгән авыр күз карашын кешеләргә йөртеп чыкты.

— Ырудашларым! — диде ул, эчке бер тетрәну белән.— Капка төбенә яу килде. Безнең борын төбебездә генә, безнең изге җиребездә ул әнә урда корды. Җирем-суым өчен, ыруым өчен мин туган улымны гына түгел, үз-үземне дә кызганмыйм. Теләсәгез нишләтегез — улым да, үзем дә сезнең карамакта. Телисез икән — улымны, телисез икән — үземне... хатыннарымны, башка угылларымны изге эш өчен йолык кылыгыз!

— Кылырбыз да шул! — дип чәрелдәде Утташ кам, янап, куанып.

— Ашыкма, кам баба,— диде аңа каршы Күрән би,— минем сиңа бер генә соравым бар. Син әйт безгә: йолыкка кеше биреп кенә, Алмыш ханнан котыла алабызмы без?

— Йо-ок! — диделәр акбүреләр беравыздан.

— ...Без йолыкка кеше биргән өчен генә Алмыш хан үзенә тиешле каланнан баш тартырмы? — диде тагын да би.

— Йо-ок! — диделәр акбүреләр, язгы Чулман сыман шаулап.

— Шулай булгач,— диде Күрән би, күтәренкелек белән,— йолык биру-бирмәү турында сөйләшкәнче, калан түләү-түләмәү турында сөйләшсәк, яхшырак булмасмы?

— Шула-ай! — диделәр кораллы ирләр, катауны яңгыратып.

— Алайса, әйтегез: утыз мең кеш түлибезме, ягы белән орышабызмы? — диде ыру башы.

Кешеләр тагын тынып калдылар.

— Ыхым, ыхым,— диде Майчан аксакал, яңадан таягын шакылдатып.— Оланнар, ырудашлар! Утыз мең кеш безне аяктан җыкмас, ни... аты коргыры... кем... Алмыш ханның кылычы — җыгар. Эт күңеле бер сөяк. Алсын да китсен!

— Ах, бер генә сөяк булсачы! — диде Күрән би, ачынып.

Майчан аксакал сүзләрен башкалар да яклады.

— Түләргә кирәк!

— Алсын да китсен! — диештеләр кешеләр, шау-гөр килеп.

— Юк, түләмибез! — диде шул чакны кемдер, шау-шуны күмеп.

Кешеләр тавыш килгән якка — койма өстенә күтәрелеп карадылар. Сакчылардан, кораллы ирләрдән бер читтәрәк анда баштанаяк коралланган яшь бер углан басып тора иде.

— Тотыш!

— Югалган Тотыш! — диделәр акбүреләр.

— Сөйлә, углан! — диде Майчан аксакал, Тотыш ягына таягын изәп, тынлык урнашкач.

— Сөйлә, сөйлә! — диештеләр башкалар да.

— Атам, анам! Олуг аксакал Майчан баба! Ырудашлар, ил агалары! Тыңлагыз, сезгә сүзем бар! — дип кычкырды Тотыш, көр, яңгыравык тавыш белән.— Мин әле ир түгел, шулай да сез миңа сүз бирдегез. Мин әле ир түгел, шулай да мин кулыма корал алдым, кичерегез мине, ырудашлар! Ыруыма куркыныч килүен ишетеп, мин, белексез углан, сезнең янга ашыгып кайттым. Элекке ярамаган эшләремнең барысы өчен кичерегез мине, ырудашлар!

— Кичерәбез, олан,— диде Майчан аксакал.

— Кичерәбез, кичерәбез, сөйлә! — диделәр кораллы ирләр.

— Менә шул...— диде Тотыш, яңадан сүз башламакчы булып. Тик, куанычтан, дулкынланудан, күрәсең, кирәкле сүзен таба алмыйча, беравык тотлыгып торгандай итте.— Күрәсезме, ырудашлар, безнең көчебез җитәрлек түгел,— дип кычкырды ул, бераздан үзенең аяк астында тынып калган меңләгән кешеләргә карап.— Котан белән Акбога кайтып җитсә дә, күршеләрдән булышка алайлар килсә дә, безнең

барыбер көчебез артмаячак. Безнең күбебезнең кулында уктан-җәядән башка берни юк. Киемнәр шулай ук таза түгел. Карагыз болгарларга — күбәсез ирне күрерсезме, тимер калкансыз, тимер алпаксыз ирне күрерсезме? Алар нинди яхшы өйрәтелгән... шаушу юк, ыгы-зыгы юк — мең кешесе бер кешедәй! Көч алар ягында, ырудашлар. Тик шулай да мин, утыз мең кеш түгел, ябагай бер тиен дә бирмәскә димен!

Аның бу сүзләре дөрләп янган учакка бер чиләк су сипкәндәй булды. Аста, кешеләр арасында шаркылдап көлгән тавышлар ишетелде.

— Атам, анам! Ырудашлар, туганнарым! — диде Тотыш углан, көлгән тавышларга колак салмыйча.— Моңарчы сез минем бер генә теләгемне дә үтәмәдегез. Яшьлегем, белексезлегем аркасында мин сезгә, ыруга күп кайгы салдым. Инде сезгә бер сүзем бар... бер теләгем бар: тыңлагыз! Мин Алмыш ханның иң көчле алыбы белән очрашырга телим. Мин берүзем ыру өчен ягыдан үч алырга телим! Җиңсәм, болгарлар буш кул белән китәр, җиңеләм икән — калан түләрсез!

Сораулар һәм биремнәр.

1. Тотышның «юлбасар», «башкисәр» булып үсүенең сәбәпләрен, егетнең эчке кичерешләрен сөйләгез. Ни өчен ул кешеләрдән читләшә? Кайда, ничек үзенә юаныч таба, кая омтыла?
2. Нинди вакыйгадан соң Күрән би Тотышка ышана, аның белән горурлана башлый?
3. Кешеләрнең табигатькә табынулары аларның нинди сыйфатлары турында сөйли? Мәсәлән, аларның яшенле яңгырдан куркулары һәм сөенүләре сезгә танышмы, аңлашыламы?
4. Алмыш ханның яу белән килүе көтелмәгән хәлме? Күрән бинең кичерешләрен сөйләгез. Бу урында хикәяләү кем исеменнән алып барыла?
5. Дошман явының таләбенә акбүреләр нинди җавап бирәләр? Кем нәрсә тәкъдим итә?

Акбүреләр башта аңламыйчарак тордылар. Аңлап алдылар да кисәк кенә кузгалышып куйдылар, җиңелчә шауларга, гөрелдәргә тотындылар. Тирә-яктан:

— Яшә, Тотыш! Бай бул, Тотыш!

— Коткар ыруны, коткар катауны! — дигән сүзләр ишетелде.

Икеләнгән, каушап калган акбүреләр күңелендә Тотышның сүзләре ышаныч чаткылары кабызып җибәрде. Башлар югары күтәрелде, коралларга куллар ныграк тотынды. Әнә ул Тотыш углан, нинди таза, нинди көчле! Кем белә, җиңеп куйса, калан да түләнмәс, кешеләр дә исән калыр. Җиңелә икән инде, алай үзе атлыгып торгач, әйдә, урыны оҗмахта булыр.

Күпчелек шулай дип уйлады. Тик ата кеше генә икенче төрлерәк уйлады. Үзенең углын ул беренче тапкыр күргәндәй булды. Ул аның көче-батырлыгы белән дә, күңеле белән дә үз-үзеннән — үз атасыннан гына түгел, мондагы барлык кешеләрдән, барлык ырудашларыннан өстен икәнлеген аңлады. Ул аны — кичәге башсыз углын — үзенең төп яклаучысы итеп тойды. Димәк, ата кешенең күңеле тое[1] булган! Димәк, аңа ышаныч баглап ул ялгышмаган! Бинең күзләренә яшьләр килде.

— Углым! — диде ул, Тотышны кочагына алып.— Бүгеннән башлап син — ир! Әй ырудашлар, ишетәсезме, Тотыш углым минем ир булды! Мин аның теләгенә каршы килмим, мин аңа ак юл телим, җиңү телим. Орыш, углым, ягы белән, күрсәт ирлегеңне!

— Орыш ягы белән!

— Ак юл сиңа, Тотыш углан! — диделәр аксакаллар.

Күрән би, углының теләген белдереп, болгарларга ук атарга кушты.

Болгарлар укны алдылар, битекне укыдылар да ат кешнәгән кебек шаркылдап көләргә тотындылар.

— Ничек көләләр бездән! — диде Тотыш, иреннәрен чәйнәп.

Күп тә үтмәде, болгарлардан икенче ук килеп төште. Каен тузына ике генә сүз язылган иде. Бу «бергә — өч» дигән сүзләр иде. Акбүреләрнең йөзе каралай янып чыкты. Бергә — өч! Димәк, Тотыш бер-бер артлы өч алыпны җиңәргә тиеш, бары шул чагында гына ул җиңүче булып саналачак!

Яшь егетнең нык кысылган иреннәре калтыранып китте. Шулай да ул куркуын тиз арада җиңә алды. Су астында озак чумып торганнан соң, өскә калкып чыккан кеше сыман, ул, озын итеп, күп итеп, бер тын алды да:

---

[1] *Тое* — сизгер, алдан сизүчән.

— Мин орышам! — диде.— Мин сүземнән кайтмыйм.
— Юк! — диде Күрән би, болгарларның битеген урталай ертып.— Бу тигезлек түгел. Бу бернинди йолага да, түрәгә дә туры килми. Алар бездән юри көләләр.
— Мин барыбер орышам, атай,— диде Тотыш, кабатлап.— Мин баш тартсам, алар бездән тагын да ныграк көләчәкләр.

Аның шулай дип әйтүе булды, болгарлар, күрәсең, акбүреләрнең икеләнүен күреп, тагын да ныграк шаркылдап көләргә тотындылар.

— Курыкты!
— Астына җибәрде!
— Алыбыгыз кайда? Чыксын орышка!
— Сукыр сычканнар, сезгәме соң арысланнар белән алышырга! — дигән сүзләр ишетелде.

Койма өстендәге кешеләр, ягының көлүенә үртәлеп, эчләре пошып, тын гына басып тордылар. Акбүреләр аптырабрак калган бермәлдә койма өстенә Койтым бикә килеп менде. Ул аста кешеләр арасында тотканланып калган иде. Инде ул түзмәде, кешеләрне ырып-җырып, туры коймага якын килде, каяндыр ирләр алып килгән күчерелмәле баскыч буенча югары менде.

— Углым! — диде ул, йөрәк түреннән чыккан бер өн белән.— Мин барысын да күреп, ишетеп тордым. Углым, күземнең яругы... бавыр итем, йөрәк маем! Бар, орыш! Мин сиңа изге теләктә булырмын. Бөтен ырудашларың изге теләктә булыр. Күп көттем мин шушы көн килүен. Үч ал ерак бабаң өчен, анаң өчен, ыруларың өчен, углым! Әнә явыз ягы безнең изге җирдә!

Койтым бикә алтын-көмешләр, тимерләр-җизләр елкылдаган, ят байраклар җилфердәгән якка төртеп күрсәтте. Аның сүзләреннән Тотыш кайбер нәрсәләрне аңлап та җитмәде. Ул бары бер генә нәрсәне аңлады — әйе, ул орышырга тиеш! Анасының ялкынлы сүзләре аның күкрәгеи бетмәс-төкәнмәс көч белән, куаныч белән тутырды, болгарларның икенче угыннан соң, атасының каршы килүеннән соң күңелендә баш күтәрә язган икеләнү, каушау тойгысы кул белән алгандай юкка чыкты.

— Бергә — өч булуына исең китмәсен, углым,— диде Койтым бикә, аның уйларын сизенгәндәй.— Өчкә

түгел, өч унга, өч йөзгә каршы чыгудан да курыкмый торган батыр бул, углым! Синең ерак бабаң Кайду алып шундый батыр булды, синең бик еракта калган ерак туганнарың барысы да шундый булдылар. Анаңның туган ыруын туздыручыдан, атаңның туган җирен басучыдан канлы үч ал, углым! Теләгем шул: куркуыңны салып тапта!

— Мин курыкмыйм, анам!— диде Тотыш, елмаеп.

— Куркуын курыкмыйсыңдыр да,— диде Күрән би, үртәлеп.— Бу — тигезлек түгел. Бу — бездән көлү!

— Син ни телисең, би?! — диде Койтым бикә, иренә эндәшеп.— Ягыдан син кызгану, тигезлек, изгелек көтәсеңмени?! Ул сине таларга, үтерергә, яндырырга килгән, түбәнсенеп шуңа үпкәләргә уйлыйсыңмы?! Күтәр башыңны, күзеңне ач, Күрән би!

— Баш та каткан инде,— диде би, мыгырданып.— Әле өч көн бар, ашыкмыйк, уйлашыйк...

— Уйлашыр чак түгел — илне ягы баскан! — диде Койтым бикә, кискен генә.— Углыңны җибәрмәсәң, үзем чыгам Алмыш ханга каршы. Тик берне үтерсәм, өчкә саналырга тиеш. Җибәр укны Алмыш ягына!

Күрән би авыр башын күтәрде, көрсенеп: «Язмыш... каргыш»,— дип мыгырданды да битекчегә карап алды, «Мин орышам. Тотыш»,— дип язарга кушты.

Койма тышына тагын ук очты.

Тотышка киенергә атасы булышты. Ул аңа үзенең авыр күбәсен, нык, авыр калканын бирергә теләде. Тотыш атасының бернәрсәсен дә алмады. Ул җиңелчә генә киенергә булды. Өстенә ул иң элек юка, җиңел күлмәк, аның өстеннән кыска тунын киде. Муенына нечкә каешка тагылган кечкенә бүре башы — ыру кумарткысын[1] такты. Кыска тунның күкрәк турысына юка тимер кисәкләре тегелгән иде. Аның өс киемендәге тимер бары шул гына иде. Аннары баш киеме — алпагы тимердән иде. Алпак башыннан төшеп китмәсен өчен, ул ияк астыннан сакалдырыгын бәйләп куйды да кысып билен буды, кылычын такты. Шуннан соң ул бер кулына — калкан, икенче кулына сөңгесен алды.

---

[1] *Кумарткы* — төрле бәла-казадан сакларга тиеш булган һәм үз янында йөртелә торган табыну әйбере, талисман.

Атка атланыр алдыннан ул, йөгереп, койма өстенә менде, беренче тапкыр күргәндәй, як-ягына каранды; еракта көмештәй җемелдәп яткан Чулманга, татлы исләр аңкытып, ап-ак чәчәккә күмелеп утырган шомыртларга; катау артындагы, чокырлар артындагы зәңгәрсу калкулыкларга, урманнарга күз йөртеп чыкты. Күңеленнән ул үзенең туган җире белән, үзенең барлык ыруы белән — атасы-анасы, туганнары белән саубуллашты. Ул үзенең ерактагы ише белән — Ямгырчы би кызы Тәңкә белән саубуллашты. Ул үзенең үткән бала чагы белән, көн дә күреп өйрәнгән агач өйләр, тар урамнар, җилдә-яңгырда караеп беткән коймалар, капкалар белән, кырыс ирләр белән, зәңгәр төтеннәр белән саубуллашты.

Көн кояшлы иде, җылы иде. Кайдадыр якында гына чыр-чыр килеп кошлар очып йөри, баш өстендә, көмеш шөлдер булып, тургай чыңлый иде. Тиздән менә орыш буласына, кемнәрнеңдер озакламый шушы җылыдан, киңлек, иркенлектән аерылачагына әз генә дә ышанасы килми иде. Әле кичә генә бала-чага уйнап йөргән болында, яшел богдай чирәме җәелеп яткан киң яланда күңелләрне тетрәндереп шаулашкан ят, чит, ягы кешеләр барлыгына бөтенләй ышанасы килми иде.

Тотыш юри ул якка карамаска тырышты. Туган җирен күздән кичергәч, ул койма өстенә тезләнде дә ак болытлар күпереп йөзгән биек, зәңгәр күккә карады.

— Тәңрем! Мин, Акбүренең Тотыш атлы углан, алыплар орышына чыгам. Миңа көч бир, кыюлык, җиңеллек бир, Тәңрем! — диде ул, ялварып. — Явыз ягы, кергән болгарларның башы киселеп минем аяк астына төшсен. Сөңгем очлырак, кылычым үткенрәк булсын. Янымда сакчым бул, изге булышчым бул, олуг Тәңрем!

Шуннан соң ул атасын, анасын кочты, туганнарын кочты. Аңа Йолдыз-кашканың туганы Ташбәкәлне җитәкләп китерделәр. Йолдыз-кашка кебек, Ташбәкәл дә бөтен ыруда иң яхшы, иң сылу атлардан санала иде, тик ул бераз кечерәк кенә. Шулай да ул көчле, чыдам, җитез. Кешечә сөйләшергә аның теле генә юк. Тотышны ул тавышыннан түгел, күз карашыннан да аңлый иде.

Алыплар орышына бар нәрсә җитеш икәнлекне белдереп, катау ягында быргы уйнадылар. Болгарлар да, шуны ук аңлатып, кару[1] бирделәр. Шуннан соң ике якта да, йөрәкләрне җилкендереп, берьюлы унлап-унбишләп дөңгер кагарга тотындылар.

Менә ашыкмыйча гына ур өстенә күпер төшә башлады, капкалар ачылды, тешкә тиеп чыгырлар шыгырдады, тимер күгәннәр ыңгырашты. Тотыш Ташбәкәлнең тезгенен бушайтып җибәрде, күләгәле капка авызына чабып керде дә, кояшлы ачык җиргә — яланга ыргылды.

Ул туп-туры җаваҗга таба карап чапты. Иң элек ул үзе белән орышачак алыпны күрмәкче булды, тик каршыда урмандай калкып торган ир-атлардан башка, аллы-зәңгәрле-сарылы ефәк җаваждан башка бүтән берни күрмәде. Бер җиргә тупланган шул тикле күп кешеләрнең тере, усал, кызыксынучан күз карашларын тою аны чак-чак кына каушаткандай булды. Шулай да бу тиз арада юкка чыкты. Ул анасы Койтым бикәнең өндәү сүзләрен исенә төшерде. Ул әйтерсең кинәт кенә шушы башлар, сөңгеләр, байраклар өстеннән югары күтәрелде; күтәрелде дә аларга — үзләренең җирен таптап, ия булып, күкрәк киереп торган килмешәкләргә — корычтай нык, салкын бер күз карашы ташлап алды. Бу мәлдә ул үзен барлык алыплардан, барлык сөңгеләрдән, кылычлардан көчле итеп, бөек итеп тойды.

Шул чакта ул, сөңгеләр, алпаклар, калканнар урманыннан аерылып, үзенә таба якынлашып килгән болгар алыбын күреп алды. Болгарларның бу иң атаклы батырлары Чәкән алпагыт[2] иде.

Чәкән алпагыт богадай[3] таза, арыслaндай көчле иде. Баштанаяк ул тимергә төренгән, шуңа күрә аның сөңге, кылыч үтәрдәй бер генә йомшак җире дә юктыр кебек. Үзенең таза, көр кола атында ул таштан уеп ясалган баганадай нык утыра; киң битле, зур башлы. Күп орышларда бите-башы яраланып, ямьсезләнеп беткән бу усал, кансыз, коточкыч алпагыт турында, кылыч белән бер сукса, тимер киемле кешене урталай ярып

---

[1] *Кару* — җавап.

[2] *Алпагыт* — батыр, алып, көрәшче.

[3] *Бога* — үгез.

төшерә, дип сөйлиләр. Аның белән орышкан бер генә батырның да әле исән калганы юк, дигән сүзләр дә йөри.

Чәкән алпагыт янында Тотыш углан бала-чага кебек кенә күренә. Буйга да ул аннан кайтышрак, киеме дә, кораллары да батырларныкына охшамаган кебек. Болгарлар аның йөзендәге кырыслыгын да, күзләрендәге очкынлы ярсуны да, киеме аша бүртеп торган беләк тычканнарын да күрә алмадылар. Алар бары аның яшь, җиңел... өтәләнгән булуын гына күрделәр. Алар аннан эчләрен тотып көләргә тотындылар. Чәкән алпагыт, гыжылдавык бер ямьсез тавыш белән:

— Әй, син, Камырбатыр! Бар, кайтып кит. Синнән өлкәнрәге килсен! — дип кычкырды.

Тотыш эндәшмәде. Аның бары иреннәре генә ныграк кысылды да, куллары гына чытырдатып коралларын тотты. Күк күкрәгәндәй булып яңгыраган көлү тавышларын, йөзенә бәреп әйтелгән мыскыл сүзләрен ул әйтерсең ишетмәде дә. Чиксез ачу, үч тойгысы аңа көч бирде, корычтай ныклык бирде.

«Анаңның туган ыруын туздыручыдан, атаңның туган җирен басучыдан канлы үч ал, улым! Теләгем шул: куркуыңны салып тапта!» — диде Койтым бикә, аның колак төбендә пышылдап, изге орышка өндәп.

Алар шулай икесе бер-берсенә капма-каршы чабып килделәр. Атлар, арт аякларына басып, усал итеп кешнәп җибәрделәр. Чәкән алпагыт, сары тешләрен ыржайтып, җиңел генә, шаярткан кебек кенә сөңгесе белән төртеп алды. Сөңге башы шыгырдатып Тотышның тимер калканын тишеп чыкты. Егет агарынып китте. Тиз генә ул калканын тартып алды, Ташбәкәлнең корсагына төртте дә читкә ташланды. Чәкән алпагытның артына чыгып, ул аны узып китте. Шуннан соң кырт кына борылды, сөңге ыргытмакчы булды, тик каршыда гына болгар алыбының ямьсез, коточкыч йөзен күреп каушап калды.

Ике батыр тагын да беравык бер-берсенә карашып торгандай иттеләр. Чәкән алпагыт, «сәләмә» батырны бер селтәнүгә сөңге очына элә алмавына ачуы килеп, күрәсең, монысында чынлабрак орды. Ул бик тиз, бик туры төбәде. Ул бик каты бәрде. Яшь егет шулай да аның сөңгесеннән өлгеррәк булып чыкты. Күкрәгенә очлы тимер килеп керде дигәндә генә ул, ияреннән

шуышып, уңга ташланды. Башы белән аяк астына егылып төшмәс өчен, сөңге сабын җиргә төртеп алды да, җилдәй выжлап, тагын алпагытны узып китте. Бераз җир чабып баргач, ул җиңел генә иyренә утырды, өзәңгеләргә ныгытып басты, борылды да аткан уктай Чәкән алпагытка таба томырылды.

Аның бу күз иярмәс җитезлеген ике якта да күреп алдылар. Акбүреләр куанып гүелдәргә тотынды.

Икенче тапкыр оятка калу Чәкән алпагытны чын-чынлап котыртып җибәрде. Иреннән калка төшеп, атының башы өстеннән үрелеп, ул, кыя таудан ычкынып киткән иләмсез зур таш кисәге сыман, Тотыш өстенә килә башлады. Күзен кан баскан усал үгез кебек дулап, үкереп килде. Монысында ул Тотышның үзен генә түгел, әйтерсең аты-ние белән бергә күтәреп ормакчы булды.

Шулай да ора алмады... Тотыш углан үзенә төбәлгән сөңгене калканы белән читкә тайпылдырып җибәрде. Карап торучылар, таң калып, тагын гөрләп алдылар. Болгарлар ягында инде җиңелчә генә киенгән яшь җегеттән көләргә беркем батырчылык итмәде. Киресенчә, аның менә шулай җиңелчә киемле булуы, яшьлеге, өлгерлеге аларның күңелендә чын-чынлап соклану тойгысы тудырды.

Өченче кат буш сөңге тотып калган Чәкән алпагыт, ахрысы, кирәгеннән артык кайнарланып ташлады. Ул, ачуына булашып, күрәсең, онытылыбрак китте. Кирәк чакта ул атын борып өлгермәде: аты аны ераккарак алып китте. Ике яктагы кешеләр әле генә булган очрашу күренешеннән айный алмыйча торганда, Тотыш углан беркемнең башына килмәгән, көтелмәгән бер җегетлек эшләде. Үзенә төбәлгән сөңге башын читкә тайпылдырып, Чәкән алпагытны узып киткәч, ул атын борып тормады: сикереп кинәт иyргә басты, артына борылды... борылды да күз ачып йомган арада сөңгесен ераклаша барган җайдакка тондырды. Туры ыргытылган саллы сөңге, тимер киемне, тимер сөякләрне җимереп, киң арканы үтә-сүтә тишеп керде.

Үз көченә, үзенең үлемсезлегенә нык ышанган Чәкән алпагыт сөрлегеп китте, тезгенен тартып, атын кире борды. Тешләрен кысып, соңгы көчен җыеп, ул да сөңгесен ыргытты. Сөңге ерак китә алмады: чыңлап, ыңгырашып, аяк астындагы тузанга барып төште.

Атаклы алпагыт, күкрәген тишеп чыккан очлы тимерне кысып тоткан килеш, көчәнеп беравык ияр өстендә утыргандай итте дә барлык авыр киемнәре, кораллары белән гөрселдәп ишелеп җиргә төште. Аты туктады, куркынган зур күзләрен уйнатып, кызганыч тавыш белән кешнәп җибәрде. Җайдакның калканы доңгырдап читкә тәгәрәде, алпагыт яртылаш туфракка буялды.

Акбүреләр ду килеп шауларга тотындылар. Болгарлар да ду килделәр: кайберәүләр чәчен-башын тырнап җыларга тотынды, кайберәүләр, янап, сүгенеп, катау ягына сөңге күтәрделәр. Тик шулай да беркемнең дә Тотыш угланны яманларга теле бармады. Күпчелек яшь алыпның язмышына соклану белдерде. Кырыс ирләр, орыш-сугыш белгечләре чын батырлык алдында баш иделәр.

Ул арада Тотыш углан үтерелгән алпагыт янына килде, сөңгесен тартып алды: киң аркадан, чишмә булып, куе кан атылып чыкты. Сөңгедәге канны Тотыш үлгән алыпның киеменә сөртте. Шуннан соң ул, сөенеченнән очынып, катау ягына чабып килде. Тузан туздырып, баш очында сөңгесен уйнатып яңадан хан җаваҗына якынлашты.

— Әй хан, чыгар икенче батырыңны! — дип кычкырды ул.

Яңа орыш башланганлыгын белдереп, тагын быргылар кычкырды, тагын дөңгерләр дөпелдәде. Киң җаваҗ артыннан яланга Будрач сукман[1] килеп чыкты.

Будрач сукман — Алмыш ханның Чәкән алпагыттан кала икенче батыры. Чәкән алпагыт үзенең коточкыч көче, кансызлыгы белән, ат өстендә яхшы орышуы белән танылган булса, Будрач сукман икенче яктан атаклы. Ул чирмеш, урман кешесе, шуңа күрә атта яхшы орыша алмый. Аяк өсте орышка исә аңа беркем каршы тора алмый иде. Тотыш белән Чәкән алпагытның орышын күзәтеп утырган Алмыш хан яшь җегетнең көчле якларын да, йомшак якларын да тиз арада төшенеп алды. Аның иң зур өстенлеге җиңеллек булса, иң йомшак ягы да шул ук җиңеллек иде.

---

[1] *Сукман* — батыр сугышчы, алып.

«Җәяүлегә каршы торып карасын әле»,—дип уйлады хан, үзалдына көлемсерәп.

— Мин кылыч белән орышам! — диде Будрач сукман.

Тотыш берни әйтмәде, атыннан сикереп төште дә сөңгесен җиргә кадады, кылычын кынидан алды. Ташбәкәл, иясе өчен пошынган сыман, кыска гына итеп кешнәп куйды, теләр-теләмәс кенә катау ягына юыртты.

Ак чырайлы, саргылт кашлы Будрач сукман буйга калку түгел. Ул — бик таза, нык, авыр сөякле. Чәкән алпагыт кебек, ул да баштанаяк тимергә төренгән. Аның да кылыч үтәрдәй бер генә йомшак җире дә юк шикелле.

Батырлар, бер-берсен сынап, күзгә-күз карашып тордылар да, икесе дә берьюлы кузгалып куйдылар, таптанып алдылар, кылычларын селтәп, ярсып шундук орышка да ташландылар. Тимергә тимер тиеп чыңлаган, мышнаган, дөп-дөп баскан тавышлар ишетелде. Кояшта көзгедәй булып кылыч йөзләре, калканнар ялтырап китте.

Карар күзгә таш тутырылган капчык сыман авыр күренсә дә, чирмеш батыры да бик җитез, өлгер кыланды — андый җитезлекне, өлгерлекне Тотыш аннан бөтенләй көтмәгән иде. Будрач сукманның кулында кылыч уйнап кына торды. Тотыш, кысрыклауга чыдый алмыйча, әкренләп-әкренләп чигенә барды, Будрач исә, яшь җегеткә тын алырга да ирек бирмичә, шулай кысрыклап килде-килде дә, кинәт кылычын ике куллап тотып, бар көченә орды. Шундый иттереп орды — кылыч астында кеше түгел, таш булса, таш та урталай ярылып чыккан булыр иде! Тотыш ярылмады — җиргә егылды. Карап торучылар «аһ!» иттеләр. Сөенергәме, сөенмәскәме икәнлеген әлегә беркем белмәде. Нык селтәнгән кылычның яртылаш диярлек җиргә батканлыгын, яшь җегетнең үлемгә кыл арасы гына торып калганлыгын күргәч, акбүреләр дә, болгарлар да күкрәк тутырып тын алдылар.

Тотыш аягына басты, чирмеш алып ташланганчы, тиз арада кылычын, калканын иплəде, артка чигенде. Шул ук мәлдә аның күз алдына Тәңкә күренеп китте. Беренче төнне аның белән куышуы исенә төште. Яшьтәшләре белән куышлы, качышлы уйнаганда әле

йөгереп, әле туктап, егылып калу, читкә тайпылу, шулай итеп, куучыны алҗытып бетерү алымын яхшы белсә дә, бу авыкта аңа бу ниндидер яңалык булып тоелды. Кылычын күтәреп, Будрач сукман яңадан өстенә килә башлагач, ул тиз генә читкә сикерде. Ул моны берничә тапкыр кабатлады. Будрач кызып китте. Тешләрен шыгырдатып, кан баскан күзләреннән куркыныч очкыннар чәчрәтеп, ул Тотыш угланны туктаусыз эзәрлекләвендә булды. Тотыш исә әле башын иеп калды, әле йөгереп китте, йә булмаса болгар батырының артына чыгарга итеп карады. Уңга-сулга боргалану авыр киемле кешегә шактый авырга туры килде. Яшь җегетнең нишләргә чамалавын ул бик яхшы аңлады, шулай да берни эшли алмады — Тотыш углан тиен кебек җитез, тиен кебек җиңел, тиен кебек тешле, усал иде.

Шулай мачы белән сычкан шикелле куышкан арада, Будрач сукман Тотыш угланның кая, ничек тайпылачагын алдан ук чамалап алды, тагын бер тапкыр — монысында инде соңгы тапкыр кизәнергә булды. Читкә киткән җегет исенә килеп өлгергәнче, ул аның артыннан килеп тә басты, кылыч сабын тагын ике куллап тоткан килеш, бар көченә селтәнеп тә җибәрде. Монысында өстән аска түгел, кыйгачлап, уңнан сулга таба селтәде. Чалгы белән печән чапкандагы кебек, ул Тотышны, кай төшеннән генә булса да, урталай кыеп төшермәкче булды. Тотыш углан, кайсы гына якка тайпылса да, ничек кенә егылса да, барыбер аның чалгысына эләгергә тиеш иде.

Тик ул Будрач сукман уйлаганча уңга да, сулга да тайпылмады, туп-туры аның аяк астына ташланды. Үткер кылыч аның баш өстеннән ыжгырып үтте. Алмыш ханның икенче батыры, кылычы артыннан ияреп, баскан урынында әйләнгәндәй итте. Шул ук мәлдә, бөтен яланны тутырып, йөрәк ачысы белән:

— А-а-а-а! — дип акырып җибәрде.

Тотыш кулындагы үткер тимер астан, корсак турысыннан сабынача йомшак иткә батып керде, эчәкләрне, бөер-бавырларны кисеп үтеп, күкрәгенә таба шуышты. Сукман кулындагы кылыч, калкан чыңлап, җиргә төште. Ак чырайлы, саргылт кашлы чирмеш алып, авызын ачып, ашыгып тын суыра-суыра, баганадай, артка ауды.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Тотышка куркуын җиңәргә нәрсә ярдәм итә? Аның әтиәнисе, ырудашлары, туган җире белән саубуллашу күренешен сөйләгез.
2. Койтым бикәнең улына әйткән сүзләреннән сез нәрсә аңладыгыз? Ни өчен ул үз ыруын да искә ала икән?
3. Кара-каршы килгән дошманнар арасында да гаделлек була аламы? Күрән бинең «Бернинди йолага да, түрәгә дә туры килми» дигән сүзләрен ничек аңладыгыз? «Идегәй» дастанындагы «түрә» сүзенең мәгънәсен дә исегезгә төшерегез. Гомумән, ерак тарих турындагы әсәрләрне чагыштырып укырга тырышыгыз, аларда күп уртаклыклар күрерсез.
4. Тезләнеп, Тәңрегә ялвару Күрән бигә һәм Тотышка ни өчен кирәк булган дип уйлыйсыз?
5. Алмыш ханның алыплары көчле булсалар да, бездә теләктәшлек уятмыйлар. Ни өчен дип уйлыйсыз?
6. Тотышның, алыплар белән чагыштырганда, өстенлеге нәрсәдә? Бу күренешне укыганчы, сез нәтиҗә нинди булыр дип күз алдына китергән идегез?

Берьюлы ике батырыннан колак каккан Алмыш хан, Тотыш угланга тын алырга да ирек бирмичә, өченче кешесен чыгарды. Монысы Корыч-Тимер дип аталган яшь, чибәр алып иде. Ул — Алмыш ханның чыбык очы туганы булган Алып-Тархан бинең сөекле углы. Ул да болгарлар арасында атаклы алыплардан санала. Корыч-Тимер инде күп кенә яуларда булган, орышларда катнашкан, җиңгән, бүләкләр алган. Холкы белән ул эре, борнай бер җегет. Барс кебек җитез, кансыз бу яшь алып бер дә юктан кызып китә, кирәк икән — шундук үзгәрә дә белә. Үзенең якыннары аны «ике яклы пычак» дип атыйлар. Тотыш углан кебек, ул да җиңелчә генә киенгән.

— Мин дә кылыч белән орышам! — диде ул, ялан уртасына чыккач.

Батырларның кара-каршы килеп басулары булды, быргыларның чинарга тотынулары булды, шундук орыш башланып та китте. Яшен чаткылары чыгарып, тиз арада кылыч йөзләре чәкешергә тотынды.

Тотыш углан беренче адымыннан ук ялгыш җибәрде. Будрач сукманны этләгән кебек, Корыч-Тимерне дә ул этләргә, алҗытырга чамалады. Тик болгар батыры аның бу алымын аңлап, өйрәнеп өлгергән иде инде. Шуның өстенә, Тотыш кебек үк, ул да бик җиңел

сөякле иде, шуның өстенә ул әле әз генә дә көчен түкмәгән иде. Корыч-Тимер Тотыш угланнан бер адым да калышмады. Акбүре батыры нәрсә эшләсә, ул да шуны эшләде, ул кая тайпылса, ул да шунда тайпылды, йә булмаса, аның алдарга чамалавын сизеп, шундук аның юлына аркылы төште. Тотышка ул күтәрелеп карарга да ирек бирмәде.

Тотыш ярсый башлады. Нинди дә булса яңа нәрсә уйлап табарга аның башы җитмәде — күз алдында ялт-йолт килгән кылыч йөзе торган саен аның эчен пошырды, ачуын китерде. Ул яңадан анасының сүзләрен, Тәңкәне исенә төшерде, тик инде берни дә аңа баштагы өстенлекне, салкын канлылыкны кайтара алмады.

Ул, алдалап берни барып чыкмаганлыгын күргәч, соңгы көчен җыеп, матур кара мыеклы чибәр ягыга каршы ыргылды, аны кысрыклый башлады, бер-ике тапкыр каты гына орып-орып алды. Берсендә Корыч-Тимернең калканы чак-чак кына кулыннан төшеп китмәде, икенчесендә ул башын саклап иелеп кала алды.

Акбүре батырының бетмәс-төкәнмәс көченә, ярсуына бөтен катау, бөтен ялан таң калды. Ике якта да тынлык, киеренкелек соңгы чиккә җитте.

Кинәт болгарлар ягына бозлы җил исеп киткәндәй булды. Тотыш өстенлекне тулысынча үз кулына алды, Корыч-Тимерне чын-чынлап кысрыклый башлады.

Көтмәгәндә ул нәрсәгәдер абынып китте. Шул чагында Корыч-Тимер, ач бүредәй, аның өстенә ташланды. Аның кылычы Тотыш кулындагы калкан читен уеп төшерде, сулъяк беләкне кисеп керде дә сөяккә җитеп төртелеп калды. Тотыш углан чайкалып китте. «Беттем»,— диде ул, үз-үзенә бик тыныч кына, бөтенләй чит кеше турында уйлаган кебек. Булган бар көчен, ярсуын бер учка туплап, ул Корыч-Тимернең ияк астына, муен турысына орды. Болгар алыбы башын иеп өлгерде, бары тимер алпак өсте генә сыдырылып китте дә, киселгән беләктән, киемнәрне чылатып, кайнар кан агарга тотынды. Шул ук мәлдә яшь җегетнең күңеленә «Бетәм!» дигән икенче уй килде. Бар нәрсәне онытып, ул канлы ярасын кысып тотты.

Корыч-Тимер куанып ырылдап җибәрде, бер селтәүдә Тотышны юк итмәкче булып, Будрач сукман

сыман кылычын ике куллап югары күтәрде. Ярасы белән мавыккан Тотыш угланга яңадан көрәш тойгысы, каршы тору тойгысы кайтты. Үткер кылыч үзенең муенын чабып өлгергәнче, ул җиргә егылып калды. Тик монысында ул баягыча ягының эчен айкый алмады. Ярасын ычкындырмаган килеш, сырты белән җиргә терәлеп яткан килеш, ул аңа бары кушаяклап тибеп кенә җибәрә алды. Авыртуга түзә алмыйча, болгар батыры чинап җибәрде, җиргә барып төште.

Җирдән алар икесе дә бер үк мәлдә сикереп тордылар. Тордылар да... Тотышның уң кулы буш түгел, яралы кулында корал юк иде.

— Ы-ы-ы! — дип үкерде кара мыеклы чибәр алып, куанычыннан нишләргә белмичә.

Ул инде орган да булыр иде, урталай кискән дә булыр иде. Корыч-Тимернең үкерүеннән дә көчлерәк булып, көтмәгәндә Куар оган[1] әйтерсең күкрәп җибәрде.

— Тукта! — дип кычкырды кемдер, аның артында гына.

Ирексездән ул туктап калды, артына борылды. Аның каршысында таудай булып Алмыш хан калкып тора иде.

— Тукта! — диде хан, кабатлап.— Син җиндең!

Чибәр алыпның чибәр мыек очы тартышып куйды. Шулай да ул коралсыз Тотыш углан янына килде дә, янап:

— Җыгыл! — диде.

Үзенең җиңгәнлеген белдереп, кызыл итеге белән аның күкрәгенә басты, кылычын итек башы янына терәде. Сөңгеләр, алпаклар урманы шауларга тотынды. Акбүреләр, караларына коелып, беравык аңламыйчарак тордылар да, барысы берьюлы диярлек кычкырып җыларга тотындылар.

Тотыш җиңелде, Акбүре җиңелде. Нәрсә карап тордың, Тәңрем?! Кайда булдыгыз, изге ияләр?! Тотыш җиңелде...

Җиңелде... Ул күзләрен ачты, үзенең борын төбендә генә җирәнгеч итек башын күрде, итек башы янында, үзенең бугазына якын төштә коточкыч салкын тимерне

---

[1] *Оган* — көрәшүче, сугышчы.

күрде. Тимер дә тик тора, итек тә кузгалмый. Тын алуы шундый авыр!

Җиңелсә дә, ул әле исән бугай. Әнә ул уйлый, күрә...

Ул җиңелде... Ах, нинди кыен, нинди оят очлы тимер белән итек табаны астында тын алып, күреп, уйлап яту!

Орыш тәкәнде. Языга[1] үлек күмүчеләр чыкты. Кан, тузан эчендә аунап яткан Чәкән белән Будрачны алар күтәреп алдылар, арбага салып, каядыр алып киттеләр.

Үлгән батырларны алар урман арасына алып барачаклар, аларның киемнәрен, коралларын салдырып алачаклар. Коралларның иң яхшыларын — ханга, калганнарын, кайткач, хатынына йә булмаса туганнарына бирәчәкләр. Кием-салымнарын алар үзләренә калдырачаклар. Үлекләрне күмеп тормаячаклар, ник дигәндә — монда батырларның туган җире түгел. Болгарлар киткәч тә, аларны монда чит кешеләрнең, бүре-козгыннарның мыскыллавы бар. Төнлә беркем күрмәгәндә алар үлгән алыпларны ачык, калку җиргә алып барырлар да, баганага терәп бастырган килеш, утын ягып яндырырлар. Кайнар көлне күккә очырырлар. Шулай итеп, болгарларның кыю батырлары мәңгелеккә — күккә ашар.

Ялангагы үлекләрне алып китү белән, орыш урынына имчеләр чыкты. Алар яралы Тотыш янына килделәр, аның киселгән беләгеп карадылар: яраны яхшылап салкын су белән юдылар да киселгән иткә яра ташы кырып салдылар, шуннан соң беләкне ныгытып бәйләп куйдылар. Шул эшләрне башкаргач, төсе качкан, агарынган яшь җегетне кабыкка салдылар, күтәреп шулай ук аны да каядыр алып киттеләр.

Ике як арасында кыскача гына сөйләшү булып алды. Күрән би Алмыш ханның катау янындагы яланнан үзе урда корган җиргә — Тәкәшүр болынына кайтып китүен теләде. Тиешле бурычны дүрт көндә үзем илтеп түләрмен, диде. Алмыш хан үз чирүенә шундук кире борылырга боерык бирде. Болгарлар, тузан туздырып, әкрен генә чигенә башладылар.

---

[1] *Язы* — ялан, буш җир, мәйдан.

Сырт өстендәге юлдан сулга борылып, вак куаклар янына килеп җиткәч тә, Койтым бикәне болгар күзәтчеләре туктатты. Унлап ир-ат[1] каяндыр караңгыдан килеп чыктылар да тавыш-тынсыз гына аларның юлларына аркылы төштеләр, төрле яктан уратып алдылар.

— Ым?[2] — диде күзәтчеләрнең алдагысы, сөңгесен югары күтәреп.

— Мин — Акбүре ыруының башы Күрән бинең хатыны,— диде бикә, күтәребрәк, битенә капланган бөркәнчеген чак-чак кына ачып.— Мин Алмыш ханга барам.

— Үзең генәме? — диде бер күзәтче, күрәсең, алай башы.

— Үзем генә,— диде бикә,— болар — минем сакчыларым.

— Сезне бүген туйга чакырганнарые, шунда барасыңмыни? — диде алай башы.

— Мин болай гына барам. Мин — Койтым бикә. Минем углым Тотыш — хан кулында.

— Тотыш?

— Ә-ә! — диештеләр күзәтчеләр, үзара гөрелдәшеп. Аларның бу гөрелдәшүендә Тотышка карата олылау сизелде.

— Алайса, син Тотыш алыпның анасымыни? — диде алай башы, кызыксыну белдереп.

— Менә, ичмасам, орышты! Күпме яшәп, шундый батырны күргәнем югые.

— Чәкәнгә каршы чыгарга йөрәге җитү — үзе генә дә батырлык!

— Үзе шундый яшь, үзе чибәр! — диештеләр күзәтчеләр.

— Сез мине җибәрәсезме? — диде Койтым бикә.

— Ниерәк шул...— диде алай башы.— Ярар, барыгыз... алай Тотышның анасы да булгач...

Төнге күзәтчеләр, аларга юл биреп, як-якка таралдылар. Койтым бикә үз кешеләре белән тавыш-тынсыз гына кузгалып китте. Алар берничә адым ераклашырга да өлгермәделәр, алай башының арттан:

---

[1] *Ир-ат* — монда: атлы сугышчы.

[2] *Ым* — сугышчыларның, очрашканда бер-берсен тану өчен, алдан билгеләп куйган сүзе; пароль.

— Әй, туктагыз әле! — дигән тавышы ишетелде.

— Менә Кудаш сезне озатып куяр,— диде алай башы, якынаеп.— Юкса хан урдасына җиткәнче сезне адым саен туктатачаклар.

— Озатсын,— диде бикә.

Аларны, чыннан да, адым саен диярлек туктаттылар: әледән-әле караңгыдан каравылчы-күзәтчеләр килеп чыкты. Алар барысы да ым сорадылар. Озатучы аларга бер-ике сүз белән генә аңлатып бирде дә, төнге кунаклар яңадан кузгалып киттеләр. Хан тирмәсе янында Кудаш аларны каравыл башына тапшырды. Каравыл башы Койтым бикәне юлдашлары белән аерым тирмәгә алып керде. Ул аларга көтеп торырга кушты.

— Минем турыда ханга җиткерәсеңме? — диде бикә.

— Юк,— диде каравыл башы.— Сезне туйга чакырдылар. Килмәдегез. Соңга калган кеше хан янына кертелми. Аш-су беткәнче, кунаклар таралганчы көтеп торырга туры килер.

— Алай икән...— диде бикә, таркау гына, бөтенләй икенче бернәрсә турында уйланып.

Кайчанга тикле көтәргә? Кунаклар әллә таң атканчы таралышмаслар. Юк инде, көтәргә икән, көтәргә! Кайчанга чаклы булса да. Ул монда буш кул белән кайтыр өчен килмәде. Кайда булыр аның углы? Кайдадыр шушында... Ничек коткарырга аны? Ничек алдарга сакчыларны? Ничек катауга кире кайтырга? Кайткач нишләргә? Туктале, нишләптер башы буталды әле аның. Кайчан бетәр бу туй, кайчан ул аны... ханнымы, углынмы күрә алыр?

Койтым бикәнең күңеленә шундый уйлар килде. Тотышны коткару өчен, үзенең нишләргә тиешлеген ул әле булса ачык кына күз алдына китерә алмады. Ул бары аны йолып алырга тиешлеген генә, үзен, углын, ыруын — ике ыруын да! — утка салган явыз кешене күргәч, аны нидер эшләтергә тиешлеген генә аңлады. Ул, әледән-әле куенына кулын тыгып, кәзлек[1] сабын тотып-тотып карады. Ярый әле аны тентемәделәр!

Көтеп тору Койтым бикә уйлаганча ук озакка сузылмады. Төн уртасы узып, җәйге караңгылык

---

[1] *Кәзлек* — хатын-кыз хәнҗәре.

тарала башлаганда, хан тирмәсеннән, җиңелчә шаулашып, кунаклар чыкканы ишетелде. Каравыл башы, Алмыш хан йокларга ятканчы дип ашыгып, Койтым бикә турында әйтергә китте.

Күп тә үтмәде, каравыл башы кире килде, бикәне хан янына алып китте. Тышкы ишектән кергәч тә, бикә иң элек ак киезләр җәелгән тар гына аралыктан барды, аннары сулга борылды, уңга борылды да кечерәк кенә дүрткел бүлмәдә туктап калды. Бүлмәдә бизәкле кечкенә баганалар башына утыртылган пыскыйлар янып тора иде. Там буена йомшак утыргычлар куелган, идәнгә бизәкле киез җәелгән иде.

Каравыл башы, каршыдагы ишеккә башын тыгып, керергә ярыймы икәнлеген сорады, шуннан соң ул, башын кире алып, керергә яраганлыгын әйтте. Бикә аның нәрсә әйткәнен аңламады, йомшак урынында оеп тик утырды. Бу серле тирмәдә, тышкы яктан бернинди тавыш-тын ишетелми торган бу киез тамнар арасында, үзенең барлык күңел тынычлыгын алган явыз кеше янәшәсендә ул кинәт үзгәрә башлады. Тиктомалга аның аяклары карышты, куллары авырайды, йөрәге никтер куркып-өркеп тибәргә тотынды.

Тәңрем, нәрсә бу? Барлык тереклек иясендә була торган бер курку-өркү генәме бу... үзеңнән көчлерәк, баерак булган барлык кешеләрдән курку-өркү шикелле генә курку-өркүме әллә соң монда тагын бүтән нәрсә дә бармы?

Койтым бикә урынына береккәндәй утырганда, каршыдагы ишек үзе ачылып китте. Чүлмәккә кычкырган сыман калын, көр тавыш белән таныш кеше:

— Кем бар анда? Керсен! — дип кычкырып җибәрде.

Алмыш ханның «яшел бүлмә» дип аталган йокы бүлмәсе әле генә бикә утырган дүрткел бүлмәдән икеләтә, өчләтә зур.

Тамнарга тоташ яшел ефәкләр эленгән иде. Түшәмнән дә, чыбылдык кебек булып, ачык төстәге яшел ефәк салынып тора.

Идәнгә бизәкле зур Иран паласы җәелгән. Ишеккә каршы якта, имән агачыннан сырлап, матурлап ясалган киң, биек ятак урыны калкып тора. Ятак турысында ак ефәккә кара белән, гарәп иҗекләре белән изге сүзләр язып эленгән. Шунда ук түшәмнән көмеш чылбырга тагылган алтын эт башы да асылынып тора. Болгар

ханының тынычлыгын чумак йоласы да, төрек йоласы да бергәләп саклыйлар иде.

Әлеге зур ятак урынын, ятак янындагы тимерле тартманы, тартма өстендәге котычыкны[1] санамаганда, «яшел бүлмә»дә башка берни юк. Аннары идәннең урта бер җирендәрәк, бизәкле багана башында, пыскыйда — чүлмәк савытта чырт-чырт килеп кара май яна. Кара майның кара сөреме баш өстендәге яшел чыбылдык янындагы ачыклыктан үзәк төннеккә таба суырылып тора.

Алмыш хан, алтын-көмешле киемнәрен салмыйча, ике кулы белән биленә таянып, ятагында утырып тора. Койтым бикә үзе дә сизмәстән тетрәнеп китте: ул шундый яхшы белгән яшь Алмыш углан танымаслык булып үзгәргән! Орыш көнендә ул аны ерактан гына күргән иде. Чынында ул аңа ныклап карамаган да иде. Тәңрем, нинди кансыз бу язмыш дигән нәрсә! Элекке яшь туерадай таза, сылу Алмыш углан ботак-сатаклы карт имәнгә әйләнгән. Бите, күз кабаклары шешенке. Корсагы үскән, симез. Ярый әле сакал-мыегын чумакларча матурлап, түгәрәкләп кистергән.

Күрән бинең өлкән хатыны, ятактагы кешегә таба бер-ике адым атлады да, йола саклап, башындагы бүреген салды, тезләнде. Алмыш ханның йокламаудан, күп эчүдән бөтенләй йомыла язган күзләренә бер күтәрелеп карады да, коры, нык бер тавыш белән:

— Мин, Акбүре ыруының башы Күрән бинең хатыны Койтым бикә...— дип сүзгә башлады.

Нәрсәдер исенә төшерергә тырышып та төшерә алмыйча, кашларын җыергалап, аптырап утырган ханның йөзе кинәт ачылып китте.

— Койтым! — диде ул, урыныннан торып.

Иңбашыннан тотып, ул бикәне аягына бастырды; күрәсең, буза, сычук кызуыннан айный алмыйча, элеккечә аны кочагына алмакчы булды. Бу ничектер бөтенләй көтмәгәндә булды. Койтым бикә, ике куллап, аны этеп җибәрде. Зур, авыр ир кеше чак-чак кына чайкалып китте. Ул, кызарынып, биленә таянды. Чынчынлап ачуланырга да, ачуланмаска да белмичә, ул үзенең мәңгелектән кире кайткан яшьлегенә — утялкынлы, тере, сылу яшьлегенә карап торды.

---

[1] *Котычык* — кечкенә сандык, шкатулка.

— Койтым! — диде ул, яратып, ягымлы итеп.

— Мин сиңа үтенеч белән килдем... Болгар йортның... Алмыш хан,— диде Койтым бикә, никтер буталып, кабаланып.

— Чынмы бу, синме, Койтым?! — диде Алмыш хан, әле булса исенә килә алмыйча.

— Бу — мин,— диде бикә, үз-үзен тынычландырырга тырышып.— Онытма, син Алмыш углан булмаган кебек, мин дә Шелке ханның кырнагы түгел. Мин — Күрән бинең хатыны.

«Күрән би» сүзен Алмыш хан беренче тапкыр ишеткәндәй булды. Бу сүз аның кайнарлыгын сүрелдерә төште. Әйе, әйе, Күрән би. Тотыш углан... Каравыл башы әйткәние шул — бинең хатыны дигән иде. Катаудан килгән. Би хатыны. Каян килеп эләккән ул монда? Язмыш кая китереп ташлаган! Әйе, кырнак иде, инде әнә би хатыны булган. Алтынны юлга ташласаң да — алтын, шүрлеккә куйсаң да, утка тотсаң да — алтын! Койтым бикә түгел, Алтын бикә! Нишләп Күрән бине кызганды соң әле ул? Туздырасы калган оясын, аласы калган тартып хатыннарын, кызларын. Ах, кем белгән аның болай булырын!

— Алайса, син Күрән бидә? — диде ул бераздан, елмаеп, бикәнең күзләренә карап.— Белмәдем, монда мин элегрәк килгән булырыем.

— Ярый әле элегрәк килмәгәнсең,— диде бикә.

— Менә килдем, таптым! Алам! — диде Алмыш хан, эчке бер омтылыш белән.

— Инде соң,— диде бикә, салкын гына.

— Соң түгел!

— Соң! — диде бикә, ачуына ирек биреп.— Синең атаң Шелке минем туган ыруымны туздырды, атамнан-анамнан аерды. Инде менә син килдең минем икенче оямны туздырырга. Син миңа кан-яшь, кайгы алып килдең. Минем икенче туган ыруымны да син кара кайгыга салдың. Шулай булгач, ничек итеп син миңа, соң түгел, дип әйтә аласың?! Моннан унтугыз ел элек мин берни аңламыйдырыем. Инде мин күп нәрсәне аңлыйм. Мин — Күрән бинең хатыны — сиңа үтенеч белән килдем. Тыңлыйсыңмы мине, Алмыш хан?

— Сөйләп кара,— диде хан.

Ул, күрәсең, истәлекләреннән дә, исереклегеннән дә айный башлады. Кисәк кенә ташкын булып калкып

чыккан күңел тойгылары аның шулай ук ташкын булып тиз арада кире чигенде.

— Мин... Тотыш угланның анасы...— диде бикә, калтыранып.

— Тотышның?!

— Әйе. Син аны миңа кайтарып бир. Үлеме, тереме — кайтарып бир. Үтенечем шул.

Койтым бикә тынын кысып, туктап калды. Алмыш хан да тып-тын булды. Җентекләп, нидер чамаларга тырышып, ул чибәр хатынның агарынган йөзен күзәтте.

— Синеке? — диде ул, үзалдына сөйләнгән сыман. Аннары башын калкытты да, бөтенләй чит кешегә, ханга әйләнеп: — Синеке генә түгел, минеке дә! — диде.

Аның «минеке»сен Койтым бикә үзенчә аңлады.

— Юк, синеке түгел! — диде ул, кычкырып.— Түгел! Мин бик яхшы беләм — түгел! Бир углымны миңа! Яралы килеш, үле килеш... теләсә ничек кайтарып бир. Мин шуңа килдем, шунсыз китмим!

— Китмә,— диде хан, тыныч кына.

Аның бу тынычлыгында буй җитмәслек көч, бөеклек сизелде. Беренче тапкыр бикә аны — үзе янындагы бу ир кешене — язмыш билгеләгән олуг хан итеп тойды.

— Мин сине кумыйм,— диде хан, шул ук тынычлыгын саклап.— Кал янымда, хатыным булырсың. Углың белән кал. Би хатыны булуга караганда, хан хатыны булу яман түгел.

— Миңа углым кирәк. Тотыш кирәк! — диде бикә, күз яше сизелгән бер йомшаклык белән.

— Синең углың миндә тотык[1] булып калачак,— диде хан.

— Күрән би тотыклыкка сиңа башка углын бирер,— диде бикә.

— Миңа Тотыш углан кирәк,— диде хан, үчекләшкән сыман.

— Бир Тотышны миңа, бир! — дип кычкырды бикә, көчсез бер ярсу белән.

---

[1] *Тотык* — берәр таләпнең үтәлүен тәэмин итү өчен, дошман якларның берсе тарафыннан кулга алынган каршы як кешесе (заложник).

Кинәт ул кулын тун изүенә шудырды, кәзлек сабына тотынды. Тик ул аны кыныдан суырып чыгарырга да өлгерә алмады, таза ир кеше, аның нишләргә теләвен күреп, җиңел генә беләгеннән кысып тотты да тез чүктерде.

— Белексез! — диде ул, ачусыз гына мыгырданып.

Бикә егылып китте, башы идәнгә бәрелде. Үзенең көчсезлегенә, булдыксызлыгына ачыргаланып, ул тыела алмыйча җыларга кереште. Ул бик озак җылады, күз яшьләре агып беткәнче, барлык ачу-ярсулары, барлык тойгылары юылып чыкканчы җылады. Үкси-үкси торып утырды да үзенең баш очында аякларын аерып басып торган коточкыч кешегә ялынычлы күзләрен текәде.

— Алмыш... углан, үтермә мине... бир углымны! — диде.

Берни аңлатмый торган таштай йөзен үзгәртмичә, Алмыш хан, бөек Тәңре кебек (тфү, тфү), явыз айна кебек, албасты кебек, югарыдан аңа карап торды.

— Мин әйттем: ул синең генә углың түгел,— диде ул.— Мин аны үлем тырнагыннан тартып алдым. Мин! Корыч-Тимернең кылычын мин тотып калдым. Син аны тапкансың, мин аны үлгәч терелттем. Шулай булгач, Тотыш алып... Тотыш арыслан синеке генә түгел, минеке дә!

«Менә нәрсәне әйтә икән ул!»— дип уйлады бикә, үзалдына, ниндидер бер тынычлык белән. Аның эченә җылы йөгерде. Тотыш алып... Тотыш арыслан? Алмыш хан үзе шулай ди!

— Алайса, син аны үтермәячәксең?! Коллыкка сатмаячаксың?! — диде ана, пышылдап, елмаеп.

— Ул миндә тотык булып калачак,— диде хан, кабатлап.— Ике елдан соң ул синең яныңа исән-сау килеш кайтыр. Аның урынына тотык итеп миңа Күрән би үзенең бүтән углын җибәрер. Югыйсә үзеңә тиешле каланны да менә шулай яу белән килеп алырга туры килә. Моннан соң мин дә, каган кебек, үземә буйсынган биләрнең угланнарын тотыкка алачакмын!

— Син... сүз бирәсеңме? — диде Койтым бикә.

— Сиңа тагын нинди сүз? — диде хан.— Алмыш ханның сүзе бер булыр!

— Алайса, тагын бер үтенечемне тыңла,— диде бикә, аягына басып.— Углымны күрергә булмасмы?

— Ник? — диде хан, уйлангандай итеп.— Кочаклашып җылашыргамы? Үтерәсең киләмени? Аның янына имчеләр сине түгел, мине дә кертмәсләр. Кайгырма, миннән аңа кырын күз карашы булмаячак.

— Бай бул, сау бул, Алмыш хан! Бай бул, сау бул, углым Тотыш! — диде Койтым бикә, җиңел сулап.

1970

Сораулар һәм биремнәр.

1. Тотыш ни өчен җиңелә? Шуннан соң нинди вакыйгалар була? Тотыш ыругын саклап кала аламы? Орышның нәтиҗәсен ничек бәялəр идегез?
2. Күмү йоласына игътибар итегез. Йолаларның төрле булуы нәрсәләргә бәйле икән?
3. Сездә үкенеч яки соклану хисләре уяткан урыннарны кабат укып күрсәтегез. Нигә Тотышның язмышына битараф калып булмый?
4. Койтым бикә Алмыш хан янына нинди максат белән килә? Максатына ирешәме? Ни өчен, Тотышны алып яки күреп китә алмаса да, ул Алмыш ханга саулык тели?
5. Алмыш ханга сез нинди бәя бирер идегез? Ул сездә нинди тәэсир калдырды? Басып алучы, талаучы, җимерүче генәме ул? Бу шәхесне тулысынча аңлау өчен, романны ахырга кадәр укып чыгарга кирәк. Сез анда тагын да кызыклы язмышлар, геройлар, вакыйгалар белән очрашырсыз.
6. «Тарихлардан килгән хакыйкать» дигән темага сочинение языгыз.

Дөнья яралганнан бирле сулар кая таба ага?

«Менә тагын яз җитте...» Гади генә җөмлә. Яз килгән саен, без «менә тагын бер кыш үтеп китте, үтә гомерләр» дигәнрәк бер моңаю һәм «ниһаять, салкын кыш үтеп китте, җылы җәйләр җитә» дигән куану белән бу җөмләне гел әйтәбез. Бу сүзләрне меңәр еллар буена меңнәрчә кешеләр дә, үз чорын, үз хәлен күздә тотып, зур өметләр, кайнар хисләр белән кабатлаган.

Романга без шушы сихри сүзләргә ияреп кереп китәбез. Вакыйгалар барачак урын тасвирлана. «Тирә-якны яктыга, куанычка күмеп, җирдәге барлык терегә күз кысып, шаярып ягымлы кояш кайнар укларын яудырды. Җир өтәләнгән тунын салып ташлады. Инешләр, елгалар, ермаклар, ташулар — барысы да Чулман атлы олуг суның кочагына омтылдылар». Бу күренеш безнең күңелләрне әсир итә: ничә гасырлар элек

барган вакыйгалар кайдадыр еракта түгел, без яши торган шушы җирләрдә барган икән, ул елгаларның исемнәре генә үзгәргән, җир-сулар исә —шул ук. Кешенең бөтен гомере җир белән бәйле. Кеше туды дигән мәгънәне дә тантаналы итеп әйтергә теләгәндә «кеше җир өстенә килде» дип, зурлап әйтәбез. Нинди рәхимле, сабыр ул җир: күпме сугышлар, кан коюларны кичерә, никадәр гасырларны, язмышларны үз җилкәсендә күтәрә!

Менә шундый хисләр дулкынын кузгатырлык итеп табигать тасвирлана. Күрән би белән Тотышның, изге җан иясенә дәшкәндәй, ата-бабалар җиренә тезләнеп ялваруларын, Тәңре дип кояшка табынуларын аңлап, ихлас кабул итәсең. Чынлап та бит, табигать,— нәкъ романда тасвирланганча, кешеләрне, барлык тереклекне куенына сыендырган илаһи көч. Бүген без шушы изге мөнәсәбәтне, ярату, табыну хисен югалтып, ярлыланып барабыз.

Тагын бер як әһәмиятле. Борынгы кешеләрнең үзләренә Тәңре, изгеияләр эзләп табып, аларга табынуларында зарурилык булган. Шул дәрәҗәдә ышану кешеләрнең үзләре теләп кабул иткән уртак фикере, барысы өчен дә тигез, гадел нигез ролен үтәгән. Буыннан буынга тапшырылып, сакланып килгән бу йола-кануннар тормышның нигезен, яшәүнең тәртибен саклап торганнар. Бер үк нәрсәгә ышану, бер үк нәрсәләрне тану уртаклык хисен тудырган, кешеләрне берләштереп торган. Бердәмлекнең никадәр әһәмиятле, кирәкле хис икәнлеген без бүген аеруча ачык тоябыз.

Әсәрдә тасвирланган вакыйгалар, тарихның үзе кебек үк, катлаулы, кырыс, рәхимсез. Бер дә уйламаганда, акбүреләр ыругының башлыгы Күрән би авырый башлый. Урман-таулар, сазлык-баткаклыклар артында дошман яуларыннан еракта, тынычта яшәгән кечкенә бер ыругда аны сихәтләндерерлек имче-табиб юк. Ул, зур өметләр белән, сәүдәгәрләрне көтә. Бердәнбер аралашу юлы булган Чулман елгасы буйлап, агымның түбән ягыннан килергә тиешләр алар. Ел саен, яз җитүгә, Чулман буйларына җан кертеп, монда юк малларны төяп килеп җитә торган сәүдәгәрләр быел күренмиләр. Имче дә, шифалы дарулар да, булса, аларда гына була. Өстәвенә Тәңренең илчесе булып, ыругның хәлен кайгыртып яшәргә тиешле Утташ кам да үз файдасын гына уйлап, төрле мәкерләр корып, кешеләрне котыртып йөри. Шул борчу-мәшәкатьләрне көчәйтеп, казаяклар яман хәбәр алып киләләр: барысын да буйсындырып, калан

түләтеп торган Алмыш хан яу белән кузгалган. Берләшеп, аңа каршы чыгаргамы әллә коры җирдән килеп җитә алмас дип ышанып сабыр итәргәме? Йә, Тәңре! Нинди катлаулы бу дөньяда яшәве, никадәр акыл, зирәклек кирәк, сиңа теләктәш кешеләр кирәк! Күрән би берьялгызы әнә нинди авыр хәлдә. Кызгану хисе — кеше табигатендәге иң матур, иң кирәкле хис, ул бездә дә Күрән бигә, акбүреләр ыругына теләктәшлек уята. Киеренкелек иң соңгы чиккә җитә: урманнар, сазлыклар аша үтә алмас дип уйлаган Алмыш хан, иксез-чиксез гаскәре белән, акбүреләр катавын чорнап ала. Казаякларның берләшеп яу чыгарга дигән тәкъдимнәрен кабул итмичә ялгыштылар, ахрысы, алар.

Бөтен бер ыругның язмышы дәрәҗәсендә үк безне Күрән бинең улы Тотыш язмышы да дулкынландыра. Аның бала чагы, би баласы булуына карамастан, кагылып-сугылып, кимсенеп үтә. Әнисе Койтымны Күрән би кол итеп сатып алган, аның чибәрлегенә кызыгып, ничәнчедер хатыны иткән була. Өлкән хатыны авырып үлгәч, йола буенча, икенче хатын өлкән булып калырга тиеш булса да, акылын, булганлыгын исәпкә алып, аксакаллар белән киңәшеп, Койтымны өлкән бикә итәләр. Менә шуннан соң гына Тотыш белән яшьтәшләре дә, өлкәннәр дә исәпләшергә мәҗбүр булалар. Кимсенүләр, әрнүләрен күңеленә җыеп үскән Тотыш, чыннан да, шактый башкисәр булып, көченә, ашкынуларына урын таба алмыйча бәргәләнеп яши. Шулай да ул, үсмер булып җиткәч, бер егетлек эшли: этисе аны, мал төяп, кешеләр биреп, салкын төньякка җибәрә. Барып җитә алмыйча, ярты юлдан борылыр дип уйлый, ләкин Тотыш, сәүдәсен уңышлы гына башкарып, бер этен, бер кешесен дә югалтмыйча әйләнеп кайта.

Менә шушы Тотыш иң авыр, хәлиткеч вакытта искиткеч кыюлык күрсәтә. Берәүнең дә башына килмәгән тәкъдим ясый: ул Алмыш ханның алыбы белән бергә-бер орышка чыгачак. Җиңә икән — Алмыш хан кире китәргә тиеш, җиңелә икән — акбүреләр калан түләргә мәҗбүр булачаклар. Тотышның эти-әнисенә, ыругдашларына мөрәҗәгать итеп әйткән сүзләре, Койтым бикәнең улына фатиха бирүе, орышны тасвирлау — романның дастаннар телендә язылган иң матур урыннары. Тотышның үзе өчен дә иң хәлиткеч, аның йолдыз булып балкыган мизгеле бу. Барысының да өмете, ышанычы, язмышы аның кулында, шуны күтәрерлек көч-куәт тоя ул үзендә.

Безне тетрәндергән, Тотышның, хәтта ыругның язмышыннан да югарырак торган тагын бер мәсьәлә бар, ул — гаделлекнең җиңү-җиңмәве. Тотышның теләгенә Алмыш хан «бергә — өч» дип җавап бирә. Бу, — әлбәттә, күрәләтә кимсетү, акбүреләрне мыскыл итү! Бу — бернинди кагыйдәләргә дә сыймый торган гаделсезлек. Тотыш бит өч баһадирны гына түгел, менә шул гаделсезлекне дә җиңәргә тиеш. Үз җирен, ыругын, ата-анасын яклап сугышка чыккан егеткә гаделсезлек кузгаткан үч тойгысы көч бирә. Дошманны да шаккатырып, ул үзеннән күрер күзгә күп өстен булган, тимер таудай нык, көчле ике алыпны җиңә. Дөрес, нәтиҗәдә Тотыш өченче алыптан җиңелә, әмма максатына ирешә, ыругын дошман явыннан саклап кала... Дошман табаны астында калу Тотышка нинди хурлыклы, кыен, оят тоела! Бу үкенеч безнең күңелләрне дә телеп үтә — юк, гадел булмады бу орыш, гаделсезлекнең үчен кайтарырга кирәк. Тотыш өчен дә, безнең өчен дә, кем өчен дә бер үк бит ул гаделлек. Үткәндәге гаделсезлекләрне дә төзәтергә була, яңаларына да юл куймаска тырышырга кирәк икән. Гаделлек белән бергә кайдадыр, мәкер-хыянәт булып, гаделсезлек тә яши бит әле.

Шулай да язмыш бик үк рәхимсез дә түгел. Тотыш исән кала. Алмыш ханның үзе дә, гаскәре дә Тотышның батырлыгына, кыю, чая булуына, җитезлегенә, осталыгына сокландылар, аны танымый кала алмадылар. Улын коткару уе белән килгән Койтым бикә моны аңлый. Шуңа күрә ул, улын әсирлектән коткара алмаса да, аңа мөнәсәбәтнең яхшы булачагына ышанып, тыныч күңел белән кайтып китә.

Дәреслектәге сез укыган өлешләр — романнан өзекләр генә. Әсәрнең икенче өлешендә вакыйгалар Итил (Идел) елгасы ярларына күчә, Итил суы кебек үк бормалы язмышлар, зур тарихның хәрәкәтен гәүдәләндергән вакыйгалар, яңа геройлар, таң калырлык гүзәл мәхәббәт тасвирлана.



Туфан Миңнуллин
(1935 елда туган)

Берсеннән-берсе кызыклы пьесалар иҗат итеп, бүгенге татар сәхнәсен «тотып торган» драматургларның берсе — Туфан Миңнуллин.

1935 елның 25 августында Татарстанның Кама Тамагы районы Олы Мәрәтхуҗа авылында Габдулла Миңнуллин гаиләсендә бер малай дөньяга килә. Габдулла агай — әдәбиятка гашыйк кеше, шул еллардагы популяр шагыйрьләрнең берсе булган Хәсән Туфанның псевдонимын малаена исем итеп куя.

Туфан, урта мәктәпне тәмамлагач, беркадәр вакыт төрле эшләрдә (хисапчы, бухгалтер һ. б.) эшли. Ләкин аның тормыш сукмагы барыбер әдәбият-сәнгать дөньясына борыла. Мәскәүдә театр училищесында укый, Минзәлә театрында, бераздан Г. Камал театрында артист була, Казан телестудиясендә, «Чаян» журналында эшли. Аннары бөтенләе белән иҗат эшенә күчә.

Туфан Миңнуллин — сатирик повесть, шаян хикәяләр, шигъри парчалар һәм эпиграммалар авторы. Ләкин аның таланты тулы булып ачылган өлкә —драматургия. Бүгенге көнгә ул 40тан артык пьеса язды. Алар арасында «Канкай углы Бәхтияр», «Без китәбез, сез каласыз» (Габдулла Тукай турында), «Моңлы бер җыр» (Муса Җәлил турында) кебек тарихи драмалар, «Үзебез сайлаган язмыш», «Әниләр һәм бәбиләр», «Монда тудык, монда үстек» һ. б. драмалар, «Әлдермештән Әлмәндәр», «Яшьлегем — җүләрлегем» шикелле комедияләр, «Диләфрүзгә дүрт кияү» кебек водевильләр, «Авыл эте Акбай» дигән балалар пьесасы һ. б. әсәрләр бар.

Татар әдәбиятын, сәнгатен үстерү өчен бөтен гомерен багышлаган Туфан Миңнуллин Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә (1979 ел) һәм Россиянең Станиславский исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды (1979 ел), аңа «Татарстанның һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе» (1978 ел, 1984 ел), «Татарстанның халык язучысы» (2005 ел) дигән мактаулы исемнәр бирелде.

БӘХЕТЛЕ КИЯҮ

Комедия бер пәрдәдә, ике күренештә

КАТНАШАЛАР:

Харис — авыл карты.
Нәфига — аның карчыгы.
Мөнирә — кызлары.
Нури — кияүләре.
Гөлбикә — авыл карчыгы.
Исмәгыйль — бригадир.

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Харис карт өенең ишегалды. Сәхнәдә берәү дә юк. Бераздан шәһәрчә матур, зәвыклы итеп киенгән Мөнирә керә. Керә дә капка артындагы Нурины чакыра.

Мөнирә. Рәхим итегез, кияү. Төкле аякларыгыз белән. Гафу итегез, тун җәеп куя алмадык. Туныбыз юк.

Нури керә. Ул да бик ыспай киенгән. Башында — салам эшләпә. Бер кулында — чемодан, икенчесендә — кармак саплары.

Мөнирә. Түрдән узыгыз, кадерле кияү.

Нури. Тукта әле син, Мөнирә. Бабай белән әби күрсә, яхшы түгел.

Мөнирә. Әһә, курка да башладыңмы? Казанда бик батырайган идең бит. Карап карыйк, нишләрсең икән? *(Тәрәзә янына барып.)* Әти!.. Әни!.. *(Җавап юк.)* Әллә өйдә юклар инде?

Болдырга йөгереп менә. Ишектән кереп югала. Нури, чемоданын да куймыйча, ишегалды уртасында таптанып тора. Тирә-ягына карана. Мөнирә өйдән чыга.

Менә сиңа мә! Исәнмесез, кияү. Берәү дә юк.

Нури *(чемоданны — җиргә, кармак сапларын болдырга сөяп куя)*. Бай яшиләр, ахрысы.

Мөнирә. Менә, иптәш Маннуров, бәхетле кияү, сизденңме инде кем кызына өйләнгәнеңне?! Кадерен бел. Борыныңны бик күтәрмә.

Нури. Монда кунак булырга ярый.

Мөнирә. Кая киттеләр икән?

Нури. Миңа әйтмәделәр.

Мөнирә. Әйдә, өйгә керик булмаса.

Нури. Шушы кояшны ташлап өйгә керәмме соң? Казанга кайтканда негр кебек булып кайтам, дип сүз бирдем. *(Күлмәген, майкасын салып, болдыр тактасына элеп куя.)*

Мөнирә. Әни кайтса, шулай каршыларсыңмы? Килешмәс.

Нури. Мин киенгәнне күрми дә кала ул. *(Сыртын кояшка таба борып.)* Пешерә. Шәп. Эх, эчәргә су да булса!.. Елгагызны бик мактаган идең, әллә коенып кайтабызмы?

Мөнирә. Өлгерербез. Кайтсыннар. Әллә кая китмәгәннәрдер. Беләсеңме, Нури, нәрсә эшлибез? Баздан салкын катык алып чыгам.

Нури. Әзерләп куйганнар ди.

Мөнирә. Курыкма, безгә җитәрлек бардыр әле.

Өйгә кереп, савыт алып чыга да бакча ягына китә. Нури, юынгычны күреп, шуның янына килә, юынгычтан сыртына су агыза. Капка ачылган тавышны ишетеп, тиз генә күлмәге янына ташлана, күлмәкне киеп куя. Исмәгыйль керә. Бер-берсенә карашып торалар. Нури, Исмәгыйль каршына барып, кулын суза.

Нури. Исәнмесез... бабай.

Исмәгыйль. Исәнме, Харис абый өйдә юк мәллә?

Нури *(Исмәгыйльгә текәлеп карап)*. Ә... ә... юк шул, абый кеше.

Исмәгыйль. Кирәк иде бит. Син кем буласың соң, танымыйм?

Нури. Мин — кияү... кияүләре...

Исмәгыйль *(ишегалдында аунап ятсан бүкәнне күләгәгә алып килеп утыра. Кесәсеннән кулъяулык чыгарып сөртенә. Аның йөрешендә, хәрәкәтләрендә, сөйләшүендә ниндидер сүлпәнлек, эленке-салынкылык сизелә. Йөзендә нәрсәдәндер канәгать булмау билгесе ярылып ята)*. Кыздыра, хәерсез. Радиодан егерме биш градус дигән булалар, кая монда егерме биш, кырык бардыр.

Нури. Шәп.

Исмәгыйль. Нәрсә шәп?

Нури. Кояшны әйтәм. *(Күлмәк изүеннән күренеп торган ялангач күкрәген чәбәкләп куя.)*

Исмәгыйль *(Нурига мәгънәле карап ала).* Үзең генәме?

Нури. Мөнирә белән.

Исмәгыйль. «Беломор»ың бармы?

Нури. Тартмыйм бит, абзый.

Исмәгыйль. Шәп. *(Кармак сапларына күрсәтеп.)* Синекеләрме?

Нури. Әһе. Мөнирә әйтә, безнең елгада балык мыжлап тора, ди. Бер салганда икешәр эләгә, ди. Дөресме?

Исмәгыйль. Белмим... Кая китте соң бу Харис абый? Нәфига апа да юкмы?

Нури. Юк.

Исмәгыйль *(күккә карап).* Берүзе бит, хәерсез. Яндыра да яндыра. Шәһәрдә сез көтеп ала алмыйсыздыр әле.

Нури. Быел яздан бирле рәтләп кызынган юк. Монда рәхәтләнәм инде. Казанга кайткач танымаслар да.

Исмәгыйль. Берәр ракета тиеп бәреп төшерми, ичмасам. Тәк, ярый. Харис абый кайтса әйт әле, мине тапсын. Исмәгыйль минем исем, бригадир... *(Нурига кырын карап.)* Да, кияү диген. Кунакка кайткан, имеш... Тәмәке тартырга өйрән. *(Чыгып китә.)*

Нури *(аптырап).* Нинди кеше соң бу?

Катык тутырылган савыт күтәреп, Мөнирә керә.

Мөнирә. Менә рәхәтлән, кияү. Тешеңне сындырырлык.

Нури. Мин монда бер кешегез белән таныштым. Бөтенесе дә шундыйлармы сездә?

Мөнирә. Нинди?

Нури. Чырае җимерек. Сөйләшүенең рәте-чираты юк. Миндә үче бар кеше шикелле. Авылыгызның бөтен кешеләре шулай булса, Аллам сакласын.

Мөнирә. Кем соң ул?

Нури. Исмәгыйль, ди, бригадир, ди.

Мөнирә. Исмәгыйль абыймы? Исмәгыйль абый кебек ачык йөзле, яхшы кешене син бөтен Казаннан эзләп табалмассың.

Нури. Табылмавы хәерле. Мин аңа бабай дип дәштем, җитмәсә. Яле, карточкасын бир әле бабайның, тагын бер карыйм. Бөтенесе бертөсле.

Мөнирә *(ридикюленнән карточка чыгарып бирә).* Кайтып төшәргә өлгермәдең, ошамый да башлады.

Нури *(үз-үзенә).* Авыл кешесе авыл кешесе инде. Мәгънә җитеп бетми...

Мөнирә. Шул авыл кызына өйләндең ич.

Нури. Синең авыллыгың... Тәмәке тартырга өйрән, ди.

Мөнирә. Йә, ярый. Киткәндә икенче төрле сөйләрсең әле. Мә салкын катык, кызуыңны басар. *(Болдырга менеп, чиләк-көянтә алып төшә.)*

Нури. Кая барасың?

Мөнирә. Салкын чишмә суы алып кайтып куйыйм. Әйдә, минем белән.

Нури. Әй-лә, кәефем бозылды.

Мөнирә. Чебен тимәс чер итәр. Бигрәк тиз бозыла кәефең.

Көлеп чыгып китә. Нури күлмәген салып элә дә катык ашый башлый. Гөлбикәнең тышта: «Нәфига, Нәфига!» — дигән тавышы ишетелә. Нури тиз генә күлмәген киеп куя.

Гөлбикә *(керә).* Нәфига! Нәфига күрше! *(Җавап ала алмагач, болдырга бара. Нурины күрә.)* Абау, җаным, кем бу? *(Гөлбикәнең үз-үзен тотышында да Исмәгыйльгә хас сүлпәнлек, чырае да шулай ук караңгы.)*

Нури. Исәнмесез.

Гөлбикә. Шөкер әле. Нәфига күрше өйдә юк мәллә?

Нури. Юк шул.

Гөлбикә. Менәтерә, ә. Кирәк ие. Син кем соң?

Нури. Кияүләре.

Гөлбикә. Шулаймыни... Кирәк ие бит, ә. *(Чыгарга таба борыла. Аягы белән бәрелеп, кармак сапларын аудара.)* Хәерсез. *(Кармак сапларын аягы белән этәреп җибәрә дә чыгып китә.)*

Нури *(тәмам аптыраган).* Әллә нинди кешеләр.

Мөнирә кайта.

Мөнирә. Ни сөйләштегез Гөлбикә әби белән? Әкәмәт карчык ул. Бер сөйләшә башласа, качып котылып булмый. Энәсеннән алып җебенә кадәр җентекли-

җентекли сораша. Без кайтканны белеп, кунакка чакырырга кергәндер әле. Чакырдымы?

Нури. Чакырды. Әйдә, җыена башла. Син нәрсә, мине үртәр өчен мактыйсыңмы авылың кешеләрен? Дөресен әйт инде, исең китмәсен, безнең авыл кешеләре шулай томана инде, диген.

Мөнирә. Юкны сөйләмә.

Нури. Монысына түзәрсең дә. Әби белән бабай шундый булса нишләрсең?

Капкадан Харис белән Нәфига керәләр. Аларның хәл-халәте дә Исмәгыйль белән Гөлбикәнеке кебек. Мөнирә, әтисе белән әнисен күрүгә, аларга ташлана, икесен дә кочып үбә.

Мөнирә. Без инде үпкәләп китәргә җыенган идек. Кайтып төштек, сез юк. *(Нурины күрсәтеп.)* Әти, әнә киявегез.

Харис *(Нури янына килеп, салкын гына күрешә)*. Саумы, кияү.

Нәфига да Нури белән кул биреп күрешә, ләкин «саумы, кияү»дән башка сүз әйтми. Шатлыклы очрашуны көткән Нурига бу чөй өстенә тукмак кебек тәэсир итә. Ул бөтенләй коелып төшә.

Нәфига. Нигә өйгә кермәдегез?

Мөнирә *(шат)*. Киявегез сездән башка өйгә керергә ашыкмасын әле, дидем.

Нәфига *(болдырга таба атлап)*. Әйдәгез.

Нури *(үзен үзе кулга алып, шат булырга тырышып)*. Ә без сынатмадык, салкын катык белән сыйландык.

Нәфига *(исе китмичә генә)*. Әйбәт булган.

Мөнирә. Ә мин салкын чишмә суы алып кайтып куйдым.

Харис. Шулаймы... Ярар... Нәфига, самоварыңны куй. Сусап кайтканнардыр. Мин озакламый кайтырмын.

Мөнирә. Әти, кая барасың?

Харис. Исмәгыйльне күрәсе иде. Барыгыз, керә торыгыз. Бар, кияү, ятсынма.

Ишектән кереп киткән Нәфига артыннан Мөнирә белән Нури иярә. Нуриның атлавы атлау түгел, әйтерсең лә аны бауга бәйләп сөйриләр. Ишегалдында берьялгызы калган Харис әрле-бирле йөренә, Нуриларның чемоданын, гамьсез генә, җирдән алып, болдырга менгерә. Кармак сапларын сөяп куя. Аннан капка ягына сүлпән генә атлый. Өйдән Нәфига чыга.

Нәфига. Сиңа әйтәм, кер инде. Барырсың... Бергәләп чәй эчеп алыйк.

Харис туктап уйланып тора да теләр-теләмәс кенә өйгә керә. Пауза. Өйдән Мөнирә чыгып, чиләк белән су алып кереп китә. Бераздан ишектә Нури күренә. Йөзе ачулы.

Нури. Ял ит, күңел ач, Нури, рәхәтлән!

Мөнирә чыга.

Мөнирә. Нигә чыгып киттең?

Нури. Нишләргә кирәк иде соң миңа? Авыз йомыш уйнап утырыргамы?

Мөнирә. Сиңа ошап булмас инде.

Нури. Ә сиңа ошыймы? Кунак каршылауның нәрсә икәнен беләм мин.

Мөнирә. Кунак дип биеп йөрмәсләр инде.

Нури. Алар миңа килсә, мин биер дә идем, бишкә ярылыр идем. Юк, монда нәрсәдер бар. Бөтенесе бергә сүз куешкан кебек.

Мөнирә. Арыганнардыр. Яшьләр түгел ич.

Нури. Эш аруда түгел. Аларның минем белән сөйләшәселәре килми. Минем кайтуым ошамый аларга. Бәлки, башка кияү көткәннәрдер. Сиңа кияүне үзләре сайлап куйганнардыр.

Мөнирә. Әллә ниләр уйлап чыгарма. Язган хатларын үзең укый идең.

Нури. Хатта нәрсә язмаслар.

Мөнирә. Нигә миңа ачуланасың? Әйт соң үзләренә.

Нури. Шул гына җитмәгән. Куып чыгарырга да күп сорамаслар.

Мөнирә. Җүләрләнмә. Әйдә, ал чемоданны. Чәй кайнагандыр.

Нури. Чәй кирәкми миңа, ачык чырай кирәк.

Мөнирә. Ачык чырайны бүтәннәрдән генә таләп итмә. Үзең дә бит әле турсаеп йөрисең.

Нури. Әллә берүзем, дурак кеше шикелле, шаркылдап көлеп утырыйммы? Минем нинди икәнне беләсең. Берәүнең дә зарланганы юк.

Мөнирә. Акрын, кемдер чыгып килә.

Харис *(өйдән чыга)*. Нигә монда торасыз? Барыгыз, чәй өлгергән. Гаеп итмә, кияү, мин барып кайтыйм әле. *(Капкадан чыгып китә.)*

Нури. Йә?

Мөнирә *(ул да уйга калган).* Ни булган соң, чыннан да? Минем әти болай түгел иде. Үзләре моннан бер ай элек кунакка чакырып яздылар. Әллә берәр кайгылары бармы?

Нури. Булса әйтсеннәр, мин бит алар кайгысыннан көләргә кайтмадым.

Мөнирә. Әйттем мин сиңа, телеграмма сугыйк, дидем.

Нәфига чыга.

Нәфига. Нигә кермисез? Әйдә, кияү.

Мөнирә. Әни...

Нәфига. Нәрсә, кызым?

Капкадан Гөлбикә керә.

Гөлбикә. Нәфига! Син кирәк иең.

Нәфига. Нәрсә, Гөлбикә апа?

Гөлбикә. Сүзем бар ие.

Нәфига Гөлбикә янына бара. Гөлбикә аны капканың теге ягына алып чыгып китә. Нури аптыраганнан көлеп җибәрә.

Мөнирә. Нигә көләсең?

Нури. Юк, мин бернәрсә дә аңламыйм. Кайда соң без? Кешеләр арасындамы? Сөйләсәң, ышанмаслар. *(Көлеп.)* И, Казанда йөргән булдык. Әбигә ефәк күлмәк, бабайга костюм эзләдек. Бүләк, янәсе. Рәхим ит, Нури, бир бүләкләреңне. Тик кемгә бирергә? Кеше юк ич бу өйдә. Китик, булмаса, Мөнирә.

Мөнирә. Кая?

Нури. Казаныбызга.

Мөнирә. Нури!.. Нигә син...

Нури. Йә, кирәкми. Синең дә кәефең бозылса, аннан бөтенләй түгәрәкләнә. Нәрсәгә шулай борчылырга соң? Гомер яшисеме? Ун көнгә түзәрбез, шулай бит? Курыкма, сиздермәм. Янымда син булгач, миңа шул җиткән. Көндезләрен кызынырбыз, балык чирттерербез. Кайтып йокларга чоланнарын бирсәләр...

Мөнирә. Алай түгелләр иде бит алар, алай түгелләр иде. Әгәр бердәнбер кызлары аларга артык икән...

Нури. Ачуланыша күрмә тагын. Үзләре беләләрдер. Син мине яратасың, мин сине яратам. Иң кирәклесе шул... Әйдә, ясаган чәйләрне эчик. Без андыйлар түгел. Без кунак та була беләбез, кунак та итә беләбез.

Пәрдә.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Вакыйга шул ук урында бара. Бер көн узган. Вакыт иртә. Кояш яңа гына чыгып килә. Пәрдә ачылганда Нәфига, тыз-быз чабып, әле өйгә керә, әле чыга. Иртәнге аш әзерләп йөрүедер, күрәсең. Менә ишектә Мөнирә күренә. Ана белән кыз болдырда очрашалар.

Нәфига *(шат, әйтерсең алыштырып куйганнар)*. Тордыңмы, кызым, бәбкәчем? *(Кочагына алып сөя.)* Бердәнберем минем. Кияү йоклыймы?

Мөнирә. Йоклый.

Нәфига. Йокласын, тимә. Йокысы туйганчы йокласын. Атаң белән сөйләштек әле. Бигрәк килмәгән җире юк инде. Холкы да төсе-бите, буе-сынына тартса, дөнья күрке инде, дөнья күрке. *(Мөнирәгә сокланып карап.)* Кызыбыз да шул безнең былбылга тиң. Юынып ал, кызым, умивалнеккә яңгыр суы тутырып куйдым. Хәзер сөлге алып чыгам.

Мөнирәнең аркасыннан сөеп кереп китә. Мөнирә әнисенең кинәт үзгәрүенә аптырап калган.

Нәфига *(әйләнеп чыгып)*. Кызым, иртән нәрсә ашарга ярата кияү?

Мөнирә. Белмим тагын. Ни булса, шуны ашый иде.

Нәфига. Син — ир хатыны, кызым, белергә кирәк... *(Мөнирәнең кәефе юклыгын күреп.)* Нигә син алай күңелсез, кызым? Кичә дә үпкәләгән сыман нәрсәдер әйттең бугай.

Мөнирә. Әйттем дә, ишетмәдегез бит.

Нәфига. Әллә куйган ризыкларым ошамадымы?

Капкадан Харис керә.

Харис. Бәй, кунак кызы торган да. Нихәл, кызым? Нигә алай иртә? Кияү кайда?

Нәфига. Шулкадәр кычкырмасаң. Әкрен. Йоклый.

Харис *(тавышын әкренәйтеп)*. Уятырга кирәк. Йоклап ята торган көнме?

Нәфига. Тик кенә тор. Кайчан уянасын үзе белер.

Харис. Йокласын, алайса, тимәгез. *(Ашыгып капкадан чыга башлый.)*

Нәфига. Кая китәсең тагын?

Харис. Мәрзияне әйтәм, кибетен ачмый.

Нәфига. Ачмаса, сиңа нигә?

Харис. Сабыр, анасы. *(Чыгып китә.)*

Нәфига *(кинәт исенә килеп).* И Ходаем, мичем нишли икән?

Ашыгып кереп китә, Мөнирә юына. Нури чыга.

Нури. Хәерле иртә, Мөнирә. *(Кояшка карап.)* Соңга калганмын балык чирттерергә.

Мөнирә. Син әнине күрдеңме?

Нури. Юк. Кухняда нишләптер йөри иде. Күренмәскә тырышып чыгып шылдым. Ә нигә?

Мөнирә. Болай гына.

Нури. Ну, кызык иттем үзем дә. Сез дәшмәсәгез, мин дә дәшмим, дидем дә авызга су кабып тик утырдым. Мин йоклагач та, шулай сөйләшми утырдыгызмы?

Мөнирә. Сөйләштек.

Нури. Рәтлерәк кияү таба алмадыңмыни, диләрме?

Мөнирә. Аларның синең белән миндә эшләре юк иде. Бүген күрсәң үзләрен.

Нури. Нишләгәннәр?

Мөнирә. Телләрендә кияү дә кияү.

Нури. Хәерлегә булсын! *(Тирә-якка каранып.)* Әллә яңгыр яуган инде?

Мөнирә. Төнозын дөбер-шатыр килеп яуды. Сизмәдең дә, йокладың.

Нури. Димәк, нервылар нык. *(Зарядка ясый.)* Үзгәргәннәр, дисеңмени?

Мөнирә. Үзгәрмәгәннәр. Элеккечә.

Нури. Яхшы. Үрдәкләренә каз куя беләбез без. Болай эш чыкмас, ошамаса да, булганына риза булыйк, дигәннәрдер.

Ишектә Нәфига күренә дә, яңадан кереп китеп, кулына кружка тотып чыга.

Нәфига. Кияү дә торган икән. Әйбәт йокладыңмы, кияү? *(Кружканы Нурига биреп).* Мә, кияү, шуны эчеп җибәр, иртән сауган сөт бик файдалы була ул. *(Нури кружканы ала.)* Тынычлап йоклый да алмагансың инде. Без авылда шулай иртә торабыз шул. Өйдә тынчу да. Печәнлеккә урын әзерләргә кушармын бабаңа. Кайнар коймак чыгарыйммы, кияү?

Нури *(гаҗәпләнеп).* Рәхмәт, әби.

Әби сүзен кияве теленнән ишеткәч, Нәфиганың йөзе тагын да ачыла. Куануыннанмы, оялуыннанмы, йөгереп диярлек кереп китә.

Нури. Әкәмәт!.. Әкәмәтище!.. Үзгәргәннәр. *(Юына.)*

Капкадан Гөлбикә керә. Йөзе шат, йөрүендә җиңеллек, яшәреп киткән кебек.

Гөлбикә. Торгансыз да икән. Йокыгыздан бүлмим дип, керергә базмыйча йөрдем. Кул биреп күрешеп чыгыйм, дидем. *(Күрешә. Нуриның аркасыннан кагып сөя.)* Бәхетле кияү. Авылыбызның бәхете гел бәхетле кияүләрдән. Кайсын гына алып карама, бөтенесе шул. Сания кызы Әлмирәнең Исламы дисеңме, Хәйруллалар кияве Саматны әйтәсеңме, үзебезнең Фәритебез тагын... Кызларыбыз әйбәт шул. Әйбәткә әйбәтне насыйп итә. Әле беркөн Хәмдебану ахирәт белән сөйләшеп утырдык. *(Мөнирәгә.)* Сине искә төшердек. Кияүгә чыкканыңны ишеттек тә, без карт-корының шул бит инде аның, бик сөенештек. Теләк теләдек. Ишеттек, Нәфига белән Харис күршеләрне туегызга чакырганыгызны да ишеттек. Бара алмадылар шул. Йорт-җирегезгә үзем күз-колак булырмын, дип тә әйтеп караган идем. Мин карчыкка ышанмадылар, ахрысы. Менә шулай яшәп ятабыз инде без, Мөнирә кызым. Көн туса, көнем күршеләремдә үтә. Үзең эшкә ярамый башлагач, кешеләр эшләгәнгә куанып, шөкер кылып йөрисең инде. Кияүнең исеме ничек?

Нури. Нури.

Гөлбикә. Абау, бигрәк килешле исем. Нурисламмы, Нуриәхмәтме? Юкса безнең авылда кайберәүләр балаларына әллә ниткән исемнәр тагып бетерәләр. Әлбирт, Мәлбирт. Әйтә дә торган түгел. Үзебезнең кияү Миңнефәрит тә баласына Ирек дип кушкан. Хатлары килде.

Нәфига чыга.

Нәфига. Нихәлләрең бар, Гөлбикә апа?

Гөлбикә. Бүген Аллага шөкер, диген, Нәфига күрше. Менә мин тагын кереп җиттем әле.

Нәфига. Әйдә, әйдә, үт.

Гөлбикә. Юк, үтеп тормыйм, Нәфига күрше. Менә кияү белән Мөнирәне алмага кергән ием.

Нәфига. Иртә таңнанмы? Әле аларның ашаган-эчкәннәре дә юк.

Гөлбикә. Аллага шөкер, ашарга да, эчәргә дә хәстәрләдем.

Нәфига. Юк, юк! Әле үзебезнең дә күреп туйганыбыз юк.

Гөлбикә. Күреп туймадык дип... Үзегез дә керегез. Бездә рәхәтләнеп сөйләшеп утырырбыз. Бәхетле кияүнең аягын бусагама бастырасым килә.

Нәфига. Кыстама да, Гөлбикә апа. Кайнар коймагым өстәл өстендә. Әйдә, үзең кер. Әйдә, кияү, суынганчы ашап алыгыз. Кая китеп югалды инде бу Харис?

Гөлбикә. Башта безгә кермәсеннәр дисеңмени инде, Нәфига?

Нәфига. Керерләр. Сезгә дә керерләр.

Гөлбикә *(Нәфига өстендәге ефәк күлмәкне күреп).* Абау, нинди затлы күлмәк кигәнсең, Нәфига.

Нәфига. Киявем бүләге, Гөлбикә апа.

Гөлбикә. И-и-и!.. Кайлардан гына таптыгыз бу чама затлы әйберләрне? Сөбханалла!

Нәфига. Хариска —кәчтүн-чалбар.

Гөлбикә. И-и-и! Менәтерә. Вәт бит, ә! Ала белеп алуларын әйт әле син!

Капкадан, атылып, Исмәгыйль килеп керә.

Исмәгыйль. О-о! Менә бу миңа ошый. Мин килгәнне көтеп торалар. Шулай, бригадирны аягүрә каршыларга кирәк. Йә, саумы, кияү? Әби белән бабай мунча ягып чабындырдыларммы әле?

Нәфига. Синең шул, рәтле сүзең булмас.

Исмәгыйль. Нигә, ялгыш әйттемме әллә? Нәфига апа, барыгыз әле, өйгә керегез. Бар, син дә, Гөлбикә әби. Мөнирә, син дә.

Гөлбикә. Нигә куасың әле, син кем?

Исмәгыйль. Барыгыз инде, нәчәльство әйткәнне тыңлагыз. Ашыгам, эшем күп.

Нәфига, Гөлбикә, Мөнирә кереп китәләр.

Исмәгыйль. Йә, нихәл соң, кияү?

Нури *(ни булганын һаман аңлап бетермичә).* Яхшы.

Исмәгыйль. Молодец! Исемең ничек дидең әле, хәтердән чыккан.

Нури. Мин әле сезгә аны әйткәнем дә юк. Нури.

Исмәгыйль. Нури? Молодец! Кара әле, Нури кияү, мин ашыгам, әйеме. Син ничек болай, ниме?

Нури. Нәрсә?

Исмәгыйль *(кесәсеннән аракы шешәсенең башын күрсәтеп).* Аз гына, очрашу хөрмәтенә диимме...

Нури. Без кичә очраштык бугай.

Исмәгыйль. Аны искә алма әле син. Әйдә, Нәфига апаң чыкканчы... Хатын-кызның күрмәве хәерле. Бәхетле син, Нури туган. Шуңа хөрмәтем. Кунакка чакырып сыйлау икенче булыр, бусы бераз гына, аяк өсте генә. Закуска әйбәт,— каклаган каз боты. *(Кесәсеннән кәгазьгә төргән каз боты чыгара.)* Күп түгел, икебезгә бер чөлли. Әллә син андыйны авызга алмыйсыңмы? Алай булса гафу ит.

Нури. Юк, эш анда түгел. Уңайсыз.

Исмәгыйль. Син миннән тартынма, туган. *(Кесәсеннән рюмка чыгара.)* Менә Мәрзиядән городской стакан да ала килдем. *(Рюмкага салып.)* Тот әле. Юк, син әллә ни уйлама. Мин дә моның белән артык шаярмыйм. Бүген көне шул! Йә!.. *(Нури эчә.)* Молодец! *(Каз ботын Нурига тоттырып, үзенә салып эчә. Нури каз ботын кире кайтара.)* Юк. Миңа кирәкми. *(Һава иснәп.)* Вуздыхы әйбәт, закускаң бер читтә торсын. Тагын бернеме?

Нури. Җитәр.

Исмәгыйль. Ну, анысын үзеңә кара. Мин тагын берне әмәллим дә шабаш. *(Салып эчә дә шешәсен болдыр астына яшереп куя.)* Калганы торсын. Алай-болай кирәк булса карарсың. Мыскыл итә дип уйлама, Харис абый аракы белән дус түгел, аракы эчкән кешеләрне җене сөйми. Ә син— яшь кеше.

Тәрәзә ачыла. Анда Нәфига.

Нәфига. Кияү, Исмәгыйль, өйгә керегез.

Исмәгыйль. Булды. Кем, Нәфига апа, бетте. Хәзер керә.

Тәрәзә ябыла.

Нури туган, бүген кич безгә килеп чыгарга вакыт табарсыз бит? Кәнишне! Молодец!

Нури. Кичә мин сезне бабай дип торам.

Исмәгыйль. Ә, чепуха. Була ул. Унбиш көн кырынмаган идем. Бүген менә унсигез яшь. Ярамый, туган, кырынмый йөрергә, ярамый. Бригадир гына булсаң да — командир, синнән үрнәк алалар. *(Кармак сапларына күрсәтеп.)* Синекеләрме? Әйбәт. Ну, мин сиңа күрсәтәм балыкның кәттәләрен. Салган саен —кызылканат. Мотоциклда йөри беләсеңме?

Нури. Беләм.

Исмәгыйль. Молодец! Кирәк булганда оялма, Исмәгыйль абый, давай, диген, вәссәлам. *(Болдыр астына ишарәләп.)* Тагын бергә нәфесең юкмы?

Нури. Юк, юк. Рәхмәт.

Исмәгыйль. Кичәге өчен миңа ачуланмыйсыңмы?

Нури. Нигә?

Исмәгыйль. Рәтләп сөйләшеп булмады ич. Ачуланма, туган, дөнья бит.

Нури. Кичә, чыннан да, икенче төрле идегез шул. Сез генә түгел, Гөлбикә әби дә, бабайлар да. Бүген бөтенесе үзгәргән.

Исмәгыйль. Булгандыр, булгандыр. Син үзең шәһәрдә туып үстеңме?

Нури. Әйе.

Исмәгыйль. Сиңа аңлавы читенрәк шул алай булгач. Болай бит, туган...

Харис кайтып керә.

Исмәгыйль. О-о! Әнә хуҗа да кайтты. Саумы, Харис абый.

Харис. Ничәнче тапкыр исәнләшәсең инде. Кияү, нихәл, әйбәт йокладыңмы?

Нури. Рәхмәт, бабай.

Харис. Йә, Исмәгыйль, ни әйтерсең безнең кияү турында?

Исмәгыйль. Молодец!

Харис. Бабасына охшаган. Нәкъ менә шундыйдыр дип уйлаган идем.

Нури. Иртә мактыйсың түгелме, бабай?

Харис. Алай димә, кияү, синең хатларыңны укыйбыз без. *(Нури кулындагы каз ботын күреп ала да, мәгънәле итеп, Исмәгыйльгә карый.)* Син нәрсә?

Исмәгыйль *(Нурига күз кысып алып)*. Юк инде, әллә мине белмисеңме, Харис абый? Гөлбикә әби күчтәнәче ул. *(Үзе аягы белән болдыр астындагы шешәне эчкәрәк этәргә тырыша. Шешә ауган тавыш ишетелә.)*

Харис. Тукта әле, тукта. *(Иелеп болдыр астына карый. Шулвакыт чалбар кесәсеннән шешә төшә.)*

Исмәгыйль *(көлеп)*. Эләктең бит, Харис абый.

Харис. Әкрен, Нәфига апаң ишетмәсен. *(Шешәне кесәсенә салып куя.)* Айга-елга бер аракы эчәсең, шуны

да адәм рәтле итеп эчмисең. Нәрсә, безнең өйдә урын беткәнмени?

Исмәгыйль. Ашыга идем, Харис абый. Аннан соң өйдә Нәфига апа, Гөлбикә әби дигәндәй.

Харис. Шулай дисәң инде. *(Кесәсендәге шешәгә ымлап, Нурига.)* Кияү, син гаепкә алма инде. Мин үзем болай да... Бердәнбер кияү кайткач...

Исмәгыйль. Ярый, мин тайыйм әле, Нури кияү.

Харис. Кая ашыгасың? Әнә болыт та килә. Кияүгә дә күңеллерәк булыр.

Нәфига чыга.

Нәфига. Уф Алла! Кайткансың икән. Әйдәгез инде. Кияүне ачка үтерәсез ләбаса.

Көчле күк күкрәү ишетелә. Харис, Исмәгыйль, Нури күкрәү тавышы ишетелгән якка карыйлар. Болдырдан Нәфига төшә. Өйдән Гөлбикә белән Мөнирә дә чыгалар.

Харис. Килә, тагын килә.

Гөлбикә. Рәхмәтең белән, хәерең белән кил.

Исмәгыйль. Бүген төнлә уянып китсәм, Харис абый, ява бит, ява. Урамга йөгереп чыгып, бөтен авылны уятырдай булдым.

Харис. Ә кем йоклаган дисең син? Җаны булган кеше шундый чакта йоклап ятамы? Тагын бер-ике генә көн яумаса да, барысы янып-көеп бетә иде бит.

Гөлбикә. Киявебез, Харис күрше, киявебез алып кайтты яңгырны. Бәхетле кияү. Рәхмәт төшкере. Гомере озын булсын.

Нури. Мин?.. Ничек?

Харис. Син, кияү, Мөнирә кызым белән икәүләп. Игеннәр генә түгел, үзебез дә кара көя башлаган идек. Яшәүнең кызыгы бетә башлаган иде. Хәтта сез дә күзгә күренмәдегез кичә. Кайгыбыз бик зур иде шул.

Нури. Без кайтмасак, яумас идеме?

Нәфига. Анысын кем белә инде, кияү. Тик сез кайткач явуы хак.

Мөнирә *(көлеп)*. Кичә куркуга төшердегез...

Гөлбикә. Шул яңгыр булмау галәмәте. Игеннәр тишелеп чыкканнан бирле тамып та караганы юк иде бит. Аптырагач, кичә Алладан сорап карыйк мәллә дип, карт-корыны җыярга уйлаган иек. Нәфига күрше риза булмады. Кеше көлдереп йөрмәгез, дип әйтте.

Исмәгыйль *(көлеп)*. Алладан сораганны Нури кияү алып кайтты диген, Гөлбикә әби.

Нури. Безнең заманда яумаса да куркыныч түгел. Монда булмаса, башка җирдә ява.

Мөнирә. Икмәкне башка җирдән китерерләр иде.

Харис. Хикмәт андамыни, балалар! Ачтан үлүдән курыкмыйбыз. Тик җир кысыр кала иде бит. Янган-көйгән басуларыбызга карап, читтән килгән икмәкне ашаудан да авыр нәрсә бармы соң? Үзебезнең кулыбыз белән иккән икмәкне кулда тотып торуга ни җитә, син моны аңлап та бетермисеңдер, кияү. Рәнҗемә. Рәхмәт сиңа. Бәхет алып кайттыгыз, куаныч алып кайттыгыз.

Исмәгыйль. Әнә ышна җиренә сибә дә башлады.

Гөлбикә. Җир тәмам туена, Алла боерса.

Исмәгыйль *(сикеренгәләп такмаклый)*.

Яңгыр, яу, яңгыр, яу!
Майлы ботка казанда,
Тәти кашык базарда...

Эх, малай чак искә төшеп китте.

Харис. Тәти кашык, майлы ботка киявем белән кызыма. Кара, кияү, синең яңгырың бу!

Харисның сүзен җөпләгәндәй, күк күкри.

Пәрдә.

1967

Сораулар һәм биремнәр.

1. Үз сүзләрегез белән, кыска гына итеп, комедиянең эчтәлеген сөйләп бирегез.
2. Комедиядә конфликт үзенчәлеген нидә күрәсез? Нури белән Мөнирәнең әти-әнисенә, авылдашларына хәтере калуга китергән сәбәп җитдиме, аның көчле каршылыкка әверелүе мөмкинме?
3. Автор әсәрен ни өчен «комедия» дип билгеләгән? Аңлашылмаучылыктан килеп чыккан хәл сезгә көлке тоеламы?
4. Персонажлар арасында сатирик яки комик характерлар бармы?
5. Харис, Нәфига, Гөлбикә әби, Исмәгыйль образлары сездә нинди тәэсир калдырды? Аларның җиргә, үз хезмәтләренә мөнәсәбәтләрен аңлатыгыз. Монда сурәтләнгән авыл кешеләренең матур сыйфатлары турында сөйләгез.
6. Кунакка кайткан яшьләргә беренче көндәге (күренештәге) битараф мөнәсәбәтне сез аңлыйсызмы һәм аклыйсызмы?

Чынлыкта шулай булыр иде дип уйлыйсызмы? Фикерегезне дәлилләгез.

7. Беренче һәм икенче күренешләр арасындагы төп аерманы табыгыз. Ул нәрсәдә: табигатьтәме, кешеләрнең кәефендәме? Авыл кешеләренең чын йөзе һәм рухы кайсы күренештә тулы ачыла? Бу күренешләрдә кешеләрнең үз-үзләрен тотудагы аерымлыкны сурәтләү ярдәмендә автор нәрсә әйтергә тели? Ул үз максатына ирешкәнме?

8. Аңлашылмаучылыклардан файдалану М. Фәйзинең «Галиябану» драмасында да очраган иде. Бу яктан «Бәхетле кияү» комедиясен «Галиябану» драмасы белән чагыштырыгыз. Һәр әсәрдә бу алымның нәрсәгә хезмәт итүен ачыклагыз.

9. Гөлбикә һәм Исмәгыйльнең сөйләм телләрендәге үзенчәлекләрне табып күрсәтегез. Алар бу образларны җанландыруга хезмәт итәләрме?

Табигатьтән килгән мәрхәмәт

Сез алдагы сыйныфларда кайбер комедияләр белән таныштыгыз инде: V сыйныфта — «Хуҗа Насретдин», VI да — «Беренче театр», VII дә «Җилкәнсезләр» әсәрләрен укып өйрәндегез. Ул комедияләрдә искелеккә ябышып яткан, тискәре, киребеткән яисә үзен әллә кемгә куеп, башкалардан акыллырак дип санаган тинтәк, түбән җанлы кешеләрнең сатирик сурәтләнешен, аларның көлкегә калуын күрдегез.

«Бәхетле кияү» әсәре белән танышканда игътибар иткәнсездер: комедияләрнең икенче төрлесе дә була икән. Монда кешеләрдәге кимчелекләрдән көлү юк. Чөнки персонажлар — әйбәт кешеләр. Шулай да без «Бәхетле кияү»не укыганда елмаябыз, көләбез, яратып көләбез. Көлү нидән туа соң?

Көлү монда, беренчедән, мәзәк хәлдән туа. Ә ул мәзәк хәл аерым кешенең начарлыгыннан да, үзе өчен генә нинди дә булса файда эзләвеннән дә килеп чыкмый. Эш шунда: беренче мәртәбә кунакка кайткан кияүләрен һәм күптән күрешмәгән кызларын ни Харис агай, ни Нәфига апай бар дип тә белмиләр. Бу — татарларга һич тә хас булмаган нәрсә. Чөнки кияү безнең халыкта аерата хөрмәт ителә. Шуңа күрә Нури да, Мөнирә дә, нишләргә һәм нәрсә әйтергә белми, гаҗәпкә калалар. Төрлечә уйлап, фараз итеп карыйлар. Яшь кияү, үзен ошатмадылар дип уйлап, каенаталары һәм бу авыл кешеләре турында шактый ук ямьсез фикергә дә килә. Мәсьәлә икенче көнне төнлә яңгыр явып узгач кына ачыклана. Авылда күптән яңгыр яумаган,

игеннәрнең корылыктан харап булу куркынычы туган икән. Авылның карт-корысы инде яңгыр боткасы пешереп карау уена килгән, кияү белән кызны бар дип тә белмәү шундый мәшәкатьләр аркасында икән.

Һәр сәхнә әсәренең үзәгендә каршылык (конфликт) була. «Галиябану»да Исмәгыйль белән Галиябану, Хәлилләр арасындагы көрәш, «Хуҗа Насретдин»да Хуҗа белән Бики сәүдәгәр, Ахун, Колый тарханнар арасындагы тартыш. Бу әсәрләрдә конфликт ачык һәм кискен.

Ә «Бәхетле кияү» — үзенчәлекле әсәр. Монда ачыктан-ачык бәрелешкә кергән көчләр юк. Каршылык аңлашылмауда гына. Яшьләр авыл кешеләренең битарафлыгы үзләренә бөтенләй кагылмавын белмиләр. Тегеләре дә, олы хәсрәт алдында торганга күрә, кунакларга аңлатып бирүне башларына да китермиләр. Икенче күренеш беренчесеннән гомуми рухы белән тамырдан аерылып тора. Олыларның төшенке кәефләре, үзләрен авыл кешеләренә хас булмаганча тотулары белән ихласлык, кече күңеллелек, кунакчыллык арасында зур аерма бар. Әсәрне менә шул кызыклы һәм мавыктыргыч итә. Мөнирә һәм Нури белән бергә аптырап утырган укучының да, сер ачылгач, күңелендә канәгатьләнү хисе туа. Нәтиҗәдә персонажларның эш-гамәленә, кечкенә генә ялгышларына да көләсең, яратып, үз итеп көләсең. Исмәгыйль һәм Гөлбикә әбинең сөйләү үзенчәлекләре дә, «чөлли» белән булган кечкенә генә «маҗаралар» да укучыга ошый. Олыларның барысы да тыйнак һәм беркатлы, ягымлы һәм итагатьле, үз җирләрен җаны-тәне белән яратучы кешеләр булып гәүдәләнәләр.

Автор комедия әсәрләренә аеруча хас булган арттырудан да оста файдаланган. Беренче күренештә өлкәннәрнең, кунакларны санга сукмыйча, тыз-быз килеп йөрүләре — шуның бер мисалы. Әйтерсең лә шулай чабышып йөргәч, яңгыр ява инде. Ә бит чынлыкта, ни генә булмасын, кунакны алай каршыламыйлар. Ләкин комедия жанры мондый гайре табигыйлекне күтәрә. Чөнки мондый арттыру көлке тудыруга хезмәт итә.

Әсәрнең сәнгатьчә эшләнешендәге үзенчәлекләр башка якларда да күренә. Мәсәлән, беренче күренештә Исмәгыйль кояшның артык кыздыруыннан канәгатьсезлеген ачык сиздерә: «Берәр ракета тиеп бәреп төшерми, ичмасам»,— ди ул. Ә Нури — шәһәр кешесе, моның нигә әйтелүен аңламый, киресенчә, «шәп!» дип утыра. Чөнки аның кояшта кызынасы бар, ул ялга кайткан.

Яки әнә Нәфига карчык, икенче көнне йокыдан торгач, юынырга «яңгыр суы тутырып куйдым» ди. Ягъни төнлә яңгыр явып узганлыгы аңлашыла. Зиһенле укучы һәр ике очракта да эшнең нидә икәнен сизәргә мөмкин.

Драматург персонажлар теленең үзенчәлекле булуына да тиешенчә игътибар иткән. Монда һәркем, бигрәк тә өлкәннәр, үзенчә сөйли. Фразеологик әйтелмәләр[1] иркен кулланылган. Мәсәлән, «чебен тимәс, чер итәр», «бишкә ярылыр идем», «авызга су кабып», «үрдәкләренә каз куя беләбез без», «чырае җимерек», «чөй өстенә тукмак» һ. б. әйтемнәр, сүзтезмәләр әсәр телен баета, җанлы һәм халыкчан итә. «Бәхетле кияү» дигән исем үзе дә күп мәгънәле. Әлбәттә, Нури кайтмаса да, яңгыр яуган булыр иде. Аның бәхетле булуы монда гына да түгел. «Бәхетле кияү» дип аңа башта ук Мөнирә әйтә. Чыннан да, ул бәхетле. Чөнки әнә нинди сабыр, акыллы кызга өйләнгән, ул аны ярата. Әби-бабасы да тәртипле, туган җанлы кызлары һәм кияүләре өчен үлеп торалар икән. Бу авылның кешеләре, күрше-күлән мөлаем, кунакчыл, эшчән икән. Чыннан да, мондый авылга кияү булу — үзе бер бәхет.

---

[1] *Фразеологик әйтелмә* — телдәге тотрыклы тәгъбир.

Аяз Гыйләҗев
(1928—2002)

Әдәбият һәм сәнгатьнең тылсымлы дөньясы нидән гыйбарәт икән дип уйлана башласаң, бер закончалык ачыла: тормыш-чынбарлыкны өйрәнеп, шуны чагылдыра торган әсәрләр һәрвакытта да чынбарлыкка охшап кына тормыйлар. Аларда кайчак вакыйгалар, күренешләр, төрле хәлләр шундый итеп сурәтләнә, реаль тормышта болай була алмаганлыгын аңлап торасың. Тик нигәдер мондый әсәрләр күбрәк дулкынландыра, хыялны уята, шулай булырга тиеш, дип ышанып кабул итәсең. Хикмәт шунда: автор үзе без күрмәгән, аңламаган мәсьәләләргә төшенеп, кешеләр, дөнья турында көтелмәгән рәвештә уйланып яза. Тасвирланган вакыйгалардан бигрәк, ул ясаган ачыш гаҗәпләндерә, уйландыра, әсәрне дәвам итеп, үз уй йомгагыңны сүтә башлыйсың.

Менә шундый үзенчәлекле, берәүне дә кабатламаган, тормышның байлыгы дөнья малында түгел, кешенең изге күңелендә икәненә инанып, шуны әсәрләре белән раслап яшәгән язучы иҗатын өйрәнә башлыйбыз.

Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев 1928 елда Татарстанның Сарман районы Чукмарлы авылында укытучы гаиләсендә туа. Казан университетында укый, Казакъстан якларында төзелешләрдә эшләп ала. Университетны тәмамлагач, журналларда әдәби хезмәткәр һәм редактор вазифаларын башкара. 60 нчы еллардан башлап ул — татар әдәбиятының күренекле прозаигы һәм татар театры сәхнәсенә кызыклы пьесалар биргән драматург. Вакытлар үтү белән, аның «Өч аршын җир», «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят», «Мең чакрым юл», «Җомга көн

кич белән» һәм «Әтәч менгән читәнгә» повестьлары яңа мәгънәләре белән ачыла баралар. Әсәрләрнең исемнәре үк яшәүнең асыл сыйфатлары, кыйммәте турында уйландыра башлый.

Күренекле прозаик, үзенчәлекле драматург һәм үткен каләмле публицист буларак танылган Аяз Гыйләҗев Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә (1983 ел) һәм РСФСРның М. Горький исемендәге Дәүләт бүләгенә (1987 ел) лаек булды, аңа «Татарстан Республикасының халык язучысы» дигән дәрәҗәле исем бирелде (1993 ел).

ЯЗГЫ КӘРВАННАР

(повесть кыскартып алынды)

Җанны өшетә торган салкын коры кич килде.

Көндез алдаучан җылы булып торды да, төш авышуга, мә сиңа, зират тавыннан өзлексез җил исә башлады. Зират тавыннан, кояш баешыннан искән җил, гадәттә, үзәнлектә ышыкланып утырган безнең бәләкәй авыл өстенә язын-көзен — яңгыр, кышын исә кар-буран алып килә торган иде. Бүген битләрне аяусыз чәнчеп, кием-салымнарны әрсез йолыккалап, туктаусыз коры салкын җил исте, суытты, көн ямьсезләнде. Карткорылар мич яңакларын сыйпаштырып чамалап тордылар да тиз үк мичләргә ягып җибәрделәр, ишегалларында, җил үтәрдәй араннарда калган малтуарны җылы абзарларга куып керттеләр.

Көне буе ачык һавада уралганга, без көннең аз гына үзгәрүен дә сизеп-искәреп торабыз. Җил азаюына игътибар иттек, чын күңелдән сөенештек, ындырдан җиде олау солы төяп, төнгә каршы Чаллы элеваторына юлга чыгасыбыз бар иде.

Имән урамын чыгып бер җир буе киттекме икән, уң яктан, Олы су дип йөртелгән үзебезнең инеш буеннан, үзәнлектән җыр тавышы ишетелде. Бер кыз җырлый иде. Башта, бу суыкта, күз бәйләнгәндә кайсы исәре шырылдап йөри икән дип, мәзәк итеп кенә тыңлаган идем, кинәт калкынып турайдым, чикмән якамны кайтардым. Кызның тавышы аермачык ишетелә, ул йөрәкне өзәрлек моңлы, ягымлы иде.

Җил басылды, бөтенләй тынды-сүнде, атлар адымнарын акрынайттылар, сагайдылар, тәгәрмәчләр генә

әрсезләнеп шыгырдый, тын тартырга куркып, колакларымны үрә торгыздым. Кыз юлга таба чыга иде, ахрысы, чөнки аның тавышы яңгырабрак, моңы үтемлерәк, сүзләре ачыграк ишетелә башлады. Ни тырышсам да, кызны аермачык таный алмадым, җыры исә бөтен барлыгымны, арба-атымны, юлымны — барырымны һәм кайтырымны, каралып-куерып килгән офыкларны күмеп китте, онытылдым! Ташкын иде аның тавышы, моң дәрьясы иде!

Үз ирекләренә куелган атлар тагын да акрынрак атлыйлар, кызның сүзләре ап-ачык ишетелә башлады. Кыз кабат-кабат бер үк сүзләрне кабатлый икән.

Алтын булып агаем ла...
Көмеш булып тамаем!

Аның да күңелендә иләс-миләслек, ярларына сыешмаслык яшьлеге тулышып ага иде бугай, чөнки ул шушы сүзләре белән сихерләнгән, тылсымланган иде. Бары үзе өчен генә яшертен җырлавы, шуннан тәм табып бәхет эчендә йөзгәне аңлашылып тора, ул инеш үзәнлегендә, Олы су иңкүлегендә, алай гына да түгел, җир йөзендә, чиксез-үлчәүсез галәмдә бары тик үзе генә дип уйлый иде. Түбән авыл юлында җиде атлы аны тыңлап барадыр дип уена да кертмәгәндер.

Без — җиде кеше. Җиде төрле ата баласы. Толлар да бар арабызда, буй җиткән ятим кызлар да, безнең сыман егет-җилән дә бар. Кем елагандыр, кем сөенгәндер, бу җырны берәвебез дә ишетми калмагандыр...

Атлар Тирән чокырның караңгы авызына барып туктагач сискәнеп киттем: кем мин, кая барам болай?!

Иң арттагы аттан төшкән Дамир, кыскарак кәкре аякларын яза-яза, миңа якынлашты:

— Ибраһим, әй, ишеттеңме? — дип сорады.

— Саңгырау түгел лә,— дидем мин, атымның аркалыгын тикшереп.

— Син дә инде,— диде Дамир, кинәт үпкәләп.

Уңайсызланып киттем, һич уйламаганда, иптәшемне үртәп маташам икән ич! Сугыш безнең елгыларга да якыная башлагач, хәрби комиссариаттан кайтканда, Дамир: «Колак сызлый, малайлар, минем ишетүем хөрти»,— дип сөйләнгән иде. Андыйга сизгер егетләр шундук эләктереп алдылар: «Колакай да колакай!

Саңгырау да миңгерәү! Армиягә барырга дигәч, Дамирның колагына гөмбә үскән!»

Солдатка каралучылар теленә эләкмә, ник әйткәненә үкенгәндер Дамир... Яшьтән үк кушаматларга бай булды ул. Әтисе дә тапкан исем, тфү... «Тамыр» да диделәр аны, «Камыр» да, Дамир дип әле ничә ел гына эндәшә башлаганнар иде, хәзер «Колакай»...

Аны-моны абайламыйча мин дә шуңа ишарәләгән булып чыктым...

Чокыр тирәсендә бөялешеп торганда, җыр, тоныккына булып, тагын яңгырап китте, хәзер инде ул шактый еракта, сүзләрен дә, моңын да тәгаен аерып булмый, җыр авыл ягыннан минем йөрәккә тоташ моң булып кына сызылды, язын килгән тургайлар, былбыллар, барысы бергә җыйналып, китәр алдыннан безнең яклар белән хушлашып, суык шәфәкъкә карап, күмәк иңриләр төсле тоелды.

Каян килгәндер минем иләс-миләс күңелгә мондый чагыштыру, валлаһи, ул мизгелдә шулай уйладым!

Хәвеф-хәтәрсез генә бу шомлы урынны да уздык.

Хәзер атларны йолыккалау юк, аларны үз җаена куеп, җәяү генә барабыз. Дамир тагын минем яныма килде, камчы сабы белән юантык муенын кашып:

— Кем икәнен белдеңме? — диде.

Төпченеп баруына ачуым чыкты, искәрмәстән яңгыраган моңны үземнеке генә итәргә теләдем, шуңа күрә баягыдан да кырысрак итеп җавап бирдем:

— Йөри шунда тилереп!

— Югары очның Әдилә тутаң булыр ул!

Сискәнүемне белдермәс өчен йөткерендем, үзем дә Әдиләдер дип уйлаган идем аны! Шул икән, үзе икән...

Әдиләнең җырлаганын байтактан ишеткән юк иде. Былтыр яз, кар астында кышлаган башак ашап, Сарсаз авылында кияүдәге апасы үлде Әдиләнең, дүрт баласы тезелешеп калды. Әдилә шул ятимнәрне карарга Сарсазга җизнәләренә китте дә инде ике җәйне, бер кышны шунда уздырды. Җырны шунда өйрәнеп кайткан дисәм, ай-һай, дүрт сабый янында җырларга вакыты калды микән? Хатыны үлгәннән бирле, җизнәсе дә бик рәтсезләнгән, бик эчә дип сөйләгәннәр иде. Бөтенләйгә кайтты микән Әдилә әллә сагынып кунакка гынамы?

Әдилә... Әдилә... Бер-ике тапкыр чәчен тартып елатканым да бар... Ул үзгәргәндер, без дә үстек... Сылу гына кызлар Дамир белән безгә дә каш сикерткәлиләр хәзер, аулак өйгә чакыралар, чиккән кулъяулык бирәләр, ап-ак өч пар пирчәткәм агач чемодан төбендә ята...

Юк, Әдилә акылсыз бала түгел, Югары оч кызы булса да, мин аны әйбәт беләм, Сабирҗан абзый кызы, дүртенче-бишенчеләрдә укыганда ук, «Мирсәет бәете»н җырлап, карчык-корчыклардан балавыз сыктыра торган хисле, моңлы бала иде бит ул.

Дамир ничек танып алган диген, менә сиңа колакай!

Үзгәргәндер Әдилә, күрмәгәнгә ике җәй, бер кыш узды лабаса! «Көмеш булып тамаем» диме? Зарлану, кайгыру түгел ич монысы, кешегә, дөньяга, җиргә яхшылык теләү! Изгелеккә, юмартлыкка омтылып җирсенә бит кыз күңеле!

Арба тәгәрмәчләрем күңелле генә шыгырдыйлар...

Көмешне күргән бар анысы! Әллә нинди ят ил императорларының олысымак сурәтләре сугылган көмеш талирлар әбинең чулпысында чың-чың итеп китә торган иде.

Әдиләне элекке кебек итеп сәхнәгә чыгарасы иде бер, тамсын иде, чәчелсен иде көмеш булып!

Юк, Әдилә алай ансат кына билен бирмәс, усаллыгы да, чаялыгы да җитәрлек кызыйның. Берзаман, ул бишенчедә чакта, артык иртә калкынган күкрәкләренә уйнап кына кагылып киткән идем, сул яңагыма шундый чәпәде, искә төшкәндә хәзер дә кызарам...

Арба тәгәрмәчләрем шаярышып җырлашалар!..

Кайчан кайтты икән, кайчан?

Кайчан китә икән?

Китәме?

...Мытыестан ашыктырдылар, атна да узмагандыр, җәй буе йөрткән сбруйларымны Дамирга илттем, нык арыгайган, зур күзле юлдашым Озынъял белән саубуллаштым.

Такта чемоданга чабата киндерәсе белән киндер тышлы колак мендәрен бәйләдем дә Чаллыга юлга чыктым. Бу юлдан байтак кешеләрне әле сугышка, әле бәхет эзләргә Пермь, Ярослау якларына озатканым бар, хәзер үзем китеп барам, хәерлегәме? Дөнья безнең кулга күчеп бара торгандыр шул...

Имән урамын чыгуга, әллә нишләп күңелем тулды. Юк, авылдан китү, әнкәйдән аерылу сагышы түгел иде минем күңелдә. Чаллы ерак түгел, бик сагынсаң, җәяүләп кайтып килергә дә була! Минем күңелне моңарчы тоелмаган, моңарчы бар икәнлеге дә беленмәгән ят сагыш, ят моң биләгән иде. Имән урамының ава-түнә утырган иске-москы текмә читәннәренә тикле моңлы, сагышлы иде бүген... Колак төбемдә, тургай җыры кебек булып, сихри өн чыңлый иде.

«Алтын булып агаем-ла!..»
Әлә-лә-ләү!
«Көмеш булып тамаем!..»
Әлә-лә-ләү!..

Көн суык. Көн шыксыз. Юл кантарлары бозланып каткан. Ак чебеннәр оча, чокыр-чакырлы юлдан арба дырык-дырык бара. Дамир — олаучы, ул безне Чаллыга хәтле илтергә тиеш.

Дамир белән безнең аралар кызык кына була башлады. Ни атна, ни шимбә дигәндәй, тиктомалдан Әдилә турында сүз башлый да минем күңел кылларын тарткалап карый. Йә булмаса бер дә юкка Әдиләне яманларга тотына. Чигү-тегү эшен дә белми, имеш. Фәлән дә төгән, имеш. Аның кызыксынуын сизеп, мин дә сер бирмәскә булдым. Ак димим, күк димим, белми торсын әле!.. Малай җүләр түгел, сизенде, сизенгәч үчегешергә кереште. Юлга чыксак, атын иң алга куа. Кичке уенга җыелсак, минем сүзләрне очсызга чыгарырга тырыша. Гомергә уртага чыкканы юк иде, гармунчы чакырып, мунчаларында биергә өйрәнә башлаган! Күрегенең җиде җиреннән тын өреп торган җиде бакалы тальянын кардыга, ат караучылар йортына илтеп куйды, буш вакыты булдымы — шуны шырылдата, өйрәнә, янәсе! Гел алга чыгарга, гел узарга тели Дамир.

Минем курска барасын ишеткәч, шартлый язды малаең! Бусында үзем дә аны җәлләдем, өйләренә бардым.

— Әйдә, мин әйтәм, Хәкимҗан абзыйны кодалыйк, бергәләп укырбыз.

«Юк» дип кул гына селтәде бу. Мин үгетләргә тотынгач, серен сөйләп бирде. Теге вакытта военкоматтан «колагым каты» дип юрамалый әйтеп кайткан икән

ул! Төс аермый икән егет, дальтоник икән! Кызылы белән яшеле бер икән тегенең. Военкоматта караган күз врачы аңа кистереп әйткән: «Армиягә дә алынмыйсың, машинага да утырмыйсың, үзеңә бер һөнәр тап»,— дигән...

Тез астына суктылар егетнең! Без Чаллыга укырга китәбез, тирә-юньдә дан таралды, ә ул монда җимерек кардыда атлар янында кала...

Телгә алмыйм дип тырышсам да, Дамирга карауга шул искә төшә: кызыктыр инде ул, ә? Болыннар кызыл булып күренәме аңа? Ә шәфәкъ ямь-яшелме? Менә сул кул яктагы Сарсаз авылына хәтле сузылган уҗымнар аңа кып-кызыл булып күренәдер. Ә кызларның бит очлары ямь-яшел... Яшел иякле Әдилә!

...Имтиханнардан котылдык, кулга «тракторист» дигән документ тоттырдылар. Иптәшләр, укытучылар белән саубуллаштык та фатирларга таралыштык. Олау көтәбез. Алдан хәбәрләшкән буенча, безне алырга, ат җигеп, Дамир үзе килергә тиеш. Председатель айгырын җигеп килер микән әллә үзе җигеп йөри торган берәр җегәрле атта гына килерме?

Минем дә, авылдашым Торна Хәмитнең дә тракторист булып авылга шәбрәк атта юрттырып кайтып керәсе килә! Председатель айгырында выжлап авылга барып керәсе иде дә бит!..

Чаллыда ятып шәпләнгәч, тракторчы исемен алгач, борын күктә иде, авылга чана тартып кайтып керергә бик хурланган идек, ярый әле караңгы төште, авылдашлар безне күрми калды.

Дамирның көнләшүдән бавыры кабарган, белеп торам, ул минем таныклыкны ике тапкыр сорап алды, кат-кат укып, пичәтен иснәп карады. Эчемнән генә тантана иттем: менә җиңешеп караган идең, мөгезле чана сөйрәп калдыңмы, абзаң һөнәр иясе булды!

Курсларда укыганда, күңелләр күтәренке иде. Барыбыз да яшьләр, төрле районнардан җыелган булсак та, бик тиз дуслашып өлгердек. Чак кына дөнья мәшәкатьләреннән аерылып, дәреслекләрдә сөйләнгән, китапларда язылган тормыш беләнрәк яши башлаган идек без. Мин үземнең авылга кайтып керүемне дә шулайрак итеп, шәп итеп, һичьюгында тантаналы итеп күз алдыма китергән идем. Менә мин кайтып төшәм, янәсе... Председатель да куана, гомергә елмаймаган

хисапчы да кѳлә, әнкәй дә шатлана, агай-энеләрне әйткән дә юк!.. МТС директоры безне җыеп ала да әле яңа гына Бѳгелмә станцасыннан кайтып тѳшкән, буяу исе килеп торган тракторларга утырта... Музыка, байраклар, котлаулар.

Шушы тантананың бер читендә мин һәрвакыт Әдиләне дә күрә торган идем! Мондый күңелле киләчәктә Дамирга бик бәләкәй, бик кысан урын калдырган идем мин...

Кояш шактый күтәрелсә дә, идарәдә беркем юк иде. Җыештыручы Бәдәр җиңгинең борынына корым кунган, ул соңгарып кына мич томалап маташа, бүлмәгә зәһәр күмер исе чыккан иде. Борынымны җыерып беравык кѳтеп утыргач түзмәдем:

— Болар кайда соң? — дип сорадым.

Бәдәр җиңги дә, беренче күргәндәй, урындыкларга, таплы-таплы эскәмияләргә күз ташлады, тѳтен кызарткан сирәк керфекле күзләрен челт-челт йомгалап:

— Кайсысы кирәк ие соң сиңа? — диде.

— Соң, Хәкимҗан абзый кайда? Башкалар?

— Аларның ни, белмисеңме әллә?

— Белмим бит. Мин кичә генә Чаллыдан кайтып тѳштем.

Чаллы сүзенә дә исе китмәде Бәдәр җиңгинең.

— Кардыда алар,— диде, күзләрен сѳртеп.

— Нишлиләр анда?

— Тѳшеп кара, үзең күрерсең.

Тѳшәсе дә килә, килми дә. Монда, идарәдә, халык арасында очрашасы килә иде Хәкимҗан абзый белән!

Сикереп тордым да кардыга чаптым. Трактор белән җенләнеп йѳреп, мин үземнең канатымны, аерылмас тугры дустымны, шушы еллар эчендә ничәмә-ничә йѳз чакрымнар бергә узган Озынъялымны бѳтенләй хәтеремнән чыгара язганмын! Йѳз-мең чакрымнар узылган. Ә аның бер чакрымы да җәһәннәм баскычларын үтү белән бер иде ич!

Карды янына тѳшмәгән булсамчы!..

Озынъялым үлмәгән икән үлүен...

Дүрт җиреннән юан арканнар белән әрлеккә асылган ат мине танымады, мин аны... Дамир күрсәткәч кенә, янына бардым хайванның... Ул, зур күзләрен тутырып, миңа карады, таныды, дымлы борын тишекләрен кыймылдатып куйды, нәзек тавыш белән ыңгырашып

сәлам бирде. Юк шул, янымда сиңа дигән кучтәнәчем юк шул, акыллым... Кесәмдә икмәк кыерчыгы түгел, таныклык ул... Мин тракторчы дигән язу... Моннан соң синең яныңа буш кул белән төшмәм, бәрәңге кабыгы белән булса да сыйлармын үзеңне!..

Дамирга вак-төяк өчен үчегешеп маташуларым шундук онытылды, кичкә хәтле кардыдан чыкмадым, атларның асларын тазарттым, кыргыч белән ябагаларын кырдым, түбәдән су тама башлаган урыннарын ямадык...

Фураж да, солы да юк иде атларга, күгәрә башлаган салам белән җан саклап торалар икән бичаралар.

Кичке чәйдән соң мин тагын кәнсәләргә атладым. Бу юлы Хәкимҗан абзый берүзе генә утыра иде. Күрештек.

— Тракторчы дип кәгазь бирделәр,— дидем мин, юаш кына.

— Анысын булдыргансың,— диде ул, кәгазьгә кырын күзе белән генә карап.

Белдермәскә теләгән идем, үзеннән-үзе үпкәмне әйтеп салдым:

— Сөендереп булмады сине, Хәкимҗан абзый,— дидем.

— Сөенәм, үскәнем, бик шатланам.

— Кул кысып котламадың. Кәгазьдәге билгеләргә күз салмадың.

— Күңелем белән бик котладым, үскәнем... Тик күңел бит, әллә ничегрәк дип әйтимме... икегә бүленгән! Яртысы, олы яртысы җылый аның, үскәнем, синнән яшерене юк. Менә мартка кердек. Калхуз келәтендә бөртек симәнә юк. Күзгә кырып салырга бер бөртек журна юк! Атлар барысы өрлектә... МТС машиналарына өмет бар, мәгәр чират кайчан җитә?..

— Трактор бирәчәкләрме соң?

— Аннан ни файда? Инеш буеннан вак таш җыеп чәчәрсеңме? Менә бүген нәрәт килде. Сарман ягыннан. Кәсле дигән глубинкадан өч йөз центнер солы симәнәсе язганнар. Иртәгәдән шуны ташый башларга кирәк. Кәслегә иртәгәдән калмый, ишетәсеңме, иртәгәдән калмыйча, җитмеш биш чана чыгарырга кирәк. Ә ул җитмеш бишне әфсен укып җыясыңмы? Шүтке түгел, алтмыш биш чакрым диләр аны, Кәслене! Ә җибәрмәсәң — бәла! Атна-ун көннән юл өзеләчәк. Өзеләчәк,

көт тә тор, син ашыкканда гел шулай була ул, үскәнем. Ярты авыл — карт-коры. Яртысы — аксак та туксак. Менә син чана тартып Кәслегә барасыңмы? Кесәңдә дукамент, син дә трактор дауларга килгән!

— Дауламыйм, Хәкимҗан абзый,— дидем мин, тыйнак кына.

— Даула син, үскәнем, даула. Әгәренки даулашмасак, эшебез җайга китәчәк түгел безнең. Дауларга кирәк. Тракторын да, машинасын да — барын да даула! Булачак ул трактор, бирәчәкләр аны. Тик менә бүгенгесе кыен, Журна дигәне чәчне агарта! Солы Кәследә. Алтмыш биш чакрым!..

Шулчак ишек ачылды, ап-ак мамык шәлгә уранган, ак пирчәткә кигән түгәрәк кенә кыз килеп керде. Карадым да каттым: Әдилә ич бу!

Председательгә әллә ни әйтмәк булам, телем тотлыга. Әдилә Хәкимҗан абзый белән оялып кына исәнләште дә миңа кулын сузды:

— Ибраһим да кайткан икән, исәнме.

— Мин кайтырга киткән... Менә син ничегрәк? — дидем туп-туры.

Ул шәл почмагына авызын яшереп көлемсерәде.

— Мин дә менә... җизнине өйләндереп кайттым.

— Ниндирәк кеше алды инде? — диде кызыксынып председатель.

— Анысын кем белсен инде, Хәкимҗан абзый! — диде Әдилә, җитди генә.— Күршеләрендә кодача тиешле бер апа бар иде. Ире сугыштан кайтмаган, бер малае белән тора. Шул ике тол бергәләп оя кордылар.

— Гомерле булсын,— диде председатель, ияген кашып.

— Бөтенләйгә, алайса? — дидем мин, шатлыгымны яшермичә.

— Бөтенләйгәдер инде,— диде ул, нигәдер миңа түгел, Хәкимҗан абзыйга карап.

— Кайтуың яраган,— диде ул.— Менә солы симәнәсе ташырга керешәбез. Син дә барырсың.

— Кая?

— Кәслегә.

— Бик якын икән! — дип көлде кыз.— Күршетирәдән, әйтик, шул ук Сарсаз глубинкасыннан симәнә алып булмыймы? Анда да бардыр ич солы? Әллә Кәследә мөгезлесеме?

Хәкимҗан абзый төксе генә елмайгандай итте:

— Ә-ә, үскәнем! Кыз бала шул син, җиңел уйлыйсың. Һе, хатын-кыз шул... Кайсы глубинкада нәрсә бары анысы инде аның — дәүләт сере. Сугыш сере белән бер анысы! Безнең катнаш юк анда. Менә Чаллыдан килгән нәрәт. Пичәт басылган, кулы куелган. Кәседән диелгән и бетте-китте. Барасыңмы?

— Ярар, барырмын,— диде Әдилә, җәберсенмичә генә.

— Мин дә барам,— дидем, кинәт кенә.

Хәкимҗан абзыйның чырае ядтырып китте, ул ике куллап чутка ябышты һәм чырт-чырт итеп төймәләрне авыштырды.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Вакыйга кайда һәм кайчан бара? Кем исеменнән хикәяләнә? Әсәр геройлары сездә нинди тәэсирләр, фикерләр уятты?
2. Кызның җырлавы һәм җыр үзе нәрсә белән чагыштырыла? Шул урыннарны табып, тагын бер кат укыгыз. Җырлаучыны күрмәгән, кем икәнен белмәгән килеш «ул инеш үзәнлегендә, Олы су иңкүлегендә, алай гына да түгел, җир йөзендә, чиксез-үлчәүсез галәмдә бары тик үзе генә дип уйлый иде»,— дип, нәрсәдән чыгып әйтеп була? Тыңлаучыларга җыр ни өчен шулай тәэсир итә?
3. Ибраһим белән Дамирның үзара мөнәсәбәтләрен анализлагыз. Аларның характер сыйфатларын, рухи халәтләрен аңлатып карагыз.
4. Табигатьне сурәтләгән урыннарга игътибар итегез. Бу күренешләр әсәргә нәрсә өстиләр? Алар әсәрнең кайсы яклары белән үзара бәйләнгәннәр?
5. Персонажлар барысы да бертөсле сөйләшәме? Сөйләмнәреннән чыгып, ул геройлар турында нәрсә әйтә аласыз?

Кәнсәләрдән без икәү чыктык. Язгы төн. Төн айлы, анда-санда гына юка болытлар ага. Урам яп-якты, инә эзләп табарлык. Урам буп-буш. Анда-санда гына тәрәзәләрдә зәгыйфь утлар җемелди, кеше күләгәләре уйный.

— Кайтыр юлың ерак, усал маэмайлар күп, озата барыйммы? — дидем мин, кыюланып.

— Эшең булмаса, бар,— диде ул.

Барабыз. Элек урам уртасыннан киң, төз ат юлы була торган иде, хәзер тар сукмак — атлаганда берберебезгә тиеп-тиеп китәбез.

— Иркен яшәдегез, ахры, Чаллыда,— диде Әдилә кинәт.
— Нигә?
— Бер матур белән танышкансың икән.
Эсселе-суыклы булып киттем.
— Каян белдең?
— Дамир сөйләде.
— Ә, Татлы тамыр! — дигән булдым мин.— Сөйләр ул!
— Бер дә ояты юк,— диде Әдилә олыларча,— әйбәт кыздыр бит?
— Беркем белән дә танышканым юк,— дип мыгырдандым мин.— Кирәге-кирәкләре бер тиен.
— Арзан бәяләдең син кызларны.
— Мин укырга бардым ич анда, Әдилә.
Юк, Әдиләгә ачуым килеп түгел, Дамирның сүзләренә каным кыза башлады! Каян уйлап чыгарган диген, белә малаең кайсы почмакта сагалап салып егарга кирәклеген! Сүзне тиз-тиз икенчегә бордым, югыйсә кызып ук китүем бар иде.
— Тутаңның балалары җылашып калдымы?
— Җыламый нишләсеннәр? Миңа ияләнделәр. Олы кызын алып кайттым әле, бездә торып торыр.
— Җизнәң нихәлдә?
— Җизнәгә нәрсә? Куенында яшь кәләш, авыз ерык...
— Өмете синдә икән дип сөйләделәр.
— Аның өмете булгандыр да, минем өмет башкада шул!
Әдиләнең шулай олыларча, кыю итеп, ачыктан-ачык сөйләшүенә исем китте.
— Кемдә инде ул синең өметең? — дидем мин, йөрәгем дөпелдәгәнен ишеттермәскә тырышып.
Әдилә көлеп җибәрде:
— Бик тиз белер идең бугай.
Сүзсез калдырды бу кызый мине, тәмам зиһенемне бутады. Беравык дәшмичә бардык.
— Әллә оныттыңмы? — дип сорады ул кинәт.
— Нәрсәне, Әдилә?
— Оныткан, икмәктер, оныткан!
— Әйт инде!
— Минем чәчне тартып китүеңне! Яңагыңа чалтыратуым хәтереңдәме?.. Әллә син башка кызларның да чәчен тарта идеңме?

— Онытмадым, Әдилә! Башкаларныкын тарткан булмады, кояштыр!

— Сөям дигән ымың түгел идемени ул, Ибраһим?

— Ай-һай, каты чәпәгән идең яңакка!

— Онытырлык булмасын дидем, Ибраһим... Егетләрнең хәтере кыска бит аларның... Яшене нинди, күкрәве шундый булсын дидем! Син дә чәчне тарткан идең бит... Яңагың шешмәгән идеме, кая, карыймчы, эзе калмаганмы?

Ул, ак пирчәткәсен салып, минем яңакны сөйде.

— Кытыршы,— диде ул.

Аның бармаклары йомшак, кайнар һәм хуш исле иде. Мин ихтыярсыздан аның кулын эләктереп алдым, икебез дә оялып читкә тайпылдык.

Аларның йорт турындагы карт тирәкләр тонык кына гөжлиләр.

— Иртәгә иртә торасы бар, Ибраһим,— диде ул.

Мин аның йомшак бармакларын учымда иркәләдем.

— Хушлашабызмыни, Әдилә?

— Иртәгә күрешәбез бит.

Аны-моны уйлап тормастан, аңа тартылдым, ул бер генә секундка минем кочагыма керде дә җитез җәнлек кебек йомылып чыгып та китте, борын төбемдә генә капка ябылды. Аяк тавышы ишетелеп торды, менә ул, тукран төсле генә тукылдатып, ишек шакыды, этисенең: «Кем йөри анда, кызым, синме?» — дигән карлыккан тавышы ишетелде...

Мин, Түбән оч бозавы, хат язарга куркып йөргән булдым! Үскән Әдилә, үзгәргән... Ике кыш, бер җәй дүрт баланы карап, гаилә башлыгы булып яшәгән кеше шул!

Күз алдым яктырып киткән кебек булды, күтәрелеп карасам, тулган ай болыт астыннан чыгып килә...

Бүгенге көн өчен вакыйгалар артык күп булса да, бер җепкә тезгәч, алар бары тик бер мәгънә алалар иде: әйе, яшәү җиңел булмаячак! Әмма яшәргә, тырышырга кирәк! Әйе, авыр, җәфалы, бөлдергеч сугыш беткәнгә кайчан гына бит әле! Күкрәкләр тыныч сулый башлаганга күпме вакыт узды... Әйе, безнең буын бәхетлерәк... без күкрәкләргә салкын мылтык түтәсе түгел, кызлар кыса алабыз...

Әдиләне озаткан кичтә мин, эссе көндә чишмә суын туйганчы эчкән кеше төсле, сафланып, тынычланып кайттым...

Кайтышлый Дамирларга кагылдым. Дамирның әнисе сорамый-нитми генә ишек ачты, кече якта сукыр лампа яктысында җеп эрли икән. Дамир, җылы яратканга, мич башына менеп утырган.

— Кем бар? — дип кычкырды ул, муенын сузарга тырышып.

Сырма төймәләремне чишеп җибәрдем дә аның янына мендем. Менгәч, сырманы салып ук куйдым. Мич төбе кап-кайнар, һава бөркү иде. Икебез дә аякларны асылындырып утырдык.

— Кайтып кына егылган идем,— диде Дамир, акланып.

— Чанагызны сорап торырга кердем. Беркөн Чаллыдан бик җилле алып кайткан иде.

— Кәслегә барасыңмы? — диде Дамир, бераз күтәреп.— Мин дә барам.

— Сине дә җибәрәләрме?

— Үзем барам. Мужыт атларга бераз өлеш чыгарырлар. Чәчү алдыннан аларны азрак сыйламыйча ярамас. Барам! Мин алып кайтканын, мужыт, кардыга төшерерләр... Улаклар күгәрә башлады бит... Ята алмыйм тик кенә карды өендә, йокыга китә алмыйм!.. Алар бит төне буе ыңгырашалар!..

Җитмеш биш чана дигәч, бер дә исем китмәгән иде, бик күп була икән ул! Көн артык җылы да, салкын да түгел, сирәк кар ява. Кешеләр җиңелдән киенсәләр дә, җылы киенгәннәр, билләрдә каеш, аллы-кызыллы сөлгеләр, төрле төстәге билбаулар. Муеннарда җылы шарф. Яз ае булса да, март тотрыксыз ул, кәефе кырылып буранланган чагы да еш була. Арада өлкән апалар, җиңгиләр дә, егет-җилән дә бар. Егетләр, хатын-кыз арасына катнашырга читенсенеп, идарә болдыры тирәсенә бөялеп тәмәке көйрәтәләр. Хатын-кызларның байтагысы соңгы вакытларда эшкә чыкмаган. Югары очлар Түбән очларны, Түбән очлар Югары очларны танып алып, ерактан ук бер-берсен сәламлиләр, кочаклашалар, бер-берсен күрми торган арада гәүдәләренә сарган хәсрәтне коярга теләгәндәй җилтерәтешеп тә алалар, бер-ике минут сүз әйтә алмыйча елмаешып торалар да китә сүз чишмәсе челтерәп!..

Арыш арасындагы бодай кебек, бер-ике ир-ат та бар. Болары — кичәге фронтовиклар. Алар җитди, кырыс, шушы гайре табигый җанланышның бар хикмәтен

алар гына белгән кебек, фронтовиклар председательгә тартылганнар. Куллар шинель кесәсендә. Һәр шинельдә кесә бар, һәр кесәдә кул гына юк... Хәкимҗан абзый, үзе дә юлга чыгарга җыенган төсле, кыска тунының билен зәңгәрсу пута белән кысып буган. Речь сөйләргә җыена, ахры, йөткеренә, тамагын кыра...

Ниһаять, Әдилә дә килеп кушылды...

Шуны көтәм икән, шуны эзлим! Башкалар күземә күренмәс булды, ярминкә гөжләгәндәй тавышлар тынды, берәү дә сизмәслек итеп кенә сәлам алыштык, рәхәт булып китте.

Карасам, дәү, биек мөгезле чанасын сөйрәп Дамир Әдилә янына барып та җиткән, җим тырмаган тавык кебек, аягы белән кар тырмаган була, нидер сөйли. Тик кыз егетнең үзенә түгел, чанасына карады.

— Чана дисәң дә чана бу! — диде ул.— Үзең ясадыңмы?

— Ясамыйча? Арсаң-нитсәң, чанаң-ниең белән утыртам да кайтам,— диде Дамир, авызын ат дагасы кадәр ерып.

— Әйем,— диде Әдилә, иркәләнеп.— Куркам.

— Нигә?

— Кем чанасына утырасың... ни диләр әле?

— Үзеңә Әдилә чанасына кунакларга туры килмәгәе,— дидем мин, Дамирның Чаллыга килеп кергәндә алҗыган кыяфәтен хәтерләп.— Конюхларның аяк йомшак аларның, төшке ашка да айгыр җигеп кенә кайталар.

Ул арада Хәкимҗан абый өскәрәк, такталары кылдый-былдый торган болдырга менеп басты.

— Туганнар,— диде ул.—Исән-имин йөрергә тырышыгыз. Бер-берегезне юлда ташламагыз. Инде быелгы читен яз соңгысы булсын! Тезләнсәк тә, егылыр өчен түгел, сикереп торып йөгереп китәр өчен тезләнербез. Быелгысы елда без тәмам ныгып, көчәеп, йөгереп китәргә тиешлебез ки, и анысы шулай күренеп тә тора! Йәгез, туганнар, ипләп кенә кузгалыгыз...

— Атлылар очраганда таптап китмәгез! — дип кычкырды кемдер. Кемнәрдер күңелле генә көлеп куйдылар. Хәкимҗан абзый бу ялгыз тавышны ошатып бетермәде бугай, шул якка карап әйтә куйды:

— Быел яз бирешмәскә кирәк, туганнар! Быел яз!..

Авылда чактагы ыгы-зыгы күзгә күренеп кимеде, һәркем җанына якын юлдаш, күңеленә уңай сердәш сайлап алып, шуның белән гәп куертып бара. Сүз юлны кыскарта, юлдагы сүз — чыннан да, җан азыгы, сүз озын-авыр чакрымнарны санатмый. Юлда иң куркынычлысы уй һәм ялгызлык...

Без өчәү атлыйбыз. Өчәү булгач, адымнарыбыз эре, җиңел, күңелләр көр. Дамирның уены-чыны бергә, мине тешләргә тырыша, сүзләре белән чәнчеп-чәнчеп куя, мәгәр мин тыныч. Безнең Әдилә белән икәү генә белгән серебез бар, безнең икәү генә узган юлыбыз бар. Җитмеш биш җан арасында барсак та, без икәү! Икәү генә, икебез генә! Бу кышкы юл, бүгенге юл, иртәгәге юл ничаклы озын булмасын, ул барыбер кичә без икәү үткән юлның дәвамы гына...

Йөзе белән борылып, ул миңа чана бавын сузды:

— Җәле, Ибраһим, шәлемне генә рәтлимче.

Миңа сузды бит, Дамирга түгел! Дамир, сыртына камчы төшкән чыгымчы ат кебек, алга ыргылды, без янәшәдә икәү генә калдык. Минем кулда ике чана бавы. Юк, мин ике чана тартып бармыйм хәзер, мин ике йөк бәхет тартып барам, ике куаныч минем кулымда! Юл буенда гына учма-учма саламнар кадалган — маяклар. Күземә алар парлы-парлы булып күренәләр... Мин Сабан туенда чаптар атта барам-мыни!.. Сары маяклар — тирә-яктагы кызларның сары яулыклары, сары кәләпүшләр, сары тасмалар... Рәхәт!..

Әдилә, туктап, ак шәлен рәтләде, сырма кесәсеннән чите китек көзге чыгарып купшыланган булды.

— Матур син, бик матур,— дидем, үз-үземне бе-лештермичә.

Ул ялт кына як-ягыбызга карап алды.

— Миңа матур булмыйча ярамый.

— Әйе шул.

— Бик тиз ризалашасың әле син! Шундый кындәм кешеме дисәм...

— Тиз түгел, Әдилә. Мин күптән шулай уйлап йөрим.

— Ни дип уйлыйсың?

— Син — җырчы кыз. Җырчы кыз матур булырга тиеш. Җырчы кыз — үреп салган такыя төсле, аны бөтен кеше күрә.

— Остарган син... Чаллыда...— диде ул, күзләре белән мине иркәләп.

Шәл читеннән дулкындай чыгып торган чәчләрен аз-маз җыештыргач та, ул бияләен кияргә ашыкмады, яланкул гына чана бавына үрелде, мин аның үтә йомшак бармакларын тотып алдым, сөйдем.

— Эссе,— дидем мин, туп-туры алга карап.

Әдиләгә карарга да кирәкмәс иде хәзер, безнең куллар бер-берсенә нидер әйтәләр, сөйләшәләр. Аларның сүзен-ымын, сихри өнен без икәү генә аңлап барабыз.

— Синең кулларың ныгыган,— диде ул.

— Тимерне нык бордык тегендә.

— Чаллы матурдыр?

— Әллә ни күреп тә булмады. Кыш бит, кар ерып кая барасың. Җәен матур гына була. Кама буйлары, аргы якта зәп-зәңгәр урманнар, анда, Тарловкада, санаторий диләр, чирлеләр ята икән. Ап-ак пароходлар йөзә. Ә Чаллы үзе — сары ком. Элеватор тавы биек-биек, текә яр, әллә кай төшләр күренеп тора.

— Тауны яратам мин... Сарсазда чакта түтинең олы кызы белән Кашка тауга әллә ничә барганым бар.

Сарсаздан Кашка тауга дүрт-биш чакрым, бала җитәкләп әнә кая барып йөргән икән Әдилә!

— Таудан мин сине күрдем!

— Ничек?

— Югары авыл урамыннан атка утырып чыгып килә идең!

Көлештек. Кар мулрак төшә башлады, җил дә исеп куя, кар бөртекләре шомырт чәчәкләре күк коелып безнең юлга түшәләләр, безнең сырма җөйләренә килеп куналар. Әдиләнең сызылып торган кара кашларын агарталар... Без барабыз. Без хәзер бер сүз дә сөйләшмибез. Куллар кулда, сизәм: уйлар да тоташкан...

Бераздан көн җепшетте, юл авырайды, алдагы рәтләр буталышып туктaлдылар. Без әлегә арттан барабыз, ерак-еракка сузылган кәрван күз алдыбызда. Без дә туктaлдык. Куллар теләр-теләмәс кенә бер-берсеннән аерылдылар.

Алдагылар:

— Яшьрәкләр алга чыксын,— дип шауладылар.

— Майлары эресен бераз.

— Такыр юлдан парлашып кына теркелдәрләр иде бугай...

Бусы безнең капканы кагулары булды. Мин алга ыргылдым, Дамир миңа иярде, Әдилә дә бездән калмады.

Әдилә белән икәү генә алга чыктык. Элек, без арттан барганда, бөтен кеше күз алдыбызда иде, хәзер без аларның күз алдында. Безнең янәшә барган җилкәләр аларга серне ачып ташламаса ярар иде! Бая тотаклашкан җылы куллар шул тиклем шаһитлар алдында бер-берсеннән ерагайсалар да, без бик якын, ымишарәләр аңлашырлык дәрәҗәдә якын идек...

Уйлыйм-уйлыйм да ышанырга, ышанмаска да белмим: каян килде миңа шушы хәтле бәхет?! Сугышның беренче аенда ук ятим калып, тол ананың сыңар канаты астында, туйганчы аш ашамыйча, күңел юанырлык кием кимичә, кайчагында кимсенеп тә, кайчагында чамасыз гарьләнеп тә яшәп килгән сынык күңелне нишләттең, Әдилә?! Гомер онытырлык итмәдең...

Барыбызның да курыкканы буран иде. Бик мәкерле, бик алҗыткыч, бик дәһшәтле була җепшек, кара март бураннары! Кешенең адымын салмакландыра, акылын җуя, изрәтә, зиһенне томалый, авыр кар дөньяны да, күкне-җирне, нужалы юллардагы адәм балаларын да күмеп-каплап китә... Әдилә белән башта һәр кар бөртегенә куанышып барсак та, безнең иреннәр дә кысылды, илдә хәсрәт барда тыйнак булуың әйбәтрәк! Барабыз, барабыз да, иреннәргә кунган карны ялыйялый, ымсынып, күккә күтәрелеп карыйбыз. Күк шундый түбән, салынкы, үрелсәң, болытларны сөзеп алып булыр төсле. Ява, туктарга һич исәбе күренми. Кәрванның ахырын, азактагы кешеләрне түгел, бездән ун-егерме сажинда баручыларны да аерып танып булмый. Бер якка янтаебрак, иелеп атлап барганга, кешеләрнең ярты якларын кар сарып киткән...

Зарыгып көтелгән завод үрен төшә башладык, хәзер бераз гына уңайрак булачак. Буш чана да килә-килә кулны талдыра икән, уң кулымның беләзеге сулыксулык сызлап куя.

Үр уртасына җитәрәк, безгә каршы менеп килүче атлар очрады. Биек-биек чаналарга юл биреп, төрле якка сибелештек. Борыннарга ат исе, авыл кешесе өчен

гаҗәеп якын, кадерле терлек исе килеп бәрелде. Дамирга карадым, аның соры күзләре зур булып ачылган, шаккатудан иреннәре дә ачык, үзе әкиятләрдәге шүрәлене күргәндәй хәйран калып тораташ каткан иде.

— Икмәк ашыйлар шул, таза икмәк! — Дамирның күзләренә моң чыкты, тавышы калтыранды.

Әдилә, шукланып:

— Дамир, бу атларның берәрсен сиңа бирсәләр, нишләр идең? — дип сорады.

Дамир телсез калды, Әдиләнең соравын ишеткәннәр көлешә башладылар.

— Дамирга бирсә, күрсәтә ул.

— Киптереп өрлеккә элә.

— Казылыкчы Дамир!..

Атлылар узып бетте, сүз җебе шуларга ялганды. Кемнәр кайсы Сабан туенда нинди атта чабышканнар, кайсы авыл атлары фәлән елларда беренче килгән, кем малае, егылып, ничә кабыргасын сындырган... Сабираттәй: «Мин килен булып төшкән елны унике ат җигеп килгәннәр иде»,— дип куйды. «Керәшен очында Май чапканда* өчәр ат җигеп чыгар идек, унарунбишәр кеше төялсә дә, атлар йөрәк кагып кына барырлар иде»,— диештеләр. Түбән очлар... Бер генә тантана да, бер генә бәйрәм дә ир канаты — аттан башка узмаган. Һәркемнең атка бәйләнешле бик кадерле истәлеге бар икән, колыннар, байталлар, чабышкылар, юртаклар, йөк батырлары — барысы да хәтердә сакланган, заводның шома сыртлы, кыска койрыклы тук атлары шул истәлекләрне кузгатты, барыбыз да, күңел сандыкларыбызны ачып, хатирәләрне уртак итәргә тырыштык. Сүзләр буранны оныттырды, хатирәләр эчпошыргыч җепшек бураннан көчлерәк булып чыкты...

Хәзер исә атлар өрлектә, кешеләр ятим...

Атларга да кешеләрсез читендер, хәрәкәтсез тору бик кыендыр. Төннәрен ыңгырашалар, ди ич Дамир! Аларның төшләренә дә чуклы-чәчәкле, аллы-гөлле Сабантуйлары, колын койрыгы төсле йомшак-ефәк уҗымнар, бәйгеләр, ярминкәләр, Май чабулар, яшел

* Керәшен татарларында Масленица бәйрәме.

аланнарда керт-керт итеп тукранбаш кыркып йөргән чаклары керә торгандыр... Алар да карды ярыкларыннан сызгырып кергән тыгыз, март җилен тоялардыр, аларның да каннары кайнарланып китәдер... Бик тирәндә, зәңгәр томанлы ат хыялында айгыр кешнәгән тавышлар яңгырыйдыр...

Без, алдагылар, хәзер тубыктан диярлек кар ерып барабыз, әлерәк кенә узып киткән ат-чана эзләре чак-чак шәйләнәләр.

Беркадәр өскәрәк менгәч, аркылы урам уза. Аркылы урамның ике ягына агач кибетләр, ашханәләр, учреждениеләр урнашкан, почта да шунда. Телефон чыбыклары яман усал үкерәләр. Җил арасыннан завод гудогы да юаш кына, тук песи мырлаган кебек кенә ишетелеп китте. Чаналарны кибет ишеге төбенә тартып китердек тә, төркем-төркем булып, эчкә кердек. Тик без кызыгырлык берни дә юк иде кибеттә. Балта сабы, көрәк сабы, агач көрәкләр, җилпуч... Кәнфит-прәннекләр күзне кыздырса да, алары карточкага гына бирелә икән.

Чабата кары эрегәнче тизрәк урамга чыктык. Урамда калган иптәшләр арасында ниндидер җанлылык сизелде.

— Ичмасам, без эш майтарып йөрибез,— диде кибеткә каршы бинадан чыгып килүче Сабираттәй.— Ашханә икән анда!

— Югары авыллар килә дип майлы бутка пешереп куйганнармы?

— Белен дә, майлы бутка да юк, иллә мәгәр чәйләре бар!

Бу хәбәр үтә сөенечле иде, каты-коты белән салкын җилдә тамак ялгауга караганда, җылыга кереп берике стакан кайнар чәй эчеп җибәрсәң, бу инде — юлга көч дигән сүз. Ә безгә көч бик кирәк иде әле... Бик кирәк!

Бәләкәй ашханә барыбызны да сыйдырмады, өлкәнрәкләр эчкә узды, яшь-җилкенчәк аптырап тормады, «Насыйп түгел икән, бигрәк әйбәт!» дип гөрелдәшеп, тышта калды. Берничә чананы уртага куеп, үзебез шулар тирәсенә урнаштык. Байтак кеше калай кружкадыр, котелоктыр тыккан икән; ашханәдән уттай кайнар ике чиләк су алып чыктылар, кем кишер чәе, кем җиләк чәе йөздереп, шуңа әйбәт төс кертте.

Дамир да, мин дә кружка тыкмаганбыз икән, Әдиләнең бизәкле чәшкәсенә чират алдык.

Өйдән чыккан ризыкларны уртак табынга куярга кирәк иде.

Иң кыен вакыт иде бу. Берәүләр кыенсынып тынып калды, күзләр җиргә тәгәрәделәр... Кысыр сыер җилене тиклем генә ризык капчыкларыннан нәрсә-кара чыга башлады. Алабута кушып пешерелгән, кайрактай кара катламалар, бәрәңге кырып шуңа сыңар уч кына әремле арыш оны кушып пешерелгән ләчтә ипиләр, тәгәрәткән бәрәңгеләр... Таза ипиләр дә солы, ясмык, борчак оны кушып пешергәнгә вакланып, уалып торалар.

Болар барысы да уртага чыгып тезелделәр. Уртадагы чана өстендә чиста ашъяулыкта урын калмады диярлек. Каян башына килгән диген, ашъяулыкны Әдилә тыккан икән!

Гыймай Фатихының яссы күкрәкле, бөкрерәк кызы Гөлбәдәр генә, «күрәләрме-күрмиләрме» дигән сыман аска карап, табынга бер кыерчык бодай ипие куйды. Аның кыерчыгы яңа туган ай күк балкыса да, табын уртасында ахыргача утырып калды...

Куллар табынга үрелде...

Табын янында гына була торган тантаналы тынлык урнашты. Алабута катнашкан булса да, алда — ризык. Аны олыларга кирәк!.. Кешеләрнең сулыгып-сулыгып ризык сораган ашказаннарына рәхәт җылылык йөгерде, йөзләргә кызыллык белән елмаю чыкты, төс кунды, беренче рәхәттән соң телләргә татлы сүз килде, туганлашу, татулашу килде. Берәүләр: «Бик күңелле башланды бу сәфәр, ахыры да шулай хәерле тәмамлансын»,— диделәр. Очрашуларына, бергә сәфәр чыгуларына куанышкан хатын-кыз тук казлар кебек каңгылдаштылар. Сугышка хәтле баеп, ныгып калган авылларны телгә алдылар.

Әзерлексез чыккан без агач авызларга да чәй чираты җитте, теләгәнчә кинәндек. Борын өстенә борчак-борчак тир бөртекләре чыкканчы эчтек. Мондый да тәмле чәйне, ай-һай, моңарчы эчкәнем бар идеме икән?!

Завод урамында чәй эчеп утыру бик тансык булса да, безгә ашыгырга кирәк иде. Әбәт иткәндә чак кына тыелып торган буран тагын кар өерә-өерә уйнаклый башлады. Аяклар кызганда хәрәкәт итәргә кирәк иде.

Барасы җир байтак, бүген барып җитеп, Кәследә кунарбыз да иртәгә таңнан кире борылырбыз...

Үрне шәп кенә, күмәк кенә төшсәк тә, тау менә башлагач сынаттык. Моңарчы язгы су кебек тоташ бара идек, хәзер исә юл чуарланды, берәүләр өстә үк, икенчеләр мыш-мыш менеп килә, шактый халык әле тау итәгендә диярлек, завод урамын яңа чыгып киләләр.

Сабираттәй дә шулар арасында икән, ул да таугa иң соңгыларының берсе булып менде. Бите тимгел-тимгел кызарган, утлы күзләре чокыраеп баткан, Әдилә дә шуңа игътибар иткән икән:

— Сабираттәйнең чанасын үзеңә ал, Ибраһим,— диде ул.

Сабираттәйнекен дә алдым, тагын бер-ике алҗыган апаның чанасын үземнекенә бәйләдем, миннән күрмәкче Дамир да өч-дүрт чананы бергә төйнәде, без аның белән лилипутларның корабларын сөйрәп баручы Гулливерга охшап киттек...

— Булмас бу,— диде Дамир, өметсезләнеп.— Бүген шулай җәгәнгән хатыннар иртәгә ни кырырлар?

— Иртәгә мондый алҗыткыч тау юк инде,— диде Әдилә.— Кайту ягына юл җиңелрәк тә була.

Заводтан соң алты чакрымда Тарлау авылы. Тарлауга кергәндә, кара буран чыкты. Моңарчы яннан искән җил әле каршыдан бәрде, әле артка төште: эре-эре кар кисәкләре өерелеп очып килеп яңакларга, керфекләргә сыланды, болай да салынган башлар тагын да түбәнрәк иелде.

— Булмый,— диештеләр берәүләр.

— Шушында куна калыйк.

Азчылык шулай дигәч, күпчелек икеләнде.

Әдилә болай диде:

— Бүген ничек булса да барып җитәргә кирәк.

— Нигә кунып чыкмаска? — дидем мин дә, азчылыкны уйлап.

— Бүген куна калсак, иртәгә барып кына җитәбез. Тагын көн ярым кайтырга... Ә нәрсә ашарбыз? — диде Әдилә.

Сабираттәй, буылып-буылып йөткеренсә дә, аны яклады:

— Барыйк без... Кәслегә барып җиту кирәк. Әйдәгез, тагын бер нык кына талпыныйк.

Ишле халыкка кара буран да куркыныч түгел алай, йөрәксенеп, Тарлау урамын да чыгып киттек. Авыллар ешайды... Әхмәт, аннары Әлмәт, Бәләкәй Әлмәт... Бөгелмә ягындагы Әлмәтнең адашы...

Авылда чакта юлны ничек узасын, көчебезнең күпмегә җитәсен берәү дә күз алдына китерә алмый иде. Анда барысы да сер иде. Хәзер исә юлның без уйлаганга караганда күп авыр, алҗыткыч булуы күренде. Шушы таркаулык мизгелендә, гомуми аптыраашта Әдиләнең тапкырлыгына, кыюланып сүз әйтә алуына, Сабираттәй кебек авылның авторитетлы хатыннарының аңа ияреп китүенә мин хәйран калдым. Каян килгән аңа шундый сизгерлек? Каян килгән төпле итеп сөйли алу?

Егет-җиләнгә эш артты, без әле артка калабыз, әле юл таптарга алга чыгабыз. Олы гына апалар бакча балалары кук тотаклашып атлыйлар, чөнки җил, гәүдәләрне сындырырдай җил, һаман тукталмаган җил. Телефон чыбыклары безгә хәбәр китергән кебек ачыргаланып, өзгәләнеп сызгыра...

Теләк уртак карарга әверелде: тырмашып булса да Кәслегә барып кунарга! Иртә таңнан исән-аман солыны төяп чыга алсак, үз авылыбызга соңгарып та кайтып керә алабыз. Иртәгә ашыкмасак та булыр, бүген бирешмәскә кирәк. Бүген, бүген, бүген!..

Сораулар һәм биремнәр.

1. Ни өчен Ибраһим белән Әдилә берәү дә сизмәслек итеп кенә сәлам алышалар? Алар мөнәсәбәтенә каршы килерләр идеме? Әллә хикмәт башка мәсьәләдәме?
2. Ибраһим белән Әдилә Дамирга ни өчен чит итеп, кимсетеп түгел, бераз үртәбрәк булса да, үз итеп карыйлар? Ибраһим үзе бу хәлне ничек аңлата? Шул урынны табыгыз.
3. Ашханә янындагы уртак табын ничек тасвирланган? Ул безгә нинди нәтиҗәләр ясарга ярдәм итә? Ни өчен Гөлбәдәр куйган бодай ипие табын уртасында ахыргача утырып кала? Ни өчен Ибраһимга чәй гомердә булмаганча тәмле тоела?
4. Ибраһим белән Әдиләнең бер-берсенә генә түгел, башка кешеләргә карата да игътибарлы, мәрхәмәтле булулары нинди мисалларда күренә?
5. «Һәр шинельдә кесә бар, һәр кесәдә кул гына юк» дигән җөмләне ничек аңладыгыз? Ни өчен хикәяләүче турыдан-туры әйтми?

6. «Күк шундый түбән, салынкы, үрелсәң, болытларны сөзеп алып булыр төсле» дигән образлы чагыштыруның тагын нинди вариантларын таба алыр идегез? Образлы әйтелмәләрне (мәсәлән, *күңел сандыгы, күзләр җиргә тәгәрәделәр* һ. б.) тагы да эзләп табыгыз.

Кәслегә җитәрәк, Әдилә, җиңелрәк сөякле өч-дүрт кызны ияртеп, алга китте, алар, без тупланып барып кергәнче, идарәдә фатирлар белешеп, кешеләрне җидешәр-сигезәрләп кайсын кемгә бүлеп тә куйганнар иде. Без исә Кәслегә кеше аягы басылгач кына барып элгәштек.

Без кергән өйдә ишле генә гаилә яши икән. Хуҗабыз Габбас абый сугышта булган, ахры, өстендә искерә төшкән юка гимнастерка. Ул без тезелешеп кергән чакта ишек яңагына таянып баскан иде, чишенеп, өсбашларыбызны таратып ташлаганчы, шуннан кузгалмады. Аның яңаклары эчкә суырылган, йөзе кырыс, сирәк сакалының бөртекләре, эре-эре булып, төрле якка чәбәләнгәннәр. Пошынып та куйдым, идарәдән керткәннәрдер кертүен, хуҗага безнең ябырылу бер дә ошамады, ахрысы! Аның каравы хатыны Сәрвәр апаның теле телгә йокмый, орчык күк тирәбездә бөтерелеп йөри, анысын-монысын сораша, тула оекларны кибәргә үзе элде, киемнәрне җылыга мич буена таратты.

— Комачау ясадык сезгә,— дидем мин, Габбас абыйга карабрак.— Балаларны да кузгаттык.

Хуҗа һаман эндәшмәде.

Сәрвәр апа, бәрәңге әрчегән җиреннән бүленеп:

— Куйсана,— диде,— без күнегеп беттек инде, әле өченче көн дә уникe кеше кунып чыкты. Сез дистәгә дә тулмаган!

— Уникe? — дип ах иттеләр кызлар.

Әдилә барып бәрәңге әрчешмәкче иде, Сәрвәр апа: «Ял ит, хәлдән тайгансыз ич»,— дип, тегенең кулыннан пычакны тартып алды.

— Габбас абый гына безне өнәмәде шикелле,— дидем мин, һаман ишек катында басып торган сүзсез хуҗага карап.

— Сөйләшми ул,— диде офтанып Сәрвәр апа,— сугыштан шулай кайтты. Инде кырык дүртнең кышында, немецның койрыгына каты кыл бәйләгәндә, яннарында гына мина шартлап, телсез калган. Болай

ачылыр әле диләр, ничек булыр инде, Ходай ни язган. Балалар бәхетеннән ачылып китсә кана да бит...

Бабай бездән: «Кайсы авыллар сез, озак килдегезме, юллар ничек?» — дип сорашып алды...

Сәрвәр апа башкаларның кемгә фатир төшүләре турында да кызыксынды. Алты-җиде кешенең моннан өч өй аркылы гына туктауларын белгәч, башын кагып, иренә ымлады. Габбас агай, бик җитдиләнеп, җыерчыклы киң маңгаен тагын да җыера төшеп, аңа текәлде, аннан ризалыгын белдереп башын какты, беренче тапкыр йөзендә елмаюга охшаган яктылык чагылды. Намазлык өстендә утырган бабай да, аларның ымнарын аңлап:

— Җайсызрак булган икән шул,— дип өстәде.

Сәрвәр апа бабайның сүзен ачыклагач кына, без эшнең нәрсәдә икәнен аңладык.

— Ни инде, Мәҗит хатынына, Миңниса җиңгиләргә кергәннәр, алайса, сезнекеләр,— диде ул.— Күңелләре тар түгел аларның, юк, бик әйбәт кешеләр, фатирына да кертәләр, йомышка-юлга йөрергә дә ипле кешеләр, мәгәр тамак яклары кысанрак быел... Өй эчләре тулы хатын-кыз, Мәҗит үзе Сталинградта калды, Миңниса үзе саулыкка мохтаҗ... Бил белән интегә. Җитмәсә, былтыр бик казаландылар, Ходай күрсәтмәсен! Сыерлары ужым ашап күбенде, чак чалып калдылар... Бәрәңге абзарларына су кереп әллә нихәтле бәрәңге кисәүгә әйләнде... Сезнең андагыларны бәрәңге белән сыйланырга монда дәшәрбез. Калган ашым да бар, кысыр умач булса да, сөт белән агарткач ару гына булыр әле. Ипиемне дә угыз белән изгән идем...

— Алай икән, алай,— диешеп тыңладык.

Сәрвәр апа тагын җиде кешене ияртеп кайткач, болай да кысан өй эчендә инә төртерлек тә урын калмады. Габбас абзый һаман урынга утырмады, аяк өсте тегеләрне каршылады, чишендереште, олы табак белән бәрәңгене дә үзе китереп утыртты.

Ян сәкегә яр карлыгачлары күк тезелешеп утырышсак та, һәр урындыкка икешәр кеше калды, чоланнан буш тәпәннәрне керттеләр, әйләндереп каплагач, алар да эшкә ярады. Алай да Дамир белән миңа урын җитмәде, бәрәңге тутырган калай табакны минем тез өстенә куеп, икебез җылы мич янына чүгәләдек.

Ир кешеле өй... Хуҗасы бар өй! Әтиле өй!.. Дамир да, мин дә — ятимнәр... Ә монда әтиле балалар... малайлар... Кергәч тә мин аларга көнләшебрәк караган идем, хәзер әллә ничегрәк...

Өстәл янындагылар да һаман-һаман шул сүзгә әйләнеп кайтабыз. Элек матур гына сөйләшкән кешенең авыр контузиядән соң тынсыз-өнсез калуына барыбызның да күңел сызлый, бу хәл белән берничек тә килешәсе килми иде. Сәрвәр апа да ике сүзнең берендә ирен телгә ала:

— Ял итсен, диләр... Диңгез буена барсын, диләр. Нинди диңгез ди әле монда! Нинди ял! Карап торган ирләребез биш-алты бөртек булгач, ел әйләнәсендә көнетөне эшлиләр. Сезгә дигән симәнәләрне хәстәрләп куючылар да шулар! Менә тормышлар аруланыр, җайланыр, аннан дәваланырга да өлгерер, теле дә кайтыр. Менә сез дә яхшы теләктә торыгыз!..

Ул ак яулыгының очы белән күз яшьләрен сөртте. Зиһенем ачылып, күз алларым яктырып китте. Бу мәшәкатьләр, кадерле кунакны каршылаган кебек каршылау, егермегә якын кешегә әзерләнгән сыйлы табын, өченче көн генә кунып чыккан уникe кеше — үз яхшылыгыннан тыш аның өчен — Габбас абый өчен дә эшләнә! Аның исән кайту куанычы шул тиклем зур, сөенече шулкадәр мул — Сәрвәр апа бу сөенечне тел белән генә гомердә дә әйтеп бетерәчәк түгел!.. Шуның өстенә якын кешесен — балаларының газиз әткәсен — телле итәсе килү теләге шундый көчле ки, ул һәр кичне утыз-кырык кешене фатирга кертергә риза, базында бәрәңге барында, чоланында он барында ул барысын туганнарча бүлешәчәк, кергән мосафирлар аларны онытмасын гына, Габбас абыйлары өчен теләктә генә торсыннар!

«Кешеләрне Габбас абыегыз гозерен үтәп кертәм»,— диде ул соңыннан... Мөгаен, анысы да хактыр. Юк, бу теләкләре уртак аларның, алар өй эчләре белән чиксез бәхет тоеп, сөенешеп, сөешеп яшиләр, үз бәхетләре белән кешеләрне дә шатландырырга телиләр.

Яшәүнең иң бөек максаты, кешенең иң гади сыйфаты шул түгелмени?

Алтын булып агаем ла...
Көмеш булып тамаем!..

Шушы җырдагы кебек ич аларның тормышлары... Әдиләне бер җырлатасы иде...

Аркада җылы мич, тездә бушап бара торган кайнар табак... Өй эчендә әйтеп, сөйләп бетерә алмаслык рәхәтлек, һәркем үз күршесенә бәрәңгенең тәмлерәген куярга тырыша, күңелне күтәрә торган татлы сүзләр әйтелә... Бәрәңгене ялт иттердек. Аннан чәй килде. Чын чәй, куе итеп ясалган такта чәй. Сәрвәр апа чоланнан бал керткәч, барыбыз да ах иттек. Бал,— бердән, бик кадерле кунакка гына куела торган нәрсә, зур сый, икенчедән, март ае булса да, аларның баллары шикәрләнмәгән, ягъни утырмаган, кичә генә суыртып куйган төсле сап-сары, сәмигъ сагыз диярсең! Чак кына куерган балны, ояла-ояла, калак очларыбызга әләктереп кенә бер-ике каптык...

Күршедә тукталган юлдашларыбызны андагы хуҗалары, Миңниса апалар, безнең янга бәрәңге ашарга бик авырыксынып кына җибәргәннәр икән. «Юлга алган ризыкларыбыз бер капчыкта иде»,— дигәч кенә ризалашканнар. Чәйдән соң без Әдилә белән аларны озата чыктык. Чыннан да, Миңниса апаларның бәләкәй тәрәзәләрендә ут җемелди, безнең иптәшләрне анда да, йокламыйча, хуҗалары көтә иде...

Ниһаять, Әдилә белән икәү генә калдык... Күршеләрне озатмаганда да була иде, әмма мин шушы минутны уйлап, шушы минутны көтеп чыккан идем...

— Кайтыйк, Ибраһим, син бик арыгансыңдыр? — диде ул.

— Ә үзең?

— Мин бит биш-алты чана сөйрәмәдем. Кәрванның бер очыннан икенче очына чабып та йөрмәдем.

Калдырган эзләребезгә баса-баса кайтып барабыз. Төнге буран, урамның ике ягына тыгыз тезелгән йортларны күздән яшереп, безнең ялгызлыкны тагын да көчәйтте, ник бер җан иясе булсын! Этләр дә өрми, ичмасам, шомландырып, җил генә сызгыра.

Әдилә кинәт миңа таба тартылды.

— Тукта әле,— диде ул, пышылдап.

Икебез дә тын тартмыйча тыңлап торабыз.

Йорт араларында җил йолкына, безгә үче бар сыман, колак төбендә сызгыра.

— Бүреләр! — диде Әдилә.— Чукмар менә кайчан кирәк булган икән!

Мин дә ишеттем, бүреләр улый. Берәү генә түгел, икәү, өчәү, шактый зур өер, ахрысы, берсе сузып-сузып җибәрә дә, икенчеләр кыска-кыска көчле тавыш белән күтәреп алалар. Алар әллә кайда, без әллә кайда йортлар арасында булсак та, бер өер бүре улаганга, тән чымыр-чымыр итеп куя, кот бот тирәсенә төшә...

— Этләр шуңа тынган,— дидем мин.— Бүредән шүрли алар.

— Керик,— диде Әдилә, калтыранып.

— Ерак ич алар,— дидем мин, батыр күренергә тырышып.

Габбас абыйларның өй турына гына җиткән идек, безне тәмам куркытып, гөрс итеп өй кыегыннан зур кар кисәге ишелеп төште...

— Әдилә! — дидем мин, кызның күзләрен күрергә тырышып.

— Куркыныч монда, Ибраһим.

— Күптән синең җырлаганыңны ишеткәнем юк.

— Әллә шушында җырлатыр идеңме?

— Түгел лә...

— Күптән җырлаган да юк инде...

— Нигә?

— Җыр бит ул язгы су кебек... Үз вакытын белеп кенә кузгала... Март башы — яз башы. Мин март башын бик яратам. Кешеләр уйлап чыгарган бәйрәм түгел ич бу, табигать биргән бәйрәм... Яз җитте, җырларга урыны туры килми, вакыты туры килми.

— Кояш җитми сиңа, алайса, җылылык җитми.

— Алай да димәс идем. Бүген менә, озын юл үтсәк тә, кәефем шәп...

— Син җырлап җибәрсәң, җил дә тынар, бүреләр дә туктар.

— Каян беләсең?

— Былтыр көз, Чаллыга барганда, синең җырыңны ишеттем мин, Әдилә.

— Кайчан иде икән? — диде ул, нигәдер оялып.

— Кич иде. Матур кич иде! Син, җырлый-җырлый, бер башың Олы су ягыннан юлга таба менә идең...

Быелгы язны, быелгы җәйне күз алдыма китереп карыйм... Ни генә булмасын, безне алданиләр генә көтмәсен, тыныч яз ич бу! Тыныч дөнья!.. Хат ташучы үткәнен куркып һәм өметләнеп көтәсе юк... Безнең елгыларны әле армиягә алмый торалар. Сугыш безнең

яшьтәшләргә килде дә терәлде. «Немецның койрыгын бәйләделәр»,— ди әнә Сәрвәр апа... Әдилә хәзер гел-гел авылда булачак... Әдилә... Аны олылыйлар... Иптәш кызлары да, башкалар да... Ни дисәң дә тормыш чынлыгы белән күбрәк очрашкан шул ул, ачысын-төчесен иртәрәк татыган. Апасын күмгән... Дүрт баланы карап гомер иткән... Гарип җизнәсен караган...

Төн уздымы әллә төштә генә күренеп киткән сихри бер мизгел идеме бу, әйтә алмыйм. Кәсле авылына, Сәрвәр апаларга рәхмәтләр әйтеп сикерешеп тордык... Хуҗалар безне: «Юл төшсә, туп-туры үзебезгә керегез»,— дип озатып калды...

Иртәнге кояш! Рәхмәт сиңа. Күңелләрдә өмет, тәндә көч. Аяклар ял иткән. Өс-баш, чабаталар коп-коры, җиңел. Билләр кысып буылган. Моңа синең якты нурларыңның шифасын өстәргә кирәк, иртәнге кояш. Авылыбыздан киткәндәге җанлылык кабатланмаса да, иптәшләр күңелле генә сөйләшәләр, шырык-шырык көләләр. Иртән кояш күренмәсә, кешеләр сирәк көләләр...

Тиз үк юлга чыктык, кәслеләрнең тәҗрибә зур икән, эшне тиз башкардылар. Җитмеш биш чана. Җитмеш биш капчык солы. Һәркем хәлле-хәленчә, кем чанасында өч пот, дүртне алучылар да бар, ике белән калучылар да булды. Бер кәгазь, бер үлчәү...

Буш чана сөйрәү җиңелрәк булса да, солылы капчыкларны тарту күңеллерәк икән! Юлыбызның бер максатына ирешелгән.

Чәчүлек орлык тутырылган. Әре, сортлы солы! Чәчүлек кайта Югары авылга, тереклек кайта.

Дамир чанасында төгәл алты пот... Иртә таңнан Кәсле кардысына төшеп менәргә дә өлгергән ул, авызы ерык:

— Колын күрдем бүген, малайлар...

Колын... Дамирның иң зур хыялы. Монысын мин беләм. Икенче зур хыялы аның — Әдилә! Монысын Әдилә белән икебез дә беләбез.

Нишлисең, барлык хыяллар да тормышка ашмый шул...

Алты пот солысын атларга калдыру турында уйлый Дамир...

Колын!.. Тиз генә күреп булмас әле колыннарны Югары авылда!

Әтисе дә конюх иде Дамирның. Биш яшеннән атка менеп чапкан, җиде яшеннән ызанга тырмага төшкән, ун яшьтән чытыр арба белән көлтәгә чыккан иптәшемнең хәлен Кәсле юлында аңладым. Сөйгән ярсыз да, атсыз да калган егетнең хәле яман, бик яман иде...

Әлмәткә кайтып җиттек. Кичә кич авыл урамнарын узганда, күз ачкысыз буранда Әлмәттә тереклек иясе юк сыман тоелган иде. Бүген анда да, монда да кыска бишмәтләрен җилбәгәй җибәргән, бүрек колакчыннарын күтәргән карт-коры күзгә чалынды, малае-шалае шунда урала, капка төпләрен көриләр, урамны — без узасы юлларны — ялт итеп арулап куйганнар. Кара кашлы, шалкан төсле ак йөзле апалар, кулларын каш өстенә куеп, безне каршыладылар:

— Исән-саулармысыз?

— Чәчелмичә барып җитә алдыгызмы?

— Чәй эчеп чыгыгыз!

Чәй эчеп тормадык, урамны көрәп куюлары өчен рәхмәтләр укып юлда булдык. Әлмәтлеләр авыл белән безнең кәрванны озатып калды.

Завод тавына тиклем шәп кенә бардык дияргә ярый. Берничә кеше шома юлда тәгәрәп китте дә, бер чана ватылды, Зарифа апаның капчыгы ертылып, солысы юлга ага башлады, аны берәмтекләп чүпләп тутырдык, тегәрҗеп белән шытырдатып капчыгын ямадык... Үкчә кырылганын, чабата башларына үсеп чыккан әрсез мыекларны санап тормадык...

Заводка җитеп тын алабыз дип куанышканда гына, кәрван уртасында нидер буталды, алдагылар, чаналарын ташлап, артка борылдылар, арттагылар бер урында бөялделәр. Әдилә белән без дә шулар янына ашыктык.

Сабираттәйнең йөрәк өянәге кузгалган иде.

Торымнан торымга йөрәге кузгала икән аның, дип сөйлиләр иде, бәхетсезгә вакытсыз дигәндәй, шул яман хәл завод тавы өстендә башланган икән...

Без барып арага кысылышканда, Сабираттәй, капчык өстендә кырын ятып, бияләеннән кар ялый иде.

— Хәлең ничек? — дип сорыйбыз аннан. Сабираттәй эндәшми, башын гына чайкый...

Нишләргә? Кеше йөрәге тишек капчык яки ватылган чана түгел, түгәрәк ясап уралган кешеләр, бер-икешәр адым чигенеп, хафада калдылар.

Хатыннар Сабираттәй чанасы тирәсенә җыйналгач, мин үзебезнең өс-башыбызның нинди таланган, йолкынган иске-москы булуына игътибар иттем. Ябык идек без, ямьсез идек... Кояшлы март көнендә, тау өстендәге ап-ак кар арасында барысы аермачык күренде, йончыган идек без, арыган идек... Башкалар шулай йончылганда, йөрәк авырулы хатын ничек түзә алсын? Хәкимҗан абзыйның «тузган ул!» дигән хөкеме исемә төште.

Дамирның бөтен авылга атаклы чанасына яңа эш табылды. Аның авыр капчыгын минем чанага салдык. Сабираттәйне, үрәчә арасына аякларын суздырып, Дамир чанасына утырттык.

— Түзми әмәлең юк, Сабира апа,— диде Әдилә.— Завод күренеп кенә тора. Анда инде врач бардыр, каралып чыгарсың.

Хатыннар үз чаналары тирәсенә таралышканда да сүз гел шул турыда барды:

— Кем белән кунды ул?

— Тамагына каптымы икән?

— Йоклый алдымы?..

Чанамда саллы гына ике капчык. Әдилә чанасын Югары очның бер егеткә тактык. Сабираттәй янында Дамир белән Әдилә. Тау төшкәндә, чана салулап китү куркынычы бар, Әдилә чытырдап үрәчәгә ябышкан, карап-чамалап кына төшәбез. Аяклар тая, авыр чанам дык итеп тез астыма килеп бәрелә, мин егылып та киткәлим. Сабира апа, мәрткә киткән кебек, сүз дә дәшми, күзен дә ачмый... Ә кояш җете, ак кар күз кабакларын сызлата!..

Бригадир «барма» дигән икән аңа, бөтен авыл кузгалганда ничек түзеп ятмак кирәк дип дәртсенеп, үзе юлга чыккан. Солыны өч пот салдырган...

Тау төшү ифрат авыр булды. Моңарчы чыдап килгән баулар, арканнар өзелгәләде, бер чана хуҗасын бәреп китте дә телефон баганасына барып сыланды, капчык ярылды, солы акты... Егылган кешеләргә карата такмак чыкмый инде хәзер, кешеләр тын, борчулы һәм үтә җитди иделәр. Аяк таймасын өчен, бер-берсенә тотынышып, кочаклашып төшәләр...

Бара-бара завод урамына төшеп җиттек. Сабираттәй дә тынычланып күзләрен ачты...

Хәзер эшләр җайлана!

Тик заводта врач юк икән, сугышка чаклы бар иде, хәзер тиенә алганыбыз юк шул, диештеләр кешеләр. Фельдшер бар икән, медпункт якында гына, без өчәүләшеп — Әдилә, Дамир һәм мин — Сабираттәйне шунда алып киттек. Башкаларга: «Калып торыгыз, тамак ялгагыз»,— дисәк тә, байтак кеше безнең белән барды.

Фельдшер апа бераздан безнең янга чыкты. Озын гына, эре сөякле, бераз шадрарак апа. Калын кофтасының түшендә орден ленталары. Сугыштан кайткан, күренеп тора.

Моңарчы абайламаган идек, ишек яңагы янында стенада телефон бар икән, фельдшер апа шалтырата башлады. Сарман больницасын сорады. Аннан соң завод идарәсенә шалтыратты. Аның шөбһәле сүзләрен ишетеп без бик каты шүрләдек... Сабираттәйнең хәле әйбәттән түгел икән!

Кем белән сөйләшүен аңламадык, мәгәр сүз гел безнең турыда барды. Трубкасын куйгач, ул безне ашыктыра башлады:

— Хәзер заводтан унике ат торфка китә икән. Югары авыл шундадыр бит? Сез күпер төбенә җыйналып аларны көтеп торыгыз. Өлкәнрәкләр утырып та кайтыр, ә капчыкларның бар булганын шуларга төягез.

Өчебез беравыздан:

— Ә Сабираттәй? — дидек.

— Иптәшегезне алып калам, больница белән киңәшәм дә үзем ат белән озатып куярмын,— диде фельдшер.

Иптәшләр янына чыктык, атлар турындагы хәбәргә сөенешсәләр дә, Сабира апа турындагы хәбәрне ишеткәч, аларның да борын салынды... Аптырашып, Игәнә күперенә төштек, монда озак юансак, завод атларының китеп баруы мөмкин, йөкчеләре дә кырысрак аларның, үткән-сүткәнне утыртырга бигүк яратмыйлар. Шулай булып чыкты да, олаучылар:

— Йөк төяп нишләп йөрик ди? Бүген әйләнеп кайтасы бар. Атлар көне-төне юлда,— дип карышып маташтылар. Без боек кына таралыша башлагач, кул селкеп чаналарыннан сикерешеп төштеләр һәм безнең капчыкларны чаналарга төяргә булыштылар. Арыганракларга, өлкәннәргә урын да табылды.

Атларга төялешеп тә, җәяүләп тә иптәшләр кайтып китте, без Әдилә белән монда калдык.

— Үлде бичара,— диде фельдшер.— Нишли генә алам соң мин? Таланган ич аның йөрәге, ватык сәгать күк келтерәп тора!

Әдилә, иреннәрен тешләп, миңа тартылды, йөзен иңбашыма яшереп капланып төште...

Фельдшер безне: «Үземдә кунарсыз, ялгыз торам мин, иртәгә иртән ат белән китәрсез»,— дип үгетләсә дә, кунарга заводта каласы килмәде. «Иртән килеп җитәрбез»,— дип, без кайтырга чыктык. Ниндидер көч безне өйгә, юлга өндәде...

Безнекеләр авылга кайтып та җиткәндер инде... Юл озын булса да, без бер җирдә дә тукталып тормадык, кайттык та кайттык.

— Иртәгә үк Хәкимҗан абзыйны күреп сөйләшергә кирәк,— диде Әдилә.— Моның башка берәр җае юкмы икән?

— Иртәгә түгел, бүген үк күрербез.

— Кайтып җитәсе бар шул әле.

Мин каралҗым-зәңгәр урман өстенә тәгәрәгән кояшка карадым.

— Җитәрбез...

Аяклар талды, аны сизмәдек. Тамак ачты, тукталырга вакыт кызгандык. Барган шәпкә генә икмәк сыныкларыбызны кимердек. Ни турында сөйләшсәк тә, сүзнең очына Сабираттәй килеп ялгана иде.

— Балаларын кая куярлар инде?

— Ничәү әле аның?

— Өчәү.

— Өчәү үк икән шул.

Үзебезнең урманны чыкканда, күз бәйләнә башлады. Урманнан үзебезнең авылга йөгереп дигәндәй кайттык. Туп-туры идарәгә барып кердек. Хәкимҗан абый шунда утыра иде.

— Кайтып җиттегезме, үскәннәрем? — диде ул, юаш кына.

— Без кайттык... Сабираттәй генә...

— Үлеп калды,— дидем мин.

Председатель дәшми. Без дә эндәшмибез...

— Сез, үскәннәрем, болай итегез инде... Хәзер кайтып ял итегез. Арыгансыздыр, беләм... Юлы җиңел

түгел. Мин дә көне буе даулашып районнан кайттым!.. Менә генә телефонограмма алдык, симәнәне безгә Сарсаздан, ягъни якын глубинкадан бирә башлыйлар... Чаба-чаба үзем дә койрыксыз маэмай булып кайттым менә... Эх, Сабира кызганыч!..

Иреннәребезне кысып, йодрыкларны йомарлап, идарәдән чыгып киттек.

Икенче көнне Сабираттәйне алып кайтып җирләдек. Өченче көнне Сарсаз глубинкасына элеккедән дә ишлерәк булып, озын кәрванга тезелеп юлга чыктык. Ара якын булгач, малай-шалай да безгә иярде. Дамир гына өйдә калды, аның атларына да солыдан өлеш чыгардылар. Дамир, атлар яныннан кайтып, безне озатып калды.

Әдилә белән иң актыккы кешеләр булып барабыз. Көн матур. Чалт аяз. Кар өстенә карасаң, күз чагыла. Авылны чыккач та зират тавы аермачык күренеп тора. Зиратта яңа кабер. Кызыл балчыктан өелгән бәләкәй генә таучык ак карда уйнаган кызыл төлке кебек кенә күренеп тора...

1972

Сораулар һәм биремнәр.

1. *Киң күңеллелек* төшенчәсен аңлатып карагыз. Кешеләрне һәм тормышны бизи торган бу сыйфат әсәрдә ничек тасвирланган? Үз тормышыгыздан нинди мисаллар китерә алыр идегез?
2. Әдәплелек, тыйнаклык сыйфатлары аеруча ачык күренгән, сурәтләнгән урыннарга игътибар итегез. Аерым сүзләр белән атап әйтелмәсә дә, бу сыйфатларны танып буламы, ул нинди, кайсы очракларда чагыла?
3. Җыр турында Әдилә әйткән сүзләр белән килешәсезме? Чынлап та, теләсә кайчан яки бертуктаусыз җырлап торып буламы, алай килешәме?
4. Дамирны нәрсә өчен хөрмәт итәргә була? Ибраһимның Дамирга мөнәсәбәте ничек?
5. «Чабата башына үсеп чыккан әрсез мыеклар» дигән җөмләне ничек аңладыгыз? Шул сурәтне күз алдына китерә аласызмы?
6. Повесть нинди тойгылар уята? Авторның сурәтләү теле ошадымы? Бу әсәр нәрсә турында дигән сорауга ничек җавап бирер идегез?
7. Ничек уйлыйсыз: әсәр уңышлы тәмамланамы? Тормыш авырлыгы нинди вакыйга, күренеш, хәлләрдә чагыла?

8. Повестьта тасвирланган чор белән бүгенге көн арасында зур аерма бар. Шулай да нинди уртаклык, югалмаска тиешле сыйфатлар бар дип саныйсыз?
9. «Кешеләрне шатландыру — үзе бәхет» дигән темага сочинение языгыз.

Яктылыкның чыганагы кайда?

«Җанны өшетә торган салкын коры кич килде». Сугыш чоры турындагы әсәр шулай башланырга тиеш, табигать тә бу елларның рәхимсезлегенә тәңгәл килергә тиеш дип укый башлыйсың. Әмма бераздан аяусыз, әрсез җил басыла, Чаллы элеваторына юлга чыккан атлыларны бөтен барлыклары белән, барыр һәм кайтыр юлларын оныттырып, офыкларга кадәр иңләп җыр күмеп китә. Ташкын булып аккан тавыш, дәрья булып җәелгән моң. Шулай! Заман нинди генә булмасын, аның яхшылыкка, яктылыкка ачып куйган тәрәзәләре бар! Әнә ярларына сыешмаслык яшьлек тулышып ага, бары үзе өчен генә җырлаган кыз бу минутларда бәхет эчендә йөзә. Бу җырны тыңлап сихерләнгән Ибраһим белән Дамирның да күңелләренә, язын килгән тургайлар, былбыллар барысы бергә сайрап кузгаткандай, моң тула.

Дөньяга ачылган иң якты тәрәзә икән ул — кеше күңеле. Әсәрнең төп геройлары белән дә без аларның күңелләре аша танышабыз. Сугыш өшетә алмаган яшь җаннарның матурлыгы, сафлыгы баштан ахырга кадәр әсәрне яктыртып, нурландырып тора. Нинди игелекле, юмарт гашыйклар күңеле! Алар үзләренең мәхәббәтләре турында сөйләшмиләр дә диярлек. Җаннарны җылытып, дөньяны яктыртып торган сөю хисен күңелләре белән тоеп, сүзсез дә аңлашалар. Чит карашлардан, артык сүзләрдән сакланырга тиешле кадерле серләре ул аларның, икесе генә белгән байлыклары, күңел нурлары.

Әсәр табигатьнең үзе кебек: караңгы төне дә, кояшлы көне дә бар. Әйе, яшәү җиңел булмаячак. Әмма яшәргә, тырышырга кирәк. Бер чакрымы да җәһәннәм баскычлары белән бер булган сугыш еллары калдырган газаплы юлларны әле үтеп бетерәсе бар. Келәтләрдә бер бөртек чәчүлек орлык юк, орлыкны алтмыш биш чакрымнан барып алырга кирәк. Атлар, йөк тарту түгел, гәүдәләрен дә тотып тора алмыйлар, ашарларына да күгәргән салам гына. Кул чаналары тартып, җитмеш биш кеше карлы-буранлы юлга чыга. Матур түгел бу кәрванның кыяфәте, күбесе — хатын-кыз, авыру, хәлсез.

Ашарга алган ризыклары да көч-куәт өстәрлек түгел. Шулай да нинди бердәм, чыдам, көчле рухлы алар! Яшәргә, тырышырга, бирешмәскә кирәк! Бу язны түзәргә, бүген Кәслегә барып җитәргә!

Хәкимҗан абзыйның җаны шуңа күрә икегә бүленгән: бер өлеше кешеләрнең тырышлыгына куанса, икенче яртысы тормышның рәхимсезлегеннән, кешеләр өстенә төшкән авырлыкны җиңеләйтә алмаганга елый. Чыннан да, нинди кырыс кануннарга корылган бу тормыш, кешеләрне кызганмый торган нинди рәхимсез бу дөнья! Якындагы элеваторда да бар бит ул чәчүлек орлыгы, шуннан гына ташырга рөхсәт булса, Сабираттәй дә исән калган булыр иде, дип үкенәсең. Шулай да кеше күңеленең изгелеге, яхшылыгы бизи тормышны. Сәрвәр апа белән Габбас абзыйны да олы җанлы булулары, өмет белән яшәүләре бәхетле иткән. Өмет, теләк сүнмәгәндә, яшәү, чынлап та, якты булачак. Байлык, ризык муллыгы үзе генә шатлык китерә алмый әле, табын яме, аның затлылыгы бәрәңгенең тәмлерәген күршесенә ашатырга, аңа ягымлы сүзләр әйтергә тырышкан кешеләрдә икән. Бу фикер — зур хакыйкать, яшәү мәгънәсен раслап торган дөреслек.

Сажидә Сөләйманова
(1926—1980)

Сажидә Гаделша кызы Сөләйманова Башкортстанның Яңавыл районы Яңавыл авылында туган. 1944 елда Тәтеш урта мәктәбен тәмамлагач, авылда укытучы булып эшли, аннан соң Уфа педагогия институтында белем ала, мәктәпләрдә тарих фәнен укыта. 1955 елдан аның гомере һәм иҗаты Әлмәт шәһәре белән бәйле: нефть техникумында, шәһәр радиоүзәгендә, Әлмәт әдәбият берләшмәсендә эшли, шигырьләре дә шул чорда басыла башлый. Иң беренче чиратта шагыйрә буларак танылса да, матур гына хикәя һәм повестьлар да яза. Сажидә Сөләймановадан мирас булып калган күңел байлыгы китап киштәләренә җыентыклар булып тезелгән: «Кыр казлары» (1963), «Бәхетне үзем табам» (1966), «Юллар, уйлар» (1968), «Яшәү хакы» (1970), «Кызыл каурыйлар» (1976), «Гөлбадран» (1980), «Сабыр канатлары» (1981), «Шигырьләр һәм поэмалар» (1981).

Әдәбият галиме Нил Юзиев, шагыйрәнең иҗатына анализ ясап, түбәндәге фикерләрне әйтә: «Шигърият үз серләрен һәркемгә дә ачмый... Шигырь язучылар арасыннан шигърият бик нык сайлый: күңел биографиясе һәм әйтергә сүзе булганнарын, тормыш агышына-моңына сизгер күңеллеләрен, шигъри күрү-ишетүгә ия булганнарын... шагыйрь ни дәрәҗәдә поэзиягә ышанса, күңелен курыкмыйча ачса, шигърият тә серләрен иркенрәк өләшә...

Татар хатын-кызлары элек-электән үк эшчән, тырыш, уңган һәм бай күңелле генә түгел, ә шигъри рухлы да булганнар. Сәрвәр Әдһәмова, Ләбибә Ихсанова, Гөлшат Зәйнашева, Сажидә

Сөләйманова кебек хатын-кыз язучыларның күп санлы китаплары аларның әдәби иҗаттагы рольләре турында сөйләргә мөмкинлек бирә...»*

Туган ягын өзелеп яраткан, кешедәге яхшылык, мәрхәмәтлелеккә дан җырлаган С. Сөләймановага «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» (1980) дигән мактаулы исем бирелә.

ТУГАН ҖИРЕМ, ЭЧКӘН СУЫМ!

Әнкәй миңа тәмле-татлы сүзләр
өйрәтмәгән сабый чагымнан,
яратуы күкрәк сөте белән
һәр балага тигез салынган.

Олы хисләр — күңел түрләрендә,
тел очында йөрсә, җил алыр.
Яратуың артык тирән булса,
«яратам» дип әйтү бик авыр.

Авылымны өзелеп сөям, диеп
сөйләп йөрми авыл кешесе.
Чәчә, ура, илне туендыра —
яратуның шунда көчлесе.

Болыннарым сагына, печән җитсә,
кырлар чакыра урак өстендә.
Печән исе, кара икмәк тәме
канга сеңгән ана сөтеннән.

Басуларның булды көйгән чагы,
кем кайгыдан качып котылган?
Кырны басып әрем әчесе дә
күз яшьләре белән йотылган.

Туып үскән җирем, эчкән суым,
сулар һавам — туган як кынам!
Күпме балаң яуда башын салды
шушы җирдә яшәү хакына.

---

* Саҗидә Сөләйманова. Шигырьләр һәм поэмалар.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. Кереш сүз.

Үлгәннәрнең калган гомерләре
ал таңнарга кушылып кабына.
Туган җир ул кеше күңеленә
ана сөте белән салына.

Тәпи баскан җирем, эчкән суым
кара, акмы, ачы, татлымы —
бөтен гомерем белән түли алмам
шушы җирдә яшәү хакымны.

1967

Сораулар һәм биремнәр.

1. Шигырьне тагын бер кат игътибар белән укып чыгыгыз. Образларны табыгыз. Аларның кайсылары сезгә таныш? Халык сөйләменнән, әйтемнәрдән күчкән сүзтезмәләрне укып күрсәтегез.
2. Сурәтләү чараларын эпитет, чагыштыру, сынландыруларны билгеләп чыгыгыз. Алар мәгънәгә нинди төсмерләр, образга нинди бизәкләр өсти? Мәсәлән, «тәмле-татлы сүзләр» не тагын ничек әйтеп булыр иде?
3. Шигырьдәге төп фикерне чагылдыра торган юлларны табыгыз. Нинди образлар кабатлана?
4. Шагыйрә үзе турында гына язамы әллә гомумиләштерү дә бармы? Шул юлларны табыгыз.

* * *

Кеше барыбер кошлар нәселеннән!
Төшләремдә очам кош булып.
Ничә очып, ничә мәтәлсә дә,
кеше барыбер сайлый кош юлын.

Ачылмаган йолдызлары белән
заман һаман үргә чакыра.
Үрләр менми, җырлар тумас иде
җирнең матурлыгы хакында.

1967

КЕШЕ

Лачын диләр,
канат кагып горур очканга.
Лачын булсам, җирне сөймәс идем.
Мин — кеше.
Ут шикелле диләр,
кулы тисә — эш яна.
Ут булсам соң, әллә сүнмәс идем? —
Мин — кеше.
Алтын диләр, бик кирәгем чыкса, куштаннар,
алтын булсам, бер сатылыр идем.
Мин — кеше.
Ярага — тоз, арага ут сала дошманнар,
корыч булсам да, бер эрер идем.—
Мин — кеше.

1969

Сораулар һәм биремнәр.

1. Чынлыкка туры килми торган «кеше кошлар нәселеннән» дигән фикер ни өчен ышандыра? Аңа нинди хис салынган? Ул хис борынгыдан килгән нинди ышануларга бәйле?
2. «Кош юлы» кайда һәм нинди ул?
3. Ни өчен кош һәм юл образлары кабатланса да туйдырмый, ә укыган саен дулкынландыра? Нинди үрләр турында сүз бара?
4. «Кеше» шигыренең язылу рәвешенә, сүзләрне урнаштыру тәртибенә игътибар итегез. Кайсы сүзләргә басым ясарга кирәк? Алар тезмәнең — шигырь юлының — кайсы урынына куелган? Нинди сүзләр кабатланган? Кабатлау алымы мәгънә өчен кирәкме әллә шигырьнең форма төзеклеге өченме? Шигъри бизәк дигән төшенчәне ничек аңлыйсыз? Әлеге шигырьләрдә нинди бизәкләр бар?
5. Шигырьләрдәге рифмаларны табыгыз, үзләрен генә аерып укып карагыз. Тезмә эченә яшерелгән рифмалар юкмы, рифмаларны көчәйтүче сүзләрне «ишетеп» алдыгызмы?
6. «Кеше»шигыре чагыштыру һәм капма-каршы кую алымнарына нигезләнгән, шуларны аерып чыгыгыз. «Диләр», «булсам» сүзләре нинди роль уйный?
7. Шигырьнең төп сурәтләү чарасы — метафоралар, яшерелгән мәгънәле, күп мәгънәле, күчерелмә мәгънәле сүзләрне табыгыз. Шигырьнең тәэсир көче, фикер һәм хис берлеге шул сүзләргә тупланган була. Шуңа күрә алар яныннан

ашыгып үтеп китәргә ярамый: сүзнең тәмен тоймый каласың.

8. Шигырьне берничә кат укуда ятлап карагыз, ритмына игътибар итегез, интонация ничек үзгәрә? Автор кем белән, нәрсә хакында бәхәсләшә?

* * *

Сулар ага, күлләр күккә бага,
кояш карый дөнья күгеннән.
Яз килсә дә җиргә, боз яуса да —
күкрәп уза кеше күңеленнән.

Карурманнар ава, юллар чаба,
шәһәр калка таулар ташыннан.
Таш ярса да заман, төш ярса да,
ярчыклары — адәм башында.

Йөрәгендә, кайнап, ал таң ата,
кояш бата шул ук төбәктә,—
бәндә ничек гел фәрештә булсын,
оҗмах, тәмуг — бер үк йөрәктә.

1973

Сораулар һәм биремнәр.

1. Һәр строфаның соңгы юлына игътибар итеп, шуларны гына аерып укып карагыз: нинди уртаклык һәм аерма күрдегез? Кеше, адәм, бәндә — синонимнар, аларның нинди мәгънә төсмерләрен тоя алдыгыз? Бу сүзләрнең куллану очракларын аңлатыгыз.
2. Кеше йөрәгендә, чынлап та, таң да ата, кояш та бата аламы? Болай дип әйтү дөресме? Әллә шигырь турында сүз барганда, бу сорауны кую урынлы түгелме? Ни өчен?
3. «Таш яру» һәм «төш яру» гыйбарәләре нинди мәгънәләргә ия? Заман ярамы ташны? Ни өчен шагыйрә «кеше яра» димәгән? Тукайның «шагыйранә ялган» дигән сүзләрен исегезгә төшерегез әле, ул аны кайсы шигыренә карата әйткән?
4. Бәхәссез хакыйкать булган образлы фикерне белдерүче сүзләрне без хикмәтле сүз дибез, аларда гасырлар исбатлаган нәтиҗә һәм онытылмаслык образ бергә кушыла. Бу шигырьдә шундый сүзләр бармы? Укып күрсәтегез.

ЭТЮД*

Буш урамда,
ак буранда
җитәкләшеп икәү бара.
Тәрәзәләр нурлы икән,
баганалар чыңлы икән,
таш урамнар җырлы икән,
чынмы икән?

Җитәкләшеп икәү бара,
эзләренә ак кар ява,—
эзләренә кер кунмасын,
җил тимәсен,
суынмасын.
Шул эзләргә кире кайтып,
берсе, бәлки, яшен түгәр.
Ак эзләрне,
пакь эзләрне
икенчесе килеп үбәр,—
кер кунмасын,
җир туңмасын.
Буш урамда
ак буранда
җитәкләшеп икәү бара,
эзләренә ак кар ява.

1970

Сораулар һәм биремнәр.

1. Шигырьгә ни өчен шундый исем бирелгән дип уйлыйсыз? Шигырьнең рәсем сәнгатендәге этюд жанры белән нинди бәйләнеше, уртаклыгы бар? Сез шигырьгә нинди исем куяр идегез?
2. Шигырьдәге исем сүз төркеме белән белдерелгән сүзләрне генә аерып укып чыксагыз, картина ясаламы, атап әйтелгәннәр күз алдына киләме? Ә хәзер фигыльләрне генә тезеп укып карагыз, игътибар иттегезме: дога укыгандагы кебек ялвару, теләк теләү килеп чыга.
3. Шулай да предметларга, күренешләргә җан кермәде әле. Сыйфат белән белдерелгән аергычлар — аныклагычлар

* *Этюд* — табигатьтән, тормыштан күчереп алган күренеш, картина.

кирәк. Теләсә нинди урам түгел, буш урам, бураны да нәкъ менә ак буран. Ни өчен сүзләр шундый кыска һәм үз мәгънәләрендә генә кулланылганнар? Шигырьнең матурлыгы нәрсәдә?

4. Гадилек, садәлек бөркелеп торган бу шигырь кемнәр турында сөйли? Ни өчен ул киләчәк турында да уйланып ала?

* * *

Тагын узды кыңгыраулы язлар,
чылдырдатып чәчкә чукларын.
Беләсеңме, кәккүк, бу юлларның
кая җитеп, кайчан туктарын?
Юк, әйтми тор әле, чү, әйтми тор,
гомер елын бик аз санама.
Сабый чактан көткән ал җилкәндәй,
җәйге таңнар һаман аллана.
Килә дә ул, китә. Ә мин һаман
зәңгәр ярга барып җитмәгән.
Күңелемдә йөрткән сүзләремне
кульъяулыкка әле чикмәгән.
Тагын узды кыңгыраулы язлар,
чылдырдатып чәчкә чукларын...
Ә мин төне буе яулык чигеп,
каршыларга таңны чыкмадым.
Каедым да сүттем.
Сана, кәккүк,
ничә җебем актан, карадан.
Диңгезләргә киткән җилкән кебек,
кайтмасмыни таң да яңадан?

1968

Сораулар һәм биремнәр.

1. Шигырьнең укылышына, эчке моңына игътибар итегез, аның беренче сүзләрендә үк — үкенеч, моң авазы. Алга таба ул моңны нинди образлар көчәйтә?
2. Шигырьне нинди хис-кичереш берләштереп тора? Нинди фикер үстерелә? Шагыйрә нигә нәкъ менә таңны сагына, аның кайтуын тели? Таң һәркөн ата бит, кабатланмас нинди таң турында сүз бара? Ни өчен соң без үткәнне кире кайтарырга телибез?
3. Кешегә хис-кичерешләр каян килә? Ни өчен без моңлы көй, җыр яратабыз? Аңлатырга тырышып карагыз.

4. Шигырьнең лирик герое нинди булып күз алдыгызга килде? Шигырьләреннән чыгып, аның нәрсәләр турында хыялланганын, кешеләрне, табигатьне, тормышны ничек итеп күрүен аңлата аласызмы?
5. Хәзерге шагыйрьләрнең нинди шигырьләрен беләсез? Шигырь укыганда аның кайсы ягына игътибар итәсез? Шигырь ни өчен ошый яки ошамый икәнлеген үзегез теләгән мисалларда анализлап, аңлатып карагыз.

Ач, шигърият, серләреңне...

Шигырь язу теләге кешедә кайчан уяна, шигырь ничек языла? Нигә аларның берсе сине дулкынландыра, икенчесенә исең дә китми? Шигырь кем өчен языла? Әгәр дә укучы өчен булса, нигә шагыйрьләр күп шигырьләрен яшереп язалар? Әллә шагыйрь үзе белән сөйләшә, дөнья белән серләшәме?

Талантның, бәхетнең, мәхәббәтнең ни икәнлеген, аның серен, тылсымын аңлатып бетереп булмаган кебек, шигырь турында да билгеләмәләр бирү, салкын акыл белән генә сөйләү бик кыен. Чөнки ул — иң беренче чиратта хис-кичерешләр белән бәйле дөнья. Шигырьдәге хисләр табигать күренешләренә, тормыш мизгелләренә, яшәү мәгънәсенә әйләнә. Бер үк табигать күренеше турында сүз барса да, һәр шагыйрь аны үз хисе-мөнәсәбәте, тоюы-күрүе аша үткәрә, шуңа күрә ул гел яңа була. Мәсәлән, җил турында кайсы гына шагыйрь язмаган, ә Саҗидә Сөләйманова үзенең җилләрен таба:

Нигә соң эчәм җилләрне
Көйгәнче иреннәрем?

Чынлап карасаң, шагыйрә җил турында түгел, үзенең халәте турында сөйли бит, иреннәре дә чынлыкта җилдән түгел, борчулардан көя, җил эчүе дә — аның сабырлыгы, үз күңеленә дөнья гамен җыюы. Һәр шигыре белән ул үзе һәм чиксез тормыш арасына салават күпере суза, без дә шул күпердән дөньяның матурлыгын күбрәк, көтелмәгәнчәрәк күрәбез.

Шагыйрьләрнең урыны кайда? Нинди образлар, төшенчәләр, төсләр, моңнар белән урап ала ул үзен? Менә «Туган җирем, эчкән суым!» шигыре. Шагыйрә «сүз» белән «эш» арасында: сүз җиңел әйтелсә, гел кабатланып торса — тел очында йөрсә — аның кадере югала, аны җил ала. Кадерле сүзне күңел түренә яшереп, хисне эш белән, хезмәт белән исбатласаң, тормышның бик табигый һәм зарури мәгънәсе ачыла. Шигырьне тибрәтеп торган ике канат кебек парлы образлар: туган җир

һәм ана сөте. Кыйммәтләре бәяләп бетергесез туган җир белән ана кадерен кем түләп бетерә алган? Алар хакына гомерләрен биргәннәрне, яшәлеп бетмәгән гомерләрне генә янәшә куеп буладыр.

Кеше башын иеп, җиргә карап уйлана, күзләрен күккә төбәп хыяллана, ул җир белән күк арасында, ул үзен эзли, үзе турында ачышлар ясый. Чиксезлекнең тарту көче бар, югыйсә кешегә җирдәге юллар гына җитмәс идемени, кошлар юлына, биеклеккә омтылыр идемени ул? Кешене лачыннар биеклегенә горурлык хисе күтәрә. Шагыйрә җирдәге кыйммәтле әйберләрне санап-тезеп карый, үзе белән чагыштыра. Кеше барысыннан өстен, бәлки нәкъ шуңа күрә дә заманның бөтен бәла-казалары адәм башына төшәдер дә.

Шигырь чишмә кебек: үзе үтә күренмәле, шул ук вакытта аның тирәнлеге дә бар. Мәсәлән, «Этюд» шигыренең нәрсә турында икәнлеген кыска гына итеп әйтеп була: буш урамда, ак буранда икәү бара. Урам чынлап та бушмы? Әллә җитәкләшеп барган бу икәүгә, бер-берсен генә күргән бу икәүгә генә шулай тоеламы? Хәер, урам буш та түгел бит әле, нурлы тәрәзәләр, чыңлы баганалар һәм җыр белән тулы ул. Чынмы икән бу әллә ике гашыйкка гына шулай тоеламы? «Җитәкләшеп икәү бара, эзләренә ак кар ява». Таш урамда калган эзләр күңел түрендә, хәтердә, гомер юлында калган башка эзләргә дә килеп тоташа... Барысын да үзенә җыеп алган эзләр матур образга әйләнгән. Бу икәүне күреп, аларның киләчәге өчен ихлас борчылып торган шагыйрә дә бар шигырьдә. Җитәкләшеп барган бу икәүнең юллары аерылмасмы, шуның өчен үкенергә туры килмәсме аларга? Үткән эзләргә кире кайту мөмкин түгел икәнен белмәгәннәрне ялгышлардан ничек сакларга? Шагыйрә теләк тели: ак эзләргә кер кунмасын. Моның өчен күңелләрнең пакь калуы кирәк. Менә шуңа күрә шигырь гел ак төсләргә манылган, аңа күңел җылысы салынган, шуңа күрә һәркемнең бу икәү урынында буласы киләдер кебек.

Шигырьләрен укыган саен, Саҗидә Сөләймановага күбрәк ышанасың, аның белән тагы да сөйләшәсе, серләшәсе килә. Ул әр-яңа сүз дә әйтми кебек, әмма безнең күңелләрдә йөргән, аңлатыр өчен без сүзләр таба алмаган хис-тойгылар турында сөйли. Безнең дә бит кәккүк тавышын ишеткәнебез бар, әмма аның белән шулай матур итеп сөйләшә генә белми идек. Кәккүккә кешеләр гаҗәеп моңлы бер бурыч йөкләгән: ул гомер

озынлыгын саный. Исәпләү машиналары заманы, нинди генә календарьлар, сәгатьләр юк, әмма кешегә тереклек, җан иясе кирәк. Кәккүкне, тавышы моңлы булганга, җырларга керткәннәр, өзелеп-өзелеп кычкырганга, үзе дә ялгыз булганга, аңа шундый шөгыль уйлап тапканнар.

Шагыйрә, кулъяулык чиккән кебек, сүзләрдән бизәкләр ясый, кыңгыраулы язлар, чылдырап торган чәчкә чуклары сыман, шигырь чыңлап, челтерәп торган авазлардан коеп куелган. Ал җилкәндәй өмет, ал таңнар; хыялларның зәңгәр яры ачык, якты төсләргә манылган. Нинди матур образ табылган:

Каедым да сүттем. Сана, кәккүк,
ничә җебем актан, карадан.

Кулъяулык чиккән җеп, аның төсләре шигырь юлларына килеп ялгана. Саҗидә Сөләйманова шигырьләренең һәр юлы әнә шулай укучы күңеленә күчеп дәвам итә, шигырьнең дә, димәк, шагыйрәнең дә гомерен озайта.



Миргазиян Юныс
(1927 елда туган)

Миргазиян Закир улы Юнысов Татарстанның Баулы районы Исергәп авылында крестьян гаиләсендә туа. 1944 елда армиягә алына, хәрби авиация мәктәбендә укый. Соңрак авиация училищесын да тәмамлый, эскадрильяда хезмәт итә. 1955 елны хәрби хезмәттән азат ителгәч, Мәскәү университетының филология факультетына читтән торып укырга керә. Шул ук вакытта Кара диңгез пароходчылыгында эшли башлый, чит илләргә йөри торган сәүдә корабленда капитан ярдәмчесе вазифаларын башкара. 1968—1977 елларда диңгез транспорты фәнни-тикшеренү институтында гыйльми хезмәткәр, «Наука и религия» журналында бүлек мөдире булып эшли. 1977 елдан яңадан диңгезгә әйләнеп кайта, сәүдә корабында йөзә.

Миргазиян Юнысның әсәрләре менә шундый бай, кызыклы тормыш юлыннан үсеп чыгалар, романтик хыялларны тормышка ашырырга өйрәтәләр, дөнья тирәли сәяхәтләрдә йөртәләр. «Тозлы җил», «Теләп алган давыл», «Таңда Босфор аша»повестьлары чын мәгънәсендә дөнья гизеп язылганнар. Сәяхәтләр аңа балачактан тынгы бирмәгән. Балалар өчен язылган «Тимер фил», «Занзибар зәңгәр болытлар артында» әсәрләре шул турыда сөйләп тора. Очучы, диңгезче профессияләре язучының «Табу һәм югалту», «Шәмдәлләрдә генә утлар яна», «Юлда уйланулар» кебек әсәрләренә дә фәлсәфи канатлар куя. Хикмәт шунда: язучы әйтерсең җиргә, анда яшәгән кешеләргә очар кошлар биеклегеннән, океан-диңгезләр ераклыгыннан торып карый. Никадәр еракка китсә, шулкадәр кадерле аңа җирдәге кешеләр язмышы.

Миргазиян Юнысның үз тормышы, иҗаты да геройларының язмышына һәм фидакярлегенә охшаш. Иҗатының биеклеген, әсәрләренең матурлыгын раслап, аңа 2005 елда Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелә.

ШӘМДӘЛЛӘРДӘ ГЕНӘ УТЛАР ЯНА

(повесть кыскартып алынды)

Сугыш дошман җирендә иде инде. Икенче Белорус фронты Штральзунд — Росток — Шверин юнәлешендә уңышлы һөҗүмнәр алып бара. Беренче Белорус фронты, 16 апрельдә башлаган атакасын көннән-көн көчәйтеп, стратегик заданиене үтәп килә иде. Фронт озакламый Берлинга килеп җитәргә тиеш. Каршылык күрсәтү бетмәгән әле. Кайвакыт фашист гаскәрләре өметсез чаялык белән каршы торып карыйлар. Андый урыннарда аяусыз каты кан коюлар булып ала. Дошманның чигенмәскә теләгән частьлары юкка чыгып калалар.

Кырык җиденче армия һәм Икенче танк армиясе, Берлинны төньяктан урап үтеп, Германиянең башкаласын боҗра эчендә калдырырга әзерләнә иде.

Сәләхов хезмәт иткән авиаполкта да сугышның тәмамланып килүе ачык сизелә. Соңгы очуда, безнең гаскәрләр чиктән тыш тиз алга китү сәбәпле, эскадрилья, үзебезнең частьларга зыян китерүдән куркып, бомба ташлый алмыйча кире әйләнеп кайтты. Шуннан соң атнадан артык беркемнең дә һавага күтәрелгәне булмады.

Тиздән сугыш бетәсен һәркем аңлый, һәркем сизә иде. Бу яңалыкны хәтта табигать тә сизә шикелле. Агачлар сабыр гына яфрак ярып утыралар. Кар суы инде җиргә сеңеп беткән. Җил җылынган. Кар озак яткан җирләрдә кызгылт шыткылар баш төрткән.

Экипажның өч очучысы, кояш нурларына коенып, дивизия штабына таба атладылар.

Очкан чакта экипажны уртак эш берләштерә. Һавага күтәрелү белән, бер теләккә беркетеп, уртак ихтыярга кысып төйнәлгәндәй хис итәсең. Кабиналар аерым, шуңа карамастан ялгызлык юкка чыга, мөстәкыйль булуыңны да тоймый башлыйсың. Очу эше кешегә бик күп яңа сыйфатлар өсти. Бердәмлек хисе көчәя. Үзара

мөнәсәбәтләргә җаваплырак карый башлыйсың. Бергә очкан кешеләр арасында җылы туганлык тойгысы уяна.

Башлап Сәләхов үзенең штурманы белән дуслашты. Айхал якуты Максим Майнагашев кәкре аяклы бер кеше иде. Ат менеп йөрергә уңайлы сыйраклар. Аның атлап йөрүе дә аюныкына охшашлырак. Үкчәләре бер-берсеннән ерак торалар. Йөргәндә аягының баш бармаклары бер-берсенә тия язып китәләр. Максимга битнең дә тактадай яссысы эләккән. Әллә табигать аның битен җентекләп эшкәртергә иренгән, әллә чыдам, нык булсын дип шулай эшләгән. Максимның борыны бөтенләй юк диярлек. Бит уртасында күңелсез булып күренеп торган ике тишек. Битне ясап бетерер алдыннан табигать үзенең гаделсезлек эшләвен аңлап алган, күрәсең. Ул Максимга гаҗәп матур, килешле иреннәр куйган. Иман нуры чәчеп торган коңгырт күзләр. Таң калырлык ягымлы елмаю. Шуларны күрү белән, егетнең бите җәлпәк, аяклары кәкре икәнлеген онытып ташлыйсың. Ул күзгә күренеп чибәрләнеп китә.

Юк, табигать барыбер гадел ул. Табигать, беркемне дә рәнҗетмичә, матурлыкны тигез өләшә. Әгәр гавам шаукымыннан туган сукыр инанудан арына алсак, без, аяк атлаган саен, табигатьнең бөек рәссам икәнлеген күреп куанып торыр идек.

Күзгә бәрелеп торган тышкы тәтилек безне тиз туйдыра. Күңелендә рухи күркәмлек булмаган кешедән без бик тиз гарык булабыз. Бераздан андый бәндәне күрәсе дә килми башлый. Ә рухи матурлык беркайчан да туйдырмый. Киресенчә, якынайган саен ул сине ныграк тарта, сокландыра, җәлеп итә. Ихтирамың көннән-көн арта тора. Син аның кимчелекләрен күрми башлыйсың.

Майнагашевның табигыйлегенә, аның рухи матурлыгына эскадрилья очучылары сокланып туя алмыйлар иде. Ул күренү белән эчтә бер җылылык уяна. Бераздан син аның өчен «аһ» та итмичә җаныңны бирергә әзер буласың. Сәләховның штурманы шундый кеше иде.

Авиаполкка килгән атнаны ук Майнагашев бер дуамаллык эшләп ташлады. Пистолеттан атарга өйрәнү вакыты иде. Максим лейтенант Кононенко белән

бәхәсләшеп китте. Ул болай диде: «Әгәр илле метрдан атып фуражкаңа таккан җиз крабның нәкъ уртасын тишеп чыгармасам, бөтен офицерлар алдында битемә төкерерсең». «Нәрсә ул төкерек,— диде Кононенко.— Сөрттең — бетте, аның эзе калмый». «Кала,— диде эскадрилья штурманы капитан Гусев.— Биткә тигән төкерекне мәңге юып булмый. Ул кешенең намусын, «кеше» дигән бөек исемен пычрата».

Бәхәсне тыңлап торучы лейтенант Бадальян Кононенкодан сорады:

— Әгәр крабыңа тигерә алса, син Майнагашевның нинди таләбен үтисең?

— Юк минем таләбем,— диде лейтенант Майнагашев.— Аның йөзенә пистолет төзәү үзе ни тора.

Егетләр эскадрилья командиры күрмәслек аулаграк җиргә киттеләр. Һәм шул көнне Кононенкога яңа краб эзләргә туры килде. Аның фуражкасындагы крабта бармак сыярлык тишек барлыкка килгән иде. Пуля егетнең түбә чәчен көйдереп киткән. Бу хәл зур гауга белән тәмамлана язып калды.

Ике офицерның атышуы турында кемдер полк командирына әйткән булып чыкты. Командир шул ук көнне аларның икесен дә гади солдат итеп штрафной батальонга озатырга боерык бирде. Эскадрилья командиры майор Растопчин, полк командиры белән сөйләшеп, җәзаны унар тәүлек гауптвахтада утыруга алыштырмаган булса, бу дуамаллык бик зур афәт белән тәмамланачак иде.

Шушы вакыйгадан соң Майнагашевка кызыксынып карый башладылар. Юләр атышу нишләптер аның абруен бермә-бер күтәреп җибәрде.

Сугышчан заданиегә ешрак оча башлагач, егетнең тагын бер сәләте ачылды: Максим дүрт мең метр биеклектән бомбаны кое эченә салып китә ала иде.

Мондый осталыкның каян килүен берничек тә аңлатып булмый. Тәҗрибәгә таянып та, математик хисап белән дә андый төгәллеккә ирешү мөмкин түгел. Табигать Максимга сирәк очрый торган бер зирәклек биргән иде. Бу сыйфат талант дип атала.

Сәләховның талант турындагы кагыйдәне очратканы юк иде әле. Бәлки, бу турыда кагыйдә дә чыгарып булмый торгандыр? Уртача сәләтле кешене теләсә нинди эшкә өйрәтеп була. Һәм ул һәр эшне дә

уртачарак башкаруга ирешә. Аның мөмкинлеге шул чама була. Талант исә һөнәрен иң югары, иң бөек ноктага җиткәнче камилләштерә ала. Талант — эшендә илаһи нечкәлеккә ирешүче.

Америка индеецлары, үлән тапталуына карап, сукмактан узган кешенең картмы-яшьме, ирмехатынмы, кораллымы-коралсызмы икәнлеген төгәл әйтә алганнар дип сөйлиләр. Индеецлардагы сәләт Максимда да бар иде. Һава торышын ул берничә көн алдан әйтә ала. Көннең болытлымы, аязмы булачагын гына түгел, җилнең кай яктан исәчәген, басым алышынуын, һава дымын, тагын әллә нинди билгеләрне алдан сизә иде. Бомба ташлыйсы мизгел җиткәнен дә Майнагашев ниндидер эчке бер тоем белән чамалый. Шунлыктан ул ташлаган бомба читкә тайпылмый иде.

Штурманнар бомба ташлыйсы вакытны катлаулы формула аша хисаплап чыгаралар. Андый хисапка Максимны да өйрәткәннәр. Ләкин ул, математик хисап белән генә чикләнмичә, бомба ташлаганда үзенең аучылыкта үзләштергән тәҗрибәсен дә куллана иде. Аучы кеше буларак, ул җил юнәлешен, тизлекне, җир тартуын, хәтта һавадагы магнит кырын да тәне белән тоя иде булса кирәк.

Талантлы штурман белән очуы рәхәт. Штурман самолетны алдан сызган маршрут белән адаштырмыйча алып барырга, бомба ташларга, истребительләр һөҗүм иткәндә пулеметтан атып, очкычны һәм экипажны сакларга тиеш. Талантлы штурман бу вазифалар белән генә чикләнеп калмый. Ул летчик һәм укчы-радист белән бергә сугышчан заданиенең төгәл үтәлүен хәл итә. Экипажның иминлеге, исән калуы күп яктан аның кулында. Шуңа күрә Сәйрин үзенең штурманы белән горурлана иде.

Сәйрин укчы-радисттан да уңды.

Марсель Ялчинский гаҗәп чибәр кеше иде. Дулкынланып торган куе кара чәч, кызларныкы шикелле нечкә кара кашлар, ә күзләре авыр керфекләр астына яшеренгән. Табигать, Марсельнең һәр әгъзасын артык матур итеп җибәрүен бары тик эшкәртеп бетерер алдыннан гына сизепме, егеткә вак һәм сирәк тешләр куйган. Гомумән, тәмле ашап үскән кешенең тешләре начар була. Марсельнең алгы теше ямаулы иде.

Ялчинскийның зыялы егет икәнлеген Сәләхов беренче күрүдә үк сизеп алды. Тәрбияле кеше белән мөнәсәбәткә кергәндә ниндидер эчке рәхәтлек барлыкка килә. Андый кеше янында син үзеңне тыныч һәм ышанычлы тотасың. Зыялы кеше сиңа уңайсызлык тудырмый.

Ялчинский Кара диңгез буендагы таулар янында туып үскән иде. Кырык дүртенче елның азагында, бер атна ял биреп, аны туган җиренә җибәрделәр. Ялыннан ул танымаслык булып үзгәреп килде. Әйтерсең аны алыштырганнар иде. Шат күңелле, көләч егет өенә кайтып килгәннән соң әллә нишләде. Юк кына сүзгә дә кабынып китә, күңеле сына һәм муенын элмәккә тыгар хәлгә җитә иде.

Сәләхов укчы-радист белән сөйләшеп тә карады. Сүз кузгату белән аның кәефе кырылды. Егетнең бу турыда сөйләшәсе килми иде. «Сукыр чебен шикелле нигә кешенең күзенә керергә? — дип уйлады Сәләхов.— Һәркемнең күңел түренә бикләп куйган изге сере була. Андый серне хәтта якын дусларга да ачмыйлар. Аңа кагылырга ярамый...»

Укчы-радистның әнисе — музыкант, үз республикасының халык артисты, әтисе сәнгать белгече, профессор икән. Тәрбиянең иң тирән эзе ата-ана канаты астында яшәгәннән кала. Балачакта сәнгать мохитендә тәрбияләнеп үскән кешегә казарма шартларында яшәү шактый авыр. Марсель бик түзем һәм нык ихтыярлы егет булып чыкты. Ирләр колагына гына ярарлык анекдот сөйләү, кызлар турында шапырынулар аны ифрат рәнҗетә иде. Ул түзде. Эчендәге тойгылар давылын яшерә белде.

Ялчинский сугышка кадәрге тормышы турында сөйләргә яратмый иде. Тәрбияле кеше, гомумән, семья тормышы турында тугарылырга ашыкмый. Аңларлык кеше табып, Марсельнең туйганчы эчен бушатасы килгән чаклары да була. Бигрәк тә соңгы вакытта. Ул торган төбәккә килгән афәтне ишеткәннән соң үкереп елыйсы, аңларлык кешегә зарланып юанасы килә иде аның. Ул әллә ничә мәртәбә бу турыда үзенең командиры белән сөйләшергә чамалап карады. Ничектер җае чыкмады. Ничектер тартындыра иде. Аңларлык кеше булса да — командир бит.

Лодзь шәһәрендә торганда, иптәшләренә ияреп, Сәләхов күрше частьта хезмәт итүче кызлар янына барды. Танышу башланды. Башка егетләр җиңел генә исемнәрен әйтәләр дә, күптәнге танышлар шикелле, мыскал да тартынып тормыйча черкелдәшә башлыйлар. Сәйрин исемен әйтә алмыйча газап чикте. Тотлыкты, кызарды һәм, ни эшләргә белмичә ярты сәгать чамасы аптырап утыргач, тизрәк чыгып тайды. Аның өчен исем шундый мөһим, ихтирамга һәм сергә чорналган бер тылсым кебек тоела иде. Танышканда тагын бер авырлык туа иде. Исемен татарча әйтергә Сәләхов тартына, ә үзгәртергә вөҗданы кушмый иде. Борынгылардан калган исем гыйбадәте, антропоморфизм бу егетнең күңелендә һаман яшәп килә иде. Сәйриннең туган авылында борынгыдан калып яши килгән йолалар очрый иде... Сәйриннең әнисе иренең, балаларының исемнәрен дә ят кешеләр алдында әйтми иде. Иренә «син» дип, башка кешеләргә ире турында «үзе» дип сөйли, балаларына «бәбкәм», «карлыгачым» һәм шуның кебек матур исемнәр белән эндәшә иде.

Менә шуңа күрә Сәйрин Сәләхов балачактан ук кеше исеменә җитди карарга өйрәнде. Аңа һәр начарлык, намусыңа тап төшерерлек һәр начар эш исемгә сеңеп кала шикелле тоела иде. Балачакта аңа: «Исем сиңа гомергә бирелгән, ул бер генә, аның чисталыгын, аның ихтирамын сакларга тиешсең»,— дип аңлаттылар. Сәйрин ышанды, исеменә йогарлык начарлык эшләүдән моңа кадәр сакланып килде. Исем ул синең үзең генә дә түгел бит: ул — синең йөзең, ата-анаңның, ыругыңның, нәселеңнең йөзе һәм аларның байрагы. Исем ул — синең тормыш юлыннан күтәреп барган үз байрагың.

Шулай уйлый иде икенче эскадрильяның икенче звено командиры, очучы, өлкән лейтенант Сәйрин Сәләхов.

Сораулар һәм биремнәр.

1. Сугышның тиздән бетәсен белү хәлне кайсы якка үзгәрткән: җиңеләйткәнме, авырайтканмы?
2. Сәйрин, Максим, Марсель характерларын тасвирлагыз.
3. Максимның Кононенко белән бәхәсен сез ничек бәяләр идегез? Максимның: «Аның йөзенә пистолет төзәү үзе ни тора»,— дигән сүзләреннән нәрсә аңладыгыз?

4. «Син», «сиңа әйтәм» дип эндәшү искелек галәмәте генә дип уйлыйсызмы? Теләсә кемгә шулай эндәшү урынлымы? Үз исемегез турында ни беләсез, ни уйлыйсыз? Кешегә исем аны башкалардан аеру, аңа эндәшү җиңел булсын өчен генә биреләме икән? Борынгы һәм заманча исемнәргә мисаллар китерегез. Кайсы матуррак?
5. *Сәләт, талант, даһилык* төшенчәләрен аңлатып карагыз. Бу сыйфатлар тумыштан киләме, аларны тәрбияләп, үстереп-көчәйтеп буламы?

Заданиенең уңышлы тәмамлануына тулысынча ышанса да, Сәләховның күңеле бөтенләй үк тыныч түгел иде. Нәрсәдер әкрен генә аның йөрәгенә шом сала, күңелендә астыртын шик пыскый иде. Биеклеккә күтәрелгәч, шик югалачак, ачык тәвәккәллек барлыкка киләчәк. Сәләховның шушы халәтне ничә тапкыр сынаганы булды. Ул һәр сугышчан заданиене гадел үтәргә өйрәнде, ләкин заданиене башкарып чыгу турында алдан ук борчылмаска үзен өйрәтә алмады.

Сәйрин ашханә бинасын тагын бер кат урап чыкты. Тәрәзә яныннан узганда, туктап, бертын ашханә залына карап торды. Ашханә эчен чиста итеп җыештырганнар. Түшәмгә аскан хрусталь люстрадан яктылык коела. Шул яктылыкка күмелеп, ашханәдә ике кеше ашап утыра. Сәләховның йөрәгенә сөенечле рәхәт бер җылылык йөгерде. Шундый якын, шундый газиз иде аңа бу ике кеше. Аларның бер табында утыруларында борынгыдан калган чын якынлык һәм көчле бердәмлек бар иде. «Хәзер кузгалачаклар»,— дип уйлады ул экипаж турында. Дусларының ашханәдән чыгуын Сәләхов түземсезлек белән көтә башлады.

Тәрәзә каршында ялгыз юкә агачы үсә иде. Сәйрин шул агач янына туктады. Авылда, аларның баскычлары төбендә, нәкъ шуның буйлы тирәк үсә. Тирәк исенә төшкәч, Сәләховның күңелендә юкә агачына карата кардәшлек тойгысы уянды. «Чит ил. Герман җире. Кешеләре — ят, телләре аңлашылмый. Ә агачлары гел безнеке шикелле,— дип уйлады Сәйрин.— Табигать нинди бөек! Ул үзенең бәрәкәтен һәр илгә, һәр халыкка тигезләп өләшкән. Беркемне кимсетмәгән, беркемгә дә артыгын бирмәгән. Ә шушы хакыйкатьне аңламау — адәм баласының комсызлыгы — җирне күбрәк эләктерер өчен күрше өлешенә керергә, аның җирен яулап алырга мәҗбүр иткән. Сугышны ком-

сызлык тудыра. Сәбәпсез үлемнәр, кан коюлар — бары да шуннан. Җитмәгәнмени фашистларга үз җирләре?»

Балачак та шушы тирәкләр кебек садә, саф, гөнаһсыз бит. Күкрәк тутырып саф һава сулыйсың, йөгерәсең, уйныйсың. Көне буе ректә, табигать кочагында. Кояш баеганда, әти-әниең эштән кайта. Малларны карап абзарга япкач, Сәләховлар гаиләсе тирәк төбенә кечкенә җәйгә җыела иде. Табын янында очрашу шундый рәхәт. Тирәк ботаклары аша кечкенә йолдызлар җемелдәгәне күренә. Сәйриннең әнисе аклы яулыгын чөеп бәйләгән. Яныл-пешеп чәй ясый. Башта агач кашык белән чынаякларга каймак сала, аннан соң чәйнектән чәй агыза. Чәй агызганда, борынга хуш ис килеп бәрелә.

Әтисе табын янында һәйкәлдәй мәгърур утыра белә иде. Әйтерсең аны патша итеп куйганнар. Аңа карау белән «әтиебез исән чакта дөньяда бернинди афәт, гаделсезлек һәм кимсетү булмаячак» дип ышана идең. Чыннан да, ул исән чакта гаиләгә җил-яңгыр тимәде. Күп иде авылда Сәйриннең әтисе ише кешеләр. Ышанычлы, нык, чыдам нигезгә корылган бәхетле гаиләләр дә күп иде.

Өстенлек итү — тынгысыз тойгы. Өстенлеккә омтылу ифрат мәшәкатьле. Әтисенең гаилә белән идарә итүе өстенлеккә көйләнмәгән иде. Аның һәр сүзенә, кылган эш-гамәленә Аллага ышанган шикелле ихлас күңелдән ышаналар иде. «Әтиегез болай эшләгәнне ярата...», «Әтиегез!» — иң катлаулы мәсьәләне әнә шул сүз хәл итә иде.

Әнисенең төп бурычы — гаилә эчендәге дустанә мөнәсәбәтләрне, туганлык, татулык хисен саклау иде. Бу вазифасын Сәйриннең әнисе сокланырлык итеп үтәп килде. Шунлыктанмы, Сәләховлар гаиләсендә яшәү тыныч һәм рәхәт иде. Шундый уңайлы иде гаилә куенында көн күрү.

«Барлык илләрнең җитәкчеләрен бергә җыеп, безнең баскыч янындагы тирәк төбенә утыртасы һәм әни ясаган чәйне эчертеп карыйсы иде,— дип Сәйрин юләрләрчә хыялланып куйды.— Шуннан соң да җир йөзендә гаугалар калыр идеме икән?»

Агач янында басып торганда, Сәйрингә тынычлык иңде, аның уй-хисләре, кыйбла табып, бердәм ага башладылар.

Юкә агачыннан бал исе аңкый иде. Сәйрин, якынрак килеп, кәүсәгә сөялде: «Без җаваплы заданиегә очабыз,— диде ул эченнән генә.— Син, яз җиткәч, яфрак ярасың, көзен, аларны җиргә коеп, кышка әзерләнәсең. Син — зирәк һәм мәрхәмәтле агач. Гомереңдә бер генә бөҗәккә дә зыян китергәнең юк. Без, адәм балалары, кайчан синеңчә дөрес һәм матур яши башларбыз икән? — Егет бертын тыңлап торды.— Ярый, мин китәм. Безгә исәнлек телә. Безнең кайтканны көтеп тор. Кайткач, тагын яныңа килермен. Хуш...»

Сәләхов ашханәдән чыгып килгән иптәшләренә кушылды.

Җилкәләренә парашют салып, караңгылыкны ерып баручы өч егет яланда адашып калган өч моңсу торнаны хәтерләтә иде. Хисләндерә, күкрәк эченә моң тула иде төнге очуга барганда.

Без туганнан бирле шушы җирне таптап йөрибез. Бер караганда гап-гади җир, бары туфрак кына. Очарга җыена башлагач, ул кинәт шундый газиз, шундый кадерле тоелып китә. Җиргә моңа кадәр тиешле ихтирам күрсәтә алмавына хәтта сабыйларча үкенә башлыйсың.

Самолет тирәсендә, гадәттә, очыш алдыннан була торган ыгы-зыгы башланган иде инде. Әледән-әле электромоторлар гөжелдәп ала. Кесә фонарьларының уты кабынып-сүнеп киткәли. Авиатехникларның саран гына фикер алышулары ишетелеп куя иде.

Менә самолетның моторын да кабыздылар. Мотор берничә мәртәбә ютәлләп алды да дырылдап әйләнергә тотынды. Әйләнү һаман тизәя, тигезләнә бара иде. Озакламый мотор тавышы тоташ үкерүгә әйләнде. «Тизлеккә чыдый алмыйча металл елый,— дип уйлады тавышны дикъкать белән тыңлап килүче укчы-радист.— Безнең экипаж очасы машинаның моторы. Әйлән, тизрәк җылын».

Аэродромдагылар, самолетка юл биреп, читкә тайпылдылар. Сәләхов уңъяк моторга көчле газ бирде. Самолет зәһәр итеп үкерде дә теләр-теләмәс кенә урыныннан кузгалды. Очкыч, борылып, старт ягына таба йөгерергә тотынды.

«Башланды»,— дип уйлады штурман Майнагашев.

«Тәңрем, бу гамәлемне сиңа багышладым»,— дип ярым җитди, ярым шаярта төшеп дога кылды Ялчинский.

Ә бу вакытта экипаж командиры: «Болытлар гына таралмаса ярар иде»,— дип уйлый иде.

Җирдән аерылган мизгелдә очкыч беренче адымын атлаучы сабый баланы хәтерләтә. Беренче тапкыр оясыннан чыккан кош баласы да шундый була. Әле канатлар ныгымаган, көч чамалы, тәҗрибә тупланмаган. Биеклектә шундый җитез, шундый кыю самолет җирдән күтәрелә башлаганда, кинәт югалып кала. Хәрәкәтләре шундый сүлпән, шундый кыюсыз тоела: аның күтәрелеп китә алуына шикләнеп куясың.

Сәйриннең оча башлаганына өченче ел тулып килә иде. Тәҗрибә җитәрлек. Ул Пе-2 нең бар нечкәлекләрен үзләштерде диярлек. Ә җирдән күтәрелеп киткәндә, аңа самолет таралып төшәр шикелле тоелып китә иде. Курку йөрәкне чеметеп ала. Җир ерагая башлагач кына тынычланып китәсең.

Сәләхов ашыгып шассиларны җыйды. Тизлек кинәт артып китте. Самолетның очуына ышаныч керде. Яшәү дә шулайрак бит: максатыңа барганда, өмет ышанычлырак була. Өмет канатлары, тормыш вактөяге өстеннән күтәреп, сине югарыдан алып бара.

Моторлар гөжләве, очкыч тәненең тигез дерелдәве җанга тынычлык бирә иде. Хәзер Сәләхов мөстәкыйль һәм азат иде. Һавага күтәрелгән кешегә беркем ярдәм итә дә, комачаулый да алмый. Син — мөстәкыйль. Очкыч белән язмыш аша тоташкан. Өстә чиксез зәңгәр күк. Ышанычың — сәләтең. Җир кануннары аста, еракта калдылар. Алар инде сине буйсындыра алмыйлар.

Пе-2, ерактан урап, аэродром өстенә чыкты һәм астан карап торучылар алдында маршрутка ятты.

Кинәт тирә-якны караңгылык чорнады. «Болыт эченә керәбез,— дип уйлады Сәләхов.— Калынлыгы күпме икән?» Тәрәзәләрнең тышкы ягыннан нечкә җепкә эверелеп, су тамчылары йөгерә иде. Тылсымлы төнге күк күренде. Таңга каршы тоныклана башлаган йолдызлар яна. Курстан уңдарак Сәләховның төнге йокысын алган тулы ай эленеп тора. Очкыч иксез-чиксез бушлык сахрасында ялгызы йөзеп бара. Аның эчендә — сугышчан задание үтәргә баручы өч егет. Бөрешеп утырганнар. Сәләхов моторларның эшләвен, приборларның күрсәтүен тикшереп бара. Кулы штурвалга яткан, аяклары борылу руленең педалендә.

Майнагашев, навигация линейкасының верньерын шуыштырып, маршрутның икенче этабына күчү вакытын хисаплый иде.

Корыч винтлар һаваны бораулыйлар, корыч пропеллерлар миллион еллар тупланган төнге тынлыкны җимерергә тырышалар. Тынлык бирешми. Аны берьюлы җимереп ташларга очкычның көче җитми. Җирдә яшәү дәвам итә. Кешеләр изрәп йоклыйлар, ял итәләр. Сугыш вакытлыча каядыр поскан, ышеренгән. Ул кешеләрнең уянганын сагалый. Сугышчылар хәл җыялар. Фашистлар да ял итә. Аларга да ял кирәк. Машиналар кузгалганчы гына саклана торган табигый тынлык бу.

Сәйрин сугышка кадәр тынлыкның нәрсә икәнен аңламый иде әле. Ул чакта машина тавышы тансык тоела иде. Ул икенчедә укыганда, тынлыкны чатнатып, авыл урамына көпчәкле трактор килеп керде. Тракторны кул чабып каршы алдылар. Картлар гына нигәдер шомлана төштеләр. «Җирне ат белән сөреп тә тамак туйдыра ала идек әле. Нигә китергәннәр бу шайтан арбасын? Коръәндәге яәҗүҗ-мәәҗүҗ шушыдыр инде? Безне дөмектерергә килә, күрерсез»,— дип сукранды күрше карчыгы. Ә хәзер шундый кечкенә тракторлардан туган танклар җир шарын сытып, канга батырып йөри. Чалгы чүкегәндә, урамнан кыңгыраулы ат үткәндә генә ватыла торган тынлыкны тураклап, күктә самолетлар оча. Сәйрин сизә, сугыш кораллары елдан-ел туктаусыз дәһшәтләнә барачак. Хәзер аның кулында гына да егерме мең ат көче. Сугышның көче, җимерү мөмкинлеге туктаусыз үсә. Ә кеше һаман шул килеш. Аны бит таяк белән сугып та үтереп була.

Бомбалюкларда алтышар йөз килограммлы дүрт бомба ята. Бомба эчендәге тротилларда балачакта Сәйрин ишеткән әкиятләрдәге барлык җен-пәриләр гайрәте бардыр. Коралларның көче, гайрәте һаман арта бара. Бу омтылышның ахыры булырмы икән? Бомбалюктагы дүрт бомбаны штурман фашистлар өстенә ташларга тиеш. Бомба ыргытырга барганда, алда сине нәрсә көткәнен беркем әйтә алмый.

Алар өчәү. Өчесе дә яшь. Аларның әле берсе дә өйләнмәгән, берсенең дә башлаган эшен дәвам итәрлек балалары юк. Алда — фронт сызыгы. Сызыкның теге ягында — бомба ташлыйсы объект. Шул сызык аша

узганда, аларны ни каршылар? Сугыш ул — ялкын белән ут сүндерү. Исән калу турында өметләнеп үлемгә бару. Сәйрин сугышның нәрсә икәнлеген аңларга тырышып карады. Хәер, сугышны берничек тә аңлатып булмый, аны үз күзең белән күрергә кирәк: «Юк, бүтән күрергә язмасын инде»,— дип уйлады Сәләхов һәм тирә-якны күзәтергә кереште.

Күк йөзе әле тыныч иде. Болытлар сизелер-сизелмәс кенә кызара башладылар. Көнчыгыш күзгә күренеп алсулана бара. Шундый саф, сабыйлар сулышыдай нәзберек таң беленеп килә иде. Алсулана башлаган күккә озак карап торсаң, фәрештәләр очканы күренер кебек.

«Мондый күккә озак карарга ярамый — Алла барлыгына ышана башларсың»,— дип Сәйрин көлемсерәп куйды.

— Фронт сызыгын үтәбез,— диде штурман Майнагашев.

Очучылар дикъкать белән тирә-якны күзәтәләр. Тәнгә киеренкелек таралган. Нәрсәдер көтәсең, йөрәкне билгесезлек чорнаган.

Болыт арасыннан яктылык бәреп чыкты һәм шундук сүнеп тә куйды.

— Ракета аттылар шикелле,— диде укчы-радист.

— Сизми калдым. Сулъяктарак күренде шикелле,— диде штурман.

— Нишләп болай иртә башладылар? — диде Сәләхов.— Объект шактый ерак бит әле.

— Ун минут калды,— диде Майнагашев.

Күк йөзе һаман тыныч иде. Болыт арасыннан аратирә ачыклыклар күренеп китә. Ачык урында җирнең артка таба салмак кына шуышканы күзгә ташлана.

«Болытлар таралмаса гына ярар иде!» — дип кабат тынгысызланып алды Сәләхов.

— Ракета аттылар. Монысын ап-ачык күрдем,— диде укчы-радист.

«Башланды,— дип уйлады Майнагашев,— урынны ачыклап өлгерергә кирәк». Җир күзгә чалыну белән, штурман ориентир эзләргә кереште.

Самолетның урынын төгәл ачыклавы кыен иде. Җир болыт арасындагы ачыклыктан күренеп ала да шундук күздән югала. Хисаплап тапкан нокта белән канәгатьләнергә туры килә.

Беренче снаряд самолеттан уңдарак ярылды. Чаткы кабынып сүнде, һәм һавада ак мамыктан ясалган гигант бүреккә охшаш төтен эленеп калды. Шартлау дулкыны соңгарак калып килде. Ул килеп бәрелгәч, очкыч кинәт сискәнеп куйды.

«Мессер»лар кинәт борылдылар. Икенче мизгелдә алар күздән югалды.

— Командир, качалар фашистлар! — диде Майнагашев.

— Бензиннары бетте,— диде Сәләхов.— Шуңа күрә борылдылар. Хәзер зениткалар ата башлаячак.

Аның сүзен раслагандай, алда берьюлы өч снаряд ярылды. Өч гигант мамык бүрек һавага эленеп калды.

Көн яктырган иде инде. Күк йөзе чалт аяз. Зениткаларга шундый уңай.

— Аскарак төшәргә кирәк, командир,— диде Майнагашев.

— Булмый, җиргә болай да бик якынбыз,— диде Сәләхов.— Сулъяк мотор эшләми. Өскә күтәрелергә иде. Снаряд тисә, парашют белән сикерер идек. Ярамый аска төшәргә. Әз генә биеклек калсын.

Сәләхов очкычны өскә күтәрергә ниятләде. «Их, мотор көчлерәк булса иде! — дип офтанып куйды ул.— Авыр тарта... Көче җитми».

Самолет янында тагын снаряд ярылды. Очкыч янтаеп китте. Уңъяк мотордан ниндидер чит тавыш килә иде. Винт әйләнүдән туктады.

— Марсель, ишетәсеңме? Җавап бир! Марсель,— дип ялварып сорады Сәләхов.

«Әллә арадагы кабель өзелдеме икән?»— дип уйлады ул.

Каны азайган саен, Марсельнең тәненә хәлсезлек өстәлә иде. Һава җитми. Үпкәдә кан. Сулый башлау белән, үпкәдә голт-голт кан айкала. Сулыш аласы килә. Бер генә рәхәт сулыш. Сулыш — яшәү. Яшисе килә... Бер генә минутка булса да сузасы, яшәүне дәвам итәсе килә иде.

«...Әллә музыка уйныйлар инде? Аның әнисе түгелме икән? Күзне дә ачып булмый бит, ичмасам! Хәл юк. Сулыш юк. Һәр җиргә кан тулган».

«...Әтием, әнием, алма кебек ике сеңлем әз тоелды, күрәсең. Мине дә үтерделәр...»— Марсель Ялчинскийның соңгы фикере һәм соңгы сулышы шушы иде.

Соңгы мәртәбә кан йотканда, ул зәңгәр күктә, илаһи биеклектә иде. Егетнең гомере күктә өзелде...

Кабина ут кебек кызган иде. Ялкын битне ялый, күзне көйдерә. Сәләхов, кабинадан үрмәләп чыгып, бушлыкка чумды. Колакка бәрелеп, җил сызгыра. Җир тарта. Гәүдә, һавада бөтерелеп, аска оча. Тизлек тоелмый. Тирә-якта бушлык. Күзләр йомык. Куллар, тотынырга теләп, һаваны айкыйлар. Тотынасы, туктыйсы килә. Сәйриннең гәүдәсе ана карынындагы бала рәвешендә бөгәрләнгән, бөрешкән иде.

«Парашютны ачарга кирәк!» Шушы фикер аның миен айкап узды. Куллар түштәге кызыл боҗрага үрелделәр. Сәйрин җан көче белән боҗраны тартып чыгарды. Парашютның ефәк тукымасы, ранецтан агып чыгып, өскә ыргылды. «Нигә ачылмый парашют?!»

Туракланып беткән ак ефәк, бәгырьләрне ачыттырып, баш өстендә җилферди иде. «Снаряд ярчыгы ерткан...»Куллар запас парашютка үрелделәр. Юк... Запас парашютны сикерергә өйрәнгәндә генә бирәләр... Тирәюньдә бушлык иде.

Өч секунд калды.

Сәләхов талпынды, галәмне кочып алырлык итеп кулларын канат итеп җәеп җибәрде. Мәңгегә җитәрлек итеп, комсызлык белән һава йотты. Сулыш — яшәү. Зәңгәр күк, кояш... утка пешкән битнең авыртуы, күкрәктәге кайнар тойгылар — барысы да яшәү. Аста җир. Кешеләр. Тормыш. Җир котылгысыз тизлек белән якынлаша.

Бер... Ике... Өч...

Дүртенче мизгелдә Сәйрин Сәләхов җирдә иде. Урман буе. Яшел хәтфә чирәмлек. Тирә-якта зәңгәр чәчәкләр. Шундый матур, рәхимле яшел болын Сәйриннең гәүдәсен сытты. Җир биеккә күтәрелүне өнәми. Сөяк ярчыклары егетнең итек үкчәсен үтәли тишеп чыккан иде.

Егерме яшь туларга дүрт көн калган иде аңа. Күп нәрсә калды... Күп нәрсә.

Елганың икенче ярына сырышып үскән зирек төбендә Максим Майнагашев ята. Аның баш өстендә өзелеп сандугач сайрый. Барон утарында бикләнеп калган көчекнең керсез сабый йөрәге дә афәтне сизеп алгандыр. Эт баласы чыелдап еларга керешкәндер.

Дулкынланып торган бодай кырына бер учлам кайнар көл сибелде. Язгы җил утлы көлне бодай тамырлары өстенә таратып ташлады. Марсель Ялчинскийның самолетта калып янган гәүдәсе иде бу. Янына бер йомарлам эрегән металл төшкәндә, тартай кош кычкырудан туктаган иде. Бераздан ул да зарын яңадан башлады. Кошлар тавышына ияреп, яшәү дә дәвам итте.

Адәм җирдән яралган, диләр. Җир шары — адәм балаларының төп йорты, аларның мәңгелек торагы. Җиргә кушылучылар бер гаилә булып тату яшиләр. Бу җирдә борынгы кабиләләр — готтлар, һуннар, кыпчаклар, немецлар һәм тагын әллә нинди халыкларның сугыш һәм сәясәт алып киткән вәкилләре ята иде. Шулар янына тагын өч төрле халык вәкиле өстәлде...

Сораулар һәм биремнәр.

1. Сәйриннең йөрәгенә сөенечле җылылык бирә торган сәбәпләрне ничек аңладыгыз? Кайдан килә аңа ул җылылык?
2. Әсәрдә нәрсәләр чагыштырыла, һәм нинди нәтиҗәләр ясала?
3. Гаиләдәге тынычлык, рәхәтлек нәрсәләргә бәйле? Нинди шартлар үтәлергә, нинди мөнәсәбәтләр булырга тиеш?
4. Сәләхов нигә сугышучы илләрнең генә түгел, ә бөтен илләрнең җитәкчеләрен җыярга иде дип хыяллана?
5. Җирдән аерылу, биеклеккә күтәрелү Сәйриндә нинди хисләр тудыра? *Күк, һава, илаһи биеклек* сүзләре кайсы очракта, нинди мәгънә төсмерләре белән кулланыла?

Бер мең тугыз йөз кырык бишенче елның тугызынчы мае көнне Сәйрин Сәләховның әнисе Миңлезифа апа карчыклар мәҗлесе җыйган иде.

Сугыш елларында карчыклар мәҗлес урынына кич утыру, капка төбенә җыелып гәпләшү белән канәгатьләнәләр иде. Бу — сугыш беткәннән соң, авылда үткәрелгән беренче мәҗлес. Миңлезифа моңа күптән хәзерләнә башлады. Көннәр җылыну белән, өмә ясап, йорт бүрәнәләрен эчке яктан пычак белән кырып юдылар. Карчыклар килүенә Миңлезифа апа ишегалдын чиста итеп себерде, сукмакка җәйгән ташларны төзәтте, абзар-кураларны чистартты. Бар җирдә саф, изге чисталык хөкем сөрә иде.

Шомырт чәчкә аткан чак. Авылны хуш ис чорнап алган. Шомырт куагы тирәсендә бал кортлары очып йөри. Алар басынкы гына шатланып гөжлиләр. Бал кортларының тату гөжләве куанычлы бәйрәм ясап, аларның чәчәктән чәчәккә очып-кунып йөрүләре җанга рәхәт сала. Иртән явып үткән кояшлы яңгыр бал төшереп киткән. Баскыч төбендәге тирәкнең баллы яфраклары кояшта ялтырап торалар.

Табигатькә мул, тыныч рәхәтлек иңгән. Һәр үлән яфрагы, һәр таш, һәр матдә көр һәм ифрат куанычлы шатлыкка сугарылган.

Ашка килүче карчыклар, капка төбенә җиткәч, шомырт куагы янына туктап, яулыкларын төзәтәләр, бал кортлары сузган тыныч иминлек җырын тыңлыйлар да: «Ходайның иң рәхимле көннәре»,— дип көрсенеп куялар. Яшьлек искә төшә. Һәркемнең шомырт чәчәк атуга бәйләнешле берәр онытылмаслык якты хатирәсе була. «И-и гомерләр...»

Карчыклар баскыч төбендә кәвешләрен салалар, күлмәк изүләрен сыпырып, җиңнәрен тартып куялар. Өйгә кеше керәсен алдан белгертү өчен, иплэп кенә тамак кыралар.

Мәҗлескә чакырылу аларның ярты гасыр сандык төбендә тасланып яткан күлмәкләрен кияргә мәҗбүр иткән. Күлмәкләр шундый шәп: Әби патша заманында тукылган сәрпинкәдәй тегелгән; яшел бәрхет яка, изү тирәләре укалы; аяк атлавына ияреп, киң итәкләр җилфердәп киткәндә, шомырт чәчәге һәм бал исенә нафталин, такта чәй, кызыл билле прәннек исе кушыла.

Аякларда яфрак бизәкләре төшкән кызыл сәхтиян читек. Җиңел, йомшак, аякларга иркен. Биисе килгән чакта алган аяк киеме бит. Әллә шуңа күрә, читек киеп җибәрү белән, аякларның йөгерәселәре килә башлый. Почмаклап бәйләнгән яшел кәшемир яулыклар карчыкларның иңендә җиңү әләме шикелле җилфердәп бара. Йөрәкләрдә яшьлек моңы уята, чәчүргечкә таккан талир тәңкәләр чыңлый.

«Иншалла, ашка җыелу бәхетен дә көтеп алдык»,— дип куана иде карчыклар.

Бусаганы атлап керү белән, ашка килүчеләр җил-җил түргә узалар да, ябык янбашларын сәке читенә тезгән мендәрләргә терәп, дога кылырга керешәләр.

Ярыш башлана, һәр карчык догасын озаккарак сузарга, башкалардан соңрак бетерергә тырыша. Бер-берсенә карап алалар. Бирчәйгән бармаклар җыерчыклы битләрен сыпырып бетергәч, карчыклар хуҗа хатын ягына борылалар.

— Исән-сау гына торасыңмы, Миннедифа? Йөрибед инде шунда сине бимадалап.

—Ю-ук, бер мәшәкате дә юк. Аллага шөкер, ач тормайбыд. Ходай рәхмәтеннән ташламый. Кичә олы малаемның хаты килде. Сугыш бетә дип ядган. Түрдән уд, түрдән уд инде, Сәүрә абыстай.

— Сәйринеңнән килдемени?

— Әй-йе, шунысыннан килде. Хат эченә кәртечкәсен дә кыстырып җибәргән. Сәләмүтенә сөялеп тора. Түше тулы урдыйн. Тач атасы инде.

Сәләховның фоторәсеме, кулдан кулга күчеп, карчыкларны әйләнеп чыкты. Ихлас күңелдән, янып-пешеп мактыйлар. Авылда иң иple, миһербанлы егет. Аннан да зиһенле һәм уңган малай юклыгына тәмам ышана башлыйсың.

— И-и-и, тәүфыйгы арткыры, гөбернатыр диярсең. Җилкәсенә нәрсә аскан ул? Әстәгъфирулла! Ике җилкәсендә дә йолдыд сурәте төшкән нәмәстәкәй. Аның дур урында утырганын белгертү өчен такканнармы икән? — дип гаҗәпләнә Бәдигылҗамал карчык.

— Сәләмүт йөртер өчен бирелгән дукәмиттер инде. Яраплан тиңелте ярапланны ядусыд беркемгә дә бирмәй торганнардыр аны? — ди остабикәлек вазифасын алып баручы Сәүрә карчык.

Миңлезифа малае кош шикелле очып һавага менәргә өйрәнгән. Шушы хәл карчыкларны чиктән тыш кызыксындыра. Әллә нинди әкияти фаразлар, фикерләр тудыра. Хәйран калып, телләрен шартлата-шартлата шушы турыда фәлсәфә куерталар. «Шул җен нәмәстәкәенә курыкмыйча ничек утыра икән? Егылып төшсә? Китап әйтә, Мөхәммәд галәйһиссәлам, ди, мигъраҗда, ди, канатлы дөлдөлгә атланып, Йәсрибтән очып киткән. Йөрсәлим мәчетендә намаз укып әйләнеп кайтуына түшәктәге урыны да суынып өлгермәгән, ди»,— дип аңлата Сәүрә карчык. «Мөхәммәд пәйгамбәр заманында да шулай сәләмүтләр булган микәнни?»— дип сорый Мәрфуга карчык, Сәүрә карчыкның

сүзләрен аңлап җиткермичә. Карчыклар менә нинди нәтиҗәгә киләләр: «Ахырдаман баласы нәрсәне дә булдырыр дигән бит китап. Ахырдаман дигәннәре шушыдыр инде...»

— Улың кайтып та җитәр инде,— диде Нәфисә карчык.— Бүген иртән сугыш бетте, теге Гитлер дигәнен оясына куып кертеп дөмектердек дип, радиудан сөләделәр.

— Әйдә, түргә менегед, ахирәтләр,— дип, Сәйриннең әнисе кыстый башлый.

Карчыкларны дөрес урнаштыру — катлаулы һәм нечкә эш. Берсен дә рәнҗетмичә, һәркайсына лаеклы урын бирергә кирәк. Ә аларның һәммәсе үзенчә лаеклы. Аннан соң кем кемне өнәмәвен, кемнең кем белән сөйләшергә яратуын, кардәшлек ягын, күршелек тойгыларын — боларның барысын да истә тотарга кирәк. Кунакларның берсен генә дә рәнҗетергә ярамый. Миңзифа апа шушы турыда уйлый иде.

— Син, ахирәт, түргә мен инде. Абыстай, син нигә алай кыланасың? Сәке читендә утыру килешәмени? Бер ридалыгым юк. Түргә мен, яме.

Сәкегә киез салынган... Киезгә — ак җәймә. Аның өстенә кызыл дәстәрхан җәелгән иде.

Карчыклар, табын әйләнәсенә куелган йомшак мендәрләр өстенә менеп, рәхәт итеп кунакладылар. Аякларын бөкләп, итәкләрен тез астына кыстырып җайлап утырдылар. Хәзер алар һинд йогларын хәтерләтәләр иде.

Табынга утырышып, бергәлекне сизү белән, татулык тойгысы уянды. Карчыкларның йөзләрендә канәгатьлек балкый иде.

Остабикә вазифасын үтәп йөрүче Сәүрә карчык Коръән укып алды. Аны Миңзифаның өлкән улы Сәйриннең сугыштан исән котылуы шәрәфенә багышладылар. Дога кылу башланды. Карчыклар тагын битләрен сыпырдылар.

Карчыкларның тезләре өстеннән кызыл башлы озын сөлге узды. Хәзер алар үзара тоташтылар. Бер табынга утырып, бер табактан аш ашау аларны патша сарайларына җыелып, тантаналы кул куюдан көчлерәк итеп берләштерә иде. Йөкләмә алу, вәгъдә бирү, берләшү мәсьәләләрен борынгылар шушы юл белән хәл иткәннәр, күрәсең.

Табын уртасына зур агач табакка бүленгән каклаган каз шулпасы килеп утырды.

— Җитешегез, кунаклар.

Башлап үрелергә беркемнең дә кыюлыгы җитмәде. Карчыкларның берсе дә үзен бу эшкә лаеклы дип санамый иде. Кыстау башланды. Кыстап сыйлау Миңлезифаның апасы Мәрьям карчыкка йөкләнгән иде.

— Абыстай, үрел инде. Аш суына бит. Аштан дур булып булмый дигән бит китап.

Сәүрә карчык, бисмилласын әйтеп, кашыгын табакка сузды:

— Аллаһыма ридыкна, галә кәсирән кәсирә. Телләреңне йотып җибәрерлек, Миннедифа. Төшемдә тодлы кад шулпасы ашаганымны күреп ымсынып уянганыем. Аллаһы Тәгалә аш-суыңа — бәрәкәт, балаларыңа миһербан бирсен. Балаларың янында, бергә-бергә, куаныч белән, тигедлектә торырга насыйп булсын.

Карчыклар кашык чите белән генә шулпа чөмереп алалар да, авызларына капкач, иреннәрен яулык чите белән каплыйлар.

Карчыклар ашның тәме турында сөйләшәләр иде. Элекке чакта нинди ашлар булуын, аш-су әзерләүнең серләрен, аның куанычын искә алып тәэсирләнәләр. Сугыш вакытларында ашка җыелу бәхетеннән мәхрүм тордылар. Сугышка кадәр дә кытлык чаклар бик еш булды. Шуңа күрәме, бу хөрмәт карчыкларга бик тансык иде. Чиратлап, Сәйриннең әнисен мактыйлар.

— Тоды җиңелрәк булмадымы икән? Салыр алдыннан кадны чайкап алганыем.— Миңлезифа апа, кунакларның күңелләрен күрә алмаудан куркып, ихлас дулкынлана иде. Берәүләр тозлырак ашны ярата, икенчеләр — тозның җитенкерәмәвен. Табын янында утыручыларның зәвыклары тигезләнсен өчен, тәмле сүз, ягымлы йөз белән табынны сугарып торырга кирәк. Җылы мөнәсәбәт ашны тәмләтеп җибәрә.

— Миннедифа, ашка кулың җиңел синең. Нәрсә пешерсәң дә, шулай тәмле була инде,— дип мактарга тотынды күршедә яшәүче Хоснури карчык.

Үзен остабикә санаучы Сәүрә карчык сүзнең эчке мәгънәсен аңлатып утырды:

— Саранлык ашның бәрәкәтен ала бит ул.

— Анысы дөрес. Дөньясы шулай бит, кысынкылыкка үрәндек,— дип дәвам итте Мәрьям карчык. Аның Миңлезифаны тагын да мактатасы килә иде. Үзләре икәүләп янып-пешеп кунак кыстадылар.

— Җитешегед, кунаклар. Карап утырырга куймадык, җитешегед.

Кыстау карчыкларга ошый иде. Кыстап ашату кыстап эшләтү түгел. Кыстап ашату — ихтирам билгесе. Тормышта алар башка нинди ихтирам күрәләр? Карчыкларның күңелләрендә саф канәгатьлек уянды. Көндәлек эш бер-беренә җылы сүз әйтергә вакыт калдырмый. Җылы сүзгә ни җиткән. Мәҗлес һаман җанлана барды.

Ниһаять, табынга ит тураган бәрәңге килде.

Авыр эш эшләп, саф һавада яшәгән кеше артыгын ашый алмый. Күпме азык кирәклекне аның һәр күзәнәге белә һәм вакытында ашаудан туктата. Карчыклар арасында бер генә дә иләмсез юанын күрмәссең. Чандыр, җиңел гәүдәлеләр, хәрәкәтләре кызларныкы шикелле җитез һәм салмак.

— Карале, Миннедифа, Сәйринең сәләмүтенә утырып кайтса, аны кая куеп торырсың? Абдарга сыймай торгандыр бит ул? — дип, изге беркатлылык белән сорады Бәдигылҗамал карчык.

— Ишегалдына да сыярлык түгел ул, дип аңлатты бедгә теге ранный булып кайткан Фәйрүдә малае. Бед аны дират янындагы чирәмлеккә илтеп куярбыд дип торабыд,— диде Сәйриннең әнисе.

— Беләм. Чирәмлеге бик матур. Җире дә коры. Бу яктан куркырлык түгел. Бала-чага берәр шөребен борып ала күрмәсен дип кисәтүем генә иде,— дип акланды Бәдигылҗамал карчык.

Карчыклар ихлас күңелдән Сәйриннең самолетын ышанычлырак, бала-чага күзеннән ераграк җиргә урнаштыру турында баш ваттылар. Ниһаять, очкычка бик уңайлы урын табылды.

— Идарә кырындагы буш урынга куеп торырга булыр,— диде Нәфисә карчык.— Кәҗүннәй урын. Каланча янында гына бит. Гаптелвәли карт күд-колак булып торыр.

Әңгәмә хәзер Сәйрин тирәсендә әйләнә башлады.

— Бигрәк тә миһербанлы булды инде Сәйринең. Әүлия дә әүлия, ул да әүлия,— диде Сәүрә карчык.—

Ул бит беднең Әбелкәрәм белән уйнап үсте. Шундый дирәк, шундый ягымлы ие инде. Тәрбияле ие бит. Авыдыннан бер әшәке сүз чыкканы булмады. Чебенне дә кыерсытмасые инде.

— Дирәклек аркасында инде. Мәктәптә укытучыларыннан уддырып укып йөрде бит. Атасы да шундый ие бит,— дип дәвам итте Хоснури карчык.

— Райунга киткәндә бригадир Әһлиулла урынына Сәйринне куеп китә торганые. Беркөнне шулай мәш килеп борчак утап йөрибед. Иңбашына сажин салып, Сәйрин килеп чыкты. «Бәй, нихәтле җир утагансыд икән, давай, үлчәп караем әле»,— дигән була. Пыр туддырып үлчәргә тотынды. Шул көнне ике нурмы утадык»,— дип өстәде Бәдигылҗамал карчык, башкалардан калышмаска тырышып.

— Дөрес, Сәйрин үлчәгәндә гел икеләтә артык чыга торганые инде,— дип эләктереп алды моңа кадәр сүзгә катышмыйча тыңлап кына утырган Мәрфуга карчык.

Мәрфуга карчыкның сүзгә катнашуы көтелә иде. Сәйринне армиягә озаткан кыз — аның кызы Разия бит. Карчыклар моны беләләр иде.

— Синең кыдың нәрсәлеккә укый соң? — дип эләктереп алдылар карчыклар.— Аны бит диплумның иң дурысын ала икән дип сүләгәннәр иде.

— Мөгаллимә булыр инде,— диде Мәрфуга карчык, ипле генә итеп.

Моңа кадәр әңгәмәгә катнашырга батырлыгы җитмичә утырган урта яшьләрдәге Гайнекамал соклануын белгертте:

— Мәрфугаттәй, кыдыңның укымаган китабы, танымаган хәрефе калмагандыр инде. Шулхәтле ничек бер башка сыеп бетә икән? Мин дә бит өч ел буе мәптеккә йөредем. Шул чакта укыганнарымның бөртеге дә хәтеремдә калмаган. Әйтсәм ышанмыйлар. Чикләвек җыйганда, агачтан егылып төшеп, шулай хәтерседләндем.

Мәрфуга кызын мактау да Сәйриннең базарын күтәреп, Миңзифа апаның күңелен күрергә чамаланган иде. Карчыкларның Сәйринне Разиягә өйләндерәселәре килә иде. Аларның каннарында ил-җирне таза, матур, акыллы балалар белән тутыру теләге кыбырсып тора иде.

Табак төбе күренер алдыннан карчыклар, кашыкларын куеп, авызларын сөрттеләр. Кунак сыен ашап бетерергә ярамый иде. Балалар өлеше калырга тиеш. Аннан тыш, авыл карчыклары «ризык калдыру» дигән бер борынгы йолага ышаналар иде. Имеш, ашыңны ашап бетермичә калдырып китсәң, бу йортка тагын киләсең, ди. Әйләнеп килгәнче калган ризык сине көтеп тора, имеш.

Ниһаять, табынга чия катнаш балан суы килде. Әчкелтем баллы, эчкәч күңелләрне ачып җибәрә торган ширбәт иде бу. Ширбәткә ияреп төш килде. Бусы десертка иде. Балан суыннан соң тагын бераз сөйләшеп утырдылар. Шуннан соң гөрләшеп чәй эчтеләр. Шуның белән сый тәмамланды.

Авыл карчыклары кунакларын Европа ысулында сыйлауларын белмиләр. Алар ата-бабадан калган йола буенча эш итәләр иде. Башта закуска, аш, аштан соң ит, бәрәңге һәм десерт. Каян үзләштерделәр икән Европа илләрендәге гадәтләрне? Әллә, киресенчә, ерак бабаларыбызның гадәтен Европа үзләштергәнме?

— Удган атнаны Өктәбрскигә барганыем,— дип сөйли башлады Мәрьям карчык.— Каранып барам. Һушым китеп егыла яздым: бер ташпулатның ишегеннән кулына комган тотып Мәймүнә килеп чыкты. «Бәй, күдемә күренәсеңме әллә?» — ди. Җитәкләде дә апкереп китте. Әй менәбед баскычтан, әй менәбед. «Тукта, Мәймүнә, дим, үләм, башым әйләнә». Шаркылдап көлә. Җен бит ул. Фатирларына менеп җиткәндә, күд алдымда әҗәлләрем тора ие. Асларында тагын биш фатир. Бер-берсенең баш түбәләренә басып, астагыларның түшәмнәрен таптап йөриләр. «Күгәрченнәр кебек менеп кунаклагансың икән, Мәймүнә»,— дидем үдено.

Карчыклар шәһәрдәге сәер тормыш турында озак гәпләштеләр. Шәһәрнең машиналы тормышы яшьләрне ымсындыра иде. Карчыклардан яшерен ниндидер сихерле көч аларны шәһәргә суыра. Кайберләре аш пешереп, бала каратып тотар өчен әбиләрен алып китәләр. Әмма карчык кеше шәһәр җирендә мантый алмый. Кала тормышы,— бер яктан, уңайлы, мул, түгәрәк. Әмма ул нигәдер күңелне коргаксыта. Рәхәт тә шикелле, җиңел дә шикелле андагы яшәү, ләкин сагындыра. Ул гына да түгел, калада сиңа нәрсәдер

җитми. Шул юк нәрсәне беркем берничек ачыклый алмый. Шәһәр турындагы әңгәмәне карчыклар: «Анда шушылай тәмле итеп сөйләшеп булмый»,— дигән нәтиҗәгә килеп тәмамладылар. Эчләр бушап, тәннәр рәхәтләнеп киткәнче сөйләшүдән дә хозурлырак нәрсә бар бу дөньяда?

Хәзер яшәү максаты, җан турында гөрләшәсе килә иде. Карчыклар Сәүрә карчыкны мөнәҗәт әйтергә кыстый башладылар. Ул кыстата иде.

— Кая ул, ю-ук, хәтерем начарланды. Диһенем тишекләнеп бетте инде. Бернәрсә дә хәтеремдә калмый.

— Елый-елый тыңлармын дип өметләнеп килгәнием,— диде Мәрфуга, ялынып.— Инде ничә ел шулай бергә җыелып мөнәҗәтләр әйтә алмадык.

— Көттермәче инде, ахирәт, син башласаң, мин кушылам,— диде Нәфисә карчык.

Сәүрә карчык бертын актарынды да кулдан язган бер китап сыман нәрсә чыгарды.

— Мә, Нәфисә, укы, минем күдләрем начар күрә,— диде ул.

— Ю-ук, Хоснури укысын, аның тавышы матур,— диде Нәфисә карчык.

Хоснури карчык дәфтәрне алды, кулын алга сузып, башын артка ташлап, бертын карап торды. Почмаклап бәйләгән яулыгын аркасына шудырып куйгач, матур тавыш белән башлады:

Уйлана күңел тирән уй,
Хыяллана гомер буйлап,
Сабыр ит дип, зәгыйфь күңел,
Ходаның вәгъдәсен уйлап.

Сабырлыклар саф алтын, дип,
Борынгылар әйтеп киткән.
Шулай ук уйлап карасаң,
Сабырлыкларга ни җиткән.

Тарихларда да күренми
Морадына җитеп үлгән,
Белә алмыйм кем генә соң
Бу дөньяда рәхәт күргән?

Берәүне син уйлап йөрсәң,
Рәхәт күрә бу дип, читтән,
Карасаң тикшереп хәлен,—
Рәхәт күрми үлеп киткән.

Вакыйганда да шулай бит:
Рәхәт көтсәк тә һәрвакыт,
Рәхәт көткән вакытларда
Коча да ала тар ләхет.

Күзләр юешләнде. Йөрәк ачы һәм сихәтле итеп сыкрана башлады. Бары тик карчыкларда гына сакланып калган мөнәҗәтләрнең җан, иман, вөҗдан хакындагы борынгы хаким сүзләре салмак кына ага, йөрәккә үтеп керә, бәгырьләрне тетрәндерә иде. Карчыклар яулык читләре белән күзләрен сөртәләр. Тойгылар сыкрануы җанга кирәкле пакьлек бирә иде. Күңел тирәнлегендә кешелеклелек тойгысы уяна. Шәфкатьле буласы, игелек эшлисе килеп китә.

Күрше йорттан җиңүчеләр кайтуына өй юу өмәсенә җыелган яшь кызларның җырлаулары мөнәҗәткә килеп кушылды:

...Энҗе лә мәрҗән кызларның кул бавы,
Авыр ла җан сөйгәннәрнең булмавы...

1979

Биеклек — аналар күңелендә

Борынгылар кан саркып торган яраны ут белән көйдереп дәвалаганнар: шушы «кыргыйлыкта» гаять тирән мәгънә, хаклык бар, күрәсең. Югыйсә бу дәва сәнгать чарасына әйләнмәс иде. Ватан сугышыннан соң ярты гасыр үтеп бара, ә күңел яралары төзәлми. Бәлки, яңа фаҗигаләр өстәлеп торгангадыр. Кешелек, нигәдер гыйбрәтләр ала белмичә, табигатьнең муллыгын, тыныч рәхәтлеген, Ходай биргән көннәрнең рәхимлелеген тоймый яши. Шуңа күрә күңелләрне әрнүле, үкенечле моң белән яндырып, яңадан-яңа әсәрләр языла. Сугыш турында, үлем турында, гомер турында.

Миргазиян Юнысның әсәрләренә тыгызлап моң тутырылган. Ул моң язучының — очучы, диңгезче, сәяхәтче, философ язучының — күңелендә яши. Язучы һәр әсәрендә диңгез төпләреннән төшеп алган энҗедәй ачышларын, җиде кат күкләр биеклегендәге илаһи хисләрен җир әйләнәсендәге сәяхәтләрендә күңеленнән үткәрә, үз авылы кешеләрен, татар халкының язмышын башка илләр, халыклар язмышы белән чагыштырып карый.

«Сугыш ул — ялкын белән ут сүндерү. Исән калу турында өметләнеп, үлемгә бару». Бу каршылыклар төенен чишәргә омтылу гел кабатланып тора, язучыга тынгы бирми. Сугыш-

ның ахыры якынлашкан чор. Кешеләр күңелендә өмет ышанычка әйләнеп бара, яшисе килү тойгысы тагын да үткенәйгән, яшәү белән үлем арасы сизгер дә, хәвефле дә магнит кырына әйләнгән.

Шул чикне үтүче кешедән нәрсә кала? Тапланмаган исем, әти-әнисе кушкан исем кала. Сез игътибар итегез әле: мактаулы исем-дәрәҗәләрне бирәләр, ә үз исемеңне кушалар — кешенең үзенә багышлап кушалар, керсез сакларга кушалар. Егерме яшьлекләрдән, әле өйләнеп өлгермәгән, нәселләрен дәвам итәчәк балалары булмаган егетләрдән аларны белгәннәр күңелендә якты хатирәләр кала.

Сәйрин гәүдәсен тартып алган шундый матур, рәхимле яшел болын — Германия җирендә. Туган ягында исә шомырт чәчәк аткан, бал кортлары гөжләгән Җиңү көнендә Сәйриннең әнисе Миңлезифа апа карчыклар мәҗлесе җыя. Ул әле кичә генә олы улының сугыш бетә дип язган хатын алган, шуның шатлыгын ахирәтләре белән дә уртаклашасы килгән. Ана әле улының үлгәнен белми. Аны без беләбез, ләкин шушы изге матурлыкны челпәрәмә китерәчәк кайгыны аз гына булса да тоткарлап торасы килә. Язучы да нәкъ шуңа күрә бу нарасый җанлы карчыкларга кайгылы хәбәрне җиткерми тора.

Сез игътибар итегез әле: карчыклар мәҗлесе нинди тантаналы, табигатьнең үзе кебек үк җылы, ягымлы була икән! Юк, без кунакка йөри белмибез, аның матурлык тәртибен — ритуалын югалтканбыз икән. Кунакларны әнә ничек кадерләргә кирәк, һәрберсенең күңелен күрү кебек нечкә эшне җиренә җиткереп башкарырга кирәк икән. Ризык ашау ул һич кенә дә тамак туйдыру гына түгел, уртак табын кешеләрне берләштерә; күңел изгелек, яхшылык белән тула. Сәйринне мактаулары, һәркөн әйтелми торган сүзләрне сайлап, берберсенең кадерен арттырырга тырышулары — итагатьлелек, чын мәгънәсендәге зыялылык ул.

Язучы шундый ачыш ясый: кеше гомеренең ахыры сабыйлыкка, нарасыйлыкка барып тоташа икән. Мәңге дулкынландыра торган борынгылык нурына күмелгән һәм шул ук вакытта балаларча беркатлы, эчкерсез җанлы карчыклар... Урта буыннарның кешелеген, күңел сафлыгын да ике чиктәгеләр — сабыйлар һәм карт-карчыклар саклап тора. Шуңа күрә аларны рәнҗетү, кыерсыту барлык диннәрдә дә, халыкларда да иң зур гөнаһ санала. Бу канун сакланганда, сугышлар да кимрәк булыр иде дип уйлыйсың...

ЭЧТӘЛЕК

Идегәй 4

Фатих Кәрими

Салих бабайның өйләнүе 27

Мирхәйдәр Фәйзи

Галиябану 43

Шәриф Камал

Акчарлаклар 93

Һади Такташ

Алсу 108

Киләчәккә хатлар 113

Гомәр Бәширов

Туган ягым — яшел бишек 124

Муса Җәлил

Тик булса иде ирек 178

Соңгы җыр 180

Серле йомгак 181

Сандугач һәм Чишмә........ 184

Нурихан Фәттах

Итил суы ака торур........ 194

Туфан Миңнуллин

Бәхетле кияү 242

Аяз Гыйләҗев

Язгы кәрваннар 261

Саҗидә Сөләйманова

Туган җирем, эчкән суым! 298

«Кеше барыбер кошлар нәселеннән...» 299

Кеше 300

«Сулар ага, күлләр күккә бага...» 301

Этюд 302

«Тагын узды кыңгыраулы язлар...» 303

Миргазиян Юныс

Шәмдәлләрдә генә утлар яна 308

Учебное издание

Ахмадуллин Азат Гильмуллович
Ганиева Флера Акрамовна

ЛИТЕРАТУРА

Учебник-хрестоматия для 8 класса
татарской средней общеобразовательной школы

Издание четвертое

Казань. Издательство «Магариф». 2006

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

Әхмәдуллин Азат Гыйльмуллович
Ганиева Флера Әкрәмовна

ӘДӘБИЯТ

Татар урта гомуми белем бирү
мәктәбенең 8 нче сыйныфы өчен
дәреслек-хрестоматия

Дүртенче басма

Редакторы *И. И. Кадыйрова*
Тышлык рәссамы һәм бизәлеш редакторы *Р. А. Сәйфуллина*
Техник редакторы һәм компьютерда биткә салучысы *Ф. К. Гомәрова*
Корректорлары *А. А. Дәүләтова, А. М. Закирова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 21.06.2006.
Форматы 60x90$^{1}/_{16}$. Офсет кәгазе. «Таймс» гарнитурасы. Офсет басма.
Басма табагы 21,0+форз.0,25. Нәшер-хисап табагы 18,08+форз.0,39.
Тиражы 15 400 д. Заказ З-486.

«Мәгариф»нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс (843) 292-57-48.
http: //magarif.kazan.ru.
E-mail: magarif@mail.ru

«Идел-Пресс»полиграфия-нәшрият комплексы» ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

ДӘРЕСЛЕКНЕҢ САКЛАНУ ДӘРӘҖӘСЕ

№	Укучының исеме һәм фамилиясе	Уку елы	Дәреслекнең торышы	
			ел башында	ел азагында
1				
2				
3				
4				

Җитәкләшеп икәү бара,
эзләренә ак кар ява, –
эзләренә кер кунмасын,
җил тимәсен, суынмасын.

С. Сөләйманова